Рифә Рахман

# Онытырмын, димә...

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-3 : (-2)
ББК 84(2Рос=Тат)-4 : (-6)
Х32

**Харрасова, Р.Ф.**

Онытырмын, димә... : кыйссалар, хикәяләр / Рифә Рахман ; кереш сүз авт. И.Гомәрев. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 239 б.
ISBN 978-5-298-01861-6

Бу китапка кергән әсәрләр узган гасырның төрле чорларында авылда барган вакыйга-күренешләргә нигезләнеп иҗат ителгән. Аларда күпләребез өчен таныш проблемалар чишелә, дуслык, сөю бәхете һәм аерылу сагышлары төп мотивлар булып бара, укучыны яктыга, матурлыкка илтүче идеаллар югары күтәрелә.

УДК 821.512.145-3 : (-2)
ББК 84(2Рос=Тат)-4 : (-6)
ISBN 978-5-298-01861-6
© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Харрасова Р.Ф., 2010

### КҮҢЕЛЕ БАЙДАН ХИС ЙОГАР

XX гасыр азагы татар әдәбиятында үзенчәлекле мәхәббәт шагыйрәсе булып танылган Рифә Рахман, ниһаять, прозада да үз урынын тапты. Киң катлам укучы аны моңа кадәр төрле әдәби конкурсларда лаеклы бүләкләр, урыннар алган «Судан тапкан йөземнәр», «Сары шарф», «Бер микъдар былбыл», «Сөннәтче әби» әсәрләре һәм тәүге китабы булган «Айлы күлдәвекләр» аша белә иде. Сезнең кулыгыздагы «Онытырмын, димә...» – каләм остасының икенче чәчмә әсәрләр җыентыгы.

Рифә Рахман прозасының төп үзенчәлеге нидә, дип сорасалар, һич икеләнмичә, матур һәм табигый яңгырашлы телендә, беркемдә очрамаган, кайвакыт хәтта тетрәндереп җибәргән гыйбрәтле сюжетларында, композиция кору осталыгында, дип әйтергә мөмкин. Бу сыйфатлар аның шагыйрь һәм язучылыгыннан гына түгел, галимлегеннән дә киләдер.

Рифә Рахманның күбесенчә мәхәббәт тарихларын яктырткан «Айлы күлдәвекләр» җыентыгы матур һәм якты мөнәсәбәтләргә омтылган яшьләре, сайлау-сайлануда абынулар, күңел төпләрендә яшәгән тирән үкенечләр һәм иң кадерле кешеләрне югалту сагышлары белән истә калган иде. Тупланмага кергән хикәяләрдә чынлап ярата белгән, эчке дөньясы бай кызга ихтыярсыздан бөтен тирә-як ир-егетенең карашы текәлгәндер кебек. Алар шигъри күңелле, бер үк вакытта уйчан да, шаян да гүзәлкәйгә тиңнәрне тапмыйлар, укучыга сөйләнгән тарихлар тәмамлангач, калган гомерләрендә дә шул образ тудырган идеалга омтылып яшиләрдер шикелле.

Күпләребезгә таныш проблемаларны күтәреп чыкса да, язучы безне тормышыбызда көн дә очрап торган күренешләр эчендә йөртми, кеше язмышындагы онытылмаслык вакыйгаларга алып керә, яңа китабының исеме үк моны бик ачык күрсәтеп тора. Рифә Рахман иҗат иткән уңай геройлар гамәлләре, үзләрен тотышлары белән бар дөньяны яктыртырга омтылалар, һич көтмәгән-теләмәгән, әмма тормышның реаль шартлары белән тудырылган конфликтларга тарыйлар, үкенеч ки, килеп туган каршылыкларны күпчелек очракта үз файдаларына чишә алмыйлар.

Рифә Рахман әсәрләре безгә кешене гомере буена югалту арты югалту көтә, сынаулар сагалый дип искәртә. Әлеге дә баягы югалтулар яшәешнең даими агышта икәнлеген сөйлиләр, рухыбызга якын кыйммәтләрнең кадерен белергә чакыралар. Автор милли гореф-гадәтләрнең кеше әхлагына турыдан-туры тәэсирен, уңай сыйфатлар тәрбияләргә сәләтлелеген исбатлый, кешенең көтелмәгән ситуацияләрдә теге яки бу сыйфаты белән ачылып китүен күрсәтә.

Югалту янында табыш бар – үкендергеч гамәл-күренешләрдән соң, инсан айнып киткәндәй, дөньяга күзе ачылгандай була. Ул тирә-юнен үзгәртергә тели, рухи баскычлар буйлап югарыга таба атлый. Һәр әдип-әдибә әнә шундый уңай үзгәрешләрне күздә тотып язарга тиеш тә.

Рифә Рахманның «Онытырмын, димә...» китабында без төрле типтагы геройлар белән очрашабыз. Ирләр генә башкарган һөнәрне үзенеке итәргә батырчылыгы җиткән Сөннәтче әби, башкаларга һич кенә дә язык булып күренмәслек гамәлләреннән дә җан газабы кичереп яткан Әүлия карт... Алар татар әдәбиятының онытылмас геройлары булган акыл ияләре Әлдермешләр, Акъәбиләр рәтенә бик лаеклы барып кушылалар.

Р.Рахман прозасында каршы искән язмыш җилләре аркасында гомер ахырында туган нигезеннән аерылырга мәҗбүр геройлар, бәхетле булу шартын үзенчә аңлаган, хыял белән яшәгән, җирдән күкләргә күтәрелергә күпме омтылса да, андагы мөнәсәбәтләр чылбырыннан аерыла алмаган хатын-кызлар да бар. Болар: усал килененнән еракка качып киткән һәм Тимертау каласында җирләнгән Җанбикә, шәһәр йортына авыл тормышының бер өлешен алып килә алган, шуның белән җанын тынычландырган Миңсылу, тегүче булуны балачактан күңеленә беркеткән, әмма чинга ашкан хыялы гаиләдә бәхетсезлегенең бер сәбәбенә әйләнеп киткән Рәсимә...

Хикәяләр-кыйссалар арасында динамик хәрәкәткә ия, тормыш вакыйгаларын бик нык бергә туплаганнары да, нинди дә булса кызыклы, кечкенә, әмма барыбер гыйбрәт бирерлек бер күренешне генә эчкә алганнары да юк түгел. Бу тупланма алдагы җыентыктан әнә шул төрлелек белән аерылып тора да. Монда романтик яшьлек хыяллары кырыс тормыш реалийлары белән чиратлаша.

Хәер, нигә әле озаклап сөйләп торырга?! Укучым, китапның тәүге битләрен ачкансың бит инде. Хикәяләрне үзеңчә аңласаң, геройларны үзеңчә бәяләсәң яхшырак булыр. «Ислемайдан ис йогар, күңеле байдан хис йогар» ди халык.

*Илһам Гомәрев,*
филология фәннәре кандидаты

# Кыйссалар

## СӨННӘТЧЕ ӘБИ

99 баланың сөннәтчесе – әбиемнең
әнисе Мәлихага багышлыйм

Мәфруза карчыкның үлем түшәгенә егылганлыгы көне-сәгате белән бөтен авылга таралды. Тиз арада авылның икенче башында яшәгән кызына, ерактагы оныкларына хәбәр җиткерделәр. Инде килә алырдай кеше җыелып беткән кебек булгач, карчык терсәкләренә таянып торып утырды да:

– Мөхәммәтгалиемнән хат юкмы әле? – дип сорады.

Моңа кадәр җир җимертеп йөргән, гомерендә дә көндез караватта ятуны бар дип белмәгән Мәфруза түтинең җәй уртасында якты дөнья белән саубуллашырга җыенуы үзе бер сәер хәл тоелса, инде бернәрсә булмагандай ястыкка янтаеп сөйләшеп утыруы хәер-фатиха алырга дип килгәннәрне тәмам аптырашта калдырды.

– Урын табып утырышыгыз инде, балалар, – диде ул җайлап кына. – Ерак юлдан килгәннәргә самавыр яңартыгыз.

Газизәнең күзе яңа гына агартылган мичкә биек эшләпәсен – төтенлеген – кыңгыр салып утырган самавырга төште. Якын әбисе янында кунакта булып кайтканнан соң, кызы, әбием, инде икенче килүеңә мин булмам, күркәләрне бер еллык итеп кенә әзерлә, миннән соң нарат чәе эчәргә теләүче табылмас, дип сөйләнгәли, яңадан күрмәс кебек, кочаклап бик нык аркамнан сөйде, дигән иде. Карасана! Бөтен тормышын елга агышларыдай гел белеп, сизеп тора бу олы кеше дигәнең... Ул чагында артык игътибар да ителмәгән бу сүз бик тирән мәгънәгә ия булгандай тоелды, күз төпләренә яшь бөялде, дәшмәде, кеше күрмәгәндә генә күлмәк җиңнәре белән сыпырып алды. Үзе эченнән, бәхетле әби дә инде, оныкларының балаларын күреп, карашып китә бит, дип сөенде.

Газизә, узган җәйдә кызы Нәфисә җыеп киткән күркәләрдән самавыр тергезим дип, чоланга чыкты. Кәрзингә карагач, имәнеп китте: анда нибарысы биш-алты тапкыр чәй кайнатырлык күркә тәгәрәп ята. Җитсә дә, өч көннән артыкка җитмәс, моның кадәр кунак төшкән өйгә... Кунак дияргә дә тел әйләнмәслек бер көн булды кана!

Бик тә кадерле кешесен югалтудан курку, үткәннәр турында уйлаудан туган сагыш хисе Газизәнең йөрәген кисә иде. Кызына кат-кат «киләсе җәйгә, киләсе җәйгә...» дигәне чын ук булыр микән?

Инде орлыклары да коелып беткән, әмма күрер күзгә симез, матур күркәләргә үрелгәндә, кулларының аларны бик аралап, санап, саранланып алганнарын тойды. Җитсә дә, өч көнгә җитәр, дип уйлады ул, тагын бер тапкыр кәрзиннән күтәрелгәндә икеләнебрәк торгандай. Шунда кылт итеп әбисенең намаз укыганда калдырмый торган бер теләге исенә төште. Өч көннән артык урын өсләрендә яткырмасаңчы, Ходаем, әҗәл чирләренең шул өч көненә чыдарлык түземнәр бирсәңче... Бу дога, Мәфруза әбекәченең теләк сүзләренең иң башында булып, кызны гел аптырата торган иде. Озаграк торса соң, аның якты дөнья белән шулай бик тиз хушлашасы килә микәнни? Әле ул чакта сораулы карашларын эләктереп алган әбисе гадәтенчә җемелдәп кенә елмайды да, и кызым, кеше кулларына бер дә каласы килми шул, дип куйды, үз акылыңда, үз көчеңдә китүгә җитми инде ул... Кеше куллары дип... Кем авырсына соң аны карарга? Чит-ят куллар түгел ләбаса! Бөтенесенә карап торган бер «якын әби»ләре бар!

Учлап күкрәгенә кыскан күркәләрнең берсе кире кәрзингә төшеп китте дә почмакта җыелышып яткан ишләре янына тәгәрәде. Газизә аны кире алмады. Күркәләрне күпмегә озагракка җиткерсәң, әбисе шуның кадәргә артыграк яшәр кебек идеме... Язмышны алдарга теләгәндәй, ул бер күркәне үзе үк кире кәрзингә ыргытты.

Бик тә ярата иде шул аның әбисе нарат, чыршы исләренә буылып кайнаган чишмә суыннан пешергән бөтнек чәен, бигрәкләр дә ярата иде инде менә... Бөтен халыкны аптыратып, авыл гадәтләрен санга сукмагандай, бер алар гына бакча түренә ылыслы агачлар утырттылар, бер ул гына өй каршындагы үзе белән килен булып килгән көнне төртелгән пар нарат төбенә ире Галләмнән ике генә кеше сыярлык утыргыч ясатты.

Бала чагында, якын әбиләренең өй турындагы чирәмлектә мәш килгәндә, күркәләрне шул нарат сайгаклы утыргычтан, каз бәбкәләрен саклаган кебек, таяк белән төрткәләп кенә уйнатып утырырга ярата иде ул. Аннан йомшак бәбкә үләне өстендә изрәп, кояшта кызынып яткан күркәләрне бергәләп җыялар да чәй эчәргә кереп китәләр. Каз йомышлаганчы, кеше аягы басканчы алып калыгыз инде, балалар, ди иде Мәфруза әбиләре, самавыр эченә тутырылган күркәләрдән ят, зарарлы исләр килүен, самавырның нәҗесләнүен теләмәгәндәй.

Якын бабалары вафатыннан соң олылардан нарат төбендә кемнең дә әбисе янәшәсендә ял иткәнен хәтерләми Газизә. Әллә Сөннәтче карчыкны олылап, үзләреннән аерып куепмы, әллә бу бәхетне Галләм абзыйларыныкы гына санапмы, каршысына утырырлар, наратның икенче ягына елышырлар, Мәфруза карчыкның артында басып торсалар торырлар, әмма ләкин янәшәсендә урын алмаслар.

Туктале, әби берни булмаган кебек түр башында күрше-күлән белән сөйләшеп утыра, ә мин инде аның турында үткән замандагы кебек сөйлим, диде Газизә, үзен уйлаудан ничек туктатырга җай тапмыйча.

Әле оныкларының балаларын да күрерлек кыяфәттәге, мәңге яшәр кебек тоелган Мәфруза өчен сөенмәслек идемени?! Алай да эссе җәй уртасында, печән өстендә, карчыкның халыкны бәхилләшергә чакыруы күрше-күләнне дә, балаларын да тәмам аптырашта калдырган иде.

– Ә-ә, син икәнсең, мин Гайфулланың төпчек малае керәме икән әллә дип торам тагын, – диде Мәфруза түти, үзе көткән кешеләрнең исемлеген күңеленнән тагын бер кат барлаган кыяфәт белән. – Мөхәммәтгалием дә кайтып житсә, сөннәт улларым зиратка килеп булса да хәлемне белерләр... Кайсы кая таралышып беткәннәр шул инде. Авылда яшәгәннәренең дә үз мәшәкате. Эш кешесенең мондый җәйдә эштә булганы яхшы.

Карчык, утырырга урын җайлагандай, мендәрләрне тоткалап карады. Шунда ук барысы да, хәзер, әбкәй, хәзер, әбкәй, диешә башладылар.

– Юк ла, мин болай... Тик тора алмаганнан гына. Әле менә сөннәт дигәннән... Туксан тугыз угылның сөннәт әнкәсе бит мин. Туксан тугыз! Һәр бөртегенең гомере минем кулдагы пәке үткененнән узган...

Мәфруза карчык, ерак Шүләнгер якларыннан бу авылга килен булып төшкәндә, сөннәтче әбигә әйләнермен дип башына да китермәгән иде. Приказщик картының кочагында җылынып, затлы киемнәр эчендә матурланып, йомшак түшәкләр өстендә түш киереп яшәргә иде аның исәбе. Менә бу җайсыз, җансыз булып калган ястык өсләрендә кебек түгел...

Каралты-кура турында кайгыртасы юк. Бар нәрсә килен төшешкә яңадан, ике катлыдан салдырылган, йортның тирә-ягын инде мул нигъмәт китерүче җиләк-җимеш бакчасы бизи. Су буендагы ак мунча морҗасыннан, кунак-фәлән төшкәнне хәбәр итеп, көн буена төтен төти, абзарда тук маллар күши, капка төбендә ялтырап торган тире кошевкага җигелгән кап-кара туры айгырлар биешә.

Яшь килен бирнәсеннән чыгарылган җиз коштабаклар, бакыр комганнар, өйалды стенасындагы кадакка элеп куелган чигүле башлы сөлгеләр монда яңа тормыш башланганны хәбәр итеп тора. Аларның кайсына ян бакчадагы алмагачларның кызыл, сары алмалары чөмәкәйләп тутырылган. Сандугач сурәте төшкән көянтәләр, яшь киленгә су буйларын күрсәтергә әзерләнеп, шундый ук сурәтле алюмин чиләкләргә үрелгәннәр.

Өй эченә керсәң, кире чыгасы килми: бирнә сандыгында ничә еллар буылып ятканнан соң тынчулыктан котылганнарына сөенешкән өем-өем чачаклы-чуклы тукымалар, кашагалар, чаршаулар, утыргыч япмалары, өстәлгә ямь биргән ашъяулыклар, көзге өсләре... Чигешле өлгеләр белән матурлап та җибәргәч, болай да гөлгә күмелеп утырган тәрәзәләренә эчке яктан да нур ташкыны агылгандай, яктылык иңгәндәй булды.

Өй түрендә, ылыс исләре чыгарып, самавыр гөжли. Кыз алып кайткан көнне Галләм, күркә чәе генә эчәрбез дип, йорт каршыларына пар нарат утыртты. Чынмы-дөресме, күркә утында су озак кайный, озак суына, аннан чыккан чәер исенең хуш һавасын үзенә ала, дигән була. Әйтәм җирле, чәйне алтын йөгертелгән затлы касәләрдән бик озаклап, тәмләп эчәләр.

Галләмнең борын яфракларына кунган тир тамчыларына исе китеп карап утырды ул. Бөтерелеп киткән мыекларына төшәрләр дә аннан кәрәзле бал тутырып иреннәренә якынлашкан калак өсләренә сикерерләр кебек.

Галләмне Мәфруза бер күрүдә яратты. Ялындырып тормады, сорап килгән көнне үк, әти-әнисен аптыраштa калдырып, бирнә тупларга тотынды. Без, ярар, дисәк тә, көтәсең мәллә, бер дә күргән-белгән кешең түгел бит, тагын бер ныклап уйла, әле эш узмаган, диештеләр алар. Кыз, алар каршында гомерендә беренче тапкыр зур батырлык күрсәтеп, барам булгач барам, дип ярды да салды.

Ә бит ире, чыннан да, бер дигән. Эшкә кулы ятып тора, беләгеннән көч ташый, укымышлы, динле, заманыннан да артта калмаган. Шаянлык та җитәрлек үзендә: капка алдына шәп атларында килеп туктауга, яшь егетләр кебек сызгырып кына җибәрә. Ул да булмый, Мәфруза чыгып туры айгырларны өзәңгедән тотып тынычландыра да көмеш тәңкәле каешларны капка башына кагылган алкаларга бәйли.

Аннан, җылы су салынган комганны алып чыгарга дип, тиз генә өйгә кереп китә. Мәфрузаның бу өйдә төп вазифасы – эштән арып кайткан иренә тәһарәт алырга булышу. Ул моны яратып, гомер буе шуны гына эшләп үскән кебек оста башкара. Вакытында сабынын бирә. Вакытында суын сала, чигүле тастымал белән картының кулларын үзе корыта, битләрен икенче бер сөлге белән йомшак кына итеп үзе сөртә. Шул арада җаен туры китереп, Галләм дә аны бит алмаларыннан җиңелчә генә үбеп ала. Бу йортта каенана-каената булмаса да, алар иркенләп сөешергә әле бер-берләреннән кыенсыналар, әдәпсезлек саныйлар.

Галләмнең авылдашларына аңлашылмый торган бер гадәте бар. Җәйге, көзге эшләр беттеме, дөнья күрәм дип, хуҗасыннан ял алып, ерак шәһәрләргә чыгып югала. Саквояжын җиңел генә селкеп китсә дә, капчык-капчык кучтәнәч, асыл тукымалар, бизәзек-йөзекләр белән кайтып керә ул. Аннан ай буена авылдашлары аның күргәннәрен тыңларга йөриләр. Галләм абзыйлары бер шәһәрдән икенче шәһәрне тыңлатучы чыбыклар, җир казучы машиналар, тагын әллә ниләр турында сөйли, әмма күбрәк ул әле нәрсә булачагын фаразларга, кешеләрне хыял дөньясында йөздерергә ярата.

Уналтынчы елның язында шундый сәфәрләренең береннән Галләм бөтенләй үзгәреп кайтып керде. Башына ниндидер уй тулганы әллә каян күренеп тора иде. Кечкенә төенчегенә салып кайткан вак-төяк, такта чәй белән сыйлангач, инде барысы да өстәл тирәсеннән кузгалабыз дип торганда, төпчеге Хәдичәне алдына утыртып сөйде дә:

– Анасы, дөньялар бозылырга тора бит әле, балалар турында уйламый булмый, бу ел кышка утын әзерләп тормабыз, йортны гына кисеп ягарбыз, – дип куйды.

Аскы катның аш бүлмәсен сәер тынлык тутырды. Түшәмгә карап-карап утырганнан соң, Мәфруза, кунак-фәләнгә дип тоткан астагы йокы бүлмәләре ишәя башлаган гаиләгә җитмәс, дип уйлады, әмма, бу тыгынлыкта нишләрбез соң, дип кенә сорады, карты кылган ныклы карарның сәбәбе хакында төпченергә батырчылык итмәде. Яулык почмагын тешләп тынып калды.

– Сыярбыз! – диде Галләм. – Кешеләр әнә дүртпочмаклы, мунча кадәр йортта да ничәшәрләп яши.

Иренең инде барысын да хәл иткәнлеге әллә кайдан күренеп тора иде, тик ул хатынын пошаманга төшерергә теләмәдеме, сүзне озынга сузмады. Хәер, аның киләсе көн хакында ни уйлаганын сөйләми калдыруы үзе үк билгесез хәвефләрне көтү халәтенә керткән иде инде.

Каралты-кура сүтелде, кайсы авыр тормышлырак туган-тумачага бирелде, кайсы утынга киселде. Беренче катны да җыйнаклап, түбәсендәге кызыл калайларны – тактага, абзарныкыларны имән кайрыларыныкына алмаштырдылар.

Ихата кечерәеп, каралып, мескенләнеп китте. Сыер да моңлырак мөгри, тавыклар да моңсуланып кыткылдый кебек тоелды. Мәфруза белән Галләм кичләрен нарат төбендәге утыргычта бик сирәк күренә башладылар, аларны йорт үзгәртү, дөньяны башкача көтү мәшәкате басты. Мәфруза да элеккечә, кош кебек талпынып, дәртләнеп йөри алмады, чөнки ире бай абзасыннан да эштән чыгып өлгергән, акча яклары шактый кыенлашып киткән иде.

– Патша төшәчәк бит, карчык. Кешегә генә сөйли күрмә, безнең авыздан чыкмасын: үзең генә ишеттең! Тормышның кайдан тәгәрәсен бер Алла үзе генә белә. Шунсы хак: байларга көн бетәчәк, ди. Андый вакытта баеңны, бай түгелеңне дә карап тормаслар... Авыл тулы ашарына да юк хәерче яшәгәндә, ике катлы пулатларың белән син дә шулар арасына эләгәсең инде...

Патша кадәр патшаны төшерәселәренә дә, авыл мужигына көн киләсенә дә Мәфруза ышанмады, билгеле, иллә мәгәр каршы да төшмәде. Галләмнең урыс-урагай арасында да, Казанның укымышлы кешеләре арасында да таныш-белешләре күп иде, утсыз төтен булмый, алай да дөньяларның бозылырга торуы хактыр дип уйлады.

Авыл уртасында бай йортларыннан да матур булып утырган күрекле йортның бер ай эчендә шул хәлгә килүе, Галләмнең соңгы йөреп кайтуыннан соң, кеше җыеп, күргән-белгәнен сөйләргә ашыкмавы күрше-күләнне генә түгел, тирә-як авылларны да пошаманга төшерде, кайсы нәрсәгә юраса юрады, эшнең асылына һичкем төшенмәде.

Барысы да унҗиденче елга килеп кергәч аңлашылды. Яманыннан куркыта, шул ук чакта яхшы тормышка ниндидер өметләр дә уята торган әле бу, әле теге хәбәрләр авылга көн дә булмаса да, ай саен килеп тора башлады. Аларның чынга ашасын озак көтәргә туры килмәде: патша да төште, властька большевиклар да килде, авыл байларының мал-мөлкәтен тартып алу да башланды.

Иң элек Галләмнең олы кызы Маһикамал килен булып төшкән йорттагыларның барысын урамга чыгарып ташладылар, каралтыларын, әйберләрен кайсын кемгә тараттылар. Ата кеше кызы төп йорт бусагасына килеп егылыр, шул мәхшәрдә тора алмас дип көткән иде, алай булмады, ире белән бер булып, тешләрен кысып, күршеләре йортының бер почмагында, чаршау белән бүлеп алынган аш-су ягында яшәп киттеләр. Эшләрен дә эшләштеләр, үзләренекенә кушып, балаларын да караштылар. Абзарларындагы маллары да ят итмәде, аларын сәвит кешеләре кайчандыр үз ихаталарыннан туп-туры китереп кенә куйган иде...

Галләмгә инкыйлаб җилләре кагылмады: алып чыгып китәрлек әйбер калмаган, өләшеп бетерелгән иде. Гади халыктан урысча язу язарлык кеше тапмаганга, ярлылар кәмититенә үк сайлап куйдылар үзен, каршы төшеп караса да, артык сүз көрәштерүнең мәгънәсезлеген аңлагач, писер булсам гына, дип ризалашты, өчне өчкә куша белмәгәннәр белән бергә эшләп китте.

Ел арты ел узды, көн арты көн туды, бөтенләй башкача, динсез, Алласыз тормыш башланды. Сөннәт бабалары да, мулла-мунтагай да, хәреф таныткан хәлфә дә авылдан йә куылды, йә, берни янамаса да, үзләре үк чыгып качты. Моңарчы җомгадан, җомга арты сөбхәтләреннән калмаган Галләм алай да намазын ташламады. Өйдә кылган гамәлдән куркырга кирәк дип тапмады.

Ирләр күпләп юкка чыгарылган шундый бер заманда угыл өстенә угыл туды, әмма шәп, шөлдерле, бизәлгән дугалы чаптар атларда авыл әйләнеп уздырылган бәби туйлары да, зурлап исем кушулар да онытылды. Алай гына түгел, тора-бара сөннәткә утыртырлык, баба булырлык кеше калмаганлыгы да беленде. Ул авылга чаптылар, бу авылга... Сәвит тыя дип тә тормадылар, сөннәт дигәндә, бу һәркем өчен ашау кебек бер гап-гади, эшләнергә тиешле гамәл иде. Бабалардан килгән бу йоланы бозарга һичкем яхшысынмаса да, юлы һич табылмады: Сөннәт бабаларын җир йоткан идемени?! Ахырда, ирләрчә ныклыгын, чисталыгын, батыр йөрәклелеген белгән авылдашлар Мәфрузага килеп баш иделәр: балаларыбызны чирле итмә, фәлән-фәлән абзыйдан калган сөннәт пәкесе бар, риза булып, шуны үзеңә корал ит, диделәр. Ризалашса ризалашты, ризалашмаса – юк (аны сорап тордылар микән әле?), шул көнне үк Мәфруза түтекәй Сөннәтче әби булып китте.

Ире Галләм белән йорт кенәгәсенең соңгы битенә сөннәт балаларының аты, нәсел кушаматы, туган, арулацдырылган елын теркәргә киңәштеләр. Мәфрузаның инде илле бере тулып килә, үзе дә сизмәстән, карчыклар рәтенә кереп бара иде. Алай да төсе, үз-үзен тотышы, кием-салымы белән башкалардан аерылып торган, һаман да приказчик хатыны икәнлеге әллә каян күренгән Мәфрузаны сүз белән дә картайтырга кыймаганнары, олылап, якын итеп, Сөннәтче әнкә дип атый иде.

Бала туса туа, күлмәк-ыштан кия, көн дә кашык тотып ашарга утыра – колхозлашасыңмы син, юкмы, үстерергә хәлеңнән киләме әле – сорап тормый икән. Ике-өч ел дигәндә, исемлектәге балаларның саны туксан тугызга җитте дә, дәфтәрнең ул бите, култамга салынып, бөкләп, ябыштырылып куелды. Диндарлыгыннан ырым-шырымнарга артык игътибар бирмәгән Мәфруза сөннәт дигәндә әллә нәрсә эшләде. Бабасыннан, йөзенче баланы сөннәткә утыртырга ярамый, үлә, дип ишеткәне бар иде, акылы белән шул сүзне кире какса да, күңеле тыңламады, ниндидер зур бер көч аннан сөннәт пәкесен еракка – келәттәге кием-салым салынган сандык төбенә яшертте.

Үч иткән кебек, икенче көнне үк иртә таңнан аларның капкасын дөбердәтепме-дөбердәтеп кагарга тотындылар. Урам тәрәзә аша Мәфруза килүченең күмхуҗ рәисе икәнлеген күрде, үзен чакыра дип уйламыйча, яңа гына баш агроном булып эшли башлаган ире Галләмне төрткәләп уятты:

– Нидер булганмы, әнә Мотыйк капка кага, чык тизрәк! – диде.

Галләм, каударланып-кабаланып, мич башындагы үзе серкәләндереп ясаган яңа сорт ашлыкларның тишелешен тикшерергә утырткан агач савытны бәреп төшерде. Урынына алып куймады. Мәфрузага гына кушып, ияге белән ящикка ымлады. Ишек катындагы элгечкә үрелгәч, анысы, кадагыннан ычкынып, киемнәре-ниләре белән идәнгә килеп төште. Галләм өстендәге күлмәгендә генә ишегалдына капка ачарга йөгерде.

Тик Мотыйк Мәфруза янына килгән икән.

– Коткар, җиңгәчәй, – дип сүз башлады ул керә-керешкә. – Малайның ят җире тәмам эренләгән, сөннәткә утыртмасаң, эшләр харап...

Мәфруза карчык җавап бирергә ашыкмады. Ул сөннәткә утыртып йөргәне өчен генә үзен күпме җәфалаган бу кешенең күзләренә туры карый алмады.

– Ялгышлык миндә булган, – дип дәвам итте сүзен Мотыйк. – Үз башыңа төшмичә белмисең икән ул...

Сөннәтче әбинең һаман да берни әйтмичә тораташтай торуын Мотыйк астыртынлыгы, үпкә саклавы, үлем түшәгендә яткан баласы өчен эчтән генә сөенүе дип фаразлады.

– Кичер, җиңги, ялгыш – миндә, – диде ул тагын бер кат. – Сәвит кушканча яшим дип...

– Без дә сәвит кушканча яшибез анысы, Мотыйк, – дип әйтә башлаган Мәфрузаны рәис ярты юлда туктатты:

– Мин бит, син сәвитчә яшәмисең, дип сөйләп тормыйм, сине сөннәтчелектә гаепләргә дип тә килмәдем, малайга ярдәм ит дип, олы башымны кече итеп... үлә бит... Үлә! Син эренләгән ярысын кисеп төшермәсәң, билләһи, үлә! Сиңа аның нәрсәсе бар инде?!

Үзеннән ничә яшькә кече Мотыйкның шундый чакта да үзенә бәясенә Мәфрузаның исе китмәде. Ул моңа ияләнгән иде инде, шуңа күрә сүзнең озынга сузылуыннан курыккандай, чоланга чыгып китте. Ул да булмады, чисталап ак тастымалга төрелгән сөннәт пәкесен тотып та керде һәм:

– Аның нәрсәсе бар дип уйлыйсың икән, кисәсең дә төшерәсең, – дип, Мотыйк кулына тоттырды.

– Ник, мин бит... сөннәтче түгел... – диде рәис, башка ни дияргә дә белмәгәнгә.

– Мин дә сөннәтче булып тумаган, кирәк киртәгә кертә, итекчегә дә, пешекчегә дә әйләнәсең. Кисәсен кискән инде мин, сиңа үчлек белән түгел, йөзенчегә кулым бармый. Үзеннән мондый сүзләрне һич ишетергә теләмәгән, күзләре атылырга торган Мотыйкка карап: – Балаңның гомерен уйлап кына... – дип өстәде.

Мотыйк хорафатлардан көлә торган бер кеше иде. Авылның иң акыллы карчыгы дип уйлаган Мәфрузаның шул булыр-булмас ырым-шырымга сылтап ярдәм күрсәтергә ашыкмавын ул аңларга да теләмәде.

– Соңгы тапкыр сорыйм: утыртасыңмы малайны сөннәткә, юкмы?! – диде ул җикергән, боерык биргән бер кыяфәттә.

Мәфруза да нәкъ шулай ук җавап кайтарды:

– Юк!

«Юк», дисә диде, әмма ләкин ире Галләмне ерак авылдагы бер танышына, сөннәт картына ат җигеп йөгертте. Мотыйктан битәр сабый кызганыч иде. Шундый борчулы көннәрнең берендә күктән килеп төшкән кебек сөннәтче карт малайны аяусыз үлемнән саклап калды, әмма инде Мәфрузаны рәиснең мәңгелек дошманына әверелдерде. Улының тазарып китүенә ул гына сәбәпче икәнлеген, хәер, Мотыйк белми дә калган иде. Галләм дә бу хакта сүз озайтырга теләмәде. Аның үз сөенече сөенеч: шушы ук көннәрдә хатыны Мәфруза, бөтенләй аптырашта калдырып, бәби алып кайтырга җыена иде. Ярый әле шундый вакытта кан күрмәде, өзлегеп китәргә сәбәбе аяк астында бит аның, дип фикер йөртте булачак әти.

Кара син бу Мотыйкны, көмәне борынына җиткән Мәфрузаны ду китереп чыгып китте, дип уйлады ул бераздан. Кеше кайгысы белән анысы шул мизгелдә үзенең дә тәмам башыннан чыккан лабаса! Яше илленең бу ягына чыккан хатынының балага узуыннан ул әле дә исәрләнеп йөри иде югыйсә...

Ай узды дигәндә, Мәфруза тагын бер кызны түр башындагы караватка куелган, чигүле япмалар белән чорналган кәрзингә китереп салды. Инде аның туганына да шактый көннәр үткән, матурланып, тулыланып килә, кешеләрне күрә башлаганы да тоемлана иде. Уналты көн дигәндә, әнкәсе аны кочагыннан аерды, бай кызлары гына ятарлык, бизәкләп үрелгән савытның елак бер хуҗасы итте.

Оркыя ир бала сыңары булып үсте. Буйга да яшьтәшләреннән ныграк, көчкә дә һичберсенә бирешмәслек, телгә дә кирәгеннән артык үткен булды. Сугышып-фәлән итеп йөрмәсә дә, Мотыйк малае Байрак белән генә серкәләре килешмәде, юллары каршы килсә, юл бирешмәделәр, бәхәс чыкса, икесе ике якта булдылар. Ахры, атасы малайга бу нәселгә котырган үгез кебек карарга өйрәтеп үстерә иде. Оркыяның моңа исе китмәде, теләсә, ул аны акылга утырта аласын белсә дә, кагылмады, сукмады, әмма чәкәләшкәндә юл куярга да ашыкмады.

Оркыядан котылуның җаен Мотыйк абзый тиз тапты: сугыш бетеп, тормышлар рәтләнә башлаган кебек тоелса да, Галләм абзыйның кәнсәләр тирәсеннән китүеннән, аяктан егылуыннан файдаланып, яше җитмәгән кызны урман эшенә язды. Исемлек ачыклаган җыелышта, унсигезе тулмаганнарны язмыйк инде, дип каршы төшә башлаган күршесе Салихны:

– Тулган, бик тулган, син беләсеңме, минме?! Мин малайны сөннәткә утырт дип килгәндә, инде ул аяк арасына кирәрлек бер кыз иде, – дип кырт кисеп туктатты.

Башкалар инде сүз әйтеп тормады. Алдында яшь буенча төзелгән исемлек яткан авыл сәвите рәисе дә телен тешләп калуны дөресрәк санады. Бер мәктәптә, бер үк парталар артында укып йөргән балаларның берсе Казанга – укырга, икенчесе урман егарга китте.

Нарат куелыклары эчендә, коры җиргә сылап салынган бура йортларда, кышкы суыклар башлангач, салкын, дымлы иде, җитмәсә, ашау ягы да шактый такырайды, моңа кадәр бирелгән икмәк телемнәре юкарды, сыр шакмаклары бөтенләй юкка чыкты. Һәркем алгысынып, тилмереп, әллә нинди өметләр белән язны көтә башлады. Майга кергәч, алмаш килер, аларны өйгә кайтарырлар кебек иде, тик Оркыялар авылыннан алмаш җибәрмәгәннәр икән, кызны, җәй узганчыга кадәр дип, тагын урман эшендә калдырдылар.

Ачлыкка кычыткан ашап кына түзә алмам дип уйлаган Оркыя җиде төн уртасында күлмәк-ыштаннан гына авылына качты. Бер алып чыкмаса, бер чыгар дип, сукмаклар буенча олы юл ягын чамалап йөгерде дә йөгерде, таң атканда, өендә иде инде.

Мич төбенә ипи тәгәрәтеп йөргән Мәфрузаны кызының бу рәвешчә кайтып керүе тәмам аяктан екты, җитмәсә, ире Галләм дә ни сәбәптәндер, Оркыяны уйлапмы, башкасынмы, көтмәгәндә йөрәге хәлсезләнеп егылган, инде соңгы көннәрен яшәп ята кебек иде.

– Кызым, әллә соң, белгән кебек... – диде ана кеше. – Атаң әҗәл белән булышып ята. Инде теленнән дә калды. Авызын ачтырып, су салып, сыек ризык кына ашатып торабыз...

– Юк, әнкәй, кайдан белим ди, качтым мин, әткәйне аннан күрермен, яшер мине тизрәк, – диде Оркыя, атасы янына узарга, аны да борчырга батырчылык итмичә. – Озак көттермәсләр, кем белә, эзләп тә килерләр.

Мәфруза карчык айнып киткәндәй булды. Еламады, сорашмады, борчымады, гадәттәгечә, яулык почмагын тешләп уйга калып торды да, кызына өстәлдәге иске ипине булса да каптырып, бакчага алып чыкты.

Ихата артында, абзарга якын гына өеп куелган, тутәлгә дип әзерләгән тиреслеккә ашыкмый гына зур уем ясады, төбенә киртәгә кибәргә эленгән паласларны җәйде, аннан, баш селкеп кенә, кызына кереп ятарга кушты, йөз турысына иске морҗа башын куйганнан соң, калган җирен тузган кием-фәлән белән каплады да тутәлне матур, тигез итеп яңадан өйде. Торбаның тирә ягына йолкып атылган чүп үлән, корган чыбык-чабык салды. Эш беркем аңламаслык, сизмәслек булып калды.

Чыннан да, эзләп килүчеләр озак көттермәделәр, әбәт турысында сак кына ишек шакыдылар. Шакулары йомшак булса да, сөйләшүләре каты иде. Өй асты пыран-заран китерелде, чормалар актарылды, абзардан мал чыгарылды... Түрдә яткан Галләм караваты да кузгатылды, авыру дип тә тормадылар, эзләп-эзләп тә, Оркыяны таба алмагач, аңа да янап, әйтмәгәннәрен калдырмый, пырлап чыгып киттеләр. Сорашып, күршеләреннән дә бер хәбәр алмагач, кайтмагандыр дип ышандылар, ахрысы, күздән югалдылар.

Колхоз рәисенең эшне зурга илтәсе, үзенең дә тавышка керәсе килми иде, атна дигәндә, икенче берәүне табып, берни белмәгәндәй, Оркыяны кайтарыгыз, этисе үлем түшәгендә, дип әмәлләгән хат тоттырып, урман эшенә җибәрде. Ул арада Галләм абый да вафат булып, этисен җирләргә тирестән чыгарылган кыз вакыйгасы, баштарак бөтен авылны шаккатырса да, кеше телендә озакка сакланмады. Әллә Мотыйк инде бу эш белән нәчәлникләр күзенә чалынуыннан курыкты, беркая барып, берни хәбәр итеп йөрмәде, эченнән генә, үчне тормыш алды инде, дип сөенеп тынычланды.

Мәфрузаның олы улы Мөхәммәтгали, кышкы салкында күлмәк-ыштаннан немец концлагереннан качып, аякларына салкын тидергән, урынга калган, туган җирендә кайтып яшәргә хокукы да юк, булса да, мәет җирләргә дә кайта алмаячагы көн кебек ачык иде. Аның каравы гөрнадирдай гәүдәле Нургали, вакытын гына белгәндәй, Кузбасстан чираттагы ялына кайтып төште. Әтисе белән хушлаша ук алмаса да, кабере өстенә бер уч туфрак сибәргә өлгерде:

– Авыр туфрагың җиңел булсын, салкын гүрең безнең күңел җылыбыз белән җылынсын...

Әле картлар таралгач та, бик озак китә алмыйча, инде бакыйлыктагы әтисе белән серләшеп утырды ул.

– Мин дә, синең кебек, җир асларыннан чыга алмый эшлим бит, әтәй, – диде ул уйчан гына. – Күзләр утлы күмер кебек кала безнең кара ташларны ватып өскә күтәргәндә... Җир асларыннан юл салып, сиңа таба гына барырга да... Булмый шул!

Шулай дигәндә, тавышы өзелде. Бер мәгънә салып әйткән сүзенең икенче мәгънәсенә үзе аптырап калды. Әйткәнен онытырга тырышты, тик кайткач та тынычлана алмады. Мәет чыккан йортка дога укырга җыелышкан күрше карчыкларының көенә моңланып, чыра яктысында әтисенең приказчик чагында төшкән рәсемнәрен карап утырды. Аныкы кебек мутлык бирә торган мыекларын бөтергәләде, рәсемнән караган моңлы күзләрен сыпырды. Керфекләрен йомдыргандай итсә дә, нәкъ үз яшендә булган әтисе һич кенә дә йомарга теләми, канәгатьлек хисе белән туп-туры аңа караган иде.

Иртән мич тирәсендә булышып йөргән әнисе, ашларны уздыргач, өйләнеп китәрсең инде, улым, үлгән артыннан үлеп булмый, хәзер дөнья сиңа калды, дип куйды. Нургали үзе дә бу турыда уйлаштыргалый иде. Кузбасста күз төшереп йөргән кызлары да юк, монда да көтеп алган чибәркәйләр күренми күренүен, тик менә үсмер чагында ук ошаткан берсе бар...

Мотыйкның олы кызы Халисә иде ул. Әнәй дә теләгәндә әллә өйләнергә инде?! Яучы җибәрергәме? Әнисе генә яучыласа?

Ишегалдына чыгып, баскычлар өстендә бик уйланып утырганнан соң, чоланга башын тыгып кына әнисен үзе янына дәште:

– Кил әле, әнәй, чыннан да, өйләним мин, булмаса, менә Мотыйк абзый олы кызын синең ризалыгың белән биреп куйса...

Мәфрузаның күз аллары караңгыланды. Егылмаска тырышып, ишек яңагына сөялде. Алай да, аягына ялгыш баскан гына бер кыяфәт чыгарырга тырышып, чайкалып киткән җиреннән тураерга маташты, булдыра алмады. Нәкъ йөрәк турысыннан кылт итеп без белән кададылармыни – бөгелеп төшкән хәлендә алъяпкыч эченнән генә күкрәген тотты. Юк, яшим икән әле, диде ул аннан, туктап калгандай булган йөрәгенең тек-тек кенә тибеп китүен уч төпләре белән тоеп.

Йорт ишегенә арты белән утырган Нургали боларны күрми иде. Бераздан ана турайды, улы борылып караганчы дип, сораштыра башлады:

– Халисәгәме? Безгә төшәрме соң ул? Юашлыгың да хәттин ашкан... Халисә биеп торган, башын чөеп баскан ат кебек...

– Шундыйларны ошатам да инде мин, әнәй!

Холыкка юаш булса да, өздереп әйтәсе дип санаганда, Нургалие дә әти-әнисенә охшап кала. Әйтте и вәссәлам! Шуны белгәнгә, бу турыда кабат сөйләшмәделәр.

Нургалинең китәр көннәре җиткәндә, Мәфруза карчык, яшь чагыннан калса да, әле дә өстендә бер дигән утырган, кызларча төз гәүдәсен тагын да купшылатып җибәргән күлмәкләрен киде дә, җелт-җелт атлап, югары очка – Мотыйкларга менеп китте. Китте дә Халисәне җитәкләп алып та төште. Кызның гомерлек дошманыңа барам дип әйтәсен көтмәгән Мотыйк икесен бергәләп диярлек йортыннан куып чыгарган иде. Шулай итеп, Халисә, Нургали белән куш булып, бәхет кошын тоткандай, Кузбасс якларына китеп барды.

Шушы ике баланың бергә кушылуы ике нәселне дә тоташтырырга тиеш иде кебек. Мәфруза теләгәнчә барып чыкмады. Кода-кодагый өй тутырып кунак җыйганда дәшәргә ашыкмады, күрше-күлән белән бер-бер эшне өмәләп башкарганда да балта-көрәк күтәреп килеп җитмәде. Кызы урынына почтальон сумкасын тагып йөри башлаган Хариса иреннән дә болайрак булып чыкты. Гомерен рәхәттә уздырган хатын, сумка тутырып, өй борынча йөрергә кирәклекне башына да китерми иде, кино-фәлән барганда, мунча кадәр клубның экран төбенә килеп баса да урам буенча кушаматларны тезеп китә:

– Ыштансыз Гали, Күпер асты Лотфулла, Кыяр буры Марзыя...

Исеме чыккан бере тиз генә аның кулындагы гәҗитне эләктереп ала да, башкаларны төртә-ега, кире үз урынына барып утыра. Бәхетсезлегеңә каршы, ул көнне кич чыкмасаң, хатсыз да каласыңны көт тә тор.

Мәфруза карчыкны олысы-кечесе хөрмәт иткәнгә, ул урамнан үткәндә, сугышып яткан балалар да шып кала, тәмәке тартканы тәмәкесен чалбар кесәсенә яшерә, бер-бер сәрхушы тизрәк кайда да булса шылу ягын карый иде. Почтальон кодагый, әллә кеше сүзеннән сакланып, әллә инде кызының каенанасы булганга, бераз йомшый төшеп, хатны үзе үк китермәсә дә, кемне дә булса табып, Мәфрузаларга йөгертә торган иде.

Хатлар гына сирәгәйде. Нургалинең юраганы юш килде: эшләгән шахтасы җимерелеп, гомерлеккә таш астында калды. Киткәндә, озатырга дип җыелышкан яшьтәшләренә, шаяргандай итенеп, таш басмаса, бер кайтырбыз, дип көлеп куйган иде шул. Килене Халисә дә, аталары йортына әйләнеп кайтырга теләмичә, баласы белән шул туфракка беректе. Бу хәл Мотыйгулла белән Мәфрузаны якынайтмады да, ерагайтмады да. Халисәдән килгән хәбәрләр белән бүлешмәделәр, хәсрәт-кайгыларын уртаклашмадылар. Килен, кунакка башта каенана йортына кайтып төшсә дә, аннан үз аталарында ял итте.

Кайчандыр Сөннәтче әбигә эченнән түгел, тышыннан да юньле теләк теләмәгән Харисага, аның түшәккә егылуын ишеткәч, кинәт әллә ни булды. Башта ул туксанын тутырып та җир җимертеп йөргән Мәфрузаның аяксыз калуына ышанмады. Аннан гына эчке бер тоем белән бу хәлләрнең чынлыгын аңлады. Аңлады да йөгереп килеп тә җитте. Кодагый дигәне түр караватта, мамык мендәрләргә терәлеп, күрше-күлән белән сөйләшеп, хәер-фатихасын таратып утыра. Ничек тә аңа да алып калырга кирәк иде бу изгелеге белән дан алган карчыкның яхшы сүзен. Кызы Халисәнең – каенанасы, оныгы Камилнең әбисе дә иде бит әле ул...

– Кодагый, – дип сүз башлады Хариса еламсырап кына, – инде синең дә ахыр сәгатьләрең җитә...

Тирә-яктагылар, бу ни тагын дигән кебек, аңа карап торуларын күргәч кенә, ул үзенең тагын бер хата эшләп ташлавын аңлады, әмма эш узган иде инде. Сөннәтче карчык кына әллә аны ишетмәде дә, бик сагынган кешесен күргәндәй:

– Әле, Хариса, нәкъ менә синең турыда гына уйлап утырадырыем. Кеше җибәрттем, анысы юк булды, үзең күренмәссеңме дип көттем... Юк ла, менә килгәнсең бит, – диде. – Мөхәммәтгалиемнән хат юкмы, кодагый?

Харисаның йөрәгенә май сыладылармыни: йөзләре яктырып, күзләре ачылып киткән кебек булды. Авыруның бик тә хәленә керергә теләгәндәй:

– Юк шул, юк, нигә, килергә тиеш идемени? Бакчи, килгәненә атна-ун көн дә юк ич, – дип җавап кайтарды.

– Күңелгә килсә, дөрес килә иде дә... Менә, юк икән бит әле... Тиешен тиеш кебек инде ул... Бик тә көткәнгәме соң?..

Карчыкның гаҗизләнеп әйткән бу сүзләре әле яңа гына берни булмагандай сөйләшеп утырганнарның күңеленә сагыш иңдерде. Аның иң өлкән улын сагынганын, инде сугышка алынганнан бирле бер күрергә тилмереп гомере узып киткәнлеген барысы да белә иде. Мөхәммәтгалинең өстеннән «халык дошманы» дигән кара тамга алынса да, туганнары белән күрешергә рөхсәт язуы бирелсә дә, кайтырлыгы калмаган, әнкәсенең исә ерак илләргә чыгып китәрлеге бөтенләй юк иде.

– Һе... кара син аны, ялгышканмын бит, – дип куйды ул, үзалдына сөйләнгәндәй генә. – Тагын ике көн эчендә дә килмәсә, риза-бәхиллегемне, кодагый, үзең җиткерерсең инде.

Моңарчы үзара бер юньле сүз әйтешмәгән ике гаилә эчендә шушы рәвешчә сөйләшеп утыру барысының күңелләренә әллә нинди бер җиңеллек тә китерде.

– Булмаганны, ни сөйлисең син?! Нинди ике инде ул? – диештеләр кич җитсә дә кайтып китәргә ашыкмаган күрше карчыклары.

Икенче көнне дә, өченче көнне дә йорттан кеше өзелмәде. Сөннәт әбкәсе янында үлем көтү хәсрәте белән тормыш итү рәхәтлеге үзара буталган кебек булды: мөнәҗәт көйләүчесе дә, дога укучысы да күп иде, алар ялгысытып җибәргәндә, тыныч кына итеп хәл-әхвәл дә сораштылар, дөнья турында да сөйләштеләр, әмма авыруның сәгатьтән сәгатькә бирешкәне, хәле киткәнлеге күренеп тора иде.

Өченче көнне, төш вакыты дигәндә, олы кызы фельдшер хатынга йөгерде. Күз яшьләренә буылып:

– Әнәйнең бөтен аркасы шарт та шорт килә, үзе акылында әле, һаман Мөхәммәтгалине сорый. Анысы да бахыр шушы көнне дә әнәй янына кайта алмый бит, үз хәле хәл, – дип өзгәләнде.

– Кан тамырлары шартлый башлаган инде алайса... Нык иде бит, бигрәкләр дә нык! Йөрәк түзгәнгә тән түзә алмаслык хәлгә килүдән бу... Соңгы сәгатьләредер, Маһикамал, шул улының хәбәре генә яшәтә инде аны. – Татар авылында чит-ят телне тәмам өйрәнеп, гореф-гадәтләргә күнеп беткән Шура түтекәй әнә шулай сөйләнде. – Көтеп торыгыз, мин хәзер!

Ул озак көттермәде. Ялтыравык тимер-томырларын төяп килеп тә җитте.

– И-и-и, яшисе дә яшисе әле сиңа, Мәфрузаттәй, – диде ул, карчыкның төшеп беткән, инде үлчәгечләр дә көчкә тойган кан басымын үлчәгәндә.

– Шура, тәрәзәдән кара әле, Хариса күренмиме? – дип сорады көч-хәл белән генә Мәфруза карчык. – Мөхәммәтгалиемнән хат килмәде микән? Килмәде микәнни соң?..

Урынга егылганга нәкъ өч тәүлек дигәндә, Мөхәммәтгалидән кала күрәсе килгән бар кешесе килеп беткән, инде карчыкның соңгы өмете дә өзелгән иде. Менә ул тынсыз калгандай селкенми ята башлады. Күңелне аның исәнлегенә шик алды. Карчыкның тотышында көтелмәгән якка үзгәрешләр булмагач, бу хакта кызыксынырга кыенсындылар, үзе ачыкланганны тын гына көтә бирделәр.

Харисаның кодагые кулыннан сөннәтләнмәгән улы Байрак авылда мулла булып киткән һәм, алардан ерак түгел генә урыннан нигез алып, йорт салган иде, Оркыя шуңа йөгерде. Байрак килеп ясин чыкты. Бик ягымлы күзләре белән бераз кодагый әбисенә карап утырды да хушлашып китеп барды.

Йортны тагын авыр тынлык басты. Бераздан капканың киерелеп ачылуыннан тимерләре ыңгырашып куйган тавышка барысы да айнып киткәндәй булдылар. Инде ишеккә карап, кем керер икән дип, көтеп тора башладылар. Шулчак, яңадан хәл кергәндәй, тагын бер кат исәрләндереп, Мәфруза карчык торып утырды, барысын бер кат күзеннән кичерде дә, таныш кешесен күрмәвеннән гаҗизләнеп, ишелеп төшкәндәй генә караватына ауды. Күзләре ачык иде әле:

– Мөхәммәтгалиемнән хат... – Соңгы сулыш алганда әйтелә башлаган җөмлә һавада өзелеп калды.

Кабаланып алынган тын шул арада кешеләрне ишеккә таба борды. Анда кочак киереп посылка күтәргән Хариса басып тора иде.

– Мәфруза кодагый, монда сиңа хат та, посыл...

Ул шунда үзенең нибары ярты минутка соңга калганлыгын аңлады. Йөрәген айкаган хәсрәткә түзә алмыйча, үгез кебек үкереп, урамга чыгып йөгерде. Анда, өске як урамнан, башкалар баргач, мин дә барыйм инде дигән кебек, Мотыйк төшеп килә иде. Хариса бу посылка белән хатны моннан өч көн элек үк иренең юл уңаеннан кереп хатыны урынына күрше авыл почтасыннан алып кайтканлыгын, әллә кайчангы үчләрне актарып чыгарып, эчке бер мәкер белән, көтсен әле, дип, көлеп яшереп куйганлыгын белеп алган һәм, качырылган урыныннан тартып чыгарып, кодагыена йөгергән иде.

Харисаның шушы ир белән узган гомеренең бөтен мәгънәсез сәгатьләре, үчләре, дошманлыклары башыннан кичкән кебек булды. Күзе томаланып, ул алга таба атлады һәм күркәләрен коеп, моңаеп калган нарат кәүсәсенә килеп төртелде. Чүт кенә чирәмлектә чемченеп йөргән каз бәбкәсенә басмады. Аларны саклап йөргән ата каз хатынның итәгеннән эләктереп алды. Хариса аны, мөмкин кадәр тынычлык саклап, итәкләреннән ычкындырды, көш-көш диештергәләп, читкә җибәрде. Каз ысылдаган булып кына кыланды да яңадан бәбкәләре арасына кереп ятты.

Мәфруза карчыкка чәйгә дип коелган симез күркәләрдә каз бәбкәләренең гаме дә юк. Пипелдәшеп, яшь үлән чемченүләрен беләләр. Йомшак кына исеп куйган җил кечкенә бер күркәне үләндә тәгәрәшкән бибиләр арасына куып кертте. Тәҗрибәсез бәбкә йомшак, ныгымаган томшыгы белән төртеп-төртеп карады да таптап өстеннән узды, егылды, торды, тагын егылды.

Каз бәбкәләре дә адәм балалары кебек, дип уйлады Хариса. Кайда абынасыларын, кайда егыласыларын белмиләр... Аларны әнә әнкәләре, әткәләре саклый. Инде менә шушы зур авылның кадерле бер әнкәсе юк...

Газизә, келәттән соңгыларын алып кердем инде, дигән иде, җыярга кирәк булыр әле бу күркәләрне... Кеше басканчы, казлар йомышлаганчы. Нарат чәенең сихәтенә бернәрсә җитми ди бит. Сөннәтче әби юкка шулай озак яшәмәгәндер. Әллә кешеләр хәер-догасы яшәтте микән аны?!

Юк, Харисаның айкалган күңелен чыра эссесендә генә кайнаган чәйләр басарлык түгел иде бүген. Кылт итеп күңеленә улы Байракны сөннәтләгәннән калган пәке килеп төште. Йорт бүрәнәләренең чолан ягындагы ярыгына кыстырып куйган иде бугай ул аны. Кайтырга да алырга кирәк булыр...

Хариса, догасын-фәләнен өйрәнеп, бу изге эшкә үзе керешергә күңелен беркетте. Бер гомер кичте, икенчесе башлана гына кебек иде әле... Бер гомер кичте, икенчесе башлана гына иде шул...

*2006*

## ИСЕМГӘ ИСЕМ КИТКӘН

Мәгънәвинең баласы буласына тәмам өмете өзелгән, тормыштан күңеле төшеп йөргән көннәрдә хатыны күкләрдән иңгәндәй юньле хәбәр ишеттерде: авырга узган, имеш. Бу хәл аның бөтен тормышын, күңеленең астын өскә әйләндерде дә куйды.

Боек кына бер хәлдә инеш буеннан кайтышы иде Мәгънәвинең. Авыр калай чиләкләрдә малларга чиста су алып төшкән Нурисәсенә таба кызуланырга да, килеп җиткәч, суын күтәрешергә дә ашыкмады. Юллары үзеннән-үзе кисешкәнлектән генә, алдында ук туктаган иде ул хатынының; алай да, уйланып, әле еракка – тау артындагы урман ягына, әле яшел чирәм күтәрелгән аяк астына озаклап, нәрсәнедер эзләгән, бик кадерле әйберен табарга тырышкан кешедәй текәлеп торды.

Аннан гына карашын Нурисәнең язгы сипкел баскан битенә күчерде. Кысыла төшкән күзләре эчендә йөргән кара алмаларыннан да, вакыт-вакыт мимылдап куйган юка күгелҗем иреннәреннән дә авыр уйларыннан котыласы килгәнлеге әллә кайдан аңлашылса да, сүзне Нурисә башлады:

– Районда ни әйткәннәрен дә сорашмыйсың инде алайса?

Мәгънәви, аның нәрсәсен сорашасың, сигез елдан бирле бер балык башы бит дигәндәй, җилкәләрен генә сикертте.

– Алай икән... Сиңа бар да бер икән... Инде минем белән торасың да килми, ахрысы...– дип дәвам итте сүзен хатын.

Мәгънәви чак кына «әйе» дип ычкындырмады.

– Миңа күңелемдәген сөйләргәме, әллә синең кебек үз исәбемә баткандай яшәвемне дәвам итәргәме?

Хатыны сүз куертырга, тавышка керергә тырыша кебек иде, шуңа күрә Мәгънәви аның бу соравын да җавапсыз калдырды.

– Ничә ел бергә яшәп рәхәтләнеп сөйләшеп утырган да юк бит безнең, – диде Нурисә инде моңсурак тавыш белән. – Йә су буенда, йә абзарда, йә йоклаганда ике-өч сүз алышабыз да шуның белән бетте.

Чыннан да шулай иде. Күңелең суына башлаган хатын белән өй эшеннән башка тагын нәрсә турында сөйләшәсең?..

– Ә бит мин сиңа яратып, бәхетле булырбыз кебек чыктым...

Мәгънәви нәрсәгә дип өйләнгән? Бәхетле булыр өчен, билгеле! Аның да өй тотырып бала-чага үстерәсе, кичләрен шулар белән мәш киләсе, буш башларына акыл кертәсе, үзен олы бер кеше итеп сизәсе килә иде бит...

– Әллә аерылырга гынамы? – диде Нурисә, бик сынаулы карап, бөтенләй дә көтмәгәндә.

Чыннан да, аерылыргамы, бер гадәтләнгән күңелсез тормыш белән яшәүне дәвам гына итәргәме? Бу сорауга үзе дә кайчаннан бирле җавап таба алмый йөри иде Мәгънәви. Инде менә җеп очы тартылды...

Нурисәнең шул сүзгә үзе тукталуы бик яхшы булды әле. Их, башлап аерылу ягын да үзе каерса... Гаеп бөтенләй Мәгънәвидән төшәчәк.

– Соң... Хатын-кызга билгелерәк инде! – диде ир.

Нурисә сүзне ничек дәвам итәргә белми иде бугай. Чиләкләрен җиргә куйды да яулык читеннән чыгып аптыраткан чәчләрен кыстырырга кереште, күлмәк итәкләрен тарткалаган булды.

Мәгънәви тагын ерактагы тауларга карап тора башлады. Йөзенә тагын нидер эзләү галәмәте чыкты. Эзләми иде инде ул, эзләми! Мондый вакытта сүзе табыламыни аның?!

Әнә Нурисә дә, ни әйтергә белми таптанып торганнан соң, «әллә анда берәр нәрсә бармы?» дигән бер кыяфәттә Мәгънәви караган офыкка текәлде.

Ә офык өстендәге күк... ап-аяз! Болытның заты да күренми! Күзне чагылдырырлык якты. Мәгънәвинең аскы калын ирененә сыенып яткан юкасы – өскесе кебек күгелҗем урман. Һәр әгъза, һәр күзәнәк үз ишен, тәрәктәшен эзли шул...

Вакытыннан алда олыгаеп килә иде бугай ла Мәгънәви! Нурисә, күзләрен офыктан күчереп иренә карап алгач, шулай дип уйлады. Утызга да җитмәгән, картлар йөреше кереп бара үзенә. Сахрага һава суларга йөрергә яраткан күрше Минһаҗетдин бабасы кебек көн дә инеш буйларын әйләнеп кайта.

Мәгънәви, көтмәгәндә, үзенә карап торуын сизенгәндәй, карашын хатынына күчерде. Аның инде күптән шат елмаймаган йөзендә бәхеттән сикерешкән кебек тоелган, язда җетеләнгән сипкелләрен күреп исәнгерәп китте. Күк яктысыннан кысылган күз алмалары иң эре сипкел булып калганнар! Нәрсә күзәтә соң ул? Мәгънәви хакында ни дип уйлый? Әллә күңелендә бөтенләй көтелмәгән хисләрме? Ирнең башына да килмәгән уйлармы?..

Кушылмастай булса, яңадан башларгамы сүзне, юкмы? Бераз гына көтеп караргамы? Әллә чиләкләрен бозауга илтешкән булып, ул хәл алганчы, чиләктә су беткәнче, гәп куертып торыргамы? Ничек тә тагын шул ук әйберләргә кире кайтырга иде бит...

Якында гына мари ягыннан алып кайткан яшь бозауның инде җанга якын яңгырый башлаган тавышы ишетелде.

– Му-у, су-у... – ди кебек иде ул, «язгы кояш эссесендә бездәй тора аласузму» дигән кебегрәк кызгандыртып.

Нурисә капылт:

– Ярый, мин соңгы сүземне кичкә әйтермен! – диде дә, җиргә куеп торган чиләген кире алып, якында гына авызын сузып, мөгрәп торган борынчык янына таба китте.

Аерылу турында сүз катырга әллә кайчаннан бирле кымырҗып йөрсә дә, килеп терәлгәч, бик җиңел түгел икән. Мәгънәвинең ашаганы – аш, эчкәне чәй булмады. Берәр вакыт эшләрмен әле дип калдырып торган юк-бар эшләр дә эшләнеп бетте, кич кенә җитмәде дә җитмәде.

Чәйләргә кергәндә дә, яныннан узып киткәндә дә, хатынына күз ташламаска, аның хәсрәтле йөзен күреп күңелен йомшатмаска, китү турында бер сүз башланган икән, өзәргә дә куярга дип уйлады ул.

Тора-бара гадәттәгедән әкренрәк кыймылдаган, әткәсе-әнкәсе белән тагын да ягымлырак сөйләшә башлагандай тоелган Нурисә Мәгънәвинең эчен поштыра башлады. Син монда аерылышу турында уйлап йөрәгеңне кая куярга белмисең, табан асларыңа кадәр яна, ул әнә берни булмагандай йөри бирә. Ни борчылып бер-бер сүз катмый, ни юкка-барга бәйләнеп тавыш чыгармый.

Мәгънәви түзмәде, ялга каршы мунча ягып йөргән Нурисәнең чолан ишегеннән кергәнендә, ишек яңакларын тотып, юлын кисте дә туп-туры күзләренә карады. Ни үпкә, ни ачу, ни хәсрәт билгесе юк иде аларда, әмма кайдадыр тирәндә, күңел төпләрендә ниндидер үзе генә белгән сернең яшеренеп ятканлыгы тәгаен.

Нурисәнең яшьлегендә армиягә озатып калган егете Фәтхи ялга кайткан, дигәннәр иде. Шуңа бик очынмыймы бу сантый, дип уйлады Мәгънәви. Чишмәгә суга китсә дә, соңгы вакытларда озаграк тора, даруга үлән җыям, фәлән чәчәкнең, төгән тамырның хатын-кыз авыруларына шифасы бар икән, дигән була. Шуның белән очрашуга бер сәбәп кенә түгел микән болар?

Нурисә, бер сүз дә дәшмичә, Мәгънәвинең борын төбенә үк терәлгән беләкләрен кулы белән сак кына тартып аска төшерде дә, үзенә юл ачып, чоланга узды.

Икенче яңактагы кулын ычкындырмый гына, ир, ярым әйләнеп, тагын аны күзәтергә тотынды. Кара моның кыланышларын! Әллә кем булып, ана үрдәк шикелле, арт якларын боргалый-боргалый йөрүләрен... Өстенә дә эш арасында, гомер булмаганча, өр-яңа халатын алып кигән...

Мәгънәвинең йөрәгенә Фәтхи исеме таш булып утырды, дошманын исенә төшерүдән күзләрен кан басты. Ярып берне әйтергә дә чыгып кына китәргә кирәк иде бу өйдән. Яшәсен иде аннан Фәтхиләрен-Мәтхиләрен уйлап, дуадак каз шикелле каңгырып.

Китүен китәрсең дә... Тик менә әти-әнисе барыбер шушы нигездән аяк та атламаячак. Әле бер-бер завод-фәләнгә эшкә кереп фатирлы булганчы, үзенең дә ярты гомере тулай торакта узар. Юк, ир кеше эше булса да, бу Мәгънәвидән чыга торган нәрсә түгел. Нурисәнең үзе белән ияреп килгән өе юк: китсен дә барсын Фәтхиенә!

Хатын чолан почмагында юарга салган керләрне әле тегеләй, әле болай күчергәләп торды да чыгарга уйлады булса кирәк, Мәгънәвигә таба атлады. Ул, шул арада аңа каршы басып, тагын ишек яңакларын тотты.

– Бала-чага булма! – диде Нурисә, иренең йөрәген шул сүз белән генә дә телгәләсен белсә дә. – Җибәр кулыңны, газга чәй куйган идем, кереп сүндерәсе бар.

– Ничава-а, әнкәй өйдә, газны гына сүндерә ала. Менә миңа синең күзләргә карап калырга кирәк...

Чүт кенә соңгы тапкыр дип ычкындырмады Мәгънәви, ә бит иң яхшысы, сереңне аңлар өчен, дип өстәү иде. Тагын ул телгәнчә килеп чыкмады.

Нурисә бу юлы да, иренең кулын тартып алып, ишектән чыгарга омтылды, аларның ычкынмаслык итеп ябышканлыкларын белгәч, бөтен көче белән эштән сеңерләнгән беләкләренә килеп ябышты.

– Ничава-а-а, – дип сузды тагын Мәгънәви, Нурисә кулында егәрнең көннән-көн арта гына барганлыгына ишарәләгәндәй.

Хатын иренең бу көнге кыланышларыннан тәмам туйганлыгын тыштан сиздермәсә дә, чынында тәмам ялкыган иде. Инде ул, әйдә, бер-беребезне тинтерәтик алайса дигәндәй, шарлатып иренең күзләренә карады. Әллә нинди эчке бер ярсу, әллә усаллык, әллә... Аран җимереп качарга әзер ат, ризыгын тартып алырлар дип курыккан эт... дигән фикергә килде ул һәм аның «ничава» сүзен үзенең тән матурлыгына кайтарды да калдырды. Эченнән генә, яшибез икән әле алайса, дип уйлады.

– Җибәр, Мәгънәвикәем, – диде ул аннан, ни өчендер ягымлы күренергә тырышып.

– Мәгънәви әкәем...– дип ыржайды ир. – Алар мари авылында була, оя тутырып бәбкә чыгара, көзен бакча киртәсе эче тулы кәҗә бәкәйләре йөгереп йөри. Әкәймени мин сиңа бала табып бирергә!

Нурисә Мәгънәвидән мондый тупаслык көтмәгән иде. Күз төбенә яшь килеп бөялде. Торсана шунда, дигән кебек, борылып, мунча эченә керде дә китте. Аның тәбәнәк, озын утыргычларның берсендә башын артка – мунча стенасына ташлап елап утырасын белсә дә, Мәгънәви артыннан кермәде. Еласын, тынычлансын, бераз Фәтхиен дә исенә төшереп алсын дип, эченнән сөенебрәк тә ишегалдына чыкты.

Әйтәсен әбәт ашаганда әйтер... Инде ул чагында яңадан ямьсез нәрсәләрне исенә төшереп тормас, барыбер кичкә якынрак була... Анда әле хушлашасы, күз яшьләрен сыгасы. Үпкә сүзләрен бер-бер артлы тезәсе бар...

Нурисәнең өстәл артында, әткәсе-әнкәсе янында сүз көрәштерү, ике арадагы хәлләрне сиздерү гадәте юк иде. Гадәттәгечә, берни булмагандай елмаеп, аш бүлеп, чәй әзерләп йөрде, тәмле сүзен кызганмыйча сыйлады. Табынны ничек ямьсезлисең – Мәгънәви дәшмәде.

Ирне хатынының кыланышлары бөтенләй пошаманга төшерде. Син монда аерылырга йөрисең... Ул берни булмагандай маташа. Әти-әнисе дә барыбер бер беләчәк бит инде! Ниндидер Мәгънәви аңламаган сәбәбе булырга тиеш иде моның. Туктале, бу юлы бозау эчертүдән әкрен генә, салмак атлап кына, уйга баткандай кайтып керде бит хатыны... Әллә соң анда да Фәтхи белән очраштылармы? Әйтәм җирле, яшь чакларындагы кебек, малга суны үзең генә эчерт инде, ир-ат эше бит ул, дип тинтерәтми. Мин дә мал ярата башладым, кич кайтканчы да сагынып бетәм үзләрен, дигән була. Бозау балаң түгел. Ул да булдымы сагынырлык җан... Фәтхине бозау дисәң генә инде. Фәтхинең бозаулыгында түгел монда эш, Мәгънәвинең мөгезле сыерлыгында...

Инде нишләргә? Фәтхигә барып, хатынны мин асрыйм, ә син хезмәтеннән файдаланасың, килеп алып кит кенә, дияргәме? Алай ярамас. Минзиләсенең ни гаебе бар? Әгәр ул өйдә булса, ишетеп торса? Мәгънәви турында ни уйлар? Үзе дә алтынчы класста укыганда Минзиләне озатып куйган иде ләбаса! Аннан ары күрешмәделәр дә күрешүен...

Ә менә башкалар булдыра! Чишмә юлында да, бозауга су эчергәндә дә...

Минзилә дигәннән, Мәгънәви аның кайсы төшенә кызыккандыр. Ни буе, ни тавышы күңелгә ятарлык түгел. Аягы юантык. Күзе чепи. Менә Нурисә-ә... Ул чакларда әле бигрәк тә!

Тик кысыр хатынның матурлыгыннан ни файда?! Сигез ел яшәп, бер малай да алып кайтып бирмәгәч! Минзилә, улы булмаса да, кайсын җитәкләп, кайсын итәгенә ябыштырып, өч кыз белән урамнан уза көн саен. Әнисеннән алда башын чөеп барганы кияүгә чыгар-чыкмас ук борынлаган иде бугай...

Шул бозык Фәтхи хәзер синең хатыныңа үрелеп маташсын инде, әй! Ялгыз вакытында туры килсәм, шәпләп эләктерәм инде! Су буена барып чыгып, яңагына гына бирергәме? Үз йортыңда соңгы көн яшим дигәндәме?.. Аерылган хатының өчен сугышып йөрү булып чыга түгелме? Инде килеп, авылдашларыннан да оят. Яшең утызга җиткәндә, малай-шалай шикелле хатын бүлешеп йөрү килешми. Алар, ичмасам, кызлар өчен сугыша.

Мәгънәви, өстәл янына кузгалып киткәндә, бүген беренче тапкыр юньле сүз әйтергә ниятләде:

– Ярар, рәхмәт. Чыгып, мунчаны карап керим: әзер түгел микән. Үзем беренче керермен!

– Ташка эссе салып һавасын бетерәсең, әнкәйнең йөрәге йомшак, мунча артык кызганчы, эткәйләр генә керсен инде, Мәгънәви, – диде Нурисә, аның белән килешмичә.

Килен дисәң дә килен иде Мәгънәвинең хатыны. Анысына тел-теш тидерерлек түгел. Ризыгын тәмле итеп пешерә, урыннарын көн саен кабартып, атна саен чиста җәймәләрен җәя, намазлык-тастымалын да җем итеп тота. Каенатасы белән каенанасының сүзләрен ошатмаганда да каршы төшмәс, кайвакыт кына, кич урынга ятканда, «фәлән-фәлән дип аңлатып кара әле, ризалашмаслармы» кебегрәк сүзләр белән иренең үзеннән генә үтенер.

Аерылсаң, таякның авыр ягы әти-энисенең җилкәсенә төшәчәк инде. Шактый гына төшәчәк! Әле мондый эшкә җитез, сүзгә күндәм икенче бер хатынны таба аласыңмы-юкмы?!

Мунча өлгергән иде. Каен себеркесе генә калмаган. Имәннеке дә ярар дигәндәй, Мәгънәви мунчаның күгәрә башлаган калай ләгәненә су салып, миллекне шуңа батырды.

Мунча себеркеләрен узган ел Нурисә белән генә әзерләделәр. Гомер бакый андый эшне улына ышанып тапшырмаган Габделсаттар карт уникенче июль көнне ишегалдында гадәттәгечә ду килеп йөрмәде. Аның лапастагы әйләнгечтә балта кайраганы да ишетелмәде, карчыгыннан бәйләргә – бау, улыннан алюмин чыбыклар сорап та йөдәтмәде. Әле төшлек турысында да бер уйсыз кыяфәттә чаршау эчендәге агач караватларында йокымсырап ята бирде.

Мәгънәви каралты-кура тирәсендә әйләнгәләп йөрде-йөрде дә түзмәде, кереп атасы кырына килде.

– Быел миллеккә бармыйбыз мәллә, эткәй?

– Яфраклар өлгергән дәмени? – диде Габделсаттар хәзрәт, Мәгънәвине гаҗәпкә калдырып.

– Миллекнең яхшысы нәкъ менә июльнең уникесендә әзерләнә, ди идең ләбаса!

– Әйтелгәндер инде... – дип куйды ата кеше. – Без ясасын ясаган, чабынасын чабынган...

Габделсаттар картның тузга язмаган сүзләр сөйләнеп утыруы күңеленә ятмаса да, Мәгънәви сатулашып тормады, гараждан бишекле мотоциклны гына кабызып чыгарды да, артына Нурисәне утыртып, Каенлык урманына элдертте.

Әтисе башкарган эшнең үзенә калуын өнәп бетермәгән дә иде өнәвен, һәр начарның бер яхшысы була дигәндәй, түбәсенә кемдер яшь ботаклар салып чыккан көтүчеләр шалашында әллә нинди бер исәрлек белән Нурисәне кочагына алды ул...

Көтмәгәндә килеп ява башлаган болыттан өйгә кайтып кына котылырга да була иде югыйсә. Инде миллекләр ясалган, ботак-сатак ише нәрсәләр, кемгәдер учак ягарга булса да ярар саналып, шалаш тирәсенә өеп куелган иде. Миллекләрне брезент плащ белән капладылар да, болыт үтеп кенә киткәнче дигән булып, шалаш эченә уздылар. Бу яңгырда кемнеңдер килеп чыгуы икеле дә икелесен...

– Беткән баш беткән, – дигән булды шаярып Мәгънәви. – Яшь юләрләр кебек бер онытылыйк әле. Килеп керсәләр, без түгел бу, диярмен...

Башка чакта артык әдәпле Нурисә нигәдер каршы килмәде, үзе үк кофта сәдәфләрен ычкындырырга тотынды...

Бу серле шалашка шул җәйдә, әлеге татлы көнне эзләгәндәй, узган-барганда кереп чыккалый торган булдылар.

Матур гына башланган, тәмамланган иде лә көзе дә, кышы да... Аннан гына күңеле әллә нишләде дә куйды Мәгънәвинең. Язга чыктымы, йөрәгенә бер моң әйләнә дә кайта. Киек кошлар китерә идеме аны, бала чыгарган йорт казларымы, әллә табигатьнең ниндидер сер-хикмәт нәтиҗәсендә яңаруымы, шул яңарыштан үзеңне бер читтә калган нәүмиздәй хис итүме – баштарак ул аны аңлата да алмады. Тора-бара ялгызлык, нәсел-нәсәп чылбырын өзеп дөньядан китүдән курку икәнлеген төшенде. Бу хис,

җетеләнгән саен, эчен тагын да ныграк кимерә, күңелен тәмам пошаманга төшерә башлады. Ул, шул моңсулыктан котылырга теләгәндәй, урман юлларында йөреп керергә, су буйларына төшеп утырырга гадәтләнде.

Бүген дә шундый чагында каршысына очрады аның Нурисә. Таң тишегеннән, язгы эш өстендә мең төрле сәбәп тапкан булып, районга чыгып киткән иде. Болай тиз әйләнеп кайтыр дип башына да китермәде Мәгънәви.

Иртән, автобуска соңга калмыйм тагын, ди-ди ишеккә таба атлаганда, иренең:

– Малларыңны кем карый? – дигән сүзенә дә артык игътибар итмәде Нурисә.

– Син бар бит, – дип кенә куйды. – Ияреп килгән сыерым юк.

Ияреп килгәне булмаса да, ияртеп китәр әле, дип уйлады Мәгънәви, әмма шул сүзне әйтәсе урынга:

– Мин сөт эчмим, сыерларыңны үзең белән ал, – дип өстәде.

Әткәсе-әнкәсе белән бер тамчы сүз көрәштермәгән Нурисә соңгы вакытта әллә нинди үҗәткә, каршы әйтүчегә әйләнде. Синең бер җөмләңә уны белән җавап бирә. Сәбәбен аңламый түгел, аңлый иде Мәгънәви. Яз саен әйләнеп кайта торган үз сәерлекләре үзгәртә дә куя иде хатынны.

Сәбәбен дә аңлыйсың, тик нигәдер кешедән табасы килә, дип уйлады эченнән генә Мәгънәви бу юлы. Киресенчә булса, синең ирлегеңә зыян килә, дәрәҗәң кителә кебек. Юкса... нинди дәрәҗә инде ул әби-бабайлы йортта. Һаман шул җитлекмәгән егет рәтендә йөрисең. Аны табасың, моны... Ата кеше, ну, малай, барыбер үземнән калыша дигән сыман, син әллә ниләр җимерткән кебек чакта да баш селкеп карап тора. Бакча эшләре тотынса, үзе башлап йөри. Мал суярга әзерләнәсең, ул инде сугым пычакларын кайрап ук куйган, күршеләргә дә әйтеп чыккан. Печәнгә төшкәндә дә, абзарга көтү керткәндә дә, гел аның рөхсәте белән.

Алай да атасының миллеккә үзе бармавы йөрәгенә таш белән бәргән кебек булды. Шунда гына әлегәчә аның күлмәге эчендә, җылыда яшәгәнен аңлады Мәгънәви. Шул көннән соң үзе кайгыртачак, үзеннән соң калачак уллы булу теләге йөзе белән артты.

Инде менә, йортыннан качып, иң кадерле кешеләрсез дә кала түгелме? Мунча мичендәге кисәүләрне болгатканда да, коенырга салкын кое суы ташып йөргәндә дә, күңеленнән эч пошу хисе китмәде. Эче пошса пошты, әмма аерылу уен торган саен ныграк беркетә барды.

Әтиләре кызарышып-бүртенешеп мунчадан кайтып егылганда, Нурисәнең чәй яңартып йөрүе иде. Әнкәсенә – сөтле, әткәсенә мәтрүшкә, карлыган яфраклары салган чәй китереп утыртканында да, мунчадан киеп чыгачак ару киемнәрне хәстәрләп йөргәнендә дә, Мәгънәви гел аны гына күзәтте – урта ишекнең салкын, буяулы тупсасында аңа карап сүзсез генә утырды.

Нурисәнең бу хәлгә әллә чыннан да исе китмәде, әллә исе китеп арыган, Мәгънәвинең сәерлекләренә кул селтәгән иде. Бер эшсез тик утыруына да дәшмәде, йорт эшләре барыбер үземнеке инде дигәндәй, тыз да быз йөрүендә булды.

Калынаеп бара иде хатыны, калынаеп. Инде кайчандыр зифалыгы белән таң калдырган Нурисә димәссең. Яңа гына кия башлаган халатының да сәдәфләрен тышкы яккарак күчергәнгә охшый. Өстәл әзерләп йөргәндә алъяпкычын да элеккечә билләрен өзәрлек итеп бәйләмәгәндәй күренде.

Нурисә, бөтен әйберләрне җыеп, төреп култык астына кыстыргач, Мәгънәвигә карап:

– Әйдә! – диде дә мунчага чыгып китте. Ир, баудагы бозау шикелле теләр-теләмәс кенә, аның артыннан кузгалды.

Мунча юлында да, чоланга кергәч тә ләм-мим сөйләшмәделәр. Инде чишенеп, комган-фәләннәргә сулар тутыргач, миллекне таш өстенә парлатырга салырга маташканда, Нурисәнең:

– Артык кызулатма әле, зыяны булмасын, – дигәне ишетелде. Бу нинди сүз тагын, бүтән чакта, ай, мунчаның яхшысы, арканы каезлый торганы, дип шаярта, ә бүген... Борылып, хатынына караса, Мәгънәвинең исе-акылы китте: тыгызланып түгәрәкләнә башлаган эчен, эсседән саклагандай, ике учы белән каплаган.

– Әллә...

Көмәнең бар инде, Нурисә, дип әйтергә теләгән иде, Мәгънәвинең тавышы өзелде. Ул, тын юлларын мунча эссесе куыргандай, сулыш ала алмый торды.

Нурисә, елмайгандай итенеп, Мәгънәвинең иңнәреннән кочаклап алды.

– Әйе шул... – диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә. – Балабыз булырга тора.

Нурисәнең соңгы сүзләре артыграк та тоелды. Болай да аңлаган иде бит Мәгънәви! Аңлаган!

– Кичен әйтәм дигәнең шул идемени соң? – диде Мәгънәви бераздан, аңына килгәндәй. – Иртәрәк белдерергә ярамаган!

– Иртәнрәк үзем дә шикләнә идем әле. Баштарак, эш-эш дип көн арты көн уза торды. Аннан табибтан соң әйтермен дидем. Бүген... үзең дә сорасы итмәдең бит!

Шушы тормышка өмет уяткан сүзне тагын бер таңга кадәр генә сузса да, ишетә алмас иде бит Мәгънәви! Ир биек итеп эшләнгән ләүкәгә йодрыклары белән китереп сукты да шул йодрыклар өстенә башын куеп сулкылдап еларга кереште.

Нурисәнең:

– Чү, ни булды, Мәгънәви? – дип соравына да, иркәләп җилкә сыпыруларына да җавап кайтармады, елавыннан туктарга уйламады.

Бераздан, инде хатынны болай да күп борчыдым, монысы соңгысы булсын дигәндәй, күтәрелде, күзләренә яратып, туп-туры карап торды да мунча эссесеннән тир аккан кочагына алды.

– И-и, бер генә төнгә соңласаң да! – ди иде ул кат-кат, Нурисәгә таныш түгел нәрсәнедер исенә төшергәндәй. Аннан, ул буласын төп-төгәл белгән шикелле:

– Исемен Барый кушарбыз! – дип кистереп әйтте. – Барый «бар» дигән сүздәндер ул, хатын. Бар, ызначит, Мәгънәвинең дә малае бар, дигән кебегрәк була.

Гомере буе фермада гына эшләсәләр дә, өйдә китап-фәлән булмаса да, алар төне буе, исем аңлатучы атаклы галимнәр, һәрберсен дин күзлегеннән дөресләгән мулла-мунтагай кебек, өсле-катлы гарәпчә исемнәрне дә, үзебезнең татарчаларын да уйлап, мәгънә, ишетелеш ягыннан тикшереп чыктылар. Икәүләшеп әллә никадәр исемнәрне башларыннан әйләндерсәләр дә, берсе дә Барыйга җитмидер кебек тоелып, һаман шул исемгә тукталдылар. Ахырда Мәгънәви, бу мәсьәләгә бүтән кайтмыйбыз дигәндәй, күкрәк каккан тавыш беләнрәк:

– Мәгънәвинең дә малае бар, Барые бар, и баста! – дип түгәрәкләде.

Нурисәнең баласы, чыннан да, ир бала булып, хастаханәдән үк Барый исеме белән кайтты. Исем сайлап баш ватасы булмаганга, шул көнне үк аталары Габделсаттар карт әлеге исемне колагына азан әйтеп сабыйга да ирештерде.

Бик көтелгән, күңелдән китеп барган сөюне яңадан кайтаргандай булды бала. Мәгънәви бер-ике көн бик җилкенеп, юк эшләрен дә табып гел өй тирәсендә маташты, колхоз эшенә дә чыкмады. Ферманы ул хатыны декрет ялына киткәнче үк ташлады. Августта комбайнга утырырмын әле, дигән иде. Шулай итте дә. Инде урак өсте беткән. Бакчада да җыеласы җыелган. Мичеңне ягасың да, шуның җылысына арка терәп, итеккә табан салып, телевизор карап көн уздырасың.

Бала кайтуның уртак сөенече озакка барыр төсле иде, бөтенләй көтелмәгән юл алды. Бушап калган, янтайган утын әрдәнәләрен лапастан мунча тирәсенә күчереп маташканда, Ишәй белән Кушай кебек, классташ дуслары Мөнир белән Садрый килеп керде. Яшьтиләре белән бер утырырга, ирләрчә сөйләшеп, яшьлекләрен дә искә төшереп, бәби тәпиен дә чылатып утырырга икән исәпләре. Мәгънәвинең эшеннән бүленәсе килмәде, сәламнәрен алып, рәхмәт, егетләр, диде, инде җыелып өлгергән утыннарны яңа рәт башлап әрдәнәгә салырга кереште.

Дуслар бернәрсәгә дә аптырый торганнардан түгел иделәр. Мәгънәвинең бала тәпиен юарга атлыгып тормаганын аңласалар да, китү ягын карамадылар. Киресенчә, әйдәле бергәләп, диешеп, әрдәнәне ә дигәнче ташып та өлгерделәр. Аннан мунча чоланының күтәртмәсенә кереп утырдылар. Мәгънәвигә тезәсе, утын бушаган урыннарны тәртипкә китереп куясы гына калды.

Яшь бала булгач, йә салкын тидерерләр, йә нәрсә дип, Мәгънәви, эш беткәч тә, аларны йортка чакырып тормады. Шушында гына сөйләшеп утырыйк, булмаса, дип, яхшылап җылытылган мунча алдына чакырды. Монысы инде чын ир кешегә бер дә килешә торганнардан түгел иде. Дуслар шулайрак уйлады. Тиенен дә кызгана, чистый комсызланып беткән икән бу, майлы крич, комбайнда эшли башлагач, уч тутырып акча алгач, дип куйды эченнән генә Садрый.

– Ничек? Сөйләшеп? Без тагын бәби тәпиен юарга дип килдек. Үзең чакырмассың кебек тоелган иде аны, – диде Мөнир, кесәсеннән бер акбашны чыгара-чыгара. – Менә. Бездән булсын күчтәнәч.

Садрый да буш кул белән килмәгән икән. Киртә буена салып куйган фуфайкасы эченнән тозлы кыяр, пешеп бетмәгән, соңга калган помидор, ипи ише нәрсәләр алып керде. Койма башына elenгән эмаль кружкаларны да эләктереп кергән икән, тик аларын, баланыкы, дип, эти кеше кырыйга алып куйды.

Заманында салмады түгел, салды Мәгънәви. Артыграк та җибәргәли башлаганын аңлагач, тәмам ташлаган иде. Врачка барып та йөрмәде, үзенә хас булганча, өстәлгә сугып, башка эчү юк, и баста, диде дә бетерде. Егетләрнең килеп керүе әнә шул бер куйган ямьсез гадәтләрне тагын башлау дигән сүз иде.

Эченнән моңа каршы тору теләге талпынып-талпынып куйса да, ничә еллар көткән эти булу куанычын уртаклашырга килгән дусларына күңеле булгангамы, инде артка юлның юклыгын аңлагангамы, каршы төшә алмады, бер салганнан берни булмас дигән уйлар белән, әле кичә генә үзе станокта кырдырган өйалды шкафында торган кырлы стаканнарны алырга китте.

Чолан ишеген атлаганда ук, йөрәге жу итеп куйган иде Мәгънәвинең, артык борчылырлык нәрсә булмады булса кирәк. Сабые уянган һәм нәрсәгәдер кәефсезләнеп елый иде, ахрысы. Бераздан Нурисәнең аны тынычландырган тавышы ишетелде. Бала еламый тормый инде, диде ул, үзалдына, ашыйсы килгәндер, асты юешләнгәндер...

Аннан Мәгънәви, ялгыш бер эш эшләмимме дигән шик үзен һәр тавышка сак итә, тыелырга куша, ахрысы, дигән уйга килде, чыгып барган җиреннән тукталып, стаканнарны кире урынына куярга теләгән кыяфәттә дә торды, бераздан гына, ныклы бер фикергә килгәндәй, җелт-җелт атлап, мунчага таба юл тотты.

Кысылып торган бугазы аракы кайнарлыгыннан ачылып киткән кебек булгач, үз-үзенә биргән вәгъдәләре дә, бишектә сабый бала барлыгы да онытылды. Кесә төбендә әллә кайчаннан бирле калдык-постык акчалары шалтырап йөри иде, өйгә кереп әйтеп тә тормыйча, киемнең аруругын кияргә дә кирәк тапмыйча, тәпи юуны дәвам итәр өчен, өчәүләшеп кибеткә таба киттеләр.

Шул көнне дә, аның артындагысында да, тагын-тагын йә кызмача, йә үзен аңламас хәлдә кайтып егыла торганга әйләнде Мәгънәви. Яшь бала янында тавыш күтәрмәделәр, сөенече бик зур, бер туктар әле дип, өйдәгеләр аның бу кыланышларына кул селтәделәр. Ата кеше генә туктарга уйламый иде булса кирәк.

Көннәрдән бер көнне Нурисә, ирен туктаусыз тәпи юулардан эш белән арындырырга уйлап, авыл советына барып, баланы яздырып кайтырга кушты. Түләүләре дә бар иде, берочтан бухгалтериягә шуны да биреп чыгарсың, диде.

Туп-туры кәнсәләргә киткән иде Мәгънәви китүен. Их, шул кәнсәләре дигәненең юлына кибет салып куймасалар! Шуның ялт итеп себереп куйган койма турысына килеп җиткәч, бер алга, бер артка таба атлап торгандай итте ул. Ахырда түзмәде, тәрәзәсеннән Мөнир белән Садрыйның таныш йөзе дә күренгән кебек тоелгач, сәлам булса да биреп чыгыйм дигән сылтау табып, кибеткә кереп китте.

Чыннан да, егетләр килгән, баш төзәтергә акчалары калмаганга, аптырап, прилавка киртәсенә таянышканнар, бурычлары күп җыелганга, инде кайтып китегез, дип куалаган кибетче кызның йомшаганын көтәләр, булыр-булмас мәзәкләр сөйләп күңелен күрергә тырышалар иде.

Ишектән Мәгънәви күренгәч, йөзләре бөтенләй ачылып китте егетләрнең. Сине генә көтеп тора идек әле, диештеләр. Мөнир, баласы туган ирнең сүзен кире какмассың, дигән кебек, кызга күз дә кысып алды. Анысының гына йомшарга исәбе юк иде бугай.

– Инде син – әти булган кеше, бу ике дуадак каз белән нәрсә көн буе дуңгызланып йөрисең, туктарга вакыт, Мәгънәви абый! – дип кырт кисте. – Бала тәпиен юа-юа тишеп бетергәнсездер инде.

Ә юк, Мәгънәви теләсә нинди чәчбинең үзен өйрәтүенә түзеп тора торганнардан түгел иде. Борыныннан юеше кипмәгән, ни дигән була, диде ул, төкереген йота-йота.

– Акчасы юк моның дип батыраясыңмы, кызый? Китер ике кызылны!

Мәгълүмә яңадан каршы төшәргә уйлаган иде дә, Мәгънәви абыйсының ачулы сүзләрен ишетеп туктап калды. Аннары, миңа димәгәе кебегрәк бер кыяфәт чыгарып, ике «бомба»ны өстәлгә китереп утыртты. Ябыграк савытларда затлырак кызыллар да бар иде югыйсә. Кыз ирләрнең дәрәҗәсен махсус ассызыкларга, ярамаган тагын сезгә, дип әйтергә теләде булса кирәк. Соңгы көннәрдә үзен туйдырып бетергән өч карт ахмакка арты белән борылып, киштәдә тезелешеп утырган башка шешәләрнең тузаннарын сөртергә кереште.

Әйтерсең, безнең авылда аракы шешәсенә тузан кундыралар, дип уйлады Мәгънәви. Хатын-кызны акыллы диген инде, ә? Акыллы булса, көне-төне айный алмаган иренә Нурисә кып-кызыл унлыкны тоттырып чыгара идемени? Инде менә аның да өч сумыннан җилләр исте.

Кибет артындагы ачыклыкка язда ирләр карта уйнар өчен дип бер өстәл, алачык ише нәрсә әмәлләгәннәр, өсте ябык булса да, ишексез алачыкта ноябрь аенда инде туңдыра иде. Алай да беренче яртыны алар шунда гына саласы иттеләр. Садрыйның һич буш йөрми торган кесәсеннән ипи кисәкләре, кәнфит ише нәрсәләр чыккач, күңелләре тагын да күтәрелебрәк китте.

Графин кадәр шешәләр дә бушады, булыр-булмас сүзе дә күп сөйләшенде, кибет тирәсеннән генә һич тә китәселәре килми иде. Төш тә үтте, кәнсәләр кызларының яңадан эшкә барганнары күренде. Мәгънәвинең авыл советында малаена таныклык яздырырга барасы исенә төште. Өч дус көч-хәл белән өстерәлешеп, бер-берсенә тотынышып, инде шунда таба киттеләр.

Дания апалары төшке аштан килгән, язу-сызу белән маташа иде. Болары нишләп йөри тагын дигән кыяфәт чыгарып, күзлек астыннан гына күтәрелеп карады да яңадан эшенә кереште.

– Ни хәлләрең бар, Дания апа? – диде Мәгънәви, ул утырган өстәлнең башына ныклабрак тотынырга тырышып. – Малай туды бит минем.

– Ну, шуннан? Син эчеп йөрсен өчен туган мәллә?

Секретарь хатынның төртмә сүзе Мәгънәвигә ошамаса да, җавап сүзен тиз генә таба алмады, авыз эченнән генә нидер мыгырдап алды.

– Ю-у-ук, без эчкече түгел! – диде Мөнир, дустына ярдәмгә килеп һәм имән бармагын мөһим сүз әйткәндәй күккә күтәреп. – Дусның баласы туды, ә ул безне хөрмәт итә!

– И баста! – дип өстәде Мәгънәви, йодрык сугып. Ул чак кына егылып китмәде, ярый әле суккан рәттән өстәлгә таянып калды.

– Кешенең ничә ел көткән баласы туган икән, безне эчкече дип мыскылларга ни хакың бар, Дания апа? – дип сүз кыстырды Садрый да иҗекли-иҗекли генә.

– Ну вәт, малайга бер катыргы кисәге язып бирсәнә! – диде Мәгънәви, йөрергә ымсынган сабый кебек һаман да болгана-болгана.

– Катыргы кирәк булгач, малаең үзе килер! – диде Дания апалары, болар белән юньләп сөйләшүнең мәгънәсе булмавын белгәнгә һәм, һич югы үзенең ачуын басар өчен.

– Малай минекеме? Минеке! Ызначит, катыргыга да мин килгән!
– И баста! – Ата кешенең мондый чакта әйтми калдырмый торган сүзен Садрый өстәп куйды.
– Айныгач килерсең! – диде Дания апалары, берсен дә ишетергә теләмәгәндәй һәм каядыр китәргә әзерләнгәндәй ишеккә бара башлады, әмма, чүт кенә Садрыйны екмый калгангамы йә барыбер чыгарып булмас боларны дигән уй беләнме, кире эш өстәле артына утырды.
Хатын-кыз башы белән монысы да акыл сатмаса! Мәгънәвинең бу хәл үтенә тиде.
– Минем моңа правам бар. Сәвит гражданины бит мин. Сез шуңа хезмәт итүче генә. Давай яз! – диде ул, кукраеп.
Исерек кеше белән сүз көрәштерүдән дә буш эш бар микән?! Хатын, үрелеп, шкафтан зур бер кенәгә алды.
– Үз теләгең – чабата! – диде аннары. – Әйт, язам: кайчан туды?
Мәгънәви эндәшмәде. Мөһим бер сүз көткәндәй, иптәшләре Дания апалары кебек үк аңа текәлгән иде.
– Кай-чан ту-ды? – дигән булды Садрый да, соңгы иҗекләргә аеруча басым ясап.
Тәгаен генә әйтүе бик кыен иде. Мәгънәви, ярдәм өмет итеп, аягында ныграк басып торган Мөниргә күтәрелеп карады.
– Кайчаннан бирле тәпи юабыз әле без? – дип сорады аннан бераз гына аеграк һәм тапкыррак та Мөнир үзе, шуның белән барысы да ачыкланыр бер кыяфәттә.
– Мин мунчага утын күчерешкәннән алып, – дип бик белдекле генә җавап бирде әти кеше.
– Ә кайчан утын күчерештек? – дип сорау алуын дәвам итте Мөнир.
– Әйе, кай-чан?! – Садрыйның да акыллы булып күренәсе килә иде.
– Менә анысын тәгаен генә белмим инде.
Иптәшенең сүзен җөпләп, Садрый баш какты:
– Анысын әйтүе кыенрак.
Берсе дә бала тәпиен кайчан юа башлаганнарын анык кына хәтеренә китермәде. Садрый күршеләренең шул тирәдә таналары беренче бозавын алып кайтканына кадәр хәтерли иде югыйсә. Мөнир әнә каршы ягында яшәгән Хәлимәнең ата казын авыл аркылы мотоциклда җилдереп узган яшьләр таптатканын да белә. Авылның аек чагында башка кереп калган бөтен яңалыклары истә кебек иде, әмма ләкин малайның кайчан туганлыгы гына – юк.
– Санга хәтер шулайрак инде минем, – дип куйды Мөнир, мәктәптә дусларыннан яхшырак укып та хәзер ярдәм итә алмавына читенсенгәнгә.
– Яшең киткәч кырыкка...– дип башлаган иде Садрый, сүзенең ахырына килеп чыга алмыйча, шул урында бетерде.
Малайның туган көнен белмәү, шул турыда баш вату егетләрне айнытыбрак җибәргәндәй булды.
– Әллә кибетче кызга кеше җибәртикме? Бурыч дәфтәренә язып бара бит инде ул аны, – дип киңәш итте Мөнир.
– Безнең бурычта өзеклек булганы юк! – диде, күкрәгенә йодрык сугып, Садрый.
– Шулаен шулай инде...
– Атна-ун көннән дә ким түгел, – дип куйды үз чиратында Мәгънәви. – Числасын исәпләп язып куй, Дания апа, и баста!
– Больницада яткан көнен исәпкә кертмисезмени? – дип сорады секретарь. Аның болай гына сүз куертып маташканы, егетләргә артык ышанмаганы күренеп тора иде.
– Ничек кирәк, шулай эшлисез инде, – диде Мөнир, белдекле генә кыяфәттә. – Менә мин утызынчы елның декабрендә туганмын, утыз икенең маенда гына яздырганнар. Аның каравы класста менә бу хәчтерүшләрдән ике яшькә олырак идем.
– Ике елга соңрак пенсиягә дә чыгарсың, – диде Дания апалары. – Алай дисәң, синең апаң да әнә, яшь егеткә кияүгә чыгарга кирәк чакта, яшен киметеп, инде пенсиягә җиткәндә, тиешеннән дә арттырыбрак яздырып куйды. Сезнең права, бик дөрес әйтәсез, үз кулыгызда.
– Синекендә дә инде, – диде хатын-кыз алдында юхаланырга яраткан Мөнир. – Әйдә, якынчарак бер-бер сан яз шунда. Үскәч төзәтер әле. Әнисенә башкача кирәк булса, күчтәнәч-мүчтәнәч белән бер сезнең янга килеп китәрләр. Хи-хи...
Болардан аңкыган әчкелтем-төчкелтем исләрдән тәмам гарык булган иде, Дания апаларының эшне тизрәк бетерәсе, егетләрне җибәрәсе килде:
– Анысын медпункттан сорап та белергә була инде аның...
Ярый әле фельдшер кыз да, акушерка да эштә, телефоннары да төзек икән. Чыбыкның бу башындагы ямьшәеп, искереп, буяулары кырылып беткән телефоннан шылтырата торгач, үзләренә үк эләктеләр, югыйсә медпункт мәктәп белән бер чыбыкка тоташтырылган иде.
Мәгънәвинең улы инде 10 октябрьдә үк туган икән.
– Карале, ул көнне без сине көтеп ни гомер олы юл буенда туңып утырган идек бит, – диде Садрый, бик мөһим бер нәрсәне исенә төшергәндәй. – Числасын барыбер онытканбыз!

– Ул көнне районда, апаларында гына йоклады ич ул, шуңа күрә истә дә калмаган, – дип кушылды Мөнир дә, башка бер акыллы уй теленә килмәгәннән генә.

Секретарь кызыл тышлы бәйрәмчә кенәгәгә Мөнирнең атын, атасының исемен, фамилиясен, адресларын, баланың туган елын теркәде. Хәрефләрне сырлый-сырлый гына язганга, бу эш егетләргә гайре озак, махсус озынайтылган бер гамәл кебек тоелды.

– Кызулыйсыңмы син анда, юкмы? – диде бераздан Садрый, китәрләренә өмете киселә башлагандай. – Болай кибетнең дә ябылуы бар...

Исемен генә язасы да эш бетә иде. Секретарь хатын сораулы карашын тагын ата кешегә текәде. Шулчак Мәгънәвинең башы тәмам буталган, малайның исеме дә онытылган булып чыкты. Иске пәлтәдән бозып ясалган драп кепкасын бер салды, бер киде, тәмам бөгәрләп бетерде, әмма улының исемен һич кенә дә исенә төшерә алмады.

– Кем тапты соң аны? – дип сорады Дания апалары, көтеп-көтеп тә бу өч мәхлуктан бер җавап ала алмагач.

– Соң, мин тапмый, кем тапсын? Баланың үзен хатын алып кайтты болай, – диде Мәгънәви бөтен җитдилеге белән. Аның шаярмаганы, һаман да исенә төшерергә тырышып азапланганы күренеп тора иде. Тик дуслар белән кибет тирәсендә күп йөрелеп, малайга бер тапкыр да эндәшкәне булмагач, исем дә колагына ныклап кермәгән иде, ахрысы.

Мәгънәви шактый айныган, тураеп диярлек баскан, әмма тотынмаса егылып китәр кебек, һаман да бер кулы белән өстәл почмагына ябышкан иде әле. Шул кыяфәттә күпме генә уйланып торса да, ул хәерсез исемне тәки исенә төшерә алмады.

– Мәгънәсен булса да хәтерлисеңдер бит? – диде андый чакта акыллы фикер күбрәк килә торган Мөнир.

– Әйе, әйе, мәгънәле булсын диешкән идек инде, менә минем исем кебегрәк.

– Исемгә исләре киткән! – диде Садрый, бу эшне бала-чагалыкка санап. – Әле астын юешләндереп яткан малайга кайсын кушсаң да килешә. Ул әле бер исемне дә белми.

– Ничек инде ярасын? – диде секретарь хатын. – Мулла кушкан исеме бардыр бит?

– Әлбәттә! Югары оч мулласы үзе төшеп кушты! – диде Мәгънәви, атасы Габделсаттар картның гына азан әйткәнлеген дә онытып.

– Түбән очта бу арада балалары да күп туды бит аның, – дип сүзгә кушылды ишектән килеп кергән аргы урам карчыгы. – Әле кыз кайтып сөйләп торган иде, Ингил, Нургил... тагын әллә нинди исемнәр кушып бетергәннәр.

– Габделсаттар абзый андый исемне куштырмас! – Буш сүздән тәмам туйган секретарь кыз аны кырт бүлде.

– Авылдагы бөтен таныш исемнәрне карап чыгыйк та, – дип тәкъдим кертте Мөнир тагын, – берәрсе туры килер шунда.

– Самат, Нигъмәт, Шакир...– дип тезеп китте Садрый, үзенә дә әйтер җай чыкканга сөенеп.

Бу исемнәрнең булмаячагы Мәгънәвигә көн кебек ачык иде. Аларының өйдәгеләр авызыннан чыкканнын һич хәтерләми.

– Исем ул китапка да сыеп бетмәгән. Телегезгә ни килсә, шуны сөйләшәсез инде! Сезнең урамда Фәтхи, Шәех исемнәрен дә кушканнар иде шикелле, – дип, тагын сүзгә кушылды аргы як карчыгы. – Әле Халисә дә сөйләнгән була. Җыен кыска исем хәзер, элек озынны кушалар иде дә, кыскартып бозып бетерәләр ие, болай гел мулла кушканча әйтәсең икән, исеме бозылмагач, авырту да йокмый ул балага, ди.

Карчык санаган исемнәрдән Мәгънәвигә Фәтхи генә танышрак сыман. Соңгы вакытта Фәтхи дә Фәтхи дип баш ватканын хәтерли анысы. Нурисәнең яшь чакта йөргән егете дә шундый исемле исемлесен... Хатыны авырга узганчы, көнчелеге кубып, сүзгә дә килеп маташтылар. Аның исемен миннән яшереп кушмагандыр инде, дип уйлады Мәгънәви, тәмам башы буталып. Андый исем белән үк атамыйлар да кебек атавын.

Хәер, өйгә кайтканың булмагач, төнен генә китереп ташлангач, ничек эндәшкәннәрен кайдан беләсең? Үзе дә менә, малай да малай, улым да улым гына ди ләбаса!

– Ну менә «ф» хәрефе бар иде шикелле, – диде ул, ныклырак бер фикергә килергә тырышып.

– Түбән очның Мәгънәвиләр башында тагын «ф» авазлы исем кушучылар булмадымы? – дип сорады Мөнир «күпбеләм» карчыктан.

– Балага кулай килде бит аның елы да, кайсын ишетеп бетерәсең?.. Алаен алай да, безнең очта туп тибәрлекләре дә калмаган инде югыйсә, бирмәсә бирми Ходай, җыен өйләнмәгән егет тә, кысыр кыз.

– Ярата белмиләрдер, белсәң, өйләнәсең дә, баласы да туа. И баста!

Мәгънәвинең теле шомара башлаганына хатыннар көлешеп алдылар. Сүз арты сүз китеп, ул ара исем эзләүләрен дә оныттылар, авылның башка хәлләренә күчтеләр. Мәгънәвинең генә кайгысы үзгә иде. Акча тотылган, бурыч түләнмәгән, инде малайга исем дә кушмыйча өеңә ничек кайтасың?!

– Алайса, Фәтхидер инде...– диде баш кашып кына җавап табылмасын аңлаган Мәгънәви.

Егетләр дә, кайту ягын каерганга, шулайрак шикелле ие, диешкән булдылар.

Мәгънәви, бер беткән баш беткән дип, Дания апасын сүзеннән бүлде дә яшел катыргы эченә Фәтхи Мәгънәвиевич Саттаров дигән исемне эре матур хәрефләр белән яздырып та куйды. Мөнир белән Садрый бу эшнең арты да юу белән тәмамланыр дип көткәннәр иде, алар дигәнчә барып чыкмады. Эченә ниндидер борчу төшә башлаган, сәбәбен үзе аңламаса да күз төбенә яшь бөялгән, көтмәгәндә әллә кайчан үлгән ике карт бабасы да исенә төшкән Мәгънәви әллә елый ук башлады: һәр сүзе сулык-сулык килеп чыга иде.

– Тиздән үзем бабай буласы бит, җегетләр! – диде ул дусларына, тегеләр «әйдә кибеткә» дигәнне көткәндә, әле күзен дә юньләп ачмаган малае турында уйлап. – Шулай икән, гомер үткәнне дә сизмисең. Берәүләр туа, үсә, без менә картаябыз.

– Инде малайлар безнең кебек дус булсын, – дигән булды Мөнир, өйләнү ике ятып бер төшенә кермәсә дә.

– Бергәләп тәпиен дә юсыннар, – дип сүзен ныгытты Садрый.

Бу Мәгънәвине тагын да айнытыбрак җибәргәндәй итте. Ничек инде аның малае, менә шушылай, хатыны кырыкка ярылырга җитеп чапканда, өйдә карт әти-әнисе көтеп утырганда, дуслары белән кибет артында йөрергә тиеш булсын?! Юк, Мәгънәвинең малае бөтенләй башка, әтисенең хатасын кабатламый торган, иң акыллы, иң булган егет булырга тиеш. Райком секретаре ук чыкмаса да, һич югы, аннан колхоз рәисе ясаячак иде Мәгънәви! Ызначит, инде болай кеше көлдереп йөрү килешмим, гаилә турында да уйларга кирәк, дип фикер йөртте ул эченнән. Аннан, юньләп саубуллашып та тормастан, мөмкин кадәр турырак басарга, тизрәк атларга тырышып, өйләренә кайтып китте.

Мәгънәвинең моннан ары юньле ир, ул, әти хисабына керергә теләгәнен кычкырып әйтмәсә дә, салмыш башлы Мөнир дә төшенде, «соңгы дусны югалтабыз» дигән караш белән, үзеннән арткарак калган, бернәрсәгә артык исе китмәүчән Садрыйга борылып, салмыш башын селкеп-селкеп алды.

Мәгънәви аякта торырлык хәлгә килеп кайтып керсә дә, бишек өстенә иелеп, баласының өстен ябып маташкан Нурисә аңа күтәрелеп тә карамады. Ерактан ук бөркелгән әчкелтем-төчкелтем исләр аның күңелен болгатты, ачуын китерде. Күңелендә үпкә соңгы атнада болай да җитәрлек җыелган иде. Инде тагын...

Нурисә кулындагы метрикәгә дә, Мәгънәвинең үзенә дә исе китмәгән бер кыяфәттә кич буе бала белән маташты, чүпрәк-чапрак үтүкләде, бәбие йоклаган арада урынын җәйде, өстәл тирәсен җыештырды. Инде ул, сорамыйча да, түләүләрнең түләнмәгәнлеген, иренең көн буе кемнәр белән йөргәнлеген белде. Эшләрен бетергәч, берни эндәшмичә, бала бишегә асылган почмактагы тар караватка барып ятты. Мәгънәви, хатынының үпкәсе хәттин ашканлыгын күрсәтергә тырышканлыгын белсә дә, кара, төнлә бала елаганда, аннан кул сузып кына тирбәтәсе дип, үз-үзен алдады.

Мәгънәви малае барлыгын пичәт белән ныгыткан катыргыны түр почмакта утырган буфетның документ ише нәрсәләр сакланган тартмасына салды. Салды да онытты.

Икенче көнне Садрый белән Мөнир чакырып ишек шакыганга, ул өйдә юк, таңнан районга китте, дип әйтергә анасын гына чыгарды. Бишектә яткан балага әле бабасы, әле әбисе, яратып, «Барыем» дип эндәшкәндә, күңелендә ниндидер шом кузгалган кебек иде. Ул аның тәгаен генә нәрсәгә икәнлеген аңламады.

Алдагы көн хәлләрен хәтереннән барларга тырышып, бик озак кече як өстәле янындагы сәкедә уйланып ятты, ачык кына исенә төшмәде. Баланы яздырырга дип авыл советына чыгып киткәне, кибеткә кергәне истә. Соңрак авыл советына бардылар да кем беләндер нәрсәгәдер бик озак бәхәсләштеләр дә шикелле. Дусларыннан кайчан аерылып киткәнлеген дә ныклап хәтерли алмады шул...

Нурисә ишегалдына чыгып киткәч, кичә минем белән бер-бер хәл булмагандыр, дип соравына каршы әнкәсе:

– Үз аягың белән кайтып кердең, хәйләләп утырма, кайдан эзләп, кайсы акчага эчәсенә башыгыз эшли, эчкәч кайда булганыгыз гына онытыладыр инде, икегез ике караватка яттыгыз да йокладыгыз, – дип кырпурак җавап биргәч, җитмәсә, әтисе:

– Нәрсә булсын синең кебек шайтан таягына, аны кырау аламыни, ярый әле малаеңны яздырып кайткансың, инде әти икәнлегеңне тәмам ук онытып бетермәгәнсең! – дип өстәгәч, бу турыда яңадан сүз куертмады.

Барып буфет тартмасын карады: анда, чыннан да, иң өстә Мәгънәви алып кайткан метрикә ята иде. Тынычланды.

Авыл җирендә «мин фәлән кеше» дип чыгарып күрсәтер өчен, беркем дә кесәсендә документ йөртми, аның болай да Төлке Нәгыймәсе икәнен дә, Кукыр Миңнәхмәте булуын да беләләр. Барыйның кемлеге башлангыч сыйныфларны укытырга килгән яшь кыз, беренче класска исемлек җыям, дип, метрикә кәгазен сорап кергәч ачыкланды.

Директор, ул елны балалар күп туды, барысын да беренчегә алып бетереп булмас, бер класс кына җыярбыз да, калганы алдагы елга калыр, туган елларын, исем-фамилияләрен төгәл язып кил әле, дип,

яңа гына укытучы булып билгеләнгән яшь кызны өй борынча йөрергә чыгарып җибәргән иде. Ишектән килеп керүенә үк, аны-моны һаман да белештермәгән Нурисә түр башында кукраеп утырган агач буфеттан йомшак яшел тышлы кәгазьне алып кулына тоттырды.

– Олаеп кына тапкан идем, сеңлем, инде Барый да укырга керер яшькә җитте, – дигән булды ул, сагышлы елмаеп.

Кызның, ишек катындагы өстәл кырына утырып, метрикә белән танышып, исем-фамилияләрне хәрефкә-хәреф күчергән чагы иде.

– Апа, сез әллә башка балагызның таныклыгын алып бирдегезме? – диде ул сәерсенебрәк.

– Безнең шул бер Барый гына булып калды инде...– Нурисә сүзләрнең ятышлырагын эзләгәндәй туктап торды. – Әтисе башта бик теләгән иде кебек тә... Язмагач язмый икән...

Ул арада ишектән Барыйның такыр башы күренде.

– Бу синең апаң була! – диде әни кеше, малайны алъяпкыч эченә сыендырып кочаклап. – Аның сүзен бик яхшы тыңларсың, яме, улым!

– Ялал, – диде Барый.

– Исемең ничек синең, үскәнем? – дип сорады яшь кыз, аптырашта калуын яшерергә тырышып.

– Ул безнең Барый Мәгънәвиевич Саттаров була! – Әни кешенең баласы белән мактанасы, атасы исемен, фамилиясен оныткан булса, исенә төшереп җибәрәсе килгәне әллә каян күренеп тора иде. – Шулай бит, улым?!

– Мин Балый Мәгънәвиевич Сатталов! – диде бала авыз эченә тыгылган бармаклары арасыннан гына.

– Сакауланабыз әле бераз. Бөтен ышаныч сездә инде! – Әни кеше өмет тулы күзләрен укытучы кызга текәде.

Земфира апасы Барый белән башка сөйләшеп тормады, таныклыкның кайдан алынганлыгын, кайчан алынганлыгын язганнан соң, күңеленә төрле шикләр килеп, иртәгә барысын да кайтарабыз дигән булып, катыргыны үзе белән алып, өйдән чыгып китте.

– Таныклыкны биреп җибәрәсе булгач, ни хаҗәтемә язып утырган була инде? – диде Нурисә, Барый белән икәүдән-икәү чәй чәйләгәндә, малайны тиң санаганын, инде олыларча сүз сөйләшеп булганын күрсәтергә теләгәндәй. – Ныклабрак танышасы, менә сине дә күрәсе килгәндер. Без чәйгә дә чакырмадык тагын.

Икенче көнне, күршедә генә яшәсә дә, директор Нурисә белән Мәгънәви артыннан, бергәләп мәктәпкә килергә кушып, бер малай йөгертте. Сәеррәк иде сәерлеген, әмма, беренче балалары укыр яшькә җиткән һәр ата-ана аны әзерләү эшенә бик җитди караган кебек, ир белән хатын моны бер мәртәбә санап, ничәмә ел иңгә-иң урам буйлап узганнары булмаса да, терәлешеп диярлек мәктәпкә киттеләр. Юл буе Барыйга нәрсәләр алырга кирәклеге, кием-салым, ручка, китап-дәфтәр ише нәрсәләр турында сөйләштеләр, башларына килмәгәнен укытучысыннан сорарга уйладылар.

Земфира, күрер күзгә дә чибәр генә тоелгач, бик итагатьле дә сөйләшкәч, Нурисәгә ошап калган иде.

– Яшь булса да, юньле нәстәгә тарта, – диде ул Мәгънәвигә, баланың кем укытканлыгы бик мөһим булуга басым ясап.

– Алла боерса, Барыйдан кеше ясар! – диде Мәгънәви дә, әле җиде яшьлек кеше дигәненең нинди икәнлеген бик үк ачык күз алдына китермәсә дә.

– И-и, карчык, картаймыш көнебездә бер юаныч буласы бит ул! – диде аннары, үтә дә сөенеп. – Районнан чаңгының да үз буена ярардаен алып кайтырга кирәк булыр. Инде язга чыккач, Барыйга билсәпид тә юнәтербез. Йөрмәсен кешенекенә кызыгып! Әнисе бар, әтисе эшләп тора, әле әби-бабасына да пенсия килә башлады. Тормышлар алга таба гел юньлегә китәсе...

Хыял дигәннәре ничек кабарса, шулай тиз җимерелеп тә төште.

Директор үз бүлмәсендә авыр, драп белән тышланган эш өстәле артында, як-яклары бөрмәле ак ситсы белән тарттырылган кәнәфиендә журнал актарып утыра иде.

– Әйдүк, әйдүк, түрдән узыгыз, – диде ул, күршеләрен күргәч күтәрелә төшеп. – Өегезгә генә керсәм дә була иде инде, мондый мөһим эш чыккач, мәктәпкә чакырттым.

Директорның әйткәне икесенең йөрәгенә дә шом салды, әмма ата-ана дәшмәде, аның сүз башлаганын көтте.

– Дания апага да шылтыратып белештем инде, ул да аптырабрак калды. Сез метрикә кәгазен башка исемгә алган идегезмени соң?

– Ничек? Нинди исем? Ни сөйлисез соң Сез? Барый таныклыгы турындамы? Башка бер кәгазь хакында соравыгызмы?...– дип тезеп китте Нурисә.

Мәгънәви телен йоткан кебек калган иде.

– Укытучы кыз таныклык тотып кайтып кергәч, бер шаккаттым, Дания апа белән сөйләшкәч тә, һични аңлашылмады, хәзер инде сез бөтенләй аптырашта калдырдыгыз. Барыбызның башын катырып

кына утырганчы, булмаса, туп-турыдан сорыйм: Барый – малаегызның үз исеме түгелмени? – диде директор.

Нурисә тыныч сулап куйды. Көлемсерәп:

– Тәпи йөри башлаганнан бирле аяк арaңда буталган малай турында кеше көлдереп шулай сөйләп утырма инде, Вакыйф, – диде. Аннан, үпкәлерәк тавыш белән, иренен бөрештеребрәк дәвам итте: – Булыр-булмас сүз чыкса, шул укытучы халкыннан чыгар. Җәйнең тыгыз эш көнендә юк нәрсә белән мәктәпкә чакыртмасаң!

– Мин монда нишләргә белми утырам. Сезгә балагызны бер исем белән атап, таныклыгында икенче исем тору да буш нәрсә кебек кенә күренә икән! Алайса, нәрсә сөйләшеп торырга? Таныклыкта нинди исем булса, журналга шуны язарбыз да куярбыз!

Директор журналны ачу белән япты да ачык шкафка тотып ыргытты. Гомер буе терәлеп яшәп бер сүзгә килмәгән күршеләр бер-берсен аңлый алмас хәлгә җиткәннәр иде. Директорның соңгы сүзеннән Нурисә миңгерәүләнеп үк китте, әмма үзен тиз кулга алды. «Инде ни диярсең» кебегрәк сораулы караш белән туп-туры баланы яздырып кайткан Мәгънәвигә карады. Ул нәрсәнедер искә төшерергә тырышкан бер кыяфәттә утыра бирде. Әти кеше авыл советында булганын күпмедер хәтерләсә дә, балага нинди исем яздырганын тәгаен генә белми иде, күрәсең.

– Дания апа үзе ни ди соң? – Мәгънәвинең бу соравы артык, мәгънәсез иде, тик ул шуннан да юньлерәген таба алмады.

– Ай саен туган балаларның исемен кайдан хәтерләп бетерсен Дания апагыз. Сез монда бер балагызның чын исемен белмисез, ә ул моннан алты ел элек булган һәр көнен, һәр иserекнең әйткәнен истә тотарга тиеш!

Директор кызганнан-кыза барды, аның соңгы сүзе Мәгънәвине дә, Нурисәне дә бугазыннан алган кебек итте. Икесенең дә күңеленә әлеге көннәр, ирнең көн-төн эчкәннәре, авыл советыннан да исерек кайтып керүе килде. Дания апалары да шуны исендә калдырган, әйткән булса кирәк, әллә күршедә генә торган директор үз белдеге белән генә төрттерә микән?

Нурисә, ярты җаны гына калган бер мәлдә, үлем алдыннан исән калырга соңгы омтылыш ясаган җан иясе кебек чәрелдәп җибәрде:

– Нинди исем яздырдың син, Мәгънәви?

Нәрсә дип җавап бирәсең?! Мәгънәви ни яздырганын үзе дә хәтерләми ләбаса! Директор бераз йомшап киткәндәй булды. Бүлмә почмагындагы сейфтан, яшел кәгазь кисәген алып, Мәгънәвигә тоттырды.

Анда зур тигез хәрефләр белән «Фәтхи Мәгънәвиевич Саттаров» дип куелган иде. Ирнең күз алдыннан бала туасы көннәр, яшьлектәге егете аркасында Нурисә белән ике арада чыккан гаугалар, бала тугач шатланып тәпи юып йөргән дуслар сызылып үтте. Шул шатлыкның эзе дә калмаган кебек тоелды. Көндәшеңнең исеме белән атап йөрт балаңны менә хәзер! Мәгънәви шулай дип уйлады, әмма мөмкин кадәр салкынрак калырга тырышып:

– Алмаштырасы булыр инде, – дип куйды. – Малай Барый исеменә ияләнгән бит.

Нурисә Мәгънәви кулындагы таныклыкка күз ташлады һәм аңсызланып урындыгыннан идәнгә авып төште. Бу исем хәсрәтен бераз читкә куйдыртты. Хатынны, күтәреп алып, директорның йомшак кәнәфиенә утырттылар, битенә су бөркеделәр, суккалап, йолыккалап, аңына китергәндәй иттеләр дә фельдшер кызны чакырттылар.

Нурисә мәктәптән директорның иске «Волга»сында кайтты. Үз аягында киткән киленнең агарып, култыкланган хәлдә өйгә кайтуыннан картлар да югалып калдылар.

Көтелмәгән хәлләр бөтен гаиләне аяктан екты. Икенче көнне үк Мәгънәви авыл советына йөгерде. Дания апасы аның нигә килгәнен аңлаган иде инде.

– Малаең хәзер исемне үзе генә, паспорт алгач кына алмаштыра ала, – диде ул, кулларын җәеп, берни дә эшләп булмый дигән кыяфәт күрсәтеп.

Мәгънәви монысын ук көтмәгән иде. Үз гомерендә икенче тапкыр хатын-кыз каршында сулкылдап елап җибәрде. Гадәтенчә, баста, дип өстәл дә сукмады, башындагы кепкасын учына бөтәрләп йөзенә каплады. Елатып туган бала иде шул, диде ул эченнән генә сыкрап, һаман елата икән...

Көннәр үтеп, бераз хәл алгач, авыл советы секретаре, директор белән киңәштеләр дә малайны, гадәттәгечә, Барый дип йөртергә, ә кәгазьдә Фәтхи дип калдырырга хәл иттеләр. Бераздан, үсә төшкәч, үзе карар тагын, хәзергә инде аның да нервларын какшатмыйк, диештеләр.

Моңарчы малаена җанын бирергә әзер Мәгънәви шул көннән алмаштырган кебек булды. Ничек итеп үз улына көндәшенекен куюуын ул аңлый да, моның өчен үзен гафу да итә алмый иде. Шайтан коткысы, җеннәр шаяруы дип әйтми нәрсә дисең инде моны, дип уйлады ул. Озак вакыт балага узмаганнан соң, Нурисәнең малай алып кайтуы да, инде яңадан таба алмавы да аны моңарчы башына да кереп карамаган шикләргә батырды. Әнә шундый корт кебек уйлар аны эченнән ашады, Барыйдан читләштерде.

Хәер, аның өчен инде Барый да, Фәтхи дә юк, буе билгә җитеп килгән ташбаш кына бар иде. Мәгънәви иң элек аңа исем белән эндәшүдән туктады, баштарак «улым» кебегрәк сүзләрне әйтергә тырышса, соңыннан күбесенчә «әй, син» дип чакыру белән канәгатьләнде. Моңа кадәр мондый корылыкны күрмәгән малай әкренләп үзе дә этисеннән ерагайды, әнисе тирәсендәрәк йөри, авырсанитсә, аңа елыша, соравы булса да, аңа килә торганга әйләнде.

Мәгънәви үзен эчтән кимергән уйларны хатынына чыгарып салырга ашыкмады. Ул үз агымына аккан тормышка күнеккән, гадәти тынычлыкны бозарга теләми иде. Ир уртасыннан узып киткәннән соң чыгарган тавышыңның ахыры турында да уйларга кирәк. Фәтхинең дә әнә хатыны кинәттән вафат, Нурисәң туп-туры шуның кочагына барып керсә?! Тавышлану дигәннән, төп гаеп Мәгънәвинең үзендә булганда, ничек әле артыгын батыраясың?! Атна буена эчеп йөрмәсә, бу хәлләр килеп чыгар идемени соң?! Ир башың белән улыңа хатыныңның сөяркәсе исемен так инде... Әллә соң малай, чыннан да, үзенеке булмады микән?

Нурисә Мәгънәвидәге үзгәрешләрне сизде, сәбәбен генә ачык белә алмады. Малай алдында үзен гаепле сизәдер, кәгазьдәге исемен белгәч, Барый дип эндәшә алмыйдыр, дип уйлады. Гомеренә бер мәртәбә иреннән яшереп очрашканы булмаган Фәтхи турында Мәгънәви исенә төшерсә, ул, бәлкем, кычкырып көләр генә иде. Ә болай... иренең нәкъ менә аның исемен кушарга ничек башына килгәнлегенә аннан битәр аптыраган иде.

Нурисә, әни булгач, көндәлек мәшәкатьләргә батты, Мәгънәвинең күңелсезләнеп йөрүенә артык игътибар бирмәскә тырышты. Ул арада малай үсте, җитәкләп мәктәпкә йөртер, дәрес әзерләтер яшьтән чыкты, инде үзе дә кул астына керә башлады.

Әти-әниләре дә җир куенына яткач, шушы ике җаннан да кадерле кешеләре юклыгын аңлаган Мәгънәвинең күңеле басылды. Аллаһ боерса, өйләнер дә, беренче малаена ук Барый исемен куярбыз, ә нишләп куймаска, урыста әнә ике кешенең берсе Иван Иванович, дип уйлады ул, исем бабадан – атага, атадан балага кала бирә.

Малай, башлангычта укыганда ук, иптәшләре Барый дип эндәшсәләр дә, журналда Фәтхи дип язылганлыгын белгән иде. Тора-бара, җае туры килгәндә, иптәшләре ике исемлелегенә төрттергәли үк башладылар. Күп белсә, башы ике бит аның, дип көлделәр. Белмәсә, икенче башыңнан сора, дип үртиләр иде.

Берәүләр – юри булса, икенчеләре буташып икенче исеме белән әйтештергәли башлагач, инде кайсы исеме аның чын икәнендә ул үзе дә буталды. Юк кына нәрсәдән китеп, Илфар исемле сыйныфташы белән ныклап торып эләгешкәч, тегесе, үч алу нияте белән:

– Юньле булсаң, исемең бер генә булыр иде синең, ике башлы аждаһа, ди сине минем әби дә, – дип ычкындырды.

Малайның ачуы бугазына менде. Кулга каты Барый Илфарга үзе дә сизмәстән китереп үк орды, аннан, алдына-артына карамый, өенә кайтып китте. Кече якта казан тирәсендә кайнашкан әнисен күрәкүрешкә:

– Бер исем җитмәгән идеме? – дип кычкырды. – Ике башлы аждаһа тапканнар диярсең!

Нурисә бу дорфалыкка усаллык белән җавап бирмәскә, мөмкин кадәр тынычрак калырга тырышты, үткәндәгеләрне искә төшереп, үзен дә, Барыйны да тагын да ярсытасы килмичә, хәлне бөтенләй башкача аңлатты:

– Бала чагыңда «р»ны әйтә алмаганыңа аптырап куйган идек без Фәтхине, өйрәнсәң, кире алмаштырырбыз, дидек, өйрәнә дә алмадың, Барый исеменә дә күнектең. Хата булгандыр инде болай эшләү...

Барый мондый сүзләрнең бер алдау гына икәнлегенә төшенде, әлбәттә, чөнки таныклыкның тугач та бирелгәнлеген генә аңларлык яшьтә иде инде, ә бишектәге баланың «р»ны әйтә аламы, юкмылыгын шайтаным белсенмени?! Тапкан әнисе дә хәйләле җавап! Ыштансыз сабый белән сөйләшә диярсең!

Әнисенең чынын әйтергә теләмәвен күргәч, Барый кабат сорап тормады, үз бүлмәсенә кереп бикләнде дә бик озак чыкмыйча ятты, әмма ишектән күренгәндә, аның тынычланганы, ул турыда онытырга тырышканлыгы ачык иде.

Барый күңелендәге тынлык бик кыска вакытка булган икән. Тора-бара исем хакында уйлап, үзен җәзалау аның канына сеңде. Һәр яңа танышына исемен әйткән саен, кәгазьдәге Фәтхине исенә төшерде. Җитмәсә, сакаулыгына төрттереп, башкалар да Балый абый, Бал абый дип йөртә башлаганнар иде. Инде унынчыны тәмамлап паспорт алырга кирәк булгач, чын-чынлап уйга калды. Әнә шул Барый исеменнән котылу аны, һич югы, үртәүләреннән коткарачак кебек тоелды. Әнисе белән киңәшләште дә, мулла кушкан исем кешегә чир китерми, дип, аның кирегә үгетләвенә дә карамастан, таныклыгын Барыйга алмаштырасы урынга, инде паспортына да Фәтхи дип яздыртты һәм өйдәгеләргә хәзер үзен бары тик шулай дип кенә йөртергә кушты. Бер исемлегә әйләнүнең моннан да кулай юлы юк иде аныңча. Авылдан чыгып киткәч, Барый дигәне инде тәмам ук онытылачак.

Әле кайчан гына, Барый «бар» дигән сүздән, дип мактанган ата шулай итеп Барыйсыз калды. Ул аның өчен улын чын-чынлап югалту белән бер иде. Ашамады, эчмәде, чирләп, урынга ук егылды.

Төннәр буе таныш түгел исемле әллә кемнәр белән саташып чыкты, төшләрнең начардан начарын гына күрде. Инде терелеп урыннан торгач та, йөрәгә тынгы тапмады. Мәгънәвине иң кимергәне шул булды: үз улыңа, хатыныңның сөяркәсе дип санап, кайчандыр буарга әзер торган кешенең исеме белән дәш инде син!

Фәтхи Фәтхилеген итте: авылда яшәргә калмады. Армиядән ул яңа исеменә ияләнеп, тышкы кыяфәткә үзгәреп, ир-ат холкын сеңдереп кайтты. Өйдәгеләрнең алдан әзерләп куйган сыйлары белән туйганчы сыйлангач, икенче көнне дус-ишләрен, туган-тумачаларны бер кат йөреп чыкты да, әти-әнисенең фатихасын алып, комсомол юлламасы белән яңа башланган төзелешләрнең берсенә – БАМга юл тотты. Аны чемодан-сумкаларын күтәрешеп автобус тукталышына кадәр чыгарышкан ата чын югалтуның әле яңа гына булганлыгын аңлады. Кайтты да өченче тапкыр елады. Өстәл дә сукмады, баста дип тә кычкырмады, хатынының итләре йомшаган беләкләренә башын салды да әкрен генә яшь агызды. Әлеге яшь башта – өстәлгә, аннан каерылып торган клеенка итәкләреннән пелт тә пелт идәнгә тамды. Тамчылап аккан яшь тавышы олыгаю ягына таба барган ир белән хатынның үткән гомеренә күп нокталар куеп калдыргандай булды.

**2**

БАМ якын ара түгел иде, Фәтхи ел саен кайта да алмады, шулай да акчасын, күчтәнәч посылкаларын ай саен булмаса да, өч айга бер җибәреп торды. Аның турында әтисенә шул яклардан кунакка кайткан дусларыннан да гел яхшы сүзләр генә ирешә, ул эшләгән трест хуҗаларыннан бәйрәм саен, яхшы комсомолец үстергәнсез, дип котлау хатлары килде. Инде Нурисә белән Мәгънәви олыгаеп баралар, пенсиягә дә чыкканнар, кичләрен шул хатларны укып юаналар, бер-берсенә, Мәгънәвием, Нурисәм, дип кенә эндәшәләр иде. Әле кайчан гына барган исем шау-шулары да гомер ахырының татлы мизгелләре артында тоныкланып калды. Мәгънәви үзен яңадан карчыгына якынаеп киткәндәй тойды.

Шушы тынычлыкны, шушы рәхәтлекне Фәтхидән килеп төшкән телеграмма бозды. «Өйләнәм, туйга килегез, юл расходы бездән. Наталья белән Фәтхи», диелгән иде анда.

– Ичмасам, хат кына язып салсачы! Адәм рисвае итеп марҗага өйләнүе җитмәгән! Бармыйм! И баста! – диде Мәгънәви. – Безнең малай да Наташалар белән маташа булып чыктымыни инде? Искә исем киткән дигәч тә, ата марҗа алмаса! Инде анысын, керәшеннәр кебек, Натук дип йөртербез, кунакка кайтканнарында кәлә-вәлә килеп сөйләшербез микәнни?

Мондый чакта әни кешегә кискен генә бер карарга килү кыен иде. Көн уйлады, төн уйлады да Мәгънәви фикеренә кушылды: Фәтхинең туена барып тормаска булды. Бала – ананың бәгырь кисәгеннән. Ризасызлык белдереп, улын әтисе каршысында орышкалаган булса да, эченнән ул аны аңларга, яраткандыр, нишләсен дип акларга тырыша, шуңа күрә картыннан качып кына алъяпкыч почмагына гына елаштыргалады.

– Әле ярый шушы хәсрәтне әткәй күрмәде, – дип тынычланган була иде Мәгънәви. – Ашларда, үз динегездән, үз каныгыздан өйләнегез, кыз алыгыз, дип вәгазь укып йөргән картка ояты ни тора! Телеграмма хәбәре дә әнә минуты-сәгате белән таралган.

Дөресен генә әйткәндә, татар авылында, намаз-ниязлы йортта үскән Фәтхи атасының туйга килүенә түгел, ризалык биреренә дә өметләнмәде. Инде ул үзен, әти-әнисе белән бәйләнеше бар дип санаса да, туган нигезеннән киселгәнгә исәпли иде. Марҗа белән яшәсәң, кеше арасына керергә дә җиңелрәк, рәхәтләнеп урысчасын да сөйләшә башлыйсың, тора-бара әти-әни дә моның шулай икәненә ышаныр, әле тупылдап торган малай белән кайтып та керсәң, марҗа киленнең бер алдына, бер артына төшәрләр дип уйлады.

Килен каенана туфрагыннан ярала икән, дигәннәре һәрвакыт хак түгелдер. Холыкка кайнар, эшкә иренчәк, сүзгә оста иде Наташа. Малай табуны да ун ел көтмәде, туйлар узып биш-алты ай да үтмәде, Саттаровлар кебек бер почык борынны бәби бишегенә китереп тә салды.

– Эшләнәсе эш бетте, исем генә кушасы калды, – дигән булды Фәтхи.

– Анысын инде менә сиңа тапшырырбыз, име, улым, – дип елмайды Наташа бәллүдә күз кысыкларыннан алмалары нинди икәнлеге дә күренмәгән, төргәкләр эченнән кып-кызыл ит кисәге кебек чыгып торган башка.

Малай олы йомышка әзерләнә иде булса кирәк, нindидер эһелдәгән аваз чыгарып куйды. Шуны гына көтеп торган кебек, Фәтхинең күзләре маңгаена менде:

– Әллә аңлый да инде, әнисе?

– Аңламаска, кем малае соң без?! – дип юхаланган булды марҗа хатын. – Әйе бит, Иван Фатхиевич?

Әти кешенең башына күсәк белән китереп томыру иде бу. Туктале, әле генә «исем кушу – синнән» дип маташкан хатыны аны инде үзе генә сайлап та куйган, анда да чын урысныкын тапкан була түгелме соң? Фәтхи, сабырлыгын мөмкин кадәр сакларга тырышып, хатынына дәште:

– Монысы ни дигән сүз?

– Безнең нәселдә гел шулай килә, кадерлем: беренче ир баланы бары тик Иван исеме белән атыйлар. Ул йоланы бер без генә боза алмабыз.

– Безнең нәсел йолаларын да белешер идең... Фәтхидән Иван туамыни?!

– Соң мин, үзең берни дә тәкъдим итмәгәч кенә... Фәтхи исеме янәшәсендә килешми дисәң, Федор дип үзгәртергә дә була ич инде аны, бер проблема да калмый! – диде хатын, сүзнең асылына һаман да төшенеп бетмичәрәк.

– Минем сине, миннән алган фамилияңә туры китереп, Нуршидә дип атаганым юк ләбаса!

– И-и, кайсы урысның татарга әйләнгәнен күргәнең бар, ә менә киресенчәсеннән буа буарлык!

– Бөтен ир дә, минем кебек, өйләнәсе урынга кияүгә чыкканга, үз илендә яшисе урынга коллыкны сайлаганга ул! – диде тыны буыла башлаган яшь эти.

Комсомол җыелышларында гел кызыл сүз сөйләп, агач коммунист аты алган Фәтхидән моны ук көтмәгән иде Наташа. Сагайды, бер-бер яманлык кылмасын, ташлап китмәсен тагын дип шып булды. Фәтхинең бераз басылганын көтте дә, елмаеп, иңеннән кочып алды:

– Татарча исем кушыйк, дип турыдан гына әйтсәңче! Исемгә ис китми лә минем! Әле таныклыкка бүген чыгып йөгергән кеше юк. Нинди исем кушарга теләсәң, барасың да шуны яздырасың. Үз малаең ич!

Фәтхинең бу сүзләрдән күңеле җебеде. Чыннан да, тумаган колынның билен сындыргандай кебегрәк булды. Иртәгә үк барыр да «Барый Фәтхиевич Саттаров» дигән таныклыкны алып кайтып ук тоттырыр Наташасына. Аннан артык тыпырчына алмый инде ул. Берочтан малай теләгән, Барый исемен яраткан этисенең дә күңелен күрер, Фәтхигә теле ятмады, ичмаса, онытгынныкы ул дигәнчә булыр.

Фәтхи бала тапкан ананы борчу ярамаганлыгын белә иде. Сөте качмасын, туйганчы имәрлек булсын, малай зур үссен, аннан – кеше, ә, юк, Наташа әйтмешли, бер татарчонокны үзем дә ясыйм мин, дип уйлады.

Икенче җәйдә алар, бөтен авылны шаккатырып, узгандагы хәлләрне тагын бер кат яңартып, әле яңа гына тәпи киткән малайны җитәкләп, Сөендеккә кайтып төштеләр. Бу вакытка Мәгънәви басылган, онытгынның Барый икәнен дә белгәч, бугазындагы йотылмас кебек ташны да йоткан иде. Балаларның кайтып җитәселәреннән хәбәрле ата түзмәде, автобус тукталышына китте, этисе кочагында ишектән чыкканда ук Барыйны әле бала күтәрерлек кенә хәле бар дип санаган кулларына тартып диярлек алды.

Наташа Мәгънәви өчен әллә бар, әллә юк иде. Ул һаман Фәтхи белән чөкердәште, Барыйны татарча сөйләшергә, әби, бабай дип әйтергә өйрәтеп маташты. Ахырдан, миннән булмады, инде үзегез өйрәтерсез, дип кул селтәде, әмма шунда ук, Фәтхигә карап:

– Матри, малай, туган телне онытасы да, оныттырасы да түгел! – дип өстәде. – Инде болай да авылда адәм рисвае ясадың...

Фәтхи ахыргача аңлап ук бетермәсә дә, төзәтелмәслек хата ясаганлыгын бу вакытка күпмедер төшенгән иде, этисе белән ризалашкандай баш селкеде, кушылып, сүзне куертмады, иллә мәгәр кире дә какмады, үзен акларга тырышып азапланмады.

Фәтхиләр ничек көтмәгәндәрәк кайтып керсәләр, шулай ук китеп тә бардылар кебек тоелды Мәгънәвигә, югыйсә инде көз якынлаша, Фәтхинең ике еллык ялы авылда узган иде. Нурисә исә туйганчы күреп тә кала алмадым, дип өзгәләнде.

– Урыс-урыс дигән булдык та, кешенең татар киленнәре бер кырыенда торсын! – ди торган булды, Наташа турында сүз чыкканда. – Артыгын эшләмәсә дә, әнә ничек елмаеп кына тора!

Мәгънәвине корырак санап, үпкәлисе килгәндә:

– Үткән-барганда да Фәтхине үпми калмый, «мой милый» да «мой дорогой» икән гел авызында. Малайны бәхет баскан! Үзе дә төшеп калганнардан түгел: Наташаны өрмәгән җиргә дә утыртмый. Йокларга ятканда аягын гына юмый инде! Яратмаса, шулкадәр кыланыр идемени?! Менә безнең утыз биш ел яшәгән карттан да андый назны күргән юк, – дип өстәп куярга да күп сорамый иде.

Анысы белән килешә Мәгънәви. Әллә ничек корырак булды шул хатынына. Дөнья көтеп, дөньядан нидер көтеп, Нурисә турында юньләп уйлаганы да булмаган. Юганын кигән, пешергәнен ашаган, рәхмәтен әйткән дә шул җитте дип санаган. Ә бит хатынның күңеле – бер яхшы сүздә. Күпертсәң, мендәр дә кабара! Яратсаң, хатын-кыз да матурая, бише белән кайтара. Ул моны соңлабрак, бабай булыр яшькә җиткәндә генә аңлады. Фәтхинең ул кадәр үк хатын дип өзелеп китүен өнәп бетермәсә дә, аның эше түгел. Наташаны ярата икән, яратсын соң, җаны теләгән елан итен дә ашаган!

Мәгънәвинең тормышы әнә яшәлгән еллар саны арткан саен гына мәгънәләнә бара. Фәтхи инде аның ялгышын кабатламас! Аның хаталары үзенеке булыр, әмма малаена бабасының почык борынын барыбер бүләк иткән ул!

Чыннан да, еллар сагыш-бәхет хисләрен бергә бутап үтә торды. Көннәр, төннәр бертөслерәккә әйләнделәр, бер кигән киемнәр өсләреннән озак төшмәде. Затлы күлмәк-пәлтә кайгысы онытылган, дөнья куу теләге сүнеп бара иде. Мәгънәви белән Нурисә Габделсаттар карт белән Мәймүнә

абыстайдан калган дин китапларын да ешрак караштыра башладылар. Барыйга исемне дә Мәгънәви беренче кайтканында ук азан әйтеп яңадан кушкан иде. Шушы малай аның күңелен әллә нишләп яктыртып җибәргән төсле булды. Татарчасына ук өйрәнмәсә дә, капкадан атылып керүгә үк, бабайка, дип, муенына асылына иде шул.

Тора-бара, үсә төшкәч, Барый ел саен җәйләрен авылга кайтырга атлыгып тормый башлады. Чакырып язган соңгы хатларына: «Анда мин нишлим? Барыбер татарча аңламыйм, шуңа күрә дус-ишләрем дә юк. Бабай инде минем белән уйнап, клубларга чыгып йөрмәс, намазын укып мич башында утырадыр», – дип җавап биргән иде.

Бу хат әллә нишләтте Мәгънәвине. Шаяртыбрак язылганга санаса да, асылда, чын сүзләр икәнлеген бик ачык төшенде ул. Зур шәһәрдә туган, кирпеч йортлар арасында уйнап үскән малайга чит, ямьсез иде аның чәчәкле тугайлы Сөендеклесе! Бигрәк тә ул күз төшергән кызлар кочтырырга-үптерергә ашкынып тормыйлар, урыс малае белән йөри күрмәсеннәр тагын дип кайгырган әти-әниләренең дә сүзләрен тоталар иде.

Бабалары хакына баштарак ел саен кайтса да, соңгысыннан бу ишегалдына бөтенләй аяк басмас кебек китеп барган иде Барый, шулай эшләде дә. Әтисенең ай-ваена да карамады, мең сәбәп табып, йорт саклауны да сылтау итеп, мул сулы Амур буенда гына җәй уздырырга калды.

Фәтхи улының нәкъ киресен кичерде. Һәр җәй картаеп барган әти-әнисе йортыннан тиз генә китә алмый газапланды. Балачакта уйнап үскән иптәшләрен очратса, юк-бар сөйләшеп булса да, яннарында озаграк торырга тырыша иде. Яшьлегендә озаткан, инде бөтенләй башка кыяфәткә кергән, калынаеп киткән кызларны күрсә дә, әллә кайда, тирәндә нидер өзелгәндәй булып, билгесез хисләрдән күңелен моң баса иде. Наташа моны тойды, әмма тойганын сиздермәскә тырышты. Акыллы хатын иде ул шулай да! Фәтхидән дә яхшыракны тапмасын белә иде... Шәһәрдә үзеннән башка бер минут читкә чыгармаса да, авылга кайткан чакларда ирне тәмам үз ирегенә куйды.

Бу ел да шулай булды. Инде китәбез дигән көнне дә Фәтхи су буйларын, агачлыкларны, таллыкларны тагын бер кат әйләнде, зиратка барып, бабасы каберен төзәтте. Ничек тә сузасы, озынайтасы килде аның бу авылда торган кадерле минутларны.

Фәтхиләр Сөендектән кайтышка Барый ниндидер сюрприз әзерләгән икән, әмма өйгә кергәч, тантаналы шартларда гына җиткерәм мин аны сезгә, диде. Әти-әнисен кочаклап, битләреннән чупылдатып алганнан соң, магнитофон кабызып, ниндидер марш җибәрде, аннан зал түрендәге стенканың урта тартмасыннан, кәгазьләр салып куйган бүлемнән кара күн тышка тышлаган бер катыргы алып, каршыларына таба кош тоткан кебек елмаеп килде дә, шар ярып:

– Сез мине гражданин булуым белән котлый аласыз! – диде.

Әти-әнисе авылда чакта Барый паспорт алган да шуның сөенечен уртаклашуы икән. Әтисе:

– Молодец, улым! – дип, Барыйның аркасыннан какты. Документны сак кына, кадерләп кенә тотты да рәсемле битен ачты һәм... «Борис Фатхиевич Саттаров» дигән язуга текәлеп катты. Бераздан аның шуган кебек кенә идәнгә килеп төшүен хисләргә бирелгәнлеккә – сөенечкә юрадылар. Тиз генә нашатырь иснәтеп аңга китермәкче булып азапландылар, барысы да юкка иде. Фәтхи дәшмәде. Әллә суламый да иде инде? Наташа чәрелдәп телефонга ташланды.

«Ашыгыч ярдәм» машинасында тиз арада килеп җиткән табиблар Фәтхинең инфаркттан вафат булуын теркәделәр. Бу үлемнең сәбәбе Барыйга түгел, Наташага да чын-чынлап аңлашылмый калды. «Әтине җирләргә килегез. Борис» дигән телеграмманы алган Мәгънәви абзый эшнең нидә икәнлеген бик яхшы төшенде. Ул үз гомерендә дүртенче тапкыр елады. Өстәл сукмыйча, сыкранмыйча, сулык-сулык килмичә, хәтта елаганын белдерерлек аваз да чыгармыйча. Бу елауны аның ярылырга җиткән күзләреннән үзе дә өнсез хәлдәге Нурисә генә тойды.

*2006*

## ӘЙЛӘНГЕЧ ЮЛЛАР

Көтмәгәндә-нитмәгәндә Казанга китеп бардым. Тизәктән балчык измә белән сылаштырып яңа ясалган йортыбызның дымлы идәнендә дүрт аякланып йөргән баламны, әнкәй карчыкны, аның сөекле киленен калдырып, күз күрмәгән, белмәгән якларга юл тотуны кан кардәш берничек тә аңлый алмады. Минем дә сөйләрлек сүзем калмаган иде бугай. Китәсе көнне таңда, ишеккә эленгән киезне күтәреп, ялганчы бусага төбендә тәмәке тартып алдым да, төпчеген эсседән көеп утырган өрек төбенә ыргытып, чемоданнарыма үрелдем. Ул да булмады, аның тоткасына икенче яктан Алъяр килеп асылынды:

– Ба-ба-ба, тбв-тбв-в-в, – диде ул, син кая да булса китәсең мәллә, дип сорагандай.

– Тбв-тбв-в-в шул, улым, тбв-тбв-в-в, – дидем мин, эчтә бөтерелеп килгән хисләрдән арынырга теләп.

Ул «мине дә ал алайса» дигән ишарә белән кулыма үрелде. Күтәрдем, үчтекиләп сөйдем дә, аның елавын ишетмәс өчен, идәнгә мүкәләтеп җибәрүгә үк, чемоданнарны кабат җелтерәтеп кенә кулга

алгач, инде беркемгә карамаска-борылмаска ниятләп, йортыбыз яныннан гына узган такыр басу юлына атладым. Газиз анамның ай-вайлап, мәет чыккан йортта сыктаган ханымнар кебек, туфрак тырнап елаганын ишетсәм дә, мәрхүм Ходайбирди белән Умарның киемнәрен кер бавына элеп йөргән Мәһпарәне күрсәм дә, тынычланырлык бер ишарә бирмәдем, бер сүз әйтмәдем. Бәгырь таш булып каткан, күздән яшь кипкән иде.

Бераз баруга – тау итәгенә күтәрелгәч, тукталышта алай да түзмәдем, борылып, балачагым узган биш өйле кышлакка – уң кырыйдагы акшарланган йортыбызга әйләнеп карадым: корыган арык өстенә куелган көрпәчәдә кочаклашып утырган анам белән хатыным Мәһпарә, тупса аша үрмәләгән Алъяр, аның каршысына ятып көч биреп торган Пәхлеван... Бик якын булырга тиеш бу дүрт җанга үземдә нигәдер җылылык беткән иде.

*** * ***

...Мин әле үземне белә башлаганчы ук тол калган анамның бердәнбер ир баласы булганга, ул мине Рузбәх – бәхетле дип атаган һәм бөтен гомерен шул бәхеткә илтүгә багышлаган иде. Сигезенче сыйныфка кадәр мин үзебездән ишәк өстендә ярты сәгатьлек юл булган Аккудукта укыдым. Әнкәмнең агалары шул кышлакныкы булганга, күп көнем алар гаиләсендә узды.

Бераздан атам ягыннан кан кардәшләр минем таҗик мәктәбендә укуымны хуп күрделәр һәм, безнең Колахтауга якынрак булган Гөлстанга илтмичә, Хуҗандтагы интернатка илтеп тапшырдылар.

Үзән итәгенә утырткан калкулык иранлыларның киез башлыгына охшаганга, Колахтау исеме алган кышлагым еракта калган әнкәм белән исемә еш төшкәнгә, бик якын, кадерле дә, шул ук вакытта ниндидер инде мәңге кайтып булмаска тиешле ерак бер ташлы туфрак та иде.

Алай да язмыш кайтара икән. Мамык кырларында язгы эшләр тәмамлансын, мәктәптән катыргысын алсын да Ташкентка укырга китәр дип план корган кардәшләр, мин, бераз акча җыйнаштырыйм дип, базар тирәсендә кайнашып ятканда, Хуҗандка телеграмма юллаганнар. Тиз генә кайт, янәсе. Юл кучтәнәчләрен алып, Колахтауга китеп бардым. Алдагы көннәремне үзем дә бик яхшы күзаллаганга, туган-тумача киңәшенә колак салмасым, үзем теләгән һөнәрне сайласым ачык иде, тик хәтерләрен калдырырга базмадым. Бер гәпләшеп утырганнан ни зыян дип, үземне тынычландырдым. Уйлана торгач, әнине күрәсе килү теләге дә көчәйде, күңелдә ниндидер серле дулкынлану тугандай тоелды.

Тукталышта төшереп калдырган автобус күздән югалгач та, кымшанырга базмый урынымда басып тора идем әле. Моннан – югарыдан – безнең каралты-кура уч төбендәгедәй күренә. Анамның биек тауларда көтү көткән Ибраһим исемле тудыкасының ак яллы Рейханы, атамның бертуган агасы Фагфурның тынгысыз дөлделе электр баганасындагы колаксаларга бәйләнгәннәр дә, китә алмауларыннан гаҗизләнеп, бер урында таптанып торалар.

Ихата уртасына кызыл кирпечләрдән кемдер яңа гына мич ясаган. Анасы аның көен таба алмаганга охшап тора. Казанда су кайнаган булса кирәк, корыган таяк белән астында актарына: утны сүрәнләтергә уйлый торгандыр.

– Сәламаләйкум! – дип кычкырды аңа Рузбәх, башын эсседән каплап кигән кепкасын болгый-болгый.

– Вай-вай, – диде ана, нишләргә белмичә. – Йа Аллах! Җоним уринина сигмай! Бошларимдан кечмиш холларимны, насл курдикларимны бир Аллах төшенердир.

Ул да булмады, йорт ишегеннән Ибраһим белән Фагфур да килеп чыкты.

– Ай-вай! Уз кузимиз ила Рузбәхни күрурмиз, йа! Мархаба, михмон, мархаба! – диде олы агасы.

– Валейкумассалам! Оркалига, буйлига хисоб эт, бушга чикорурдай иш куринмагында, кабул этин: йуртлы улин, одат – сунаттир, кавм одатина куз солин! – дип (әйтерсең кунак тиз генә борылачак та китәчәк иде), Рузбәх яңагына йөзен сыендыра-сыендыра исәнләшкәндә үк, Ибраһим кинәт сүзне башкага күчерде. Күпмедер дәшмичә тордылар. Аннан егет: – Кемгә? – дип сорады.

Рузбәхнең өйләнергә тиешлеге инде аңлашылган, бары тик кем икәнен генә беләсе калган иде...

– Ай, Мәһпарә, гүзәл кыз. Аннан да чибәрне табарсыңмы? Инсафлы, эшкә уңган, аз сүзле, сабыр холыклы... – дип тезеп китте анасы.

Рузбәх Мәһпарәне белә иде. Анасы ялган сөйләми. Тик... өченче буын гына туган лабаса!

– Байлыклары җитәрлек. Читләргә бирикме? – диде Ибраһим, егетнең ни уйлаганын белергә тырышкандай текәлеп карап. Өйгә чакыру да, чәй-фәлән дә онытылды. Бусагадан узганчы олы сүзне сөйләшү гадәте юк иде. Бүген бозылды...

Их! Рузбәх кулында әвәләгән кепкасын агач күләгәсендә яткан, абыйсы белән исәнләшергә дә килмәгән Пәхлеванның танавына ыргытты. Эт дертләп китте, айнымастан ят тоелган кунакка өрә дә башлады.

– Әнә син аларны тыңлама, – дип әйтә бит Пәхлеван да, – дип, Рузбәх сүзне шаяруга борырга теләгән иде, туганнарның йөзенә үпкә төсе чыкты.

– Без аны кайдан чакырып кайтарабыз, ул бер көлкегә алмакчы. Кызның яше үтеп бара. Янында кияүләр дә күренгәли. Син укыган. Ата-анасы сиңа бирү ягында. Монысы сөйләшенгән инде. Без болай... Үзең дә ничек уйлыйсың дип кенә... – бик тыныч әйтергә тырышса да, Фагфурның тавышында ниндидер каушау тоелды.

Инде «Ярар!» дип әйтәсе дә, туйга әзерлеккә тотынасы гына калганлыгын аңлаган Рузбәх чинар күләгәсендәге таш өстенә килеп утырды.

* * *

Туй үтте, туганнар таралышты. Кәләш белән кияү өчен измәдән йортны алдан ук өлгерткәннәр иде. Беренче төнне дә, калганнарын да алар шунда уздырдылар... Рузбәх чыкмады, күренмәде. Мәһпарә өлгерткән ашны да идәнгә түшәлгән ятагына кырын төшеп кенә ашады. Рәхмәте кергән ашка дога кылу белән чикләнде. Тау итәгеннән үзәнгә караңгы төшкәндә генә, бер шәүлә сыйфатында ихатага чыгып, арык янындагы чинар төбенә утырып тәмәке пыскытырга гадәтләнде. Китәргә кирәк иде, китәргә, укырга... Бу турыда беркем берни әйтергә ашыкмады. Рузбәх белән бер үк факультетка барам дип хыялланган Җәмилә менә нишләр... Җибәрергәме бер хәбәр, юкмы? Ничек тә аның күңелен рәнҗетү булыр кебек иде.

Рузбәх эчке газап белән ыңгырашып куйды. Кайтмаган гына булсачы! Анасы яшәгән иске йортның ишек чаршаулары төшерелгән, ярыгыннан сүрән генә ут яктысы сирпелә. Ул да йокламый иде, ахрысы. Рузбәх үзе дә сизмәстән шунда таба атлады.

Әнкәсе киезләр өстендә дога укып утыра иде. Улының, ниһаять, үзе янына килгәненә бик сөенде булса кирәк. Догалыкларын читкә куйды да аны янына дәште:

– Киленнең кәефе ничек, улым?

– Минем кәеф шикелле инде...

– Синекенең начар булырына һич сәбәп юк.

Рузбәх чүт кычкырып елап җибәрмәде. Нәрсә бу? Әнисе юри аңламамышка салынамы? Әллә мыскыл итәме? Бер сөймәгән кыз белән тормышыңны башлап җибәр дә, бер сәбәп юк, имеш. Җитмәсә, Җәмилә...

Алай да, тешен кысып:

– Хуп, – диде.

– Иртәгә агаларың белән басуга барырсың инде. Югары көтүлектәге сарыкларыбыз бәрәнләгән. Аларны да карап кайтасың бар.

– Мәйлең.

– Мәһпарәнең ата-аналары бай тормышлы. Бирнәсе дә мулдан. Аны рәнҗетәсе булма, – диде бераздан ана кеше, улының серен алырга теләгәндәй сынап карап.

Рузбәх җавап кайтармады. Туганнан туганга күчеп йөргән бирнәгә аның бер дә исе китми, ул бирнәләрне җыя-җыя гомере узачагы турында уйлый иде.

...Рузбәхнең юрагань юш килмәде. Мәһпарә белән икесенең кыз түгел, малайлары да булмады. Башта алар дуадак каз кебек икәү генә яшәделәр. Аннан өшкерү-төшкерүләрнең ярдәме тидеме, Ходаның болай биргән мәрхәмәте идеме, бер-бер артлы ике кыз дөньяга килеп, алары да җир куенына кереп ятты. Табиблар сабыйларның сәламәт, яшәрлек тумавын Мәһпарә белән Рузбәхнең канн кардәшлегеннән күрсә, нәсел-нәсәп, Хода бирде – Хода алды, дип тынычланды, яңа бәби, сөннәт туйлары көтеп яшәвендә булды.

Мәһпарәгә ияләшә дә башлаган, әмма яратып китә алмаган Рузбәх бәгыренә генә һәр бала таш булып утырды. Тормышның башка юлдан китмәячәген белгәнгә, ул, намазга баскан саен, үзенә ул сорады, яз җитсә, алар үскәч уйнар дип уйлаган үзәнлеккә яшь чинарлар тамырлатты.

Көткәнне, сораганны Хода барыбер бирә икән. Бер-бер артлы ике улы тугач, дөньясы түгәрәкләнгәндәй булды. Ходайбирди белән Умар инде тау битендә уйнап, җил куып йөриләр, юл буеннан җәнлек ояларын эзлиләр. Рузбәх аларны үзе кебек яшен арттырган чинары төбеннән тәмәкесен пыскытып кына күзәтә. Елаша башласалар да, шаярсыннар, тукмашсыннар, аларның шундый чагы, дип сөенә.

* * *

Бу сөенеч озакка бармаган икән. Гөлстан базарыннан болай да кәефе кырылып кайткан бер кичтә, авылга кергәнче үк, күңелне шом басты. Йорт тирәсенә бәйләнгән атлар, хатын-кызларның ай-вайлаган тавышы зур хәсрәтнең күкрәккә якынайганлыгыннан бер хәбәр иде.

Өйгә таба атлаган саен, сыктау авазлары ачыграк ишетелә барды. Мин туры балалар өчен салынган яңа йортка таба атладым. Кердем дә, идәндәге кыйммәтле паласлар өстендә ак кәфенгә төрелгән ике баламны күреп, аяк очларына егылдым. Мәһпарә белән әнкәм ике ягымнан тотып күтәреп алырга

газапландылар, аякларым тыңламады. Балаларны йорттан алып чыгып киткән чагында да хәлсезләнеп, телсез калып, бусагага аркылы барып төштем. Калганын берни хәтерләмим.

– Ходай бирде – Ходай алды, – диде анам, минем күзне ачканымны күргәч, тынычландырырга, җаныма узарга теләгәндәй.

– Кырны ашлама белән дә Ходай агулаганмы?! – дидем мин, буылырга җитешеп. – Балаларны да анда ул җибәргәнме, ашламалы дөге ашагыз, дип әйткәнме, мине дә үз туганыма ул өйләндергәнме?! Менә шулай бәхетсез ясаганмы? Нәсибәне бер мескен иткәнме?!

– Аңа тел-теш тидермә, кяфер китәрсең, – диде әнкәм сабыр гына. – Хода кушмаган эш булмас. Явызлар кылган явызлыгы өчен аның каршысында җавап бирер. Сине дә, Мәһпарәне дә бәхетсез дип кем әйтә? Биргәненә шөкер дә итә белмисез сез яшьләр...

– Арыкка ашлама сибеп үткән очучы узган ел үлгән сарыклар өчен җавап тоткан шикеллеме? – дидем мин, тагын да үрсәләнеп. – Шуңа шөкер итимме мин? Яратмаган хатынымамы? Күбенеп үлгән балаларымамы?

– Хода кушмаса, яфрак та селкенмәс. Ул күрмәгән эш булмас. Җәзасына вакыты җитмәгәндер, – диде ул тагын да сабыррак.

Мине бу карусызлык, һәрнәрсәдән ризалык чыгырдан чыгара иде.

– Шөкер итә белмисез сез, әнә шуңа дөньягыз да түгәрәк түгел, – диде анам, инде уфтанганрак итеп. – Мәһпарәнең карынында яңа балаң борынлап ятканда тавыш чыгарасың. Исәнлеген сора да тынычлан.

Чын-чынлап телсез итте бу сүз. Әнкәй өр-яңа хәбәрен әйтте дә, инде мине күрергә дә теләмәгәндәй кисәк борылып, урам якка атлады. Сүрелә башлаган хыяллар Гөлстан базарыннан соң күңелдә яңадан терелеп киләләр иде, алар тагын ерагайганнан-ерагая башладылар.

* * *

Җәмилә миңа көтмәгәндә очрады. Җимеш рәтләре арасыннан җил-җил генә туп-туры үземә таба килә иде ул. Таныгандыр да күрешергә телидер дигән идем, алай булып чыкмады. Товарымны ерактан ук ошаткан да безнең рәткә тукталырга булган икән.

Минем базарчылыгыма исе киткәнлеген сиздермәде, укуым турында да сорашмады.

– Нигә хат булса да язмадың? Бергә Ташкентка китәрбез дип уйлаган идек бит, – дип кенә әйтеп куйды. – Инде менә мин, институт бетереп, Казанга аспирантурага кердем. Анда бик күп уку йортлары бар. Сине дә чакырам.

Җәмилә минем тормыштан хәбәрдар түгел иде шикелле. Аның хакында кызыксынмавына, исе китмәгәндәй генә сөйләшүенә, әмма үзе яшәгән шәһәргә чакыруына шаккаттым. Дөнья хәлен белмәссең дигән булып, адресын алдым.

Әнкәй белеп әйтәдер, Ходай кушмаган эш булмый шул. Күңелгә Колахтаудан мәңгегә китәм дип беркетеп кайткан идем, барып чыкмады. Балалар хәсрәте, Мәһпарәнең көмәнлелеге мине тагын үзем сөймәгән гадәтләр эчендә, үзем яратмаган эшләр дөньясында калдырды. Көннәр тагын элеккечә уза башлады.

Шәһәрдән кайтып, газеталар укыштырып яткан бер кичтә, керем артыннан куып, агуланган кырлар, тозлыкка әйләнгән мамык җирләре турында мәкаләгә юлыктым да уйга баттым. Кеше, авыл, аларның язмышы, безнең югалткан балаларыбыз турында бер сүз дә юк иде аларда, шулай да мин булачак эшләргә, зур сүзләргә юл ачылганлыгын тойдым. Үзбәк-таҗик җирендә яшәгән Ходайбирди, Умар кебек йөзләгән, меңләгән балаларны исән калдырырга, кышлакка зур кеше булып кайтырга, алар турында кайгыртырга тиеш икәнлегемне аңладым.

Әллә Җәмилә шунда булганга, көтмәгәндә-уйламаганда, киемнәремне иске чемоданыма тудырдым да, үз гомеремдә беренче тапкыр әнкәмә, Мәһпарәгә чын-чынлап каты бәгырьлелек күрсәтеп, авылдан чыгып киттем.

– Ба-ба-ба, тбв-тбв-в-в... – син кая да булса китәсең мәллә? – дип сорагандай ишек бавына тотынып калды Алъяр.

– Тбв-тбв-в-в шул, улым, тбв-тбв-в-в, – дидем мин, эчтә бөтерелеп килгән хисләрдән арынырга теләгәндәй. Ул «мине дә ал алайса» дигән ишарә белән кулыма үрелде. Күтәрдем, үчтекиләп сөйдем дә, аның елавын ишетмәс өчен, идәнгә мүкәләтеп җибәрүгә үк, чемоданнарны кабат җелтерәтеп кенә кулга алгач, инде беркемгә карамаска-борылмаска ниятләп, йортыбыз янынннан гына узган такыр басу юлына атладым. Бәхеткә илтәчәк идеме ул мине, башкагамы – ул хакта уйларга соң иде. Үзең теләгән бәхеткә юллар бик әйләнгечтән икән лә...

*2005*

# ХИКӘЯЛӘР

## ЧАЛБАР

Нургали ятимлектә үсте. Ул моның өчен кемгә үпкәләргә, кемне гаепләргә белмәде. Әти-әнисенә үпкәләр иде – яшьли җир куенына кереп ятулары аларның үзләренә дә бик рәхәт булмагандыр дип уйлады. Аларны ач тоткан, шул хәлгә китерерлек чирләткән сәвит дияр иде – кем ачлыкны күрмәгән ди, әле бит яшиләр, шиңгән корсакларын да киереп яшиләр иде...

Язмышка ачуланып булмый да булмый инде! Алай дисәң... ник әле нәкъ менә Нургалинең иң булган, иң матур әти-әнисенә – шундый язмыш, кешегә каршы сүз әйтергә дә йөрәге җитмәгән малайның үзенә ятимлек тияргә тиеш идеме соң? Алай уйлады, болай... Җавап таба алмады. Усал җиңгәчәе, Ходай язганны күрми булмас, дигәч, бөтен үпкәсен үз тормышының Хуҗасына юнәлтте.

Нургали ерак туганнарында торганга, өстәлдән ризыкны да куркып кына алды, кояш чыккач йоклап ятарга да базмады. Көтүгә сыер куды, бәбкә саклады, чүп утады, җиңгәсенең бер-бер артлы туган, үзе кадәр булып килгән ике баласын карады.

Нургалинең тиздән мәктәпкә йөрер яше җитеп килә иде. Каршыдагы күрше кызы Раузага да шул чама булса кирәк. Кичләрен капка төбенә өелгән бүрәнәләргә утырып, гел мәктәп хакында сүз куерта ул. Рауза үзенә матур сумка алачакларын, көрән тукымадан күлмәк тектерәчәкләре турында кәнфит ялагандай бик тәмләп, авыздан сулар китерерлек итеп сөйли иде. Сөйли-сөйли дә, күлмәк кесәсенең төбенә качырып кына тыгып чыккан, уйнаганда керләнеп беткән бер шакмак шикәрне Нургалигә бирә:

– Ятимнәрнең теләге кабул була ул, миңа сумканың кызыл төстәгесен сора, яме!

Нургали хыялында исә мәктәптә кирәге чыгар кебек булмаган сөяк саплы пәке. Һәм... чүпрәк букча белән бер дәфтәр дә бер каләм.

– Син соң мәктәпкә дә чалбарсыз гына барачаксыңмыни? – дип сорап куйды беркөнне аның һаман да сапларының төсе генә үзгәртеп сөйләнә торган пәкесе хакындагы хикәятеннән туйган Рауза. – Мәктәпкә төпсез ыштан белән кертмәсләр!

Нургалинең бот араларын пешекләп алдыларммыни?! Ул бер-берсенә чалыштырып утырган аякларын әле тегеләй, әле болай алмаштырды, ни әйтергә белмәде. Урыныннан торды да үз турларына йөгерде. Аннан бәрәңге бакчасына – абзар артына чыгып рәхәтләнеп елады.

Җизнәләренең өе тыкрык буенда гына иде. Шуннан узып баручы бер карчык малайга карап җәлләп торган да киртә астыннан кереп юатырга булган. Башыннан сыпырган каты кулларга күтәрелеп карады да Нургали тагын да ныграк үксергә кереште.

– И балам, – диде аңа таныш булмаган түтәй, – елап берни эшли алмассың. Күзләрең генә бетәр. Син менә Ходайдан сора. Аннан башка үзеңне кызганучы тапмассың!

– Кызганса, мин ятим булыр идеммени? – диде Нургали, үрсәләнеп. – Ул булса, әти-әнине яшәтмәс идемени? Шушы яшьтә кемнең малае төпсез ыштан кия? Койма башына да кеше күрмәгәндә генә менәм бит мин!

– Көфер сүз сөйлисең, улым, – диде карчык, ни әйтергә сүзләр эзләп торган бер кыяфәт белән, озак-озак кат-кат такыр башыннан сыпырып, аркаларыннан кагып торгач. – Көфер сөйлисең! Тфү, тфү! Аллам сакласын, диген. Алла сораганга бирә ул. Сорый белмибез шул, сорый белмибез. Анысын тиеш, монысын тиеш, дибез... Син дә менә әллә кемгә әллә нәрсәләр тиеш кебектер. Бөтенесен дә булдыра аласыңмы? Син барлыгын да танымаган Алла сиңа нәрсә бирергә тиеш булсын ди?..

Чыннан да, Нургалидән, кечкенә булса да, бик күпне көтәләр, берни сорамыйлар да, кушалар да кушалар гына, ә үзе турында һәрвакыт оныталар иде. Бисмилласын әйтеп ашарга утырса да, болай... бер гадәт кенә инде ул...

Малай әбекәйнең кармак кебек бармакларына кечкенә куллары белән ябышты:

– Әби, Алла бар, дисең бит! Сора әле миңа да, сора! Бу малайны чалбарлы ит, диген. Мәктәпкә барганчы, бер чалбар кирәк миңа! Дәфтәр-ручканы анда да бирерләр әле!

Нургали, кеше арасына чыгарлык киеме булса, хәзергә ботларын кычытканга чактырып яшәргә дә бик риза иде кана. Таныш булмаган әбигә шик белән, ышанмыйчарак карап, ул тагын ялынырга кереште:

– Әби, малайларың булмаса, кайда яшәгәнеңне әйт, мин сиңа көн дә су алып кайтырмын! Утын кертермен! Кыш көне капка төбеңне көрәрмен! Бер чалбар сора инде, әби-и-и... Сора инде-е-е...

– Сорармын, улым, сорармын, мин сиңа малаемнан калган бер чалбарны болай да бирермен әле. Бу яшьтә төпсез ыштан киеп йөрү бер дә килешми. Мәктәпкә чалбарны үзең сорарсың! Ятимнең теләге кабул була ул...

Нургали тынычланды. Әби китте. Киртә астыннан бөкрәеп бик җиңел кергән булса да, кире чыга алмыйча озак газапланды. Ахырдан Нургали урамга аны ишегалды аркылы гына, олы капкадан уздырды.

Карчык күздән югалгач, малай, тиз генә бер карарга килеп, мал өенә кереп бикләнде. Бикләнде дә тагын үкси-үкси еларга, инде бу юлы яшь аралаш Аллага ялварырга тотынды. Бераздан яше кипте, теләк теләрлек хәле калмады. Юып, идәнгә капланган казан төбенә кулларын куйды да хәлсезлектән йокыга ук китте ул.

Җиңгәсе Нургалине вакытында урамнан кермәве, соңгы ашка да кайтмавы өчен орышмаска, тиргәмәскә үз-үзенә сүзләр биреп көткән иде бу кичне. Вәккас абыйсы мәктәпкә йөрергә дип бик матур чалбар алган үзенә. Бүләкнең тәмен җибәрәсе килмәде аның. Тавыкларга пешерергә сайлаган вак бәрәңгене казанга салып куйыйм дип мал өенә керсә – малай шуңа капланып йокыга киткән икән... Урам тузаныннан керләнгән йөзендә яшь эзләре ярылып ята. Хатынның йөрәге үк кысылып куйды. Бик авырлык белән генә күтәреп алып йортка алып керде, өстәл кырыендагы сәкегә яткырды. Нургали туйганчы, икенче көнне кояш чыкканчы йоклады. Уянса, сәке янындагы урындыкта – өр-яңа чалбар! Җиңгәсе, бәйрәм көндәге кебек елмаеп, ипи салып йөри. Шәфкать белән Расих та торганнар, әниләренең аяк тирәсендә мүкәләшәләр. Абыйсы инде эшкә үк киткәнгә охшый.

– Нургали, карале, абзаң каладан нәрсә алып кайткан үзеңә! – диде аңа Мәдинә җиңгәсе. – Укучы буласың бит син көзгә! Инде киндер ыштан, төпсез ыштан белән йөрү килешмәс! Болай да...

Тел очында әллә нинди матур сүзләр җыелган иде, икенче якка китте... Ул башка берни әйтә алмады, чарасызлыктан елап ук җибәрде.

– Үз балаларыбыз да булгач, сине яхшылап карый алганыбыз юк. Инде моннан ары кием алгаламый булмас, яхшылап кисәң, барыбер аларга кала бит ул! – диде җиңгәсе, мышкылдавыннан туктагач.

Кала, билгеле, кала! Нургали аңа тузан да кундырмасына бик ышана иде! Юасы да булмаячак чалбарны! Нинди пычрату! Ерту, тишү, туздыру турында инде уйлаган да юк.

Нургалигә чалбар әле зуррак, хуты белән алынган икән. Ипи пешеп, чәйләгәч, җиңгәсе кыскартып куярга булды. Нургалигә туйганчы киеп калырга да бирмичә, ялгышыбрак әйтеп ташлавына үкенгән бер кыяфәт белән ашыктырып, салдырып, шкафка тыгып та куйды. Малай моңарчы хас булмаганча киреләнеп күрсәтергә, әз генә киеп торырга сорарга уйлаган иде, дәшмәде, түзде. Ул өр-яңа чалбарга әле кичә генә өметләнми дә иде бит...

Бу көн рәхәтлекләре аның белән генә бетмәгән икән. Нургали үпкәләргә ашыгыбрак план корган лабаса. Шкаф эчендәге киемнәрне рәтләштергән итенгәч, Мәдинә җиңгәсе ишек катындагы чаршау астыннан тагын чалбарише ике нәрсә тартып чыгарды:

– Менә монысын тау башы Мәhисәрвәр түтәең җибәргән, уенга кисен, дигән. Монысын Раузаның әнисе кертте, барыбер безнең өйдә малайлар юк, әрәм генә ята, ди. Алмашка киярсең микән? Мәктәпкә генә сакларбызмы? Чалбарыңны юган көнгә дип. Кышын бик тиз генә кипми дә бит әле ул.

Нургали ничек булса да риза, мең риза иде. Кабаланып, кимәсә, тартып алырлар төсле, ул, сәкегә утырган килеш, ике аягын да Мәhисәрвәртти җибәргән чалбар балакларына тыкты, кигән җайдан гына идәнгә сикереп тә төште!

– Монысы тап-таман, җиңги!

Нургали бераздан чалбарны өйрәнүдән арыды, кабат үз эшенә керешкән җиңгәсе янына килде.

– Рәхмәт, абыйга да бик зур рәхмәт! Инде малайларны уйнатып кайтыйм, – диде. – Раузаның әнисе күренмәсме... Аңа да рәхмәт әйтәм әле мин!

Өстәлдә Нургали өчен куелган иртәнге сөт бар иде. Ул шуны да эчеп тормаска, тизрәк урамга чыгып чалбарын күрсәтергә, кеше рәтендә бер йөреп алырга теләде.

– Яраса, минем сөтне Уткүзгә генә бир әле, җиңги, чалбар хәере булсын, – диде ул, hаман да эшендә булышкан хатынның итәгеннән тартып.

Мәдинә җиңгәсе бүген әллә нинди ягымлы, рәхимле иде.

– Мәче үз өлешен алды инде, сүзең яхшылыктан китсен, сөтеңне эч, ач йөрмә! – диде ул, малайның киң күңеллелегенә куанып.

Нургали, Шәфкать белән Расихны киендереп, җитәкләп, капкага юнәлгәндә, аннан мәктәп директоры килеп керде. Кулында – зур гына бер төргәк.

– Үскәнем, син быел мәктәпкә барасың, комитет форма җибәрде, киеп карамыйсыңмы? – диде ул, төргәкне Нургалигә сузып.

Нургали чалбарларны бүген җитәрлек кигән, тап-таманы аның өстендә үк утыра иде.

– Рәхмәт, җиңгигә генә кертеп бирегез инде, ишегалды тузанында пычратып тормыйм. Бала-чаганыкын белмәссең, йә куллары белән килеп тотына, йә... – дип, эшем кешесе кыяфәте белән сүз башлаган иде, икенчерәк бетерде: – Уйнатып керим инде, көне дә бик матур.

Малай каршы як капка төбендә Рауза көткәнен белә, аның янына беренче мәртәбә чалбардан, ул әле күрмәгән чалбардан чыгарга алгысына иде.

Директор өйгә кереп китте, Нургали, капканы киң ачып, иң элек каршы якка карады. Анда, чыннан да, Рауза утыра иде. Ул Нургалинең малайлар белән икәнлеген күргәч, кулындагы шикәрен тагын кесә төбенә салып куйды. Аннан эндәшми генә кул болгады. Шәфкать белән Расихны үзеннән ычкындырмыйча, Нургали алар турына таба атлады.

Малайлар барысы да җайлап бүрәнәләргә урнаштылар. Көн саен мәктәп турында башлана торган сүз урынына, бер дә көтмәгәндә, Нургали:

– Алла бар, Рауза, бар! Мин әйтәм: сораганны рәхим-ярдәменнән ташламый, – дип ычкындырды.

Маһисәрвәр әбисе авызыннан отып алынган, нәкъ менә бүген генә бик мәгънәле тоела башлаган бу сүз Нургалине Рауза каршында олыгайтып җибәргәндәй итте. Гәп уңаена кыстырыр җөмләләр теленә килмәгәч, кыз әнисе һәр көн иртән әйтә торган сүзләрне кабатлады:

– Биргәнеңә шөкер инде, и Ходаем!

*2006*

## НӘСИБ-НӘСИБӘ

Котлыбәк әкә өендә бүген бәби туе. Күршеләре Нуриханның бичәсе Гашыйга угыл тапкан көнне аның хатыны Зәйтүнә дә кыз алып кайтты. Бу ике күршенең туганлашу хыялы күңелләрендә күптәннән яши иде, ниһаять, Хода аларның теләкләренә колак салды: җаннарны әнкә карынында нәкъ үзләре сораганча яралтты.

Көн буе, төн буе ике йортка да кунаклар агылды, куйлар суелып, казан асылып, пылау-бишбармак пешерелеп, киң итеп ачылган капкалар алдына, былбыллар оя корган карт тирәкләр астына, шаулап аккан арык өстенә көрпәчәләр корылып, зур табыннар урамга гына ясалды. Бүләкләр төрле киезләр өстенә өелсә дә, һәр хуҗа эченнән генә аларны уртак гаиләгә багышлады, балаларны да, пар бишекләр ясатып, чит-читләрен чын кытай ефәкләренә төрдереп, янәшә куйдылар.

– Колакларын тешләтү ата-бабадан калган йола булса да, без алай эшләтеп тормабыз, әмма әйткән сүзем шул: бишек иркәсе – угылыма килен буласы кызыңдыр, – диде Нурихан әкә. – Ходай гомерләрне озын язып, саннары таза-сау булып, үзләре балигълыкка чыккач, бакча эчендәге түр йортка Алла кушып алып кереп утыртабыз без аны.

– Хуп, хуп, – диештеләр килгән кунаклар.

Котлыбәкнең дә бу сүзләрдән күңеле хушланганы сизелеп тора иде, әмма ул «ярар» дип әйтергә ашыкмады. Ялтырап торган иякләрен ике яктан әйләндереп алган мыек очларын бик озак сыйпаштыргалап торганнан соң:

– Синең белән кодалашырга без бер дә каршы түгел, алай да ашыкмале, бишектәге бишкә төрләнә дигәндәй, алар үскәч ни диярләр... шуннан соң күз күрер...– дип куйды.

Бу сөйләшү кыз кодалау рәвешен ала барганын чамалаган күрше буй-буй халатының төбе тезенә кадәр төшкән уң кесәсеннән алтын сәгать чыгарып, Котлыбәкнең кушучына салды:

– Вакыт тиз уза, бу сәгать минем киленемнең өлгерә баруыннан хәбәр булыр дип уйлыйм.

Котлыбәк дәшмәде, иллә мәгәр сәгатьне кире кайтарырга да ашыкмады. Күрше, әлеге халатның сул кесәсеннән бер пар ай алка чыгарып, Зәйтүнә ханымга таба атлады, әмма ир хатынына таба үрелүне яхшысынмадымы, әллә хуҗаны олылавын күрсәтергә теләдеме, анысын да Котлыбәккә китереп тоттырды:

– Монысы Зәйтүнә ханымга кыз ярәшү бүләге булсын!

Зәйтүнәнең дә эчтән бик сөенгәне күренеп тора иде, ирдән узып рәхмәт әйтергә яхшысынмады, баш селкеп кенә куйды.

Кунаклар тагын кат-кат:

– Хуп, хуп, – диештеләр.

Котлыбәк кенә бер сүз дә дәшмәде. Олы малайга – магнитофон, кечесенә көмеш билле велосипед бирелгәч кенә, аның йөзенә бераз кызыллык җәелгәндәй тоелды. Бернинди бүләкләрсез дә кызын ут күршесенә бирергә риза булса да, ата-баба йоласы бушлай ярәшүне яхшы тапмый, һәм болар гына әле, һичшиксез, аз иде. Нурихан бу дәшмәүнең асылын аңласа да, сүзне, көттерүне һаман сузарга теләде, ул кунакларның иң зур бүләкнең, иң зур вәгъдәләрнең алдалыгын көтеп тынып калганнарын белә иде.

– Кызың киленем булырга риза булса, миннән туй бүләгенә шәһәр уртасыннан өч бүлмәле йорт, – диде ул. – Беренчегә угыл тапса – бер диган машина. Хәзергә ул үскәнче җитәрлек парчалар, баш астына йомшак мендәрләр, өстенә җиңел хәтфә юрганнар...

Аннан бераз тын алырга тукталгандай итенде дә:

– Әлегә муенсасын-алкасын, беләзеген-йөзеген бишегенә салыгыз – уенчык итеп уйнап ятсын, – дип өстәде. Халат эчендәге күлмәгенең түш кесәсенә яшерелгән алтын-полтыннарны кызның ике тәпиендә тирбәлеп утырган бәллү кырына илтеп салды.

Инде монысын ук көтмәгән кунаклар тагын да ахылдашыбрак вәгъдәне хупларга тотындылар, булачак кода да, күңеле тәмам хушланып, ризалык белдереп, киң итеп елмайды, Нурихан әкәне иңнәреннән тотып, битен битләренә куеп алды. Вәгъдә билгесе итеп, үзе дә малай яткан бишекнең кырына кынына тыгылган, таш койдыртып эшләнгән булат пычак куйды, бишекнең аяк очына ау мылтыгын терәде. Малай, барысын да белгәндәй, ыгы-ыгы килде, күзләрен дә ачып тормыйча елмайды да, ефәк башлыклары битен кыргандай, башын әле бер, әле икенче якка боргалап торгач, яңадан тәмле йокысына чумды.

Бишектәге кызның гына боларга исе китми, иреннәрен чупылдатып йоклавында, чөнки яңа гына әнкәсенең йомшак күкрәкләреннән татлы сөт имгән иде. Алай да төш аралаш ул нәрсәгәдер кулларын чәбәкәйләгәндәй итеп алды, һәм моны күргәннәр барысы да аның зиһенлелегенә, хәзердән үк бар нәрсәне аңлап торуына, олыларның бу эшенә сөенгәнлегенә юрадылар. Ул да булмады, хуҗабикәләр, пешекче хатыннар йөгерешергә тотындылар, чүмеч-пычакларын бер читкә куеп торган казанчы ирләр яңадан мич тирәсенә өерелештеләр. Тагын да көчлерәк итеп май, суган исе таралды, яңа суйган сарык итенең тамак кытыклагыч буы борыннарга килеп бәрелде.

Мәҗлескә ике яктан да бер үк мулла чакырылган, балага исемнәрнең һәркем тарафыннан әллә ничә төрлесе уйланылган, инде мулланың үзе белән килештерәсе, киңәшәсе генә калган иде. Сиксән яшьлек Мохтар молданың болар белән сөйләшергә уенда юк иде булса кирәк, инде, балакайлар, бер-берсенә ярәшкәнсез, сүзләр бирешкәнсез, насыйп ярлар тапкансыз икән, исемнәре дә Нәсиб белән Нәсибә булсыннар, дип куйды.

Чыннан да, ярыйсы гына исемнәр, кайчан гына модада йөргән Трактор да, Маркс-Энгельс та, Револьвер да, Рина-Зина да, Люа-Муа да түгел. Эчке ныклыгы булган, заман шаукымнарына бирешмәгән Нуриханга да, күршесенә дә ошады, әле яңа гына күңелләрендә йөргән исемнәр булмагандай ук юкка чыкты, ә хатын-кыз, яшьлегендә читтән генә күз төшергән егетләренең исемен уйлап, акрын гына сызып тынды...

Нәсиб белән Нәсибә ай үсәсен көн үсте, ел да аларның туган көнендә шул ук арык өстендә казаннар асылды, тулып өлгергән кара дөгедән борыннарны кытыклаган пылау пеште, учак өстенә аркылы куйган тимерләрдә яңа суйган бәрәннең кызарышкан ботлары әйләнде.

Ике гаилә дә балаларның ни арада мәктәпкә барыр яшькә җиткәннәрен дә белми калды. Нурихан әкә улы үскән арада пенсиягә чыкты, йорт тирәсендә генә маташа башлады, ә Котлыбәкне бик югары күтәрделәр. Яше олы булса да, университет мөгаллименең эшләү дәрте бетмәгән иде әле. Тиз арада ул кызы туганда доцент кына булып йөргән факультетның деканына ук әверелде. Дөрес, бу хәлләр аның язылa башлаган диссертациясен бер читкә куйдырды, әле байлыгы да сельпо председателе булып эшләгән күршесе байлыгыдай күзгә бәрелерлек түгел иде, алай да шәһәрдә дә йортлары булды, совхоз территориясенә кергән хуҗалыгында яңа туган һәр баласына шәп-шәп өйләр салып бирә алды. Ике гаиләнең тиңлелеге туган-тумача арасында бәхәс уятмый иде.

Ташкентка совхоздан трамвай юлы килсә дә, Нәсиб белән Нәсибәне укырга авыл мәктәбенә генә илттеләр. Монда аларның кияү белән кәләшлеге һәркемгә билгеле булганга, иң алгы партага янәшә утырттылар, әмма яшь укытучы кыз әйтә куйды:

– Бу партада киләчәктә иң яхшы укучылар гына утырачак, аларның башларына кызылдан пар түбәтәй кидертербез.

Галим кызы Нәсибәнең бишкә генә укыйсы беренче көннән үк аңлашылды, әмма «кияү» хәреф тә өйрәнеп килмәгән, атасы байлыкларын санарга да өйрәнмәгән иде шул. Ай дигәндә аны иң арткы партага күчерделәр. Нәсибәгә мамык тәлгәшләре төшкән түбәтәйне сул як күрше Сабирҗан малае белән пардан кидерделәр. Бу Нәсибнең үтенә тиде. Ул булдыра алганда ничек тә Нәсимнең авыз-борынын җимереп кайтарырга тырышты. Нәсим түзде, беренче партадан күчмичә, үч кайтарырга сүзләр биреп түзде. Көне-төне укыды, укуда алдынгылыкны Нәсибәнең үзенә дә бирмәде, аңа ничек тә ярдәм кулы сузарга тырышты.

Беренче сыйныф азагында да, икенчесен, өченчесен тәмамлаганда да, аннан соң да рәсемгә төшкәндә Нәсим белән Нәсибәне янәшә алгы рәтнең иң уртасына утыртсалар, Нәсибне иң соңгы рәткә, җимерек парталар өстенә, анда да бер читкә генә бастырдылар. Рәсемгә билге дәрәҗәсенә карап төшү бер гадәт булганга, кияү-кәләш хакына да бозмадылар. Шуның өстенә яшь укытучы үзе дә бу чараның тәрбияви роленә бик тә инанган иде.

Өченче сыйныфта укыганда, Нәсиб чыгырдан чыкты, түзмәде, бөтен начарлыкны кызыллы-аклы түбәтәйдән күреп, җаен туры китереп аны урлады. Эзләделәр-эзләделәр дә, тапмагач, яңасын тектерделәр. Нәсиб атна буе рәхәтлек кичереп, кош тоткандай йөреп калды. Партаның аякларын җимереп карады, шунда ук Нәсимнең әтисе килеп рәтләде. Сыйныф журналын юк итте, мәктәпне кара пошаманга төшерсә дә, анысы иске сарайлар эченнән табылды. Хәер, еллык билгеләрне журналсыз да бик дөрес чыгарганнар иде.

Зуррак сыйныфларга күчә барган саен, Нәсибтә үч хисе артты. Ул, хәтта балаларга түбәтәй кидерми башлагач, Нәсибә урынын күзлек кигән икенче бер кызга биргәч тә кимемәде, чөнки рәсемгә

һаман да элеккечә төшерәләр, Нәсим белән Нәсибә бик дуслар иде. Кияү исемендә йөргән Нәсибкә күрше кызы белән утырырга, вакыты белән ялгыш кына кулларына кагылып китәргә, булачак тормыш турында сүз катарга җай чыкмады да чыкмады. Ни гаҗәп, Нәсимгә дошманлык никадәр арта барса, ярәшелгән кәләшне сөю хисе дә шулкадәр үк көчәйде.

Карт тирәкләр күләгәсендә, йөгерек арык өстендә уртак мәҗлесләр уздырылса да, шул табыннар артында туганлашу сүзләре сөйләнсә дә, яшьләрне янәшә утыртсалар да, Нәсиб кызның ихлас кыланышларына, үзен яр, ир итәсенә һич тә ышанмады, бу уеннардан кайчан да бер качарга хыялланды.

Еллар узды. Егетләр үсте. Өч гаилә бер булып диярлек Нәсиб белән Нәсимне армиягә дә озаттылар. Нәсиб Ерак Себер өлкәләренең берсенә барып эләкте. Ул тиз генә бу якның кырыс табигатенә, кышларының озынлыгына күнегә алмады, Нәсибәнең тыйнак хатлары да аны җылытмады. Командир кызы Люба белән дуслашып китү генә кыз-егет арасында була торган, атларга куркытып торган киртәләрне җимерде. Тора-бара гади дуслык чикләре дә узылды булса кирәк... Нәсиб авылына, ныклы карарга килеп, марҗа кызын култыклап кайтырга, шуның белән Нәсибәне, үзеннән алдарак кайтып өлгергән, бәлки, инде кызга өмете юк түгеллеген дә сиздергән (?) Нәсимне аяктан егарга уйлады. Аңласыннар, кем кемнең борынына чирткәнен, диде ул. Гореф-гадәтләрне алга куйган, дини кануннарда яшәгән атасына да хәбәр итеп тормады. Ул да Нәсибкә бәхетсез мәхәббәтенең сәбәпчесе булып тоелды.

Люба-Любовьның исеме үк аны бәхетле итәчәген хәбәр биреп тора иде. Бу инде читләр куенында яшим дип хыялланган яр түгел, бу мәхәббәтнең үзе дип уйлады ул, күзләре томаланыр хәлгә җитеп ярсыган чакларында. Менә күрсәтер әле барыгызга да, күрсәтер!

Марҗа кызын кайнар кояш астында үскән егет тәненең җылысы тәмам исертте, ул аны чын күңелдән яратып, аның да шундый ук хисләрдә яшәгәненә ихластан ышанган иде. Кара-чутыр үзбәк малаена сап-сары бер Иван алып кайтып бирим әле, дип уйлады ул, авыл урамына кергәндә, кабарып килгән эчен капшый-капшый. Нәсиб сюрпризны ныклап ясарга уйлаган, поездга каршы килүләрен теләмичә, ата-анасына телеграмма да сукмаган иде.

Нурихан ага улының каената канаты астында хезмәтне дәвам итәчәгеннән дә бихәбәр иде шул...

Менә Нәсиб Нәсимнәр, аннан Нәсибәләр турына якынлашты. Йөрәге дөп-дөп типсә дә, алар йортының ялтыратып юылган тәрәзәләренә, арык өсләрендәге матурлап киселгән яшь куакларга карамады, карт тирәкләр күләгәсеннән атлады да атлады, әмма, һәрбер адымын санагандай, бик акрын барырга тырышты.

Менә ул, Любаны җитәкләп, агартылган капканың зәңгәр ишекләрен ачып, ишегалдына узды, яшь укроп, яшел суган үскән түтәлләр арасына салынган сукмактан төп йортка юнәлде. Туп-туры барырга, хисләрен тышка чыгармаска, өйгә килеп керергә дә табын тирәсенә түгәрәкләнеп утырган зур гаиләсе янына берни булмагандай киленне китереп утыртырга, аннан гына һәрберсенә сәлам биреп чыгарга уйлады.

Әле ишеккә өч адым чамасы бар иде. Кинәт тыны кысылды, күз аллары караңгыланды, аңы томалангандай булды да, Нәсиб, Любаның кулыннан ычкынып, хәлсезләнеп таш сукмакка лыпылдап килеп утырды. Ишеккә карады. Анда үзе яраткан, мәңгелек хыялында булган Нәсибәнең сурәте пәйда булгандай тоелды. Балачагына кире кайтырга теләгәндәй, аңа таба үрелде, буе җитмәде. Ниндидер чит, каты, мәңге җибәрмәскә әзер куллар аны тотып алдылар:

– Николай, вставай, Николай. Ко-о-оль...

Нәсибнең башын шушы сүзләр белән тагын бер кат ярдылармыни! Ул күтәрергә азапланган Люба кулларыннан ычкынып китте дә, һушыннан язып, сукмакка авып төште.

Каерып ачылган ишектән аңа карап торучы чыннан да Нәсибә иде. Аларның вәгъдәләшкән көне җиткәнгә, Нәсибкә көтелмәгән бер бүләк ясыйм дип тә, аталары кызны каената йортына кертеп утырткан, һәм килен булып киткән Нәсибә яшь кияү кайтышының хәстәрен кайгыртып йөрүдә иде.

Ул сукмакта аңсызланып яткан Нәсибкә, аны күтәрергә газапланган чит бер ханымга карады да катты...

*2006*

## ТАНЫШ ТАВЫШ

Әнкәй олыгая. Авыргалап та тора. Шат көннәреннән кәефсезләре күбрәк. Әллә этине сагына, әллә яшьлеген – альбомнар карап утырырга гадәтләнде. Кулына иң элек бәрхет тышлары кыршыла башлаган альбомнарның кызыл тышлысын ала ул. Шунда ук йөзенә – алсулык, күзләренә нур йөгергәндәй була.

Әнием альбомның тәүге битләрендә озаккарак туктала. Аның рәсемнәргә текәлеп ни хакындадыр уйлаганы, кемнәрнедер сагынганы, алар өчен борчылганы, яшьлегенә кайткандай кебек булганы кемгә дә аңлашылырлык. Әле яңарак кына күзләренә иңгән нур тоныкланганнан-тоныклана бара, йөзе шәфәкъ баешындагы офык кебек алсуланганнан-алсулана. Авыр сулаган күкрәкләре менә-менә дерелдәп еларга керешерләр сыман.

Ул да булмый, чыннан да, керфек төпләре яшьләнеп үк китә. Әнием озаграк тукталган битләргә нинди рәсемнәр ябыштырылганын беләм: алардан зур күзле, куе кара чәчле, ирен читләреннән оялчанлык бөркелгән, шул иреннәрне арасына нindидер серләр яшеренгән кебек бөргән яшь бер кыз карап тора.

Әлеге туташ кай ягы беләндер мине хәтерләтә, кай ягы беләндер юк...

Әнием алсу тышлы кечерәк альбомны аеруча кадерләп саклый, алган саен, тышындагы рәсемне сыпырып-сыпырып куя. Ә ул – минем тәүге сурәтем.

Мин дә гаилә архивы булып яшәгән альбомнарны еш карыйм. Әниемнән, кешеләрдән качып моңайган көннәремдә әлеге дә баягы бәрхет тышлысын сак кына кулга алам. Әтинең төсен онытмаска телимме мин? Әллә аныкыннан да үземә хас йөз чалымнарын эзлимме... Үзем дә белмим.

Аеруча соры, яңгырлы көзләрне әнием аш бүлмәсенең тәрәзә янына терәп куелган өстәл янында уздыра. Кояш батканчы көн яктысында утырыйм әле, дигән була. Авыр аш өстәленең түгәрәкләнеп киселгән түр почмагы – әни гомеренең иң белдекле шаһиты. Әле дөньяга тәүге тапкыр аңышып караган көнне дә иң элек тәрәзәгә карап моңайган әнине күргәнмендер кебек.

– Элек мин бу урында язарга ярата идем, ә хәзер элек язганнарымны укып утыруны хубрак күрәм, – ди ул, яшьлек ярларына багышланган истәлек дәфтәрләрен актарганда.

Мәхәббәт шигырьләре кайбер фото артларында да бар. Сыкрануын тышка чыгармыйча, терәлгән яшьтән шешенгән күзләре аларны күзлек аша да укый алмый торса, әни, эшемне бүлеп, мине үз янына чакыра:

– Кызым, укып бирче, синеке матуррак чыга...

Әни кебек илһамланып, җиренә җиткереп, җанын салып сөйләүчене мин белмим дә! Хәер, аның ниндидер аһәңнәре минекендә дә калгандыр, ахрысы. Телефон трубкасына әйткән беренче сүзләремнән чыбыкның икенче башындагы кеше кайвакыт кем белән сөйләшкәнлеген аңышмый да тора, үзен үк сорап шылтыраткан дуслары исә әниемнән, Гөльярга бирсәгезче, дип үтенәләр.

Чәчләренә чал төшә башласа да, ялтыравык, матур, яшьләрнеке кебек калган тавышы аның кәефле көннәрендә бөтен өебезгә нур иңдергәндәй. Келәм җәйгән идәнгә генә утырып, әнинең оекбашы аркылы да җылысы бөркелеп торган уймак аякларын учларыма алып, гөлдер-гөлдер истәлекләр сөйләгәнен тыңларга бик тә яратам.

Әнинең соңгы вакытта кәефе тагын да киткәнрәк шикелле. Яшь чагындагы, эшләп арып кайткан көннәрендәге кебек, азрак сөйләшергә, киң караваты башына утыртып диярлек куелган мендәренә арка терәп уйланып утырырга күнекте.

Эшкә йөрмәгән кешедән дә басынкырак, моңсурак адәм булмый икән лә! Аңа һәрвакыт нәрсәдер җитми, рухын ялгызлык баса, кулыннан эш төшә сыман. Чирләп киткәнгә, күп гомерен өйдә үткәрә башлаган әни белән дә шулайрак. Юкка да үпкәли, әйтәсе сүзен әйтеп бетерми, син үзең белеп сөйләрсең шикелле, ишектән керүеңә, сынаулы караш чыгарып, каршыңа килә.

Ял көннәрендә, мине дәрес әзерләп утырган җиремнән бүлеп, үзем шуны аңламаганга кәефе киткәнрәк бер тавыш белән:

– Кызым, «Галиябану» җырын җырла әле, – дип куя.

Аның яшьлегендә бу җыр теллләрдән төшмәгән, имеш. Хәзер инде тәрәзәдән тартып алышулар бетте, тупсасында баллар да катырмыйлар, егетләр белән кызлар җыр аша да аңлашмый. Заманы узган җыр инде! Тик нигәдер үзем дә бик яратам мин аны. Ул җырны мин, Хәлил кыяфәтенә кереп, әнигә багышлап җырлыйм, әллә шуңа, башкаларын тагын да матуррак җырласам да, әни нәкъ «Галиябану»ны ишетергә тели. Елмаеп, сөюле күзләр белән тыңлый ул мине. Җыр беткәч, сабый баланы иркәләгәндәй, аркамнан кага, битемнән үбеп ала.

– Матур җырлыйсың да инде, кызым! Әтиең кебек... Бала кечкенә чагында кем белән үссә, тавышы шуныкына охшый, диләр иде, ник анысы да әтиеңнекенә охшамаган икән? – ди ул. – Тагын да шәбрәк җырлар идең.

Булмаганны! Әни тавышын ничек уздыра аласың! Анда әниемнең мөнәҗәт көйләгән абыстай әбиләреннән килгән моңнар бар!

«Сиңа тагын мин бер киләм әле» дип, үзем яраткан тагын бер җырны кушымтасыннан алып башлавым була, әни кулы белән генә ишарәләп туктата. Кирәкми, җырлама, йөрәккә авыр итәсең дию.

Бу җырны әтием Кайбыч урамнарының көртле юлларын ерып килгәндә җырлаган икән. Мин иң яраткан көй – әнә шул! Әни җырларга кушмагач, ничек тыңламыйсың инде?!

– Санап кына, тагын бер киләм әле, дип кенә очрашкан кешеләрдән ерак кач син, кызым, – ди әни. – Сине чынлап яраткан кеше бер генә тапкыр килеп күрергә хыялланамыни? Гаилә корасы, яшәп китәсе килә аның...

Әни караган фотоальбомнарда әтием рәсеме юк. Ертып атканнармы аны, үзе белән алганмы – белмим. Әллә ул җырлар Кайбычта – әбиемнәр йортында саклана микән?

Безнең рәсемнәрдә – әни белән мин генә... Гаилә дусларының, әтием туганнарының рәсеме дә юк икән ләбаса бездә! Кайбычка кайтсам, дәү әнидән сорамый каламмы соң?! Әтинең сурәтен булса да бер күрергәдер бит инде миңа!

Әнием кайчак үзен дорфа тота, юкса аңа усал, тупас булу бер дә килешмәгәнлекне дә белә. Ул кәефсез вакытта әти хакында сораша башладыңмы, йөзенә төкселек чыгарып, нindилеген күрәсең килсә, түрдә эленгән көзгегә бар да кара, ди. Анда әтиеңә нәкъ унҗиде яшь, имеш.

Бу кышта миңа унҗиде тулачак. Әти яшенә җитәм... Мәктәпне тәмамлагач, театр училищесына укырга керермен дип торам. Шәбрәк җырларга да өйрәнсәм! Шигырь сөйләргә генә әни дә өйрәтә мине! Тик менә ул, үзе әйтмешли, авыз күтәреп җырлап утыруны бер-бер гаеп, аның кебек олы кешегә килешми торган эшкә саный.

Киңәштек-киңәштек тә репетиторга гына йөрергә дип хәл иттек. Газетадан «очсызга гына дәресләр бирәм» дигән белдерү тапкан идем. Хуҗасы белән телефон аша көнен дә билгеләп куйдым. Май ае җиткәнне генә көтеп тордым да аның янына – музыка мәктәбенә киттем.

...Телефон тавышны бозып ишеттерә диючеләр бар. Шулай да булгалыйдыр, ахрысы. Заһир Зәкиевич минем белән бик теләми генә сөйләшкәндәй тоелган иде: тәгаене генә, тавышны өнәмәде бугай. Моннан нинди җырчы чыксын, дип уйладымы, үтенечемне белдергәч тә, озак җавап кайтармыйча торды. Аннан бер-бер шаярту гына түгелме бу дип шикләнгәндәй:

– Сез минем белән шаярырга уйладыгыз, ахры, – дип куйды.

Ике арада тынлык урнашты.

Аннан телефон трубкасыннан Заһир Зәкиевичның:

– Сезгә, чыннан да, репетитор кирәкме? Тавышыгызны кайдадыр ишеткәнем бар шикелле. Әллә бер-бер яшь танышыммы соң? – дип сораганы ишетелде. – Дәресләрем бик кирәк булса, йөрим дип тәмам хәл иткән булсагыз гына...

Әйтерсең бала-чага шылтыраткан. Ышанмасаң соң, ышанма! Репетиторларны башка җирдән тапмаммы?! Хәер, бөтен таныш-белеш, укырга керәсе җирдән эзлә, кергәндә ярдәмнәре тими калмый, имтиханны да ничек аласыларын алдан ук чамалыйсың, ди.

Юк-бар белән маташырлык вакытмыни?! Шаяру ди монда. Имтихан бирәсе елны дус-ишләр барлыгы да онытылды. Гел йә дәрес әзерләүдә, йә компьютер артында утырам. Әнием олы кешенең шаяртуына да җитди җавап бирергә куша, хәтерләре калмасын, ди. Ул теләгәнчә эшләдем: тавышны тагын да ягымлырак яңгыратырга тырышып, борчылмагыз, әйткән икән, һичшиксез киләм, әнием шикелле, сүздә тора беләм мин, дидем.

Гап-гади генә бер җөмлә сүзне дәвам итәргә сәбәп булган икән.

– Ник, әтиләр сүзләрендә тормыймыни? – дип сорады Заһир Зәкиевич.

Аның сагаеп калганын, тавышына сизелер-сизелмәс кенә калтыравык кунганын тойдым.

– Мин әнине яхшырак беләм шул...

Мине якыннан белмәгән кеше өчен сәеррәк җавап иде бу, әлбәттә. Шаяру да, төрттерү дә, ихлас сүз дә... булырга мөмкин. Әнә шуны ачыклапмы, Заһир абый тагын беравык дәшми торды. Алай да, күпмедер үткәч, трубкадан аның:

– Туташ, минем янга килгәнче, әтиегез белән дә ныклабрак танышыгыз, – дигәне ишетелде.

Без, шулай итеп, уенын-көлкесен, җитдиен бергә кушып сөйләшә торгач, күрешкәнче үк дуслашып та өлгердек.

Яз озак көттермәде, әллә бик тә көткәнгә, быел тизрәк тә килде ул. Планнар корганда, репетиторны ризалатырлык акча табу артык авыр булыр кебек тоелмаган иде дә, әмма туплый алмадык. Әнинең яшь чагыннан ук сакланган алтын алкалары, балдаклары бар иде. Шуларның кайсын кемгә сатты, кайсын ломбардка тапшырды.

Әнием башта кызуканлылык белән, бер дә исе китмәгән кыяфәттә, барыбер тик яталар, модасы гына чыга аларның, син матурларын үзең эшләп алырсың әле, дигән иде диюен, алай да, өйдән чыгып киткәндә, кадерле әйберләре белән хушлашкандай, ридикюленнән алып озаклап карап торды. Аннан моңсу гына:

– Әтиең бүләкләре иде дә... Нишлисең инде... Барыбер синең өчен китә бит, – дип елмайды.

Минем үземә йөрәкле кайма эчендәге пар кызыл ташлы йөзек бик ошый иде. Анысын ридикюльгә кире салмады, сул кулымның атсыз бармагына кидерде:

– Безнең төсебез булсын...

Минем андый йөзекне беркемдә дә очратканым юк! Аларны элек Ташкент осталары ясаган, имеш! Әтием туганнарында уздырган җәйге ялыннан әнигә җылы як төсе итеп алып кайткан. Озак та үтми алар өйләнешкәннәр.

* * *

Дәрескә барганда, Ташкент йөзекләрен ялтыратып фыртланырга уйладым. Әнидән яшереп кенә көзгеле тартмадан алдым да, урамга чыккач, ялт итеп атсыз бармагыма кидем. Кып-кызыл ташлар язгы кояш нурында елкылдап, елмаешып алдылар. Тырпаешкан бармаклар арасыннан нурлары читкә сибелде, йөзләремә, күзләремә сирпелгәндәй булды. Әллә нинди серле, искиткеч матур йөзек иде ул!

Заһир абый эшләгән мәктәп Казанның икенче башында икән. Хезмәтенең хакы юнь булгач, башкаларга шылтыратып тормадым, ризалаштым. Яшь кешегә һава сулап кайту шикелле генә ул, ди әни.

Музыка мәктәбенең авыр калын ишекләрен каерып түгел, ярык кына ачу да җиңел түгел икән. Ярый әле, адымнарын ешайта-ешайта, артымнан кемдер килә иде. Минем кызыл ташлы балдаклы кулым тоткан ишек сабын без аның белән бергәләп тарттык, ишекне сак кына бергәләп яптык.

– Туташ, Сез кем? Кемгә киләсез? – диде әлеге ир-ат русчалап.

Мин Заһир абыйның исемен атадым да, ниндидер сихри көчләр белән тартылгандай, туп-туры аңа карадым.

Затлы киемдәге, дулкынланып торган чәчле, яшькелтрәк күзле бу ир кеше, һичшиксез, музыкант булырга охшаган. Нәзек, хатын-кызларныкыдай бармаклары, кайда тукталырга белмәгәндәй, плащ төймәләре буйлап йөгерешә. Җыйнакланган сакал иреннәренә серлелек биргән, инде чал керә башлаган мыеклар...

Кызык та инде: чигәләренә төшеп торган соргылт дулкыннарда ак бөртекләр бөтенләй күренми, сакал-мыегы агара ук башлаган. Әллә чәчләрен буяп йөртә микән ул?

– Миңа Заһир Зәкиевич кирәк иде, – дип кабатладым тагын. – Аның кабинеты икенче катта, ахрысы?

– Таныш тавыш...– диде ул, соравыма җавап бирәсе урынга. – Гаҗәп дәрәҗәдә охшаш тавыш!

Музыканттыр дип чамалаган бу адәм мине култыклап алды да, үзе белән ияртеп, икенче катка алып менеп китте. Без аның белән, картиналар эленгән коридор буенча шактый баргач, бер ишек төбенә тукталдык. Аннан очраклы юлдашым уң кулы белән ишекне җиңелдән генә этеп җибәрде дә сулы белән бүлмә түренә күрсәтте:

– Рәхим итегез, Луара!

Без икебез дә кемне очратканыбызны аңлаган идек инде. Заһир Зәкиевичның миңа бирәчәк дәрескә ашыгуы булган икән.

Түр өстәлдә кып-кызыл лаләләр куелган зәңгәрсу ваза, як-ягыннан артлы урындыклар тезелеп киткән тар гына бүлмә иде бу. Каршымдагы сул почмакка куелган тумбочка өстендә магнитофон, телевизор, видеоплеер ише нәрсәләр. Түрнең уң ягында – затлы зәңгәр фортепьяно.

Мин мондый төстәге пианиноны әле тәүге тапкыр күрә идем. Аптырабрак калганымны аңлаган остаз:

– Ә мин аны кайчандыр сөйгән кызымның күлмәгенә, күзләренә төс итеп ясаткан идем...– дип, ни хакындадыр сөйләргә талпынгандай итенде дә кинәт туктап калды. Бераздан туры карарга кыймыйчарак:

– Ә бит аның күзләре Сезнекенә охшаган! – дип куйды. – Тик менә чәчләре генә дулкынлы, соры түгел иде...

Заһир абый, үзе дә чишенеп, минем дә киемнәрне элгечкә элгәч, зәңгәр пианино алдындагы урындыкка утырды да аның ак-кара телләренә баскалый башлады:

– До-ре-до-ре-до-о-о...

Мин аны шунда ук эләктереп алып та киттем:

– До-ре-ми-ре-до-о-о... До-ре-ми-фа-соль-фа-ми-ре-до-о-о...

Бераздан Заһир Зәкиевич уйнаудан туктады, зырылдавык урындыгында миңа таба әйләнебрәк:

– Сезнең музыкаль белемегез бар, ахрысы? – дип сорады.

Кайдан килсен миңа белем? Әнинең бар эшләгәне көндәлек кирәк-яракка китә барды. Җавап бирмәдем. Аңлаганын белдереп, ул үзе:

– Ә бит көйне шунда ук эләктерәсез, – диде һәм үз янына икенче урындыкны тартып китерде дә ым белән мине шунда утыртты. – Ни дә булса уйнап карагыз әле, чыгар микән?

Мин моны ук көтмәгән идем. Бала чакта уенчык синтезаторда уйнаган барын бар да... Алай да карышмадым, тегендә-монда баскалап азапланып торганнан соң, бер кул бармакларында гына көч-хәл белән «Галиябану»ны ермачлап чыктым.

– Гаҗәп! – диде остаз.

Нинди гаҗәп! Бу да булдымы уйнау! Колак яфракларына кадәр кызарган бер вакытта тагын да оялтып юри генә мактаган булсыннар әле!

– Әллә уңайсызландыгыз да инде? Аз гына шөгыльләнсәгез дә, Сез, һичшиксез, инструментны үзләштерерсез. Эш анда түгел! Мин бит көтелмәгәнлеккә һич ышана торган кеше түгел, ә бүген әле теге, әле бу фал ачыла да тора! – Заһир Зәкиевичның пианино кырында ябышып калган кулыма текәлгән сурәттә генә әйтелгән сүзләре миңа эндәшүдән битәр үз-үзе белән сөйләшүгә тартым иде.

Заһир абый йөрәк кашлы балдак кигән кулымны саклык белән генә алып икенче кулым өстенә салды, җилкәләремне турайтып куйгандай итте, куллары белән генә иркен сулыш алырга тиешлегемне күрсәтте дә, инде җырлап та күрсәтегез дигәндәй, иякләре белән ым какты.

Андый чакта белгән җырлары да искә төшми бит аның. Йә сүзе, йә көе онытылган кебек тик торасың. Тагын шул гадәтләнгән «Галиябану»дан башладым.

Әллә ничек, рәхәтләнеп, тавышның бу бүлмәдә яңгырап чыкканына кинәнеп, онытылып, үземнән әллә нинди мелизмнар өсти-өсти, үзем теләгәнчә, үзем аңлаганча, әнием яратканча җырлый идем бугай мин аны. Тавышымны яңгыратып кире үземә ишеттергән диварлар, Заһир абыйдан дулкын-дулкын килгән әллә нинди утлар мине сихри бер дөнья үзәгенә әйләндергән иде булса кирәк. Әмма:

Галиябану, сылуым-иркәм,
Кем бәхетенә үстең син? –

дип, икенче куплетны тәмамлавым гына булды, Заһир абый сикереп торды да:

– Зинһар, туктагыз, туташ! Нинди таныш тавыш! Бер генә минутка туктагыз: миңа аның кайтавазлары белән хисләнергә вакыт калдырыгыз, – диде.

Паузаны артык озынга сузуның мәгънәсен аңламадым, өченче куплетны башладым:

Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә, ватып ал;
Сөюләрең чыннан булса,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Тәрәзәдән тартып ал.
Галия...

Иң югары ноталарда кыллары өзелгән инструмент кебек кинәт җырлаудан туктадым. Таныш та булгач, җиренә дә җиткереп җырлагач, тыңларга да тыңларга гына бит инде юкса. Пианино телләре өстенә музыкантның кыелгандай гына маңгае белән килеп төшкән башы туктаткан иде минем җырны.

Көемнең диварлар тотып алган ноталары, инструменттан саксызлык белән чыгарган аккордлар бергә кушылгандай, өермә ясагандай һәм бөтен дөньяны әйләндереп аткандай булды.

Җилкәләре дерелдәүдән туктагач, Заһир абый күтәрелде, бите буйлап агып төшкән яшьләрен селтәп аткан кебек итте дә «Галиябану»ны яңадан башлады. Өченче кат бер үк көй башланган булса да, мин дә аның йөгерек бармаклары уйнаганга яңадан кушылдым:

Тәрәзәдән карыйсың ла,
Карап кемне таныйсың?

Көй ничек көтмәгәндә башланса, шулай ук өзелде дә.

Карап күзең талдырганчы... –

дип дәвам иткән юллар һавада ялгыз кычкырган аккош тавышыныкыннан ким булмады. Мин дә җырлаудан туктадым.

Нәрсә турында булса да сөйләшергә, бу авыр тынлыкны өзәргә, бер-беребезне борчымый торган темалар табарга кирәк иде безгә. Ул сүзләр, ул темалар табылмады да табылмады.

Мин, дәрес башланмыйча да өзелгән санагандай, китәргә дип күтәрелдем, әмма Заһир абый зырылдык урындыкка яңадан утыртты. Аннан уң кулымны сул кулына алды да, икенчесенең баш бармагы белән балдагым буенча йөртеп ни өчендер:

– Шулкадәр туры килер икән! – дип куйды.

Бүтән чак булса, ир-атның мондый гамәлләрен әрсезлек санар, кулымны тупас тартып алыр идем, ә бүген... югалып калдыммы, олы кешене рәнҗетермен кебек тоелдымы, дәшмәдем. Аптыраган бер кыяфәттә аның кыланышларын күзәттем. Еламсырап алган, хискә бирелгән остазны кызганумы, башка бер тойгымы биләгән иде бугай мине.

Заһир абый балдаклы кулымны бераздан җибәрде. Торды. Арлы-бирле бүлмә буйлап йөренә башлады, тәрәзә янына килеп, миңа арты белән басты. Аннан борылмыйча гына:

– Сез Казанда күптәнме? – дип сорады.

Башка җирләрдә торган, күченеп йөргәнебез юк иде. Заһир Зәкиевичның әниемнең авылдан килгәнлеген әйтеп тормадым. Татарча яхшы, чиста сөйләшүемнән ул үзе дә аңлагандыр дип уйлыйм.

Миңа бу көнгә дәрес билгеләп ялгышкан иде ул. Арыганлыгы, нәрсәгәдер борчылганлыгы йөзенә үк чыккан. Икенче вакытта килү яхшырак түгелме, дип әйтүемә инде үзе дә ризалашып баш какты.

Курткамны киеп, сәдәфләрен төймәләп торганда, рәсемен тәгаенләп килгән художник кыяфәтенә кереп, ияген учлап, бик ныклап һәр хәрәкәтемне күзәтте. Ни алай, ни болай димәде. Кысык күзләрендә уйларның да түгәрәкләнеп килүе кемгә дә аңлашылырлык иде ләбаса!

Ишеккә килдем. Саубуллашыр өчен, соңгы тапкыр яңа танышыма борылдым. Мин авыз ачарга өлгергәнче, ул кинәт:

– Әниегезгә әйтегез, тавышы шулкадәр Сезнекенә охшаган! – диде.

Сәер... Минем кемлегемне дә белмәгән мөгаллим... Ә бит ниндидер якынайткыч дулкыннар бар иде арада! Бар!! Бер үк дулкыннарда тирбәлгән остаз күзләрендәге сагыш минем күкрәгемне дә тутырган түгелме соң? Мин, бу авыр минутларны тагын да сузарга теләмәгәндәй, атылып ишектән чыгып коридор буенча йөгердем. Аның, йөрәгемә ук кебек кадалып, акылымны айнытып җибәргән сүзләре артымнан куа килер шикелле иде:

– Ә ул тавышны минем элек тә кайдадыр ишеткәнем бар. Менә бу йөрәк рәвешендәге балдак та... Юк ла, карт кешенең хәтере бармыни аның? Бу саташуга Сез артык игътибар итмәгез инде. Шулай да кайда ишеттем соң мин бу бик җанга кадерле тоелган тавышны? Әллә соң...

– Әллә соң... Сез минем әтиме?

Башыма килгән бу уйларны әйтерлек хәлдә түгел идем. Хәер, әйтүнең кирәге бар иде микән?

Заһир Зәкиевичның «соң, соң...» дип яңгыраган ахыргы сүзләре, җырланып беткәч тә, күңелдә яңгырап торган көй шикелле, мине өемә кадәр озатты. Моңга да ирек кирәк шул! Никадәр матур яңгыраса да, диварлар эчендә ул сула. Чәчләре агарган, күзләре кысылган, йөрәге борчыган эти кебек сула.

Әни янына керергә ашыкмадым. Җан тынычланганчы, хәтердән мең сорауны бер ноктага төйнәгән этием күзләренең яшьле сурәте югалганчы ишегалдыбыздагы эскәмиядә утырдым.

*2006*

## ТИК СИНЕ АЛЫП КЫНА

Зөбәйдәнең көтүдән көтек булган чагы иде, «инде иң ахырга калдыралар икән», дигән яман уй башын сызып узганда гына, ишектән секретарь кызның сипкелле йөзе күренде:

– Тозлы Күл мәктәбе, Сезне чакыралар.

Башка бер чакта татарча дәшкәне өчен генә дә күңеленә ятышлы бу удмурт кызы суд хөкеменә чакырып торучы ишек төбе каравылчысыннан ким күренмәде.

Әнә шуңа да Зөбәйдә томырылып ишеккә ташланмады. Җай гына, ашыкмый гына, чөеп бәйләгән косынкасын рәтләде, итек киерткән кәлүшләрен җайлатыбрак куйганга салынып торды, урындыкта калдырасы киемнәрен тәртипкә китергән булды. Аны инде ашыктыра – эткәли-төрткәли үк башладылар:

– Төн җитә, кызый, урман аркылы чыгасы, утыз чакрым җәяү дә кайтасы бар бит әле. Ярый ла синең авылың борын төбендә генә.

Аның борын төбендә дигәненә дә унбиш километрлап иде, ярый ла әтисе ат җигеп килсә. Көне буе ферма эшеннән бушамаган атларны кümхуҗ рәисе бирер микән, ай-һай...

Зөбәйдәнең ашыкмавы бу очракта куркудан, хәсрәткә салачак минутларны сузудан түгел иде. Әнкәсе өйрәткән доганы кара тимер ишектән кергәнче укып бетерәсе бар. Җитмәсә, сүз катып, фикерен чуалталар, Коръән сүзенең ялгыш теленнән ычкынуын көт тә тор. Урыска рәхәт, итәк астыннан булса да чукына ул, арты белән генә дә төртенә. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла... Көфер китүеңне көт тә тор.

Бәдигылҗамал апа укытучыларның Яңа ел алды хезмәт хакын Зөбәйдә алып кайтачагын белгәч үк кара кайгыга калган иде. Иң элек, Кырказан имчесенә барып, куркулык кудыртты. Аннан, ахири карчыгына кереп, әбисеннән калган бөтине өшкертте. Белгән догаларыннан укымаганы калмады, савабы кызыма булсын дип, бер-ике яңа сүрә дә ятлады. Алар төн буе, берсе – түрдә, икенчесе кече якта район нәчәлникләре каршына барырга әзерләнделәр. Зөбәйдә китапханәдән алып кайткан газета тупланмаларын карап чыкты, Сталин, Берия, Кировларның тормыш юлын өйрәнде. Әллә куркудан, әллә беләсе әйберләрнең күплегеннән башы катты, берсен генә дә ныклап исендә калдыра алмады.

Бәдигылҗамал апа мулла кызы иде. Урыс язуыннан хәбәре булса да, изге тамгаларны хуп күрде, яшереп догасын да укыды, намазын да калдырмады, балачактан ул-кызларына да өйрәткән иде, зыяны тимәде: сөрелгән мулла оныклары дип тормадылар, укырга да алдылар, зур урыннарга да куйдылар. Инде төпчеге Зөбәйдә дә быел үз авылларына мөгаллимә булып кайтып төште.

Ул кайткач, гаилә тагын да бөтенрәк тоелыр, узганның хәсрәтләре дә онытылыр, гөрләшеп кенә яшәп китәрләр кебек иде, әллә кайдан гына «палитически грамытныст» дигән нәрсә уйлап чыгардылар. Шуннан башка эшкә дә урнаша алмыйсың, эшкә алсалар да, хезмәт хакыңны бирмиләр, имеш. Яңа эшли башлаган кызга уку елы башыннан ук бу вазифаны тапшырмаслар дип уйлаган иде Бәдигылҗамал апа. Гел син дигәнчә булмый бит ул. Әллә укыган догалары барып җитмәде, әллә

фәрештәләр ишетмәде. Егерме берендә биреләчәк декабрь аеның хезмәт хакын алырга таң тишегеннән торып Зөбәйдә китте.

Ходай язганны күрми булмас, дип тынычландыра-тынычландыра, капка төбенә кадәр озата чыкса да, кыз күрмәгәндә генә имләгән бөтине пинжәгенең эчке кесәсенә тыкса да, аркасыннан бисмилласын әйтеп сыпырып калса да, күңеле урынында түгел иде әнкәнең. Өйгә керде дә өстәл катындагы урыны җыелмаган сәкегә түнде. Әле карты Фәйзелхак кәнсәләрдән нәрәттән кайтып кергәндә дә, телсез калгандай дәшми генә шул сәкедә ята бирде ул. Самавырны да яңартып җибәрмәде, яңа сауган тәмле сөт кушып ясалган чәйгә дә дәшмәде. Фәйзелхак абый ярым үле-ярым тере хатынына карап-карап торды да, юк-барга аптырагансыз, дип кул селтәп, абзарга – мал-туар арасына, савылмаган сыер, ач бәрәннәр янына чыгып китте.

Хезмәт хакы алачак ай ахыры якынлашканда, укытучы гаиләләрендә ямь китә, бөтен мәктәпне ут йоткандай була. Ул көннәрдә директорның күзе акны карадан аермый, әле район нәчәлникләре каршына бару чираты узмаган укытучылар авыруга сабыша. Моңа кадәр темаңны юньләп аңлатып бетергәнче үк өзелгән кебек дәресләр мәңге бетмәстәй тоела, малайлар тыңлаусыз, укытучының кадере юктыр кебек күренә.

Борчылмаслык та түгел. Синең «палитически наданлыгың» аркасында бөтен мәктәпнең бушка эшләве ихтимал. Һәрберсенең өендә ким дигәндә ике бала күз тутырып икмәк, кием көтә. Әле үзенә тиң ярны тапмаган Зөбәйдә мәктәптә бер генә, әнә шуңа укытучыларның хезмәт хакын алмауны аннан күрүләре аңа үлем белән бер булачак. Бизмәнле авылында яшь мөгаллимәнең үз-үзенә кул салуы да шуның аркасында гына булды дип әле дә сөйлиләр, күңелгә шом салалар, тик кызны кызганасы урынга күбесе җилгә очкан акча турында уйлый бугай.

Уйламаслыкмыни?! Елның уникe аенда бер тиен алмавың ихтимал бит. Аннан мәктәбең белән бауга керәсең генә кала. Тозлы күлләләр алдагы айда да акчадан коры калды...

Зөбәйдә, роно коридорында сигез сәгать чират көтеп утырганда, боларның һәммәсен күңеле аша уздырган иде инде. Ишектән узганда, күңеленә әнкәсенең хәсрәтле йөзеннән, дога укып дерелдәгән иреннәреннән башка берни килмәде. И Ходаем, үзең сакла, дип ычкындыруын сизми дә калды ул. Хәлсезләнгән, арыган кызның сүзләре янәшәсендәге кешегә дә ишетелерлек түгел идеме, әллә удмурд кызы ишетмәгәнгә генә салыштымы, әллә аңлап ук бетермәдеме, әллә инде нәкъ менә аңлаганга, усалрак карап куйдымы, артыннан ишекне шапылдатып япты да кырысрак кына:

– Узыгыз! – диде. Аннан, бүлмәнең уң ягында торган өстәл янына килеп, протокол язарга әзерләнә башлады.

Бу имтихан Зөбәйдә дүрт ел дәвамында биргән имтиханнарга һич кенә дә охшамаган иде. Түрдә, авыр тәпиле имән өстәлләр артында погонлы яшел гимнастеркадан ниндидер таныш түгел ир-ат утыра. Янында – әле август аенда гына Зөбәйдәнең эш сораган гаризасына кул куйган роно мөдире. Аның өстендә дә хәрбиләрнекенә охшаганрак кием. Бары тик түшен орден-медальләр бизәмәү, иңнәрендә погоннар юклык кына иясенең хәрби кеше түгел икәнлеген әйтеп тора.

Зөбәйдә, түргә узарга кыймыйча, бүлмә уртасында тукталып калган иде. Ул инде түземсезлек белән тизрәк өстәл каршына чакыруларын, урын тәкъдим итүләрен, бу җәзаның тизрәк тәмамлануын көтте. Үзләре дә Зөбәйдәдән әллә ни олы булмаган егетләр кызга сорау бирергә дә, каршыларына чакырырга да, урын тәкъдим итәргә дә ашыкмадылар. Бигрәк тә хәрби киемдәгесе, исәрләнгәндәй, аның күкрәгенә салынган калын кара толымнарына текәлгән.

И Аллам, дип уйлады эченнән Зөбәйдә, педтехникумда укыганда, комсомол башлыгына чәч үстереп, толым очына көмеш тәңкәләр үреп йөрү килешми, дип, директор бераз шелтәләп тә алган иде үзен. Болар, имеш, искелеккә бирешүне күрсәтеп тора, капиталистлар белән сугыш-мугыш чыга калса, толымнарыңны барыбер кискәләп атачаклар. Эченнән ризасыз булса да, каршы төшмәгән иде ул чакта Зөбәйдә әлеге сүзләргә, әмма ләкин кадерләп үстергән толымнарын кистереп атарга да ашыкмады. Ерак Себер урманнарында күмелгән әбисенең кадерле тәңкәләреннән иде шул чәч очларына тагылган чулпылары. Шул чакта муен төбеннән генә кисеп ыргыткан булсачы тезгә кадәр төшеп, атлаган саен дулкындай уйнаган кара чәчләрен!

Егет хәрби комиссариат башлыгы булса кирәк. Зөбәйдә аның исемен дә белми, башка җитәкчеләр турында да өйрәнергә оныткан лабаса! Ярый әле завроно сүзне аның белән таныштырудан башлады:

– Сезнең әле очрашканыгыз юктыр, Зөбәйдә Фәйзелхаковна, таныш булыгыз, Хәбир Җәләлетдинович, районның сәяси аңлылыгы өчен җаваплы кешебез ул була инде безнең. – Аннан, янындагы иптәшенә янтая төшеп: – Зөбәйдә туташ – районыбызның яшь укытучысы. Без аңа зур өметләр баглап торабыз. Таныклыгында бер генә дүртлесе дә юк! Мәктәпнең дә көчлесен, зурын сайладык үзенә.

Имтихан бу рәвешчә башланыр дип көтмәгән иде Зөбәйдә. Заврононың күңеленә хуш килүен беренче көннән үк тойды югыйсә. Алай да... нәчәлник нәчәлник бит инде ул!

Зөбәйдә үзе дә сизмәстән алдан ук ятлап куйган шигырен сөйләгәндәй:

– Иптәш Сталин кушканча укыйбыз, эшлибез! – дип ычкындырды.

Бу сүзләр өстәл артындагыларга ошады булса кирәк. Икесе дә елмаеп җибәрделәр.

– Анысы яхшы, – дип сүзгә кушылды Хәбир Җәләлетдинович. – Без нәкъ менә сәяси аңлы кешеләрне генә үз арабызда күрергә телибез дә. Баланың ниндилеге укытучыдан башлана. Әти-әниегез кем соң? Нинди чыгышлы, Зөбәйдә Фәйзелхаковна?

Зөбәйдә телен тешләде. Әтием – мулла баласы дип әйтә алмый бит инде ул. Ярый әле завроно ярдәмгә килде:

– Фәйзелхак абый – районның танылган агрономы, умартачысы. «Кызыл көч»нең алда баруында аның да хезмәте зур. Зур абыйсы Закир Кузбасс шахталарының берсендә инженер булып эшли, диләр. Башкалары да ким-хур кеше түгел.

– Шулай укмыни?! – дип гаҗәпләнгәнгә салынды хәрби. – Алайса, һичшиксез барып күрергә кирәк. Данлыклы гаиләләр белән танышып, яшәү рәвешләрен башкаларга үрнәк итеп кую – безнең бурычыбыз.

Зөбәйдәнең табан асларына ут йөгерде. Өйгә үк барып тикшергәч, зарплатадан җилләр очты дигән сүз инде ул. Юньләп ягылмаган, өйалды тәрәзәләре ватылып, такта белән ямап бетерелгән мәктәпне дә күрсәләр, директорга рәхмәт әйтмәсләр. Ә анысы үчне кемнән аласын белер.

Завроно Сәгыйть абыйсы алдында торган кәгазьне Хәбир Җәләлетдинович үзенәрәк тартты да, ныграк хәтерендә калдырырга теләгәндәй, һәр иҗегенә басым ясый-ясый:

– Зө-бәй-дә Фәй-зел-ха-ков-на кебек чибәр кызлар да сәяси яктан аңлы булмагач, кем булсын, – диде һәм, секретарь кызга карап, русчалап кына өстәде: – Валентина Федоровна, Беренче Конституциябезнең Советларның V Бөтенсоюз съездында кабул ителүен дә, икенче бишьеллыкның халык хуҗалыгындагы социалистик үзгәрешләрне тулысынча тормышка ашырганлыгын да белә ул, язып куегызчы.

Зөбәйдәнең башы әйләнеп, күңелләре болганып китте. Ул һич кенә дә имтиханны биргәнлеген дә, егетләр башының үзенекеннән ким әйләнмәгәнлеген дә аңларлык хәлдә түгел иде, әмма исемлекнең үзе турысына кошчык рәсемен төшергәннәрен аермачык күрде.

Валентина туташка ияреп ишектән чыккач та, тиз генә аңына килә алмыйча, аркасы белән роно стенасына сөялеп торды ул. Биргән сорауларын да ишетмәде, имтиханда сөрлеккәннәрнең буыла-буыла елавына да инде исе китмәде. Бераздан секретарь кыз ул алырга онытып калдырган белешмә кәгазен чыгаргач кына, акылына килгәндәй булып:

– И кызлар, сезгә дә бирергә язсын инде, – диде. Шул вакыт атналар буе укыганнары ап-ачык булып хәтерендә яңарды. Бу минутта нәрсәне сорасалар, шуны сөйләргә әзер иде ул, әмма кызларның йөрәген «сәяси аңлылыгы» белән бозасы, без моның кадәр белмибез бит дип кайгыруларына үзен сәбәпче итәсе килмәде. Алай да җиңел генә имтихан тапшырган дип уйламасын өчен, бик җитди кыяфәттә:

– Сорамаганны калдырмыйлар икән, кызлар, – дигән булды.

Аннан яшьтән кызарып беткән күзләргә, агарынган йөзләргә һаман да карап тора алмаганга, төз адымнар белән беренче катка – бухгалтерия бүлмәсенә хезмәт хакы алырга төшеп китте.

...Зөбәйдәне ай буе ачлы-туклы яшәгән укытучылар дүрткүзләп көткән, ахрысы, өйләренә дә таралышмаганнар, дәфтәр-мазар тикшергәнгә салынып, төнгә дә мәктәптә калганнар. Капка баганаларына бәйләнгән ат пошкыруына уктай атылып ишегалдына чыктылар. Чыктылар да, соң ничек дигәндәй, чүчинкәсен каккалап кардан чистартып торган Зөбәйдәне уратып ук алдылар.

Яңа ел табынын мәктәптә корырбыз, бергәләп бәйрәм итәрбез дигәннәр иде. Ходай да шулай язган икән. Әле яшь, тормыштан тәҗрибәсез Зөбәйдәнең имтиханны уза алуы күпләрне шаккатырган да, аңа соклandырган да, кемнеңдер көнчелеген дә китергән иде, әмма акча барлыгы, ризык барлыгы янында бу хәл вак-төяк кенә булып калды, әкренләп онытылды. Барысының да күңелендә Зөбәйдәгә рәхмәт хисе туу шик тудырмаслык иде. Бүтән чакта «кар кызы – мин дә мин» дигән укытучылар берсүзсез иң яраткан рольләрен кызга тапшырдылар. Кыш бабайның гына кем буласын һич ахырынача чишә алмадылар. Уйладылар-уйладылар да хәл итүне директорга гына калдырдылар.

Яңа ел кичәсенә Зөбәйдәне бергәләп киендерделәр. Директор үз акчасына районнан көмеш укалар алып кайткан, күрше Зөмәррә апасының затлы калфаклары бар икән. Әллә нинди татарча, башка кар кызларына охшамаган кар кызы булып чыкты Зөбәйдә. Күлмәкләре генә башкаларныкы кебек җирдән, актан, крахмал белән катырылган марлядан тегелгән, итәгенә мамык тотып, таштәтәйләр белән ябыштырылган. Ука кушып үрелгән толымнары көмеш тәңкәләрне тагын да ныграк яктыртып җибәрә шикелле.

Менә ул, күкрәгенә салынган толымнарын дулкынландырып, бозга тамган тамчы тавышларын чыгарып, сихри чыңнар чыңлатып, директор бүлмәсеннән залга чыкты, сценарий буенча яшел чыршы төбендә көткән Кыш бабай янына барып басты һәм аларны әйләндереп алган авылдашларына карады. Ниһаять, моңарчы аны көтеп, тынычлык урнаштыргандай, идәнгә таягы белән төрткәләгән Кыш бабай телгә килде:

– Хөрмәтле, тозлы күллеләр, менә без, ил белән Яңа елны бәйрәм итү өчен, шушы залга җыелдык. Социалистик көрәшләрнең тагын бер елы артта калды. Иптәш Сталин җитәкчелегендә...

Кыш бабай сөйли дә сөйли иде. Аның тавышы бик тә, бик тә таныш тоелды Зөбәйдәгә, тик кем икәнлеген генә анык әйтә алмады, борылып, күтәрелеп карарга җөрьәт итмәде. Бу Яңа ел төнендә нәрсәдер булыр шикелле, билгесез хисләргә батып, битләре янып, чыршы төбендә басып торды.

Аның моңарчы беркайчан да бу кадәр гүзәл чагы булмагандыр кебек тоелды авылдашларына. Алар гүя Кыш бабайның сөйләгәнен ишетмиләр дә, Зөбәйдәгә карап сихерләнгәннәр иде. Кыз моны сизде, аның саен ныграк дулкынланды. Нотыгының ахырында Кыш бабай Зөбәйдәнең йомшак кулын үзенең учларына алды һәм бармаклары белән генә балдак сыман бер нәрсәне аның учына салып йомып куйды.

Кыз бу вакытта инде аңа караган һәм үзеннән имтихан алган хәрби кешене танып өнсез калган иде. Җитмәсә, сүзеңне Кыш бабайдан соң сөйләрсең, дип әйтеп чыгардылар бит үзен. Иң кирәк вакытта теле көрмәкләнде, ятлаган сүзләре теге чагындагы шикелле онытылдылар, фикере буталды, әмма үзе дә аңламыйча сөйләгән сүзләр шулкадәр кызык, аның уены шулкадәр табигый да килеп чыкты ки, бу кичә тагын да ямьләнеп, серле бер әкияткә әйләнеп китте.

Зөбәйдә күңеле белән бик олы вакыйгалар көткәнен тойса да, учындагы көмеш балдак әллә ниләр фаразлатса да, Сәгыйть абыйсының дусты Хәбир белән мәктәп капкасына бәйләнгән атларда үзен башка йортка алып китәргә көткәнлеген белми иде. Бу вакытка инде Бәдигылҗамал апа белән Фәйзелхак абыйга да хәбәр җибәрелгән, алар, мәш килеп, олы кунак каршыларга әзерләнәләр, әнкә кеше эченнән туктаусыз догасын укый. Дерелдәгән иреннәреннән генә аның кызы Зөбәйдә район җитәкчеләре каршына имтихан тотарга барган көннән дә кимрәк дулкынланмаганы күренгәндер.

Зөбәйдәнең чәчүргечләрендәге көмеш чулпылар, төн төсендәге толымнар тәмам сихерләткән иде егетләрне. Мөдир Зөбәйдәгә беренче күрүдә үк күз атып калган булса да, дустының үзеннән дә ныграк гашыйк булганлыгын күргәч, сер бирмәде, Тозлы Күлгә кыз кодалап барырга ризалашты. Атларның шәбен, уйнап торганын да үзе тапты. Толымнарда тәңкәләр чыңлатып, гармуннар уйнатып, атларда җилдереп кенә кичәрлек иде бу Яңа ел төне! Тик Зөбәйдәне алып кына яңа көннәргә керер төн!

*2007*

## ДЕПУТАТ ИПТӘШ

Үзе чакырды. Ялгызлыгын онытып торасы килгән көзге көннәрнең берсендә нәкъ менә ул исенә төште. Башка берәү булса, чакырыр идеме, юкмы – билгесез. Ә менә Сабиров тикле Сабировны кунакка чакыру аның үзенә дә бер дәрәҗә кебек тоелды. Ире Фәрит авылга китеп барган бер көнне бу теләкнең башына килүенә сөенеп, дәртләнеп үк китте. Бертөслелектә, акча эшләп, кирәксә-кирәкмәсә мырылдашып узган көннәр тормыштан тәмам ялкытканнар, гомеренең яшьлекне сагынып яшәр елларына кергән иде.

Иң беренче эш итеп, ишек каршында, йөгерткән көмешләренең коелган урыннары белән үзенең хан заманыныкы икәнлеген сөйләп, чекерәеп торган көзгене алып куярга уйлады.

Көзге, картайган саен, юкны бар, барны зур итеп күрсәтә ул, дип уйлады. Хәзерге сурәтләрен күреп, боекмасыннар, кыен хәлгә калмасыннар әле.

Онытылып беткәч... Инде үзгәргәндер... Камилә дә «җиләк чагы»на кереп бара. Каш төпләреннән тырпаеп килеп чыгарга гына торган тупас төкчәләр дә элекке кебек авырттырып йолкынмый. Биткә ягыласы кершән исә бармакларына элекке чактагы кебек җиңел генә буйсынырга теләми.

Зәңгәр сөрмә – үз яшенә түгел, шәмәхәсе – картайта, кызылны сөртсәң – кайгылы итеп күрсәтә. Болай да, эшкә барган саен, әллә төнеңне тагын елап уздырдыңмы, дип каршы алалар. Кызларга кызыл да килешә, дип шаяртырга яраткан Сабиров ни уйлар...

Өстенә яңа гына тектергән шифон күлмәген кигән иде. Җиңел күлмәк җиңел йөрешле итә ул. Аяклары да йорт эчендә кия торган киез башмакларда түгел, чеметтереп кенә баса торган туфлиләрдә бүген. Үкчәләре белән Сабировның рәхәтлектән май баскан йөрәген кадап-кадап кына узсын әле!

Бик алга киткән бер заводның директоры, имеш. Ахирие Галимә, теге Сабиров дигәннәре синең арттан күзен шарайтып йөргән кара-чутыр инде ул, дип тә ярасына тоз салгач, тәмам тәкате корыды. Кабул итү көнен туры китереп, депутатның туп-туры үзенә шылтыратты.

Килер. Килмичә калалмас. Халыкка, менә миңа хезмәт итәргә тиеш ич алар, дип көлде Камилә. Кирәге чыга-нитә калса дип, Сабиров турындагы мәкаләне өстәл җәймәсе астына яшереп куйган иде. Телефон номерын әнә шуннан ачыклады.

Сабиров та картайган. Алай да рәхәт яшәгәне әллә каян күренеп тора: үз-үзен яратып сыпыра торгач, маңгай чәче калмаган, корсагы зур, өстендә – затлы костюм.

Инде менә-менә килеп тә керер. Өстәлгә матур чәчәкләр өмет иткән буш ваза килеп кунды. Ишек янына депутатның аяклары туңмаслык калын табанлы, бармаклары рәхәтлек кичерерлек йомшак

башмаклар куелды. Элгечтән Фәритнең якасы керләнгән пәлтә-костюмнары алынды. Аны хәтерләтерлек берни калдырылмады.

Зал бүлмәсенә шәмнәр кабызылды. Алар бу кичне, һичшиксез, яшьлек турында искә төшереп, хисләнеп, сөйләшеп, матур-матур комплиментлар, теләкләр әйтешеп чыгачаклар.

Сабиров югары сыйныфларда укыгандагы кебек, Камиләне күргәч, тагын югалып калыр микән? Бер сүз әйтә алмыйча китеп, тагын хатлар язып аптыратыр микән? Әллә туп-туры, һаман да яратам, бер тамчы онытмадым, дип ярып кына салырмы? Менә бит Камилә дә, онытылып бетте дигәндә, бөтен хыялларының аңа гына бәйлелеген аңлады. Их, терсәк якын да, тешләп кенә булмый.

Әле беренчедә генә чагында, куркытмакчы булыпмы, Сабиров әлифба битләре арасына кипкән таракан кыстырып куйган иде. Камилә аны алып атмады. Үзенә күрә кызык табып, үтә күренмәле тышлык эченә тирәнгәрәк тыгып куйды. Кирәк бит әй, оныгына китаплар актарып утырганда, киштәнең арткы рәтендә сакланган әлифба килеп чыкты. Анысы тагын Сабиров турындагы хыялларны яңартты. Өченчедә укыганда кыйнап елатканы да, бишенче-алтынчыда өй эшләрен сорап тинтерәткәне дә исенә төште.

Ә менә соңгы сыйныфта укыган елларын хәтеренә тыныч кына китерә алмый ул. Сабировның чибәрләнгән, кызларның күз явын алырдай булган, тик үзе бер Камилә дип кенә өзгәләнгән чаклары иде бу. Кыз гына аны күрмәде дә, ишетмәде дә. Батырраклар, кыюраклар ошый иде әле аңа. Андыйлар зур кешеләр булырлар, космосларга очарлар, заводларны иярләрләр кебек тоелды. Ялгышкан икән. Мокыт кына, җебегән генә Сабировтан башка һичкем кәнәфигә дә утырмады, артык байлык та тупламады, шөһрәтле исемен илгә дә яңгыратмады. Барысы да тормышның тыныч кына агышына риза булып, бала-чагаларына канәгатьләнеп, бер сайлаган хатыннарыннан баш тартмыйча яши бирделәр.

Сабиров әнә алай түгел. Сабиров башка. Сабиров – депутат, зур заводның юан корсаклы, пеләш башлы, шар күзле хуҗасы.

Камилә тагын бер кат бүлмәне күздән кичерде. Инде барысы да әзер бугай. Ямьсезләнгәнен, картаюын исенә төшереп торачак көзгене генә аласы да...

Сөйләшкәндә, үзе дә бик сагынган сыман тоелды. Нинди борчуларыгыз бар, дигән була. Сабиров депутат булгач, борчу кала димени?!

Дөрес, Камиләнең үзе турында тәфсилләп сорашып тормады ул. Барысы да килгәч, Камилә, диде дә, адресын язып алып, телефон трубкасын куйды.

Менә шул сүз хатынның йөрәгенә ут салды. Менә шул сүз аны салкын суларга төшерде. Барысы да, ди бит, барысы да килгәч, Камилә, ди! Онытмаган кара-чутыр. Онытмаган!

Ул чагында шул җебегәннән зур кеше чыгасын белгән булсамы?! Биш бүлмәле фатирында түшәменә, уянып әйләнгән саен, алты тапкыр төкереп ятасын белгән булсамы?! Әйе шул, белгән булса, ул да Сабирова фамилиясен йөртер иде.

Сабиров дигәннән, хәерсез, исеме ничек иде соң әле? Ул, үз алдына сөйләнә-сөйләнә, гәҗиттән исемен табу өчен, өстәл япмасын күтәреп маташканда, ишектә кыңгырау шылтырады.

Кеше-кара күргәнче керер дип, келәне дә элми генә япкан иде – әле һаман алып куярга өлгермәгән көзгедәге ишек ачылып китте дә балачактан ук зур күзләрен тагын да шарлатыбрак, ялтыратып Сабиров килеп керде.

– Минем округтан булуың әйбәт булды әле, Камилә, – диде ул, керә-керешкә, исәнләшеп өлгергәнче үк. – Яңа сайлаулар да якынлашып килә. Синең белән берәр мәкалә оештырып алырбыз. «Балачактан беләм, күңеле гел укуда, кешеләргә ярдәм итүдә иде. Башкаларның тәмәке тартуына да кушылмады, кызлар белән дә шаярып тырай тибеп йөрмәде. Буш вакытында карт-корыга ярдәм итә иде, миңа да укуда күп булышты», – диярсең. Калганын уйлап бетерербез, сайлауга күбрәк карт-коры йөри, әти-әнигә миһербанлы булуымны да язарсың, аларга ул ошый.

Хатын, барысына да риза бер кыяфәттә, җәймәләре дә төшерелмәгән өстәл кырыена таянган сурәттә тора иде. Озак еллар күрешмәсә дә, Сабировны бу гаҗәпсендермәде. Йомшак җенестәгеләрне ул аптырашта калдырырга гадәтләнгән иде бугай. Дөресен генә әйткәндә, урамда юллары кисешә-нитә калса, калынаеп, олаеп барган бу хатынны ул танымый-нитми генә үтеп китәр иде. Ә болай... Нәрсәсен аңлатып торасың! Бер аяк басмаган өйнең ишеген хуҗаларча киереп ачып та керә алгач...

– Депутат була калсам, икенчесендә, билләһи, буш килмим! – дип, Сабиров, көрәктәй кулларын җәеп, Камиләгә таба атлады. – Инде яшьлектә син безгә карамадың, ирең югында бер шәпләп яратсам да ярый.

Камилә телсез калды...

*1999*

## КӘФЕНЛЕК ИНӘСЕ

Ишегалды уртасында талыгып утырган су белән генә кер уарга тотынган Вәрәкыя узган атнада ире Каратун базарыннан алган кызыл кофтасын да чайкап эләргә кирәк санап әйләндергән иде, имәнеп китте: эчке ягында ак җепне әйләндереп-әйләндереп чорнаган инә. Нәрсәгә инде бу? Киелгән кием булганмы? Әллә өр-яңа дип алдашканнармы? Бер-бер ырым-мазар түгелме? Ялгышлык белән кадалган да онытылып кына калганмы? Кара-кучкыл ханым бирде, дигән иде Зәки, чегән генә булмасын тагын...

Инәне, бисмилла әйтеп, хәвеф-хәтәрдән саклаучы догаларны укып, җебен яңадан чорнагач, су буена алып төшеп, ярга күмде. Күмде, күңеле тынычланмады. Ташлап калдырган керләрен уганда да, чишмә улакларында чайкаганда да, ишегалды аркылы тарттырылган бауларга элеп йөргәндә дә һаман шуны уйлады. Исем-фәләнен, авылын да сорап калмагандыр әле дип өзгәләнде ул. Барып сорашса, эчтән сызуы басылыр, йөрәге урынына утырыр кебек иде.

Өйдә хатын-кыз эше калмагач, абзарны, ишегалдын чистарткан, тәртипкә китергән булып йөрде. Кетәклеккә кереп, көртләргә утырган тавыкны пырхылдатып чыгарды. Кәбестә-кыярларга су сипте. Эч пошканы басылмады. Сорау арты сорау туып йөдәтте.

Алъяпкычларын өйалды стенасына каккан кадакка гына элеп, күлмәк җиңнәрен, итәкләрен тарткалагандай итте дә көтү каршыларга чыкты.

– Нихәл, Васбикамал тәтә? – диде ул, бүрәнәләр өстендә хәл алып утырган карчыкка каршы яктан гына кул изәп.

Васбикамал тәтәсе йокымсырап киткән иде, ахрысы: башын күтәреп карады да, аңлаганга салышып, инде мал асрамаса да:

– Әйе шул, көтү каршылыйм, – дигән булды.

Сөйләшерлек сүз тапмагач, Вәрәкыя чөеп бәйләгән яулык почмагы белән кулларын каплап иягенә китерде дә капка баганасына терәлде. Түбән оч ягыннан килә-килә сирәгәеп калган көтүнең башында аларның Күчтәнәче бара.

Алдагы базардан ире Зәки ияртеп кайткан арык мүкләк сыер тәки рәтләнеп килә иде. Кайчан гына эсселектән әлсерәп утырган үләннәр бу көннәрдә яуган җылы яңгырлардан шәбәеп киттеләр, яңадан яшәрделәр, сабакларында сөт-сут артты. Башын хуҗабикәгә суза-суза, авызыннан селәгәй агызып килгән Күчтәнәч капкадан узганда, урыныннан да кучмәгән Вәрәкыя аның аркаларыннан сыпырды, колагына ягымлы сүзләр пышылдады:

– Алла боерса, рәтләнербез әле, – диде ул, сыер белән бер булып сөйләшкәндәй. – Ходай бер бирсә бирә ул.

Әйе, Вәрәкыяны быел бәхет басты. Башкаларның әнә сугыштан уллары да, ирләре дә кайта алмады. Аның баһадирдай ире, бер җире имгәнмичә, күкрәк тутырып орден-медальләр тагып кайтып керде. Гаиләсе бик бетерешкәндер дип уйлаган икән, авызы ачылмаган бәрәңге базын күреп таң калды. Хатынын иңнәреннән кысып күкрәгенә таба тартты. Сары бәрәңгеләр тәгәрәшкән баз авызына карап, берни сөйләшмичә, бик озак бер рәхәтлек кичереп тордылар. Аннан бәрәңгеләрне ала бияне җиккәннән калган яхшы арбага чыгарып салдылар да өстенә Зәкинең солдаттан ияреп кайткан кожанкасын яптылар.

– Булды бу, карчык, – диде Зәки, аны тагын бер кат кочагына алып.

Вәрәкыяның бу кочакта торырга әле дә исәбе бар иде, тик ир дигәне, бер-бер уйга килеп, ки-сәктәнрәк кузгалып китте. Колхоз рәисенә ат белешергә барырга уйлаган икән. Иртәгә базаркөн. Сату яхшы буласы. Ризыкның – юк, ачлыкның чамасыз чагы...

Солдатларның сүзе сүз чак иде. Фатыйх карышып тормаган, бер көнгә генә дигән шарт белән, иң яхшы турайгырны бирергә вәгъдә биргән. Ирле кешенең ирлечә шул дип сөенде аның кош кебек кайтып кергәнен күргән Вәрәкыя да.

Зәкинең таңнан китүе дә яраган, әле башкалар килгәнче үк, бер арба бәрәңгене сатып та бетергән, тагын әйләнеп кайткан, тагын, тагын... Шулай итеп, муеныннан бәрәңге белән тулган баз бушаса да, алар абзарында колача сыер мөгри, иртәнгә чәй эчәрлек кенә сөт тә бирә иде.

Күчтәнәч – рәтләнергә охшаган мал. Инде хәзердән үк йоннары ялтырап килә, арт ягына ит тә куна башлады, сөте дә арта бара.

Ирле кешенең ирлечә инде. Зәкинең үзенә ашарга дип пешереп алган бәрәңгесенә бер хатын, балаларым ач, миңа бир дә миңа бир, дип чат ябышкан. Зәки түзмәгән, әллә жәлләгәнме, ахырдан савыты-ние, тамак ялгарга алган ярты күмәче белән үк китереп тоттырган. Хатын да буш кул белән түгел икән: төенчегенә төйнәгән өр-яңа кофтасын Зәки кулына салган:

– Мә, хатыныңа күчтәнәчкә булыр.

Шул сүз Зәкигә бик ошаган, күрәсең, сатып алган сыерын да өйгә Күчтәнәч исеме белән алып кайтып керде.

– Урыс малы дип, урысча атап йөртмәбез инде, үзебезчә булыр, – диде ул, корчаңгы сыерның маңгай уртасын кашый-кашый, каршы чыккан Вәрәкыяга елмаеп, әмма хатынына алып кайткан бүләге турында әйтергә ашыкмады.

Вәрәкыяда иреннән алда сүз башлау гадәте юк иде, кулындагы төенчекне күрсә дә, нәрсә, кемгә дип сорашмады. Зәки аны барыбер вакыты җиткәч әйтәчәк.

Ишегалды, абзар тирәсендәге эшләрне бетереп өйгә кергәнче, эңгер-меңгер дә төште, кич тә җитте. Бүген алар, Зәки дә арып кайтканга, иртәрәк ятарга уйладылар. Урынны келәткә – каен, җир җиләге, мәтрүшкә исләре аңкып торган, идәннәре агартып юылган, бүрәнәләре әле дә сарылыгын югалтмаган җиргә җәйделәр. Өйдә бала-чага чыр-чуы да юк, каенана бызгысы да ишетелми югыйсә. Вәрәкыя ире сугышка киткәнче авырга узып өлгермәгән, ә иренең әти-әниләре ул килгәнче үк күптән җир куенында иделәр.

Үзеннән алда ире кереп яткан агач сәке кырына килеп утырып, өстендәге күлмәген салыйм гына дигәндә, Зәки хатынының беләкләреннән китереп тотты:

– Ашыкма, җаным.

– Ипләп салам ич, – диде Вәрәкыя, берни аңышмастан.

– Чишенергә ашыкма, мин сиңа тагын бер күчтәнәч алып кайттым бит әле.

Зәки караватка аркылы салынган ястык астыннан гына көндез нәрсә икән дип уй салган төенчекне тартып чыгарды. Торып утырып, аякларына ишелеп төшкән юрганы өстенә куйды. Ашыкмый гына чиште, төенчекне таратып җибәрде һәм аннан бик пөхтә итеп төрелгән кып-кызыл кофтаны алып Зәкиянең иңбашларына элде.

Хатын түзмәде, торып басты, берни дәшми генә кофтаны киде. Әле бер, әле икенче җиңен тарткалап карады. Якаларын төшереп тә, күтәреп тә куйды – ничек тә бик килешле санады. Җыйнак кесәләренә куллары кереп кенә утыра!

Вәрәкыя, бераз ыспайланып торган итенгәч, кофтаны салып, ишек катындагы агач чөйгә элеп куйды да Зәки яткан карават почмагына – идәнгә барып тезләнде.

Ире аның бу кыланышларын яткан килеш кенә, эчке бер рәхәтлек белән күзәтә һәм хатыны ни әйтер икән дип түземсезлек белән көтә иде. Вәрәкыя дәшмәде. Төрле-төрле матур сүзләр эзләсә дә, таба алмады, рәхмәт хисен ничек тышка чыгарырга белмичә, иренең тир бәргән борын очларыннан үпте.

Бер үпте, ике, өч... аннан, гомер булмаганча, тыйнаксызлык күрсәтеп, шашып-шашып ук үбәргә тотынды. Бу үбү үзеннән-үзе күптән көтелгән яратышуга әверелде...

Зәки Вәрәкыяны шатландырудан шушы көннәрдә очынып-очынып яшәп китте. Эшкә дип теләп чыгып китә, хатын янына дип, ашкынып кайтып керә... Кызыл кофта аларның кичке уеннарының бер билгесенә әверелде. Аны көн дә кидереп карап күз рәхәтләндерү, салдырганда, тыны белән Вәрәкыяның колак очларын, муен чокырларын иркәләү Зәкигә дә тәм бирә, дәрт өсти иде.

...Әнә шул кофтаны, тап тиярлек җирләргә киелмәсә дә, Вәрәкыя нидәндер чайкап эләргә булды. Базардан кайтканчы, кеше кулында булганлыгын уйлады да моңарчы кичләрен үзен җылыткан кофтадан тәнен чиркангыч алгандай итте. Талыккан суда чайкаудан гына берни эшләмәс, өр-яңа кала әле ул, диде ул, янына башка керләр җыя-җыя.

Инде шул кызыл кофтадан килеп чыккан инә белән йөрәгенең нәкъ уртасына кададылармыни...

Мал да абзарга керде, савылды, төнгә ашарына салынды, тавыклар да ябылды. Зәки генә һаман күренмәде. Бу атна, күрше Гарифуллага ияреп, тагын Каратун базарына төшкән иде ул. Әбәткә кадәр дә тормам, дигән иде дә диюен. Гарифулла үзе ярты юлдан ук борылган: колхоз рәисе артыннан кеше чаптырган, кайтсын, урманга барырга кеше кирәк, дигән.

Бергә булгач, җырлашып кайтырбыз, дип, Зәки гармунын да култык астына кыстырган булды. Кайда гына йөри соң?! Бер-бер танышларына кереп, салырга уйладымы... Андый гадәте сизелми дә сизелүен.

Төнне шул арада эссе кояшта кибеп тә өлгергән кызыл кофта җылысында, түр өйнең тәрәз төбендә ялгызы үткәргән Вәрәкыя, тавык-чебешне ишегалдына җибәрим дә Күчтәнәчне савыйм дип абзарга кереп барганда, капканың авыр ыңгырашкан тавышына артына борылып карады. Анда ире Зәки сөйләгәнгә охшаган каратут битле бер ханым басып тора иде.

– Исәнмесез! Болай атылып таңнан ник килгән дип ачулана күрмәгез... Сез миннән алган кызыл кофтаны эзләп килдем. Кире кайтарыгыз, зинһар. Бәрәңге хакын көзен булса да түләрбез... Узган айда, ачлыктан үлә-нитә калсам дип, кәфенлегемне әзерләп куйган идем. Инде, Аллага шөкер, сезнең аркада исән калдык, әле колхоздан да бурычка бераз ашлык биреп тордылар.

Хатын тотлыкты, телләре көрмәкләнде, кулларын кая куярга белмәде. Өзек-өзек сүзләрен тыңлау түгел, үзенә, кая куярга белмәгән кулларына карап тору да кыен иде, алай да Вәрәкыя сабырлык белән, күңелендә тагын да арта барган пошаманлыкны басарга тырышып, көтелмәгән кунакны тыңлады:

– Кәфенлек инәсен, алып куярмын әле дип, киелми яткан кофталардан берсенең эчке ягына кададым сыман. Кичә көн буе эзләп, һич таба алмадым да, базарга килгәннәрдән сорашып, таңнан сезнең авылга чаптым. Кофтамны ачуланмыйча кире генә кайтарыгыз, булмаса...

Вәрәкыя, капканың бу ягына узса да, баскыч төбенә кадәр дә килергә җөрьәт итмәгән хатынга берни әйтмичә, аптыраганрак бер кыяфәттә келәткә кереп китте. Инәнең сере ачыклану күңел тынычлыгын кайтармаган иде. Инде, ичмасам, килеп әйтмәгән генә булсачы, дип өзгәләнде ул.

Вәрәкыя кофтаны Зәки алып кайткан рәвешчә бик матурлап төрде, шул ук төенчеккә салды да ишегалдына чыкты. Хатын һаман да капка янында ук басып тора иде. Төенчек күтәреп чыгып килгән Вәрәкыяны күргәч, каушавыннанмы, уңайсызлануыннанмы, тагын үзалдына сөйләгәндәй тәтелди башлады:

– Борчылмаслык чакмыни?! Авылыгызга туры юлдан – Зәхмәт күле аша гына килдем. Әллә никадәр кеше җыелган таллык тирәсенә. Берәүне суга атканнар диме?.. Таныганнар да бугай инде. Кичә базарга гармун уйнатып килеп кергән булган. Шул гармунына кызыкканнардыр инде, диләр. Белмәссең. Дөньяның авыр, кешеләрнең начар чагы. Ачның күзе – икмәктә... Шуны да ишеткәч, абына-сөртенә йөгердем. Бер-бер хәл чыга күрмәсен, гомер буе үземне гаепләрмен аннары, дидем...

*2006*

## КЫЗ КУЕНЫНДА НӘРСӘ БАР?

Унҗиде дә тулмаган Дилбәргә. Ул көнгә тагын ел да дүрт ай бар шул. Сорашкан-белешкәнгә, яшь күренәсе килмичә, туган елын гына атый. Кем исәпләп торып баш ватсын! Кызлар яшен яшерә, кечерәйтеп күрсәтә, диләр тагын. Картаеп, егермедә дә кияү таба алмаганнарыдыр ул. Эчтән шулай уйласа да, кычкырып әйткәне юк Дилбәрнең. Бүтән чакта «сабыем» гына дип иркәләгән әнисенең, яшең – унбиштә, акылың унбиш тиенлек тә юк, дип әрлисе көн кебек. Шул сүздән дә авырттыра торганрагын тапмый микән әллә?

Килмәсә килмәде инде Хәмит абыйсы да, хәерсез. Вагон каршысында ук күрешергә сүз куешканнар иде ләбаса. Менә-менә кочагына ташланам дип, үзе дә атыла-бәрелә чыкты. Шулкадәр ара үтеп, бер белмәгән җиргә килеп, каршы алучың да булмасын әле!

Басып тора торгач, аякларының хәле китте. Йә соңлагандыр, бер килмәсә, бер килер дип, вокзал каршындагы эскәмияләргә таба юнәлде.

Челлә иде. Агач яфраклары астында эсседән качып утыручылар шактый гына. Һәрберсенең үз шөгыле. Дилбәр дә, иннек-кершән алып төзәтенергә кереште.

Хәмит абый дигәннәре артык олы күренә шул. Әтиле-кызлы урам уртасында сөешеп торалар дип уйласалар да гаҗәп түгел. Җитмәсә, һәр килгәне саен, кыз куенында камчы бар, дип көләргә генә тора. Хәер, кайсысыннан көлгәнен кем белә...

Буяуларны тагын да өсти төште. Театрның массовка артисткалары бер читтә торсын, дип көлемсерәде. Тутырып, уч төбе кадәр көзгесенә карады. Уч төбенә аңа дөньяның бөтен матурлыклары җыелган кебек тоелды. Үз-үзе белән хозурланганыннан куркып, күз тимәсен тагын, дип куйды.

Хәмит абыйсыныкына төс итеп чаларткан чәчләрен күперткәләп алды, кашларын рәтләгәндәй итте. Унбиш яшьтә күренү куркынычы тәмам бетте.

Инде атна буе әзерлән-әзерлән дә Казан вокзалында каңгырып утыр, имеш. Авылда да егетләр буа буарлык. Бууын да буа анысы. Ә менә Хәмит абыйсы нәрсәседер белән тарта. Шул авыл буасындагы балыкларны бер тотып, бер җибәреп уйнаган кебек уйнатмавы беләнме, акылы беләнме, еллар үтеп тә күз төшәрлек калган кыяфәте беләнме...

Башкаларга исе китми дигәч тә, аның шәһәрендә дә, кем әйтмешли, егетләр мүрре! Әнә каршы утыргычта утырганы кайсы ягы белән Хәмит абыйсыннан ким? Үзе дә кемнедер көткәнгә охшый. Торып-торып сәгатенә, як-ягына каранып ала. Тотар да үзенеке итәр әле!

Андый чакта бик тә ярдәме тиючән гипнозга кереште. Ерактан начаррак күргән кызлар сыман, күз кабакларын кыса төште дә, алмаларын әйләндереп-тулгандырып йөртә торгач, егетнең кара-чутыр күзләренә китереп терәде. Терәде дә үтәли күргәндәй утыра бирде. Болытлар артындагы урманны күзәтү белән бер иде бу.

Каршыдагы егет тиз генә сихергә бирешә торганнардан булмады, ахрысы. Алай да берзаман түзмәде, үзе дә Дилбәргә, сөзеп-сөзеп, берничә мәртәбә карап алды.

Кыз чак кына «ага, сработало!» дип кычкырмады.

Егет бер утырды, бер торды. Аннан бер-ике адым Дилбәргә таба атлады да гипнозның көчен тоймый башлагандай туктап калды.

Кыз соңгы көчләрен күзләренә туплады.

Чәчәк клумбалары аша кара-каршы атлый башлаган егет белән кыз, тирә-яктагыларны сискәндереп, икесе берьюлы кычкырып көлеп җибәрделәр. Каршысында, чигә чәчләрен каралтып, яшьләрчә юка гына мыек та җибәргән, заманча фырт киемдә Хәмит абыйсы басып тора иде.

*1986*

## БЕР ТӨШ ТАРИХЫ

Хания эсселе-суыклы булып, кара тиргә батып уянып киткәндә, төн уртасы гына иде әле. Яңадан күзләрен йомарга курыкты. Эшкә тотынырга кулы бармады. Алгы бүлмәдән төшкән саран гына яктылыкка карап ята башлады. Йокы ала алмаган тәне белән уйга баткандай булды.

Ул кайвакыт үзе дә моңа гаҗәпләнә: аның баш мие генә түгел, бармакларына кадәр уйлыйдыр кебек, берьюлы мең төрле уй үз юнәлешендә ага да ага. Берсен алып атсаң, икенчесе килеп керә. Йә бөтенесе бергә өереләләр дә болай да сулкылдап яшәгән чигәсенә килеп куналар.

Лампочкаңнан ут саран төшә башлаган, сөртергә кирәк, диде бармаклары. Керү бүлмәсенең обойлары да туйдырды, алмаштыр, диде күзләре. Иркенрәк йокы күлмәге кирәк – тарлыктан үзен уңайсыз сизгән сыман иркә гәүдәсе боргаланып куйды.

Йөрәге боларның барысын да ишетеп тора, әмма башка уйлар аларны үзе аша үткәрергә ирек бирми иде.

Нигә булыр бу төш? Нигә әле таныш булмаган хатын пәке белән йөрәгенә ташланды да, үрелеп тә буе җитә алмаганга, кулларын кискәләргә тотынды? Аннан арыслан кебек ыргылды да йөзен үк кисеп төшерде... Ничек биреште? Кем ул? Кайда күргәне бар? Булмаса, аңа нәрсә кирәк? Төшләре гел чынга аша барганга, башкача уйлый алмады.

Эш белән онытылырга исәпләде. Торып, өен рәткә китерергә кереште. Хәзер ачарга дигән консервларны караңгы бүлмәдән ашау-эчү ягына күчергән булды. Гөмбәләр сирәгәеп калган... Ашата да алмадым, дип көрсенде. Юкса быел бөтен җәе буш булды, ни генә әзерләмәде?! Төрле салатлардан киштәләр сыгылып тора. Ашарга кешесе генә юк... Авылга кайткан саен, кызы, әтием килеп алсын инде, дип аптырата...

Үзе дә сизмәстән, элгечтәге сумканы алып, банкалар тутыра башлады. Унбиш ел гомере кайтканын көтеп ялгыз узгангамы, көндезләрен ул аны, гадәттәгечә, эштә дип уйлый, инде гадәтләре дә үзгәргәндер дип башына да китерми һәм җәйге йортларына күченгән Әлфискә беразга булса да җитәрлек итеп илтеп бирергә җыена иде.

Кинәт бу юклыкның, гадәттәге кайтмый калулары гына булмыйча, чын-чынлап аерылу икәнлеге үзенең дә башына барып җитте. Нинди гөмбә-кыяр кайгысы монда?! Лып итеп ишек катындагы урындыкка килеп утырды. Кулыннан коелган банкалар кайсы таш идәнгә төшеп ватылды, исән калганнары идән буйлап тәгәрәде.

Ач түгелдер әле, диде бер уе. Аңа бүген ризык кирәкмени, диде икенчесе. Йөгерә-йөгерә үзе пешерәдер, бәлешләренә инде синең исемеңне язмыйдыр, диде үпкәсе. Язмаса соң, мине көн дә алдап үпкән ич, дип турсайды иреннәре. Яратам дип мине алдамаганмы әллә, дип куырылды йөрәге. Ялганга күнеккән, әмма иясенә берничек тә аңлата алмаган колаклары очларына кадәр янды.

Һәммәсе үзенчә уйлады, һәммәсе үзенчә борчылды, Хания исә борчылырга теләми иде. Аптырагач, өстәл әзерләп, чәй эчәргә утырды. Бүген иренең эшенә кереп аласы кәгазьләре дә бар. Теләсә, күчтәнәчен дә калдырыр. Бу борчуларның барысы бер көнгә авыр булмагае.

Иртәгесен ишектән чыкканда, күршесен күрүенә шатланып: «Асия апай, шундый куркыныч төш күрдем»,– дип авызын гына ачкан иде, тегесе: «Ай, Хания, шайтани төш булсын, төкерен, сөйли күрмә берүк, алдан күререңне беләсең ич», – диде дә ишектән кереп югалды.

Кара, әллә чынлап та күрәзәче саныйлар инде, дип көлемсерәде күзләре. Булмаганны! Аллам сакласын! Күңелгә бирсә генә инде...

Аяклары баскычка теләр-теләмәс кенә атладылар.

Тиз генә эшләрен бетереп өенә юнәлгәндә, төшенә кергән ханым каршысына килеп басты. Төнге тынычлыгын алган... йа Хода! Кара киемдәге чибәркәй иренең сөяркәсе иде! Шартларга җиткән күзләренә карап, иреннәре ни дияргә белмәде. Хәвеф сизгән аяклары кызуланып ишеккә атлады.

Кара ханымның йөгерә-йөгерә үзен куа килгәнен Хания аркалары белән дә тойды. Хәле китеп тукталды, узар да китәр әле дигән өмет белән, урам кырыена чыгып, юлга арты белән борылды. Карасу-кызгылт тырнакларның пәлтә аркылы да үтеп керәсен аңлаган кебек, болай да кечкенә гәүдәсе бөрешеп калды.

Ул да булмады, артыннан ерткыч җанвар кебек ташландылар. Ул көчкә генә якындагы агачка тотынып калырга өлгерде. Качасы, йөгерәсе, ничек тә ычкынасы урынга, ни эшлисең дигәндәй, куа килүчегә таба борылды, һәм көтмәгәндә йөзен кисеп төшкән тырнаклар эзеннән саркыган кан ап-ак пәлтә якасын кып-кызыл төскә буяды. Аның исеннән тагын да авырайды. Каршы тормаган хатынны кара ханым аның саен тырный, аның саен ныграк куркыта иде.

– Күзләреңне, йөзеңне чукып алам, иреңне алдым, балаңны кочып кычыткан кебек кибәрсең, – дигән сүзләргә ни әйтергә дә белмәде.

Йөзеннән саркыган канны пәлтә җиңе белән сөртте.

– Күрәсеңме, син нинди ямьсез, ә мин нинди матур,– диде ихахайлап кара ханым.– Инде моннан соң ирең дә, беркем дә карамас. Ә миңа бөтен ирләр карый. Бөтен хатынлы ирләр! Ха-ха-ха!

Бу мәсхәрәле, ихахайлы көлү тавышыннан күкләр, урам яңгырады. Кызыл тырнаклар тагын җыелдылар, тагын ташландылар, тагын, тагын.... Иртән генә банкалар тутырылган сумка инде буш иде.

Хания, шул сумка белән йөзен каплап, һаман ысылдаган хатынга берни әйтмичә, урам буйлап китеп барды.

Кара ханым, артыннан җилпенгән саен, аңа:

– Ул – минем ирем, ул – минем ирем, аерыл, аерыл, ул сине яратмый, мине генә ярата, мине генә! – дип кычкырды.

Ханиянең күңеленә җылы йөгерде. Аһ, мин һаман да көнләшерлек икән әле, инде яратуымның үткәнен әйтмәсәң яхшырак, дип уйлады. Сөйсеннәр, көнләшсеннәр, көтсеннәр, минем урынымда – тынгысызлыгымда мәңге яшәсеннәр! Ә миңа иртәгә үк аерылырга кирәк!

*1993*

## ӘТИСЕЗ АЛМА

Иркәне күршеләренә калдырып, Арысланны эзләп чыгарга да булган иде, кире уйлады Сания. Көннәр буе әнисенең итәгеннән төшмәскә, кешеләргә бармаска гадәтләнде кызыкай. Авырып та тора. Ничәнче көн рәтләп йоклаганы юк. Төн уртасында саташып уяна да күзләре белән әтисен эзләргә тотына. Инде эзләп-эзләп әнисен дә таба алмаса, тынычланмас хәлгә җитәчәген көт тә тор.

Йокларга яткыруларыннан өметен өзгән сабыйны караватына утыртты. Киемнәрен чишендерде. Борчылганын сиздермәскә тырышып яткырды да йомшак кына үбеп күзләрен йомдырды. Кызның сулышы тынычланып калгач, аш-су бүлмәсенә чыкты. Ялгызы чәйләргә теләмәде. Суыткычтан үзе оеткан катыкны гына алып эчте.

Тәрәзә төбенә килде. Начар гадәте бар: күңеле тынгысыз чакта һәр күргәнен юрарга гына тора. Бу төндә, Алла кушып, кар яуса, матур гына яшәп китәрбез әле, дигән иде. Ява икән...

Сөенеп елмайды. Яхшылык китерерлек тагын нәрсә бар соң? Күрше йорттагы тәрәзәләрне санарга керешә. Ут элдергәннәре күбрәк булып, әле Арысланның кайтачагыннан хәбәр иттеләр. Каршы юлдан килгән бәхетле пар, чыркылдап көлеп, иренең аракыны ташлаячагын фаразлатты...

Ун тулмаган булса, эше бетмәгәнгә генә тоткарланадыр, иртәнге вәгъдәсен онытмагандыр, Алла боерса, кайтыр дип, сәгатенә карады. Озын теле уникe өстенә җитәргә биш минут бар иде әле.

Юш килгән саен юрыйсы килә башлады. Өстәге каттагы, эт, өреп, иренең әле тәмам кешелектән чыкмавын хәбәр итте. Ул ятканга, мантый пешергән иде. Кайтып керсә, өстәлгә тиз генә утыртырмын дип, аларны җылытып алды.

Эч пошканын басар өчен генә, язгалаган булып утырды. Күршеләрнең стена сәгате икене сукканда да, лифт ачылып ишеккә таба атлаган тавыш ишетелмәде.

Аллага бик ышанса да, намаз-нияз рәтен өйрәнгәне булмады. Әбисенең «авыр чагыңда бар белгәнеңне укып, бисмилла әйтеп багышласаң да ярый» дигәне исенә төште. Чынлыкта да, бар белгәне бисмилла иде.

Стенада эленеп торган шәмаил каршысына килеп тезләнде. Аның күзләре кебек яшел дип уйлады. Ырмавы ул киеп киткән күлмәк кебек көрән... «Иннә фәттаха ләкә мөбинән фәттах!» Гарәп телендә яхшы гына укый, мәгънәсен дә төшенә иде анысы. Шәмаилдәге Алланың берлеген чагылдырган изге язуны туктаусыз кабатларга тотынды, әмма моның да үзен дөньялыктан аерып куярга ярдәме тимәде.

Тагын изге язуның төсләренә игътибар итте, аның күзләре кебек яшел булуына сөенде. Алгарак чыгып торган ияген, дулкынлап уйнаган чәчләрен күз алдына китерде. Кинәт, Аллага табынасы урында иремә табынам түгелме, дип сискәнде. Кайчандыр аның, карларны аллалар кебек ап-ак дип чагыштырган шигыренә абыстай әбисенең бик борчылганлыгын хәтерләде. Аның алдында уңайсызлану хисе яңарды. Алла хакындагы язуларда Адәм сурәтен күрү, һичшиксез, гөнаһ булырга тиеш. Гөнаһ?.. Йа Хода, ул гөнаһлар шушы сурәт белән генә бетсәче!

Сания, таянырга иңнәр эзләгәндәй, бармаклары белән шома диварны кармалый башлады. Гадәттәгечә терәлеп баса торган урынында Арысланның юклыгына әллә ышанмады инде ул?! Бармаклар шәмаил тактасыннан башка һичбер нәрсәне тапмасалар да, бер урында йөренделәр дә йөренделәр. «Иннә фәттаха ләкә мөбинән фәттах!», «Иннә...»

...И Ходаем, бу шәмаил барыбер дә аның күзләре кебек яшел бит! Дәһри ясата инде, ясата. Тез буыннарын җиңелчә генә калтыравык алды, куллары йомшаганын сизде. Шәмаилне Арыслан эшләткән иде. Салкын стенада бердәнбер җылы почмак...

Башын күтәрде. Тагын шәмаилне күрде. Аның күзләренә охшаган дип уфтанды. Хәрефләре кочышып биегән кебек язулардан җан тынычлыгы табарга теләгән иде, җылылык та сизмәде. Дивар салкыныннан үзе дә туңган иде бугай мәгънәле сурәт-хәрефләр төшергән пыяла. Сания, тагын дәһрилегеннән куркып: «Барлыгыңа, берлегеңә ышанам, кызымны бәхетле ит, әтисез калдырма», – дип тәкрарларга керешә. Сыгылып төшеп, дивар буена утырды.

...Күзенә әтисе күренгәндәй булды. Ярсып алҗыган килеш оеп киткәнлеген аңламады.

Сабый чагы, имеш. Әтисе җилкәсенә утыртты. Гәүдәсе җиңеләеп калды. Тәпиләреннән сыйпады. Аяк сызлаулары сыпырып алынгандай булды. Тормыштан арыган җанына җиңеллек йөгерде. Кабат җиргә төшергәч, кулына кып-кызыл алмалар тоттырды:

– Сау бул, кызым, мин китәм инде.

Кинәт әтисенең үлгәнлеге исенә төште. Сары күлмәкле кыз:

– Әтием, китмә, китсәң, мине дә үзең белән ал! – дип, үрсәләнеп еларга тотынды.

«Миңа синнән башка бик читен» дип әйтергә хәле калмаганга, туктаусыз «әтием» дип кабатлады. Әтиле булмагач, бу алмаларның нигә кирәге бар? Ул аларны атып бәрергә теләде. Җөрьәт итмәде. Китеп барган әтисенең моңлы карашын күреп тукталды.

Арыслан кайтса дип ачык калдырылган ишектән кып-кызыл алмалар тоткан күрше хатыны килеп керде. Йокы аралаш «әтием» дип елаган сабыйны да юатмыйча, идәндә тәгәрәгән хатынны күреп телсез калды ул. Бер алманы хатынның эштән кытыршыланып беткән уч төпләренә, икенчесен – Иркәнең әле алма тотудан да сыгылырга гына торган кулларына салды.

– Китмә, китсәң, мине дә үзең белән ал! – диде ханым, хыялында ерагая барган әтисенә үрелеп.

Күрше хатыны ахириенең бу сәер үтенеченә, көтелмәгән хәрәкәтләренә каршы ни дияргә дә белмәде.

Сания, кызыл алмасын суза-суза, аның саен үрсәләнебрәк елый иде:

– Миңа синнән башка бик читен!

*1991*

## АТНЫҢ ХӘЛЕН ТАЙ БЕЛЕР

Комганчы авылының тирә-ягын әйләндереп алган таулар итәгенә әле кайчан гына утыртылган яшь наратлар инде күкрәк киереп басканнар, җилләргә каршы тора алырлык агачларга әйләнгәннәр. Рәсим, әнисе белән җитәкләшеп тәүге тапкыр Комганчы аша узганда, әле алар бөтенләй юк иде. Менә агачлар да, ул да бер дигән егет булып киләләр. Рәсим хәзер бу авыл аша җәяүләп йөрми, әнисе сигезенчене бетерүенә мотоцикл алып бирде. Алар яшәгән Алабай да, Комганчы да район үзәгеннән ерак, бу тирәгә милиционерлар елына бер килсә килә, килмәсә юк, хәер, районда да юлда тәртип саклаучыларны еш очратмыйсың. Менә Казанда эшләр башкача, диләр. Казан Казан инде ул. Зур шәһәр. Рәсимнәр авылыннан анда булган кеше дә берничә генә. Барып керергә туганың, йомышлыйм дигән йомышың булмаганда, анда нишләп йөрергә?! Авылда да бер дигән!

Башкалар машинасының юл тәгәрмәченә чорныйсы акчага мотоцикл-фәлән алуың яхшырак, дигән иде, әнисе шулай эшләде дә. Рәсимнең үзенең дә җәйләрен колхозда борчак чабып җыйган акчасы бар иде, барысы «Восход»ка керде дә бетте, аның каравы кызларның карап торганына, малайларның көндәшенә әверелде. Менә ул хәзер дә, тузан туздырып, авылның юньләп машина күрмәгән казларын куркытып, ак сакаллы карт әлсерәп утырган капка турысына килеп туктады. Мотоциклдан җәлт кенә төште дә, аумасын өчен, тимер тәпиләренә терәде, аннан чалбар кесәсеннән бөгәрләнеп беткән бер унлык чыгарып, картка сузды:

– Әнием садака җибәргән иде, Рәхмәтулла бабай, үзеңә озын гомер, сәламәтлек, тыныч картлык теләде.

Авыл аша узган саен ун сумлык садака тоттыра торгач тәмам исендә калган үсмергә карт бик озак текәлеп карап торды, тик кем баласы икәнлеген һич кенә дә исенә төшерә алмады. Комганчыда кешеләр какча, карасу, ә бу удмурт авылларында үскән егет сыман – җирәнсурак чәчле, йөзе сипкел белән чуарланган, күзләре зәңгәрсу. Дөрес, буйга шактый калку, күкрәкләре киң, беләкләре эш тәмен белгәнлеген күрсәтеп тора. Көрәшчеләргә бай комганчыларга еraктан килгән тумача булуы да бар.

Садака дип. Аны, гадәттә, ялгыз-ятимнәргә, тормышы авырларга бирәләр. Рәхмәтулла картка, уллары-киленнәре белән яшәгәч, йорт-куралары да таза булгач, садака китергән кеше юк, дога-мазар да белми ул, балачагы, яшьлеге дин белән көрәш елларына туры килде. Моңарчы турлары аша елга бер булса да узып киткән үсмердән хәерне аптырап булса да алды, инде менә кулына көчләп диярлек тоттырылган кызыл унлыкны әле болайга, әле тегеләйгә бөтергәләп утыра.

Бераз уйланып утыргандай итенгәч, бер егеткә, бер кулындагы акчага тагын бер карап алгач, Рәхмәтулла карт, ниһаять, телгә килде:

– Яным, садаканы кайтарырлык сорый алмам – бер дә дога-мазар да белмим шул, изгелегем белән дә әллә ни аерылып торганым юк. Герман сугышыннан кулсыз кайттым, гарип-горабаның чит кешегә нинди ярдәме тисен?! Улым хисабында көн күрүем. Ал син бу акчаңны кире, миңа авыр итмә, икенче бер ярдәмчесез калган корткага бирерсең.

Рәсим картның болай дип әйтүен көтмәгән иде, үзе дә югалып калды. Комганчы аша узып та, аңа садака бирмичә үткәнен белсә, әнисе тупса аша да уздырмаячак, барыбер кире җибәрәчәк. Ул Рәхмәтулла абзасының унлыкны сузып торган кара перчаткалы кулын кире этәрде:

– Алай итмә инде, бабакай, әнием үтенечен аяк астына салып таптый алмыйм.

Рәхмәтулланың да нишләргә белми аптыраганы күренеп тора иде. Ул, егеткә тагын да текәлебрәк карый торгач, нәрсәнедер, кемнедер исенә төшергәндәй булды. Әйе-әйе, кайдадыр, кайчандыр күргәне бар иде аның мондый ут күзләрне, туры карашны... Инде шул хакта белешми-нитми генә, егет үтенечен ничек кире кагасың. Ерактан икән – су эчерергә, якын-тирәдән икән – бер-бер танышыңа сәлам юлларга була, дип уйлады ул һәм туп-туры сорау бирде:

– Яным, исемең ничек, әти-әниең кем, кайсы авылдан буласың?

Рәсим ерак Алабай авылыннан икәнлеген, садаканы йортыгыз яныннан һәр узганда бирерсең дип әнисе кушканлыгын әйткәч, карт, нәрсәнедер хәтеренә инде ныграк төшерергә теләгәндәй, тагын бер кат узгынчыга карады. Аннан исән кулындагы шомарткан каен таягы белән аяк астындагы вак-төяк ташларны эткәләргә, арлы-бирле йөртергә кереште. Ара-тирә ул күн бармакларына кысылган акчага «инде сине нишләтергә» дигән кебегрәк караш ташлады. Рәсим, булмады бу дип, китәр якка кузгала башлагач кына, бер-бер уйга килгәндәй, таягын утыргыч кырына терәде дә сыңар учына гына текәлеп бисмилласын укыды һәм, йөзен сыпырып, кәҗә сакалын җыеп тоткан килеш кенә :

– Улым, бар белгәнем шушы бисмилла инде минем, әти-әниеңә, үзеңә хәер-догада калам, – диде. – Җанлы атлар заманы үткән, тимер атлар җигә башлаганбыз икән шул инде, ә бит безне ач үлемнән коткарган җаннар иде бахырлар...

* * *

Рәхмәтулла картның исенә, чыннан да, кылт итеп бер вакыйга килеп төште. Хәер, садака китерү сәбәбен туп-туры сораса, инде йөз булмаса, ун ишеткән әлеге эш-хәлләрне Рәсим үзе дә сөйләп бирмәс идемени?! Ач карынга чишмә сулары да таштай төшеп утырган, бераздан кан тамырлары буйлап тәнеңә таралган, буыннарыңа сеңгән бөтен тозыңны эретеп, тир булып тышка бәргән июль көненең тарихы ул. Кырык өченең чиләсеннән әлеге дә баягы ачыдан ачы тоз вакыйгасы булып әнисе Ләмига хәтеренә кереп калган тарих.

...Очы-кырые мәңге күренмәс кебек тоелган сугыш Алабай авылын тәмам хәлсезләтте. Ни эшкә ярарлык ир затын калдырмады, ни телгә ягып яларлык балы-мае юк, ни туйганчы бер утырып ашарлык икмәге. Көн дә җыя торгач, болын-кыр тирәсендә алабута корыды, киртә кырыйларында кычыткан күренми башлады. Алга таба да юньлеләнмәс дип уйлый башлаган, инде авырлыкка гына әзерләнгән кешеләр булганын бәрәкәтле тотарга тырышты. Елына карата кай көнне артыграк ашалган алабута шулпасы да ризыкны исрафка чыгару кебек тоелган бер вакытлар килде. Шулай да авылга җан исәбеннән тоз, чәй кайта иде әле.

Алтынчыны гына тәмамлаган дип тормадылар, болай да басудан кайтып кермәгән Ләмиганы хатыннар белән бергә район үзәге булган Тәкәнештән Кукмара станциясенә тоз алырга җибәрделәр. Юлга, узасы ара озын, таулы, төнгә дә калса ни очрамас уе белән, кызның ай-ваена карамыйча, башкаларга да сүз салдым әле, мин генә түгел дип, җитмешнең аръягындагы бабасы да кузгалды.

Исәнгилде картның баруы зыянга булмады анысы. Тауга атлаганда, дилбегәне кызы кулына биреп, арттан куалап барса да, түбән төшкәндә, карт ат башын үзе тотты, яшь, усал Ишкараның чыгымлап китүеннән, дуамаллавыннан курыкты. Көн эсселеге хәлне алды алуын, аның каравы баткаклыктан, тәгәрмәч таюдан җәфаланмадылар. Яңгыр күптән яумаганга, юллар шактый шомарган, сикәлтәсез булгангамы, баштарак атлар бик карусыз атладылар, тора-бара чыдамлыклары китте, йөкләрен авырдан тарта башладылар.

Әле алда юлның өчтән бере калса да, көч-егәр шактый кимегән. Мал-туарның кадерле чаклары иде шул. Юлны бүлмәскә дә булгандыр, әмма олылар, киңәшеп алгач, бер карарга килеп, атларның хәлен тәмам бетермик инде, диешеп ялга туктадылар.

Ишкараны, арбасы-ниеннән ычкындырмый гына, башка атлар белән утларга җибәреп, олаучылар янәшәсенә агач ябалдашы астына кереп яткач та, үзеннән дә ярдәм тигәненә сөенгән Исәнгилде карт сугыш турында сүз катты. Тегеннән-моннан ишеткән хәбәрләрен бергә җыеп, фронтта кем кайсы төшкә җиткән, Сталинның оста җитәкчелеге, алдагы җиңүдән соң илгә беркемнең дә басып кермәячәге турында сөйләде. Бу сүз солдаткалар өчен кирәкле, көтелгән иде. Ирләре исәннәре алдагы көрешү көннәрен уйлады, фронттан кайгы хатлары алганнары, әле ярый балаларыбыз исән, дип сөенеште.

Агач күләгәсендә сүз арты сүз китте, истәлекләргә, хыялга бирелеп, хатыннар олауларын ук оныттылар. Әгәр дә мәгәр «тора-бара соңгы атларны да алырлар инде» дигән сүзгә килеп терәлмәсәләр, ни эшләп йөргәннәре исләренә дә төшәсе кебек түгел иде. Шунда гына сабырсызлык белән даны киткән яшь тайның башкалар арасында юклыгы беленде. Ләмига бер бабасына, бер кирегә таба

тәгәрәгән арбадан юлга нечкә генә булып сузылып яткан тоз эзенә карады, аннан шул эз буйлап яшь тай артыннан йөгерде.

Кыз атны куып тотканчы, кояш сүрелде, көн кичкә таба авышты. Җитмәсә, Ишкара санламый, гел ычкына, ирек бирсәң, юлдан читкә ыргылырга гына тора. Атны буйсындырмакчы булып газаплана торгач, Ләмиганың хәле тәмам бетте, шуннан соң ул аны җибәрергә, үзе исә артыннан барырга, һич югы, аны күздән ычкындырмаска булды. Ат бәясенең кеше гомереннән дә кыйммәтрәк вакыт икәнлекне сугыш елында кем аңламасын?!

Инде менә бер узган юлны икенче мәртәбә узып, Комганчы авылына килеп җиткәч, хәле кимегән Ишкараның тау менәргә теләмәвеннән, арбасын ук ватып-җимереп качуыннан курыккан Ләмига капкасы ачык беренче йортка атылып керде дә:

– Ярдәм итегезче! – дип кычкырып җибәрде.

Таш белән түшәлгән ишегалдында бүкән өстендә утырган берәү, өзек кулын угалап, сызланганын йөзенә үк чыгарып, кызга таба атлады. Әлеге имгәнгән кулны күргәч, аның белән бергә Ләмиганың соңгы өметен дә кисеп ташладылар шикелле тоелды, әмма ул ашыга-кабалана барыбер тоз ташучы олаудан аерылып киткән атының үзенә буйсынмавын, бөтереп кенә йөртүен, дуамаллануын әйтеп бирде һәм кулы белән Сослан тавына карап атлаган Ишкарага күрсәтте.

Гарип фронтовиктан ярдәм тияр дип өмет тә итмәгән иде Ләмига. Ир шунда ук ачык капкадан чыгып та йөгерде, ни арада атны куып тотты һәм исән кулы белән башбирмәс хайванның ялына килеп асылынды.

Шунда Ләмига ышанмастай хәл булды. Бердәнбер чын, тансык ир кешене күргәннән күңеле булгандай, ат әллә сабырланып, әллә юашланып калды, башын еламсырап басып торган кызга борды да, томырылып, тирән мәгънәле күзләре белән, әйдә, кайтабыз, болай булгач яшибез икән, дигәндәй карап куйды. Яшел гимнастеркалы ир, ягымлы тавыш белән аңа тыңларга, акыллы булырга кушкач, ат артыннан сөйрәлеп барган дилбегәне Ләмига кулына тоттырды.

Рәхмәтулла тынычланган Ишкараны, яратып, иелгән башыннан сыйпады, тирләгән яңакларына үз яңакларын куеп торды һәм кызга киңәшләрен бирде. Рәхмәтулла абыйсына рәхмәтләрен әйтеп, Ләмига юлга кузгалды, чөнки йортның урам тәрәзәсеннән:

– Улым, кер әле, казан астына ут кына тергезеп җибәрәсе бар, – дип, солдатны чакырганнарын ишетте.

Моңа кадәр Ләмиганы кеше хисабында да йөртмәгән Ишкара хәзер, авыр йөген ризалык белән тартып, бик җай гына, аның көенә генә атлады. Шактый ара узгач, Ләмига бабасының таш кебек шомарган юлдан да сөртенә-сөрлегә генә үзенә каршы килгәнлеген күрде. Дилбегәне аның кулына тапшыргач, Ләмига, сөйләрлек хәле дә калмагандай, хатыннар янына кадәр дәшми-нитми генә барды.

Үзләре ял иткән турыга җитәрәк әле әбәттә генә юлга җеп булып сузылган тоздан бернинди эз калмаганлыгын күреп, кыз бик нык аптырады. Капчыкның бавы озын булган, күчәргә эләгеп әйләнгән һәм өзелгән, тоз капчыктан бушаганчы коелган иде ләбаса!

Арба ярыгыннан нечкә җеп булып коелып барган кире җыеп алмаслык тозны Исәнгилде бабасы, җирдән шуышып, елый-елый ялаган, имеш. Берничә метр ара узгач, картны, юләрләнмә, тоз ашап янасың, үләсең бит, җаваптан курыкма, бер-бер хәйләсен табарбыз, беркемгә сөйләмәбез, дип тынычландырганнар. Ни булса да бергә җавап бирәсен аңлаганнармы, әллә олауга кешенең миһербанлысы җыелганмы, Исәнгилде карт та, Ишкара кебек, вакытлар узгач, басылган.

Инде менә хатыннар Ләмиганы, елама, атың исән калганга сөен, тозга хәзер үк дым сеңдерәбез дә авырлыгын тутырабыз, дип юатырга тотындылар. Ләмига аларга ышанды, үз күргәннәрен сөйләп бирде дә бөтенләй тынычланып калды. Тозны тапшырып, атны бакча артындагы утарга җибәргәндә, бабасы, пырдымсыз малны тотып биргән адәмгә исән чагында, кешечә яшәсәң, узган-барганда садака бирерсең, диде. Ул әманәтне, үз чиратында, улына тапшырган иде.

*2009*

## РӘСЕМ

Мәктәпнең унъеллыгын билгеләп узу алдыннан фотосурәтче чакырттылар. Саллысын. Студент альбомнары, чыгарылыш кичәләре өчен китапчыклар ясап дан алганын. Завучны да, кайбер башка мөгаллимнәрне дә урта яшьләрдәге Рафилә ханымның чыгымчылавы бик туйдырган иде. Авырып килмәгән көненә җайларга тырыштылар.

Пәнҗешәмбегә планлаштырдылар. Килеп чыкмады. Директор белән яраткан укучысы көтмәгәндә командировкага китеп барган икән. Ул арада Рафилә ханым да аның үзеннән үк юбилей уңаеннан сурәткә төшәселәрен белеп алган һәм чакырмауларына үпкәсен җиткергән иде. Барыбер килә алмасын белгәнгә, бу юлы әдәп йөзеннән генә дәштеләр дә, инде дәресләре бар җомганы чамалап, тагын җыйналдылар.

Ниһаять, Рафилә ханым белән Алиядән башкалар барысы да иң матур киемнәреннән алдан әзерләнгән бүлмәгә кереп тулдылар.

Андый җирләрдә башлап йөрергә яраткан иң яшь укытучы гына юк иде. Ә Алиядән башка һич ярамый. Заврононың сөяркәсе булмагае, дип уйлады аның хакында директор, һичшиксез күтәргә кирәк, фатир да алып биргән үзенә, киеме дә үзе эшләгән акчага гына тиярлектән түгел...

Аның белән эш эшләп була, мәсьәлә кемнең кемлегендә түгел, нинди сүз йөрмәс, ике арага кереп ятмаганнар лабаса, ояңа үз төлкеләреңне тупларга, олыларга каршы торырлык бер йодрык булырга да уңай моментта урынына китереп сугарга дип уйлады завуч. Безнең көн килде, өлкән буыннан пот ясаганнар әнә шул Рафилә ханым хәлендә калмагае...

Яшьлеге белән күз явын алган Алияне күтәргә башына чал төшкән география укытучысы да, математик мәсьәләләрне кызлар саныннан башка күз алдына да китерә алмас хәлдәге җитмеш яшьлек Андрей Петрович та риза иде.

– Күтәргә кирәк, күтәргә! – диештеләр алар бертавыштан. – Бер коллективта эшләп, ничек инде гомергә бер килгән бәйрәмдә кемнедер кертми каласың.

Әлфиснең күңелендә Рафилә ханым сурәте торса да, борчылганын тышка чыгармаска тырышты, башкалар кебек үк, Алия турында өзгәләнгән булып кыланды. Мондый очракта гадел укытучыны телгә алуың белән генә дә дошманнар исемлегенә керүең бар. Иртәгесе көн – алар кулында, бүгенгесен әйтәсе дә юк, дип уйланды ул. Әйе, әйе, күтәргә кирәк, күтәргә!

Һәркем эченнән генә урынын директор, завуч һәм исемсез килеш кенә дә алардан өстәрәк торган Алия туташ янәшәсендә күрергә теләде. Сурәтче тегеләй бастырды, болай. Ничек тә килешмәгәнгә салышып, әкрен генә җитәкчеләргә таба елыштылар.

Моңа кадәр үз укучыларын читтәнрәк, көлебрәк тә, гаҗәпләнебрәк тә, озын гомер юлы үтеп кешеләрне яңа аңлагандай күзәтеп торган Рузия ханым да, ниһаять, үзенә лаек урынны алды. Аның акыллы карашын, мәгънәле елмаюын рәссам тотып алган һәм иң алгы рәткә үз кулы белән көчләп дигәндәй утыртып куйган иде.

Ярты сәгать кымшанмыйча гына, фотога төшәргә әзерләнгән хәлдә Алия ханымны көттеләр. Ул, әле яңа гына йокысыннан торып килгәнлеге, кайнатмыйча эчкән чәенең чынаягы да юылмыйча калдырылганы һәркемгә билгеле булса да, эш кырган кеше сыман ашыгып кына бүлмәгә узды, ефәк киемнәрдән арынгандай гына пәлтәләрен салып атты. Юк, атмады. Аның тирәсендә бөтерелгән секретарь белән пионервожатый туташкайның озын тырнаклы бармакларыннан суырып кына алдылар да, елмаеп сәлам биргәч, өф-өф итеп кенә урындык аркасына элделәр затлы пәлтәне.

Мең кат тезгәч тынычланган укытучылар тагын гөжләргә, яшь туташка үз яннарыннан урын тәкъдим итәргә тотындылар. Остазия ханымның күңелен Рафиләнең юклыгыннан бушлык хисе биләде. Ул үстергән, баласы кебек яраткан, иң талантлы, иң булдыклы дип санаган мөгаллимәгә бу киң бүлмәдә дә урын юклыгыннан гаҗизләнде. Коллективның нindилегендә аның да өлеше бардыр сыман газаплану хисләре кичереп утырды.

Фотосурәтче штативка куйган аппаратның төймәсенә басканда, Рафиләнең соңгы дәресе тәмамланган һәм ул әлеге бүлмә каршысыннан узып бара иде.

– Апа, Сез күлмәк мәҗлесенә өлгермәдегезмени? – диде аңа үзен якын иткән бер укучысы, шаярткандай итенеп.

– Күлмәк, нинди күлмәк?

– Маймыл елы бит бу ел, кешеләр күлмәк киеп, күлмәк биреп, күлмәк алмаштырып уйный... Шуны рәсемдә калдыра.

Укучы авызыннан тупасрак яңгыраган әлеге сүзләрдә ниндидер мәгънә дә бар иде, ахрысы.

Юбилейлар узды. Рәсемнәр китапчык булып чыкты. Укытучылар бүлмәсендә истәлек альбомын карап торалар иде. Практикага килгән бер студент:

– Алия апаның күлмәге нинди матур! – дип әйтеп куйгач кына, ул моны тәмам аңлады. Фотосурәткә карады. Кулында әйләндергәләп торды да, чит кеше әйберенә кагылгандай сискәнеп, кире өстәлгә куйды.

Алиянең күлмәге матур, яшәү рәвеше белән мәңгелеккә әзерләнгән остазының күзләре акыллы, һәм аларны дөньяның маймыллар кулына калуыннан сагыш баскан кебек күренде.

*2003*

## ТАҢ ҖИЛЕ

Ул, нәни чиләкләрен күтәреп, су буена төшеп бара иде. Баш очындагы кып-кызыл бантигы тыпыр-тыпыр атлаган саен сикергәләп куя. Ике толымчык итеп үргән чәч очларында да шундый ук бантиклар. Алары бу нәни кызчыкның юка җилкәләре аша әле алга, әле артка сикергәләп уйныйлар. Күзләре батып барган кояш кебек уйчан, иреннәре дымлы. Мин, гәүдәм авыраеп барганын да онытып, киртә

аша сикереп чыктым да, нәкъ каршысына – ул төшеп килгән сукмакта туктап, аның берничә адым атлаганын көттем. Сабый, җиткән кызлар кебек, күкрәкләре өстенә тын алырга яткан толымнарын артка ташлады да, бөтен горурлыгы тулган ияхләрен күтәреп, иреннәрен бөрештерде. Нидер дәшәргә уйладымы, юкмы – иреннәре шул халәттә хәрәкәтсез калды. Ул үзе дә мине күзәтә иде бугай.

Кулларымның көрәк кадәр зур булуын иң беренче тапкыр күргән кебек югалып киттем. Аларны кая яшерергә белми озак газапланганнан соң:

– Исәнме, үскәнем, исемең ничек? – дип, кызчыкка суздым.

Ул күрешергә ашыкмады. Күз алмалары, инде туар кояшка әйләнеп, нур бөркеп алдылар. Ирен читләренә серле елмаю җәелде. Шулай бераз торганнан соң, нәни генә чәнти (!) бармагын ирен очларына китерде дә:

– Тс-с-с... Ә син кем? Кемнең этисе? – дип пышылдап, соравыма каршы сорау бирде.

Бу авылга очраклы гына килеп чыккан ялгызак кунак идем. Кызчык та, мин дә сүзсез аңлаштык, ахрысы. Кабат җавапсыз сораулар бирешмәдек. Әмма бераздан:

– Зөфәр абыең мин, үскәнем, – дидем. Кыз төшеп килгән юлга чалкан ятып, гәүдәмне кулларыма терәдем. Болай түбәннән караганда, миңа ул тагын да ныграк ошый, тагын да нәзакәтлерәк күренә иде.

– Кызык, бу авылда һәркем малай дип эндәшә, алайса, Сез дә, минем кебек, кунак кына, – диде кыз, фаразы дөрес чыкканлыкка ишарәләп. Аннан ярым пышылдап, бераз шаяртканга да салыныбрак, әллә көлүемнән шикләнепме: – Ә мин менә таң җиленә төшәм әле. Чәчәкләр уянганда, таҗларына кунган җилне, яр буендагы үләннәрнең башын игән җилне җыеп каласым бар.

Шаярту булдымы бу, юкмы – белмим. Аның чиләкләрендә дә – җил, җилдә уйнаган күбәләкләр рәсеме, тып-тын иртәдә дә чигә чәчләре сибелгән, керфекләре нидәндер тибрәнә иде бугай.

Менә кыз сак кына минем аякларым аша атлап чыкты. Әйтерсең, итәгенә ял итәргә кунган йомшак җилләр минем керфекләремә дә коелдылар.

Шулай да ул тиз генә китәргә ашыкмады.

– Телисеңме, бергәләп җыябыз, – диде, нәни чиләкләрен сузган итеп. – Тик син минем әниемә генә әйтмә. Ул йокыдан торганчы, мин көн дә аның чәчләренә таң җиле сибәм. Сез беләсезме, таң җиле уяткан кеше бер дә картаймый икән. Әниемә, авылга кайткан саен, гел яшәреп китәсең, диләр. Аны көн дә таң җиле сибеп уятам. Кайвакыт керфегенә төнен ялгыш чыккан яшьне, матур сүзләр пышылдавым була, шунда ук сөртеп куя ул. Әллә таң җилеме син, кызым, дигән була.

Бу нәни танышым мине тәмам аптыраашта калдырды.

– Нинди сүз ул? – дидем мин, җитдиләнеп.

– Хәерле иртә! Хәерле иртә! – диде дә кыз, кыр кәҗәсе шикелле сикерә-сикерә, чәчәкле яр буена йөгерде. Зәңгәр чиләкләре зеңли, кызыл бантлары менә очам, менә очам дип талпына, аяк тавышлары лепер-лепер...

Йомшак кына җил исеп куя. Инде кыңгырау чәчәкләре дә зеңелдәүдә, шук күбәләкләр чәчәкләр өстенә күтәрелә, агач яфраклары да лепер-лепер... Өнемме-төшемме, дим мин, тәмам исәнгерәп. Аннан торып басам да җиләк җыйган кебек чәчәкләр арасына иелгән кызга:

– Исемең ничек, үскәнем? – дип кычкырам.

Ул да булмый, сукмакның икенче башыннан йокы күлмәгеннән генә, кечкенә буйлы, какча гәүдәле, каратутлы бер ханымның:

– Таң-гөл, Таң-гөл! – дип дәшкәне ишетелә.

Ул әллә мине күрми, әллә күреп тә игътибарга алмый. Озын итәкләренә сөртенә-сөртенә кызы артыннан йөгергәндә, мин сукмак читендә чак егылмый калам.

Менә алар бер-берсенең кочагына атылалар.

– Кызым, мин сине югалттым дип торам, – ди ханым. – Беркемгә әйтмичә, иртә таңнан каядыр китеп, шулай озак торырга ярыймыни? – Бу сүзләрдә шелтәләүнең тамчысы да юк.

Минем аякларым үзләреннән-үзләре аларга таба атлый.

– Гафу итегез аны, мин озаграк сөйләштереп тордым шул. Ул Сезне уятырга соңга калгандыр, – дим, килеп җитәрәк. Аннан әлеге дә баягы көрәк кадәр кулларымны сузам: – Зөфәр.

Ханым бөтен гәүдәсе белән шул учларыма сыеп бетәр кебек җыерыла. Дерелдәгән куллары күлмәк изүен капларга азаплангандай итенәләр дә кисәк кенә миңа үреләләр:

– Таңсылу...

Мин икенче кулымнан кечкенә кызның килеп тотканын тоям.

– Әнием, Зөфәр абый беркемнең дә этисе түгел, – ди Таңгөл, көтмәгәндә.

Аның чиләкләреннән качкан таң җиле җаннарыбызга үтеп керә, йөзләребездән иркәли...

*1994*

## ЯМАУЛЫК

Әбиемнән мирас булып күчкән сандыгым төбендә гомер эчендә бер киелмичә алып куелган күлмәкләрем, чүпрәккә сүтелгән кофта, чалбар ише нәрсәләр ята. Әнә шул кырлары җиз, көмеш төсенә буятылган калайлардан бизәкләп эшләгән агач хәзинә савытының кырыенда ике кесәсе бар. Алар – узган гомеремнең чуар көннәреннән үзем белән хәзергемә күчкән кадерле истәлекләр.

Кием-салымны алып кайтуга ук, эченә тегелгән ямаулыкларын кисеп алып, пөхтәләп үтүкләп, әлеге кесәләргә салып куям мин. Өйдә тегелгән әйберләрнең калдык-постыклары да, төрле чүпрәкләрдән кисәкләр дә – барысы шунда. Әни кечкенәдән сеңдергән гадәт буенча саклаган ямаулыкларның кайсын гына файдаланганмындыр – әйтә алмыйм, әмма ялгыз калып моңга баткан көннәрдә, сандык янына килми калмыйм. Әлеге чуар-чатыр чүпрәкләрнең һәрберсен тотып-тотып карыйм, уйланып утырам. Кайвакыт, юк кына нәрсәләр искә төшеп, еламсырап та алгалыйм.

Дөресен әйтим: каенана йортына «мондый искелек калдыгын» ияртеп килүне ирем баштан ук ошатмаган иде, чыгарып ташла, дип әйтеп-әйтеп карады да, тыңламагач, кул гына селтәде. Әнкәйгә карап, үзегез беләсездер инде, сезгә ярагач, миңа ни, дип әйтте дә бу хакта кабат сүз кузгатмады.

Сандыкны авыр тактадан үзенә иш итеп ясалган өстәл кырына – кеше күзеннән яшерерлек итеп куелган суыткыч артына урнаштырдылар. Өстенә алтын белән каеп эшләгән әбием камзулын яптым – суыткыч арты музей почмагына охшап калды.

Хәер, сандыкның башкача кирәге дә чыкты. Каенанам, олаеп китеп, аш бүлмәсенә бик авырлык белән килә башлагач, урынны аның өстенә генә җәйдертте. Әле кайчан гына сабантуй колгасы кебек туп-туры йөргән, озын зифа буйлы карчыкның кечкенә бер сандык өстенә сыярлык калуы җанны тырный, картлык, киләчәк турында уйлата иде...

Инде менә ул да, баштарак сандыкны эченнән дошман күреп яшәгән ирем дә юк. Балаларның да кайсы кая таралышкан. Мин чүпрәк-чапракларым, истәлекләрдән корган хыял дөньямда ялгызым яшәп калдым.

Әнкәмнән калган мамык, плүш көртидән бер мендәрчек сыман нәрсә әмәлләгән идем. Җомга көннәрендә үлгәннәр рухына догалар укыштыргач, дус карчыкка хәер дә кертеп чыккач, әнкәмнең тән җылысын саклаган сандык кырында – идәнгә салынган киез өстендә – истәлек әйберләрне, ямаулык-чамаулыкларны караштырып, кием төзәткәләп, кайсыннан нәрсә ясап, уйланып утырырга гадәтләндем.

Сандык эчендә минем өстемдә йөргән күлмәкләрнең берсеннән генә ни ямаулык, ни сәдәф, ни итәкләренең яңарак калган бер почмагы сакланмаган. Моның да кечкенә генә бер тарихы бар.

Мари урманнарының сурәте төшерелгән креп-жоржет күлмәкне мәрхүм ире Габбас шул якларга экспедициядән бүләк итеп алып кайткан иде Маһинурга. Заманына күрә, һай, килешле, һай, затлы иде ул! Эшендә – көнләшмәгән бер кыз, урамнан узганда күзе төшмәгән бер ир-ат калмагандыр, Маһинур әлеге күлмәкне кигәндә.

Еллар узды, Маһинур да калыная барды, әмма киң фасон белән тектерелгән әлеге күлмәк өстенә һаман да килешле ята иде. Ни тараймый, буйга үзгәрмәгән хатынга кыскаруы турында әйтәсе дә юк!

Маһинур дачага киткән бер көнне Габбас, өй эшләре белән генә маташам дип, шәһәрдә калган иде, бауда кибәргә эленеп калган керләрне дә үтүкләгән, имеш тә, үтүге әлеге матур күлмәкнең итәкләрен бер җирдән эретеп кенә узып киткән... Яраткан киемен югалтудан елар дәрәҗәгә килсә дә, Маһинур үз-үзен, кысасыннан бер дигән кофта чыгачак, дип тынычландырды һәм шул кичтә үк тегеп тә өлгертте.

Кофта да ни искерә, ни туза белмәде. Маһинур өстендә ике көннең берендә иде югыйсә. Туган көнендә чәчәкләр янына тагын бер шундый ук затлы тукымадан өр-яңа күлмәк тә күтәреп кайтып кергән Габбас ни өчендер:

– Мәдинәнең дә теге креп-жоржет күлмәге һаман да тузмый икән бит, – дип әйтә куйды. – Васыйл керне үзе үтүкләмидер шул...

Габбасның ярым көлеп, ярым чынлабрак әйткән сүзләренә ул вакытта артык игътибар да бирмәгән иде Маһинур. Алай да берзаман үзе үк, шифоньерда бер киелмәгән дистә күлмәкләр эленеп торса да, гел ире алып кайтканнарында гына йөрергә тырышканын аңлады. Еллар дәвамында шул көрән кофтада эшкә бару бер дә килешми иде. Хатын тыгыз тукымалы бер сумка текте дә мари күлмәгеннән калган итәкнең исән өлешләре белән тышлады.

Чүпрәк букчаларның модага кереп барган бер вакыты иде. Киндергә кеше башы төшерелгәннәре, чит ил сүзләре язылганнары да җитәрлек, тик менә креп-жоржеты – бары тик анда гына! Тора-бара яңадан күн сумкалардан гына йөри башладылар, әмма креп-жоржет капчык әле дә тузмаган иде. Шулай булгач, ничек җан кычкыртып ташлыйсың инде! Аны күтәреп инде авылга, дачага чаба башладылар.

Габбасның чираттагы ялга чыгар көннәренең берендә Маһинур, диңгез буена бара-нитә калсак, юньле купальнигым да юк икән бит, дип уйланды. Ә нигә әнә шул кофтадан калган, капчык тышлаган креп-жоржеттан гына текмәскә! Уйладымы – эшли инде ул. Габбас кайтканчы, ике катлап, бер кешедә булмаганча, замоклар куелып тегелгән купальникны үтүкләп өстенә кияргә үк өлгерде. Ишекләре күршеләрнекеннән аерып алынган булганга, аны күрүче юк иде – иренә ишекне ул әлеге купальникта гына ачты:

– Исән-саумы, бәгърем!

Габбас бер – аның шәрә, комлы яр өстендә кояшта кызынырга ымсынган аксыл аякларына, бер җиләс җилне кертергә әзер күкрәкләрен каплаган купальникларга карап-карап торды да:

– Карчык, купальнигыңны тузгач әрәм итмәссең, яме, трусик турысыннан миңа кульъяулык тегеп бирерсең! – дип шар ярды.

Әлеге купальник икенче таңда чүп төяргә килгән машина иңендә, искергән киемнәр, башка тукымалар кочагында Самосырово «каберлегенә» китте.

Әгәр Маһинур үзенә якын, инде җан иңгән кебек мари купальнигын озата бара алган булса, кичке якта чүплектә казынган бер ирнең, аны кулында җилфердәтә-җилфердәтә, алачык каршында сөяк-санактан аш пешереп торган, иреннәрен шәфәкъ кояшы кебек кызылга буяган бер хатынга таба: «Сиңа миннән туган көн бүләге!» дип йөгергәнен күргән булыр да иде, әлбәттә. Маһинур моны күрми-ишетми, әрәм булды дип моңаеп, тәрәз каршысында айга карап утыра иде...

*2006*

## ШӘҺӘРСКИЙ ТОРМЫШ

Шәһәрдә яшәү Кәүсәриянең балачактан килгән бер хыялы иде. Кардан өй ясасалар – аныкы кала өе булыр. Мәктәптә irекле рәсем бирсәләр – ул үзен шәһәр автобусыннан бөдрә йонлы эт ияртеп төшеп килгән бер кызчык итеп сурәтләр. Курчак киендерсәләр – анысына марҗа исеме кушар, тырнакларына кына йөгертер, битләренә кершән ягар. Кызчык тудырган хыялда берни эшләмәгән, рәхәтлектә генә яшәгән шәһәр хатыннары да, баскыч төбендә гайбәт кенә сөйләшеп утырган карт-коры да, тырай типкән, матур киенгән кызлар иде. Ул бу хыялны җәй саен Казанда яшәгән ераграк бер туганнарына барып ныгытты, кинолар карап матурайтты, үзеннән яңа бизәкләр өстәп чуарлатты...

Шәһәрдә торса... Шәһәрдә торсамы?! Шәһәрский тормыш була инде, билгеле! Җәяү йөрмисең, ашарга пешермисең, керне дә машина гына юа, капка төбен дә дворник кына себерә... Сиңа урам тутырык малайлар күз елтыратып кала, ишегалдындагылар, күршедәгеләре «бөдрә йонлы көчегеңне бер тоттыр әле» дип йөдәтәләр. Көндезләрен һава суларга чыккан саен, мороженое алып ашыйсың. И-и-и, аның шәһәрдә башкасы да җитәрлек! Пляжга барып купальниктан йөрсәң дә, беркем көлми, кыска итәк киеп уйнасаң да, беркем гаепләми!

Әле сигезенче-тугызынчыларда укып йөргәндә, Кәүсәрия йокыдан уянган вакытларда, үзен затлы чүпрәкләргә төрелгән бер бүлмәле фатирның капрон чыбылдыклары эчендә яткан итеп күз алдына китерергә, киң аркалы караватының атлас юрганнары өстендә иркәләнүне сузарга теләп тормыйча ятарга гадәтләнде. Андый чакларда кырыс холыклы әнисенең чәрелдегрәк тавышы барыбер чыбылдык капроннарын ертып керә...

– Үзең җиткән кыз, тиздән килен булып барасы, үзең төшкә кадәр йокы бүсәсең! Торасыңмы син, кызый, юкмы?!

Бу әнисен әйтер иең инде. Шәһәрчә яшәргә һич теләми. Кызылга буяган иреннәрен сузып, йомшак башмакларының очларында гына килеп, алма кебек битләренең уртасыннан, бөгелеп үскән керфекләренең очыннан гына үбеп аласы да югыйсә! Авыл инде, авыл. Миңсылу апаның бар белгәне – ашау-эчү, утын юнәтү, мал асрау кайгысы. Иртән – сыер. Кич – сыер. Җәен ничек печән әзерлим дип баш вата, кышын әзерләгәнен ничек җиткерергә белми. Чыккан бәбкәңне тилгән сагалый, үстергән тавыгыңны күршеңнең явыз овчаркасы бугазлый.

Шәһәрдә барысы да бар. Шәһәрдә барысы да башкача. Үстермәсәң дә, ач тормыйсың. Азрак ашасаң, күбрәк йоклыйсың да – вәссәлам. Йоклаган тәннән ит качмый ул! Уйламаган баштан чәч коелмый! Кәүсәрия гел шулай фикер йөртте. Арка турайтмый бөкресе чыккан әнисенә генә шәһәрский тормышның рәхәтлеген аңлата алмады.

Әнә шул хыялны тагын да үстерәсе, зурайтасы, бер шәһәр баеның ахмаграк малаена кияүгә чыгып, тормышка гына ашырасы иде дә бит, тагын да шул үзсүзле әнисе моңа ирек куймады. Сигезенчене бетереп, аттестат алып кайткан көндә, үз теләген дә сорамый-нитми:

– Укытучылыкка китәсең! – дип кырт кисте.

Борыны да кипмәгән малайлардан кеше ясау Кәүсәрия тудырган хыялда бөтенләй юк иде. Шәһәрдә торсын да, баш катырып, акыл сатып йөрсен, имеш! Үзе дуңгыз фермасыннан башканы күрмәгән әнисе генә Алла ясый ич алардан. Укытучының ни акчасы, ни букчасы дигәндәй. Анысына инде ни авылда, ни шәһәрдә көн юк. Хет башка бер һөнәр дисә иде, ичмаса!

Алай да Кәүсәрия күнде. Ризалашмаса, икенче көнне үк әнә шул дуңгызлар арасында йөрисен уйлап каршы төшмәде. Бер караганда, укытучылыкка уку аны ике елга булса да авылның чын тормышыннан ерагайтачак иде. Бәрәңге казырга, идән юарга кайтуга гына чыдар. Тик укытучылар әзерләү йорты әллә ни ерак түгел икән – үзенең дә авылныкыннан артык җире булмаган район үзәгендә генә.

Педучилищеның иң яхшы укучысы булды Кәүсәрия. Башын бәрә-бәрә укырга, кеше булырга сүз биреп чыгып киткән иде ул туган нигезеннән. Хатын-кыз гына караган ярым җимерек йорт күңелендә

йөрмәсен өчен, әнисе белән хушлашканнан соң, борылып та карамады. Тегесе, кызының үсүенә, инде үз юлыннан китеп баруына моңаеп, капка баганасына терәлеп калган иде югыйсә. Миңсылу апа бушаган, шыксыз йортына туры гына керә дә алмады, күршеләр бакчасы аркылы узды. Башта, хәл белешкән булып, Бибигөлсемнәргә сугылды, чәйләп тә утырды әле.

Күрше хатыны Кәүсәрия күңелендәге хыялны кызның үз авызыннан ук мең ишеткән, шуңадырмы Миңсылуның өзгәләнгәннәренә әллә ни әһәмият бирми иде. Аны ыкы-мыкы килүдән ярты юлда ук туктатты да:

– Мәңгегә киткән шикелле бик өзгәләнмә әле. Алла боерса, икенче ялга ук кайтыр. Көндәлек эшеңә килен дә булышырга гына тора. Авылда яшисе килмәвенә дә кайгырасы юк. Укып бетерер дә кайтыр. Сине шәһәргә алып китәргә кайтыр. Инде тел ачкычлары язсын да, йөргән җирләрендә сүзе үтеп, кеше арасына керсен, – дип фикерен бетерде.

Кәүсәрия киткән атнасында да, икенчесендә дә кайтмады. Барлы-юклы стипендиясенә киез беретка алып кигәч, чәчләрен кистереп бөдрәләтеп җибәргәч кенә, кытүмкәсен асып, Миңсылу апа янына кайтып төште. Артык сүз сөйләшмәде, зарланмады, мактанмады, эшендә ярдәмләшеп алды да, үкчәле прощайкаларында терт-терт басып, район үзәгенә китеп тә барды. Шул ике көндә дә инде ияләшеп беткән дусларын, хуҗабикәсе мич түрендә балчык чүлмәкләрдә тары ярмасыннан ботка пешереп көткән мичле фатирын сагынып өлгергән иде.

Кәүсәрия яшәгән поселок Казан түгел дә түгелен, иллә мәгәр соңгы вакытларда таңнан күз ертып чыгып, үзе сава башлаган сыер ул яшәгән хуҗабикә ихатасында юк иде. Суы да якындагы колонкада гына, авылның икенче башына көянтә-чиләк күтәреп йөрергә кирәк түгел. Керне дә алкын сулы улакларда чайкамыйлар, ишегалдында тезелешеп утырган цинклы ләгәннәрдә чуптырдаталар. Авыл түгел инде, ди иде һәр көнне уянганда Кәүсәрия бистәнең үзе үскән Чирәмлектән әллә ни артыгы булмаса да.

Кәүсәрия тәки тырышты. Исеме – гел мактаулылар арасында булып, рәсеме почет тактасыннан төшмәде. Бердәнбер иреклe юлламаны училищены кызыл дипломга тәмамлаган Кәүсәриягә бирделәр. Ул шуның белән кайсы да булса ерак бер авылга китүдән, шунда май исе аңкып торган трактористка кияүгә чыгып, биш-алты бала үстерүдән, таңнан торып, әлеге хәерсез сыерны савудан котылган иде.

Кәүсәрия, юлламасын кесәсенә бөгәрләп тыккач, әнисенең йөрәген кычкыртып биргән утыз тәңкә акчасын тотып, олы юлдан чыгып китте дә суга баткандай юк булды.

Көзгә кергәндә генә әнисе янына кайтып төште ул. Туп-туры Казанга китеп барган икән. Институтка да кермәгән, үзенең хыялында йөрткән эшләргә дә урнашмаган. Педучилище дипломы белән әллә кем булмаячагын аңлаганда, институтларга кабул итү имтиханнары тәмамланып өлгергән ди шул. Кәүсәрия апагызны Казанның кырый районнарындагы бер мәктәпкә башлангыч сыйныф укытучысы итеп эшкә алганнар. Кыз сер бирә торганнардан булмаганга, кайтышлый хәл белешкәннәргә эре бер кыяфәттә:

– Шәһәрский тормышны башладык, – диюдән артыгын ычкындырмады.

Казанга барып урнашу, бер карасаң, шул хыялның чынга ашкан башы иде бит инде. Әле барысы да алда. Машиналы кияү дә, атлас эчке күлмәктәге йокылар да, биш тиенлек җиләк мороженое да. Ә хәзергә өч тиенлек сөт туңдырмасы да бер дигән!

Кәүсәрия Казанда фатирга керүнең күпме торганын чамалый иде, хәзергә искереп беткән бер тулай торакның җимерек караватлы дүрт кешелек бүлмәсенә генә дә бик сөенеп ризалашты. Эшче кызлар белән укытучыга яшәү килешми дә, авыр да, дип уйласа да, аларына да түзде, гадәтләрен ошатмаганда да күтәрелеп бәрелмәде.

Бүлмәдәшләре арып-талып эштән кайталар да әле телевизор карыйлар, әле иптәш егетләрен җыеп чәйләп утыралар... Төне буе тыз да быз бер бүлмәдән икенчесенә йөрүләрендә. Кәүсәриянең иртән торып мәктәпкә китәсе, әнә шунда китә алыр өчен дәрескә әзерләнәсе, планын төзисе, дәфтәрен тикшерәсе бар... Авылдан килеп рәхәтлеккә чыккан кызларга моны аңлатып булырлык түгел иде, шуңа күрә эченнән сызу белән чикләнде. Ә ул күңелдә... шәһәрский хыял тагын да күперде дә күперде.

Кешечә яшәү теләге арта барган саен, аны чишү көннәренең ерагая гына төшкәнен Кәүсәрия егерме бишкә җитеп тә кияүгә чыга алмагач кына аңлый башлады. Хатын-кызлардан гына торган мәктәптә кемгә күз саласың да, эштән арып кайткач, кайларга чыгып йөрисең?! Җитмәсә, мәктәбе дә торган җиреннән шактый ерак, ашыгып атласаң да, транспортка кадәр генә дә ярты сәгать үтә. Ашарга пешерим дисәң, аш бүлмәсендә чират тезелгән. Кухня түрендә кукраеп утырган зур электр плитәсенең дә нибары ике уты яна. Кешедән алда юынып калыйм дип, башкалар уянганчы ук торырга кирәк. Ичмасам, авылда... юк ла, авылда яшәп кем рәхәт күргән!

Күңеленә килеп керә башлаган икеле-микеле уйларны Кәүсәрия әнә шул җөмлә белән кисәргә гадәтләнде. Үз-үзе, кала кыенлыклары белән көрәшеп, кызның егерме сигезе дә, утызы да, ул арада кырыгы да тулды. Бай кияү дә табылмады, кулы – эштән, башы уйлаудан туктамады.

Көннәрнең берендә Кәүсәриягә гомере буе хыялланган фатир алу кәгазен китереп тоттырдылар. Шәһәр йортында рәхәттә яшәтәчәк бай кияү генә һаман да күренми иде әле. Аның каравы олыгаеп

киткән, бераз авыргалый да башлаган әнисенең инде ялгызы гына авылда яши алмаслыгын күршеләреннән бик тәфсилләп аңлаттырган-яздырган хаты килеп төште.

*«Кызым Кәүсәрия! Синең өчен барчабыз бик сөенәбез. Инде син кеше булдың. Кирәргә – фатирың, киярргә – киемең, эшләргә эшең бар. Авыл тормышлары, үзең беләсең, рәхәттән түгел, ялгызың гына яшәү үзеңә дә кыендыр, кайтып алмыйсыңмы?»* кебегрәк тәмамланган ул хат Кәүсәрияне өнсез калдыргандай итте.

Шәһәр өенә ремонт әле тәмамланмаган, җәйге ялга да ераграк иде. Балалар арасында яшәп шактый йомшаган, үзен инде барысының әнисе кебек тойган, әнисен дә ныграк аңлый башлаган Кәүсәрия боларга карамады, зур бер машина, кеше яллап, аны янына алдыртты.

Миңсылу карчыкның фатирга килеп кергәч әйткән беренче сүзе: «Моның миче кайда соң?» – булды. Туганнары таш өйдә торсалар да, суга тышка йөргәнгә, мичкә утын якканга, ул кала өйләренең күбесе шундый була дип белә иде. Кәүсәрия рәхәтләнеп көлде:

– И әни, шәһәрнең бөтен рәхәте әнә шул мич юклыкта, су-утын хәсрәтеннән башка яшәүдә инде, – диде. Бу вакыт ул үзе дә балачактан килгән хыялының тараюын, бөтенләй шиңеп бетүен, аны җиргә төшерүен аңлады. Кәүсәрия әнисе сөенер, кушылып көләр дип уйлаган иде, алай булып чыкмады. Ул, моңаеп, үзенә ияртеп килгән агач эскәмиягә барып утырды.

– Мич өстендә арка җылытып та ятмагач, ни рәхәте бар инде бу тормышның? Саварына – сыеры, сөйләшергә мәчесе юк бит аның болай да. Әле җомга көннәрдә күрше карчыклары кереп утыра иде, ичмасам...

Кәүсәрия ни диярргә белмәде. Көннәр үтә торды. Көнозын эштә булгач, әнисенең әйберләрен карарга, кирәкмәсен ташларга, кирәген урнаштырырга вакыты юк иде. Алар бер почмакта өелешеп тора бирделәр. Вакыт-вакыт Миңсылу апа алар арасында казынды, нидер эзләде.

Шулай беркөнне Кәүсәрия кайтып керсә, аркалы урындыкның бер кырына бәйләгән гөнҗәләдән әнисенең йон тартып эрләп утыруын күреп, чүт артына егылмады. Ә карчык, берни булмагандай:

– Әле бер-бер эшкә ярыйм дип утырганыем. Ни кабаны, ни тәрәшне тапмадым. Кул белән генә язып маташам шунда. Кышын аякларың туңадыр, инде җылыда йөрерсең, – диде.

Кәүсәрия җибәргән шофер әби машинага дип чыгарган әйберләрнең шәһәрдә батмаганын үзе күрмәгәндә бер читкә илтеп барган, шуңа күрә эш кирәк-яракларыннан карчыкның әбисеннән калып, йон маенда керләнеп беткән орчыгы гына килгән иде шул.

Кыз тешен кысып түзде, каршы дәшмәде. Әле ягымлы итеп:

– И, тиктормас та инде син, әни, кул-аякларым сызлый, дисең, үзең эшкә утыргансың. Ятып кына торсаңчы, – дип тә әйтеп куйды.

Шушы матур сүзләр әнисе күңеленә тияр дип һич уйламаган иде ул. Тегесе күзләрен мөлдерәтеп карап-карап торды да сабый бала шикелле еламсырарга ук кереште:

– Ятыйм дисәң, җылы мич башы, аркаңа салырга мамык шәле дә юк бит аның монда! Гомерләрең булса, ничек яшәрсең...

– Яшәрбез, әнкәй, яшәрбез! – диде Кәүсәрия, Миңсылу карчыкның аркасыннан сыйпап. – Шәһәрский тормышның үз рәхәтлекләре бар аның!

Әнисе тынычлангандай булды. Чәй эчтеләр, авыл хәлләрен сөйләшеп алдылар, телевизор карап утыргандай иттеләр. Кич узмый да узмый, күзгә йокы керми иде. Аптырагач, бисмиллаларын әйтеп, стена буендагы тар караватта бер-берсенә аркаларын терәп йокларга яттылар. Күзләренә йокы эленмәсә дә, сиздермәскә тырыштылар, йоклаганга салындылар.

Бала белән ананың бер-берсенә сыенышып яткан тәннәрендә типкән йөрәкләрендә төрле хыяллар иде. Кәүсәрия яңа алган фатирын ничегрәк рәткә китерү турында уйланды, әнисе каената йортына килен булып килгән көннәрен, Сәйфетдинне сугышка озаткан чакларын хәтеренә төшерде. Сыерны бетермә, балалар ачтан үлмәсен, дигән иде ул. Сүзендә тора алмады шул, тора алмады. Сыер да бетте, нигез дә таркалды. Өч баланың икесе – гүр иясе. Авызыннан өзеп ашата торган иде дә югыйсә... Туганда ук зәгыйфьрәк булганнардырмы... Әтисеннән корсакта калган Кәүсәрия исә, рәхмәт төшкере, әнисенә бер иптәш булып үсте, үз янына да алды менә.

Тик... ни өе, ни сыеры... Арка җылысы бирерлек тә мич булмасын әле бу шәһәрнең таш фатирында!

Эшкә уятып, будильник шалтырады. Кәүсәрия торды. Тиз кайнатуы белән сөендергән газга чәйнеген куйды. Юынды, әнисенә дәште. Ул да торып, әзерләнеп өстәл янына килеп утырды.

– Әнкәй, – диде Кәүсәрия, – ни теләгең бар, үтим, җаныма авыр итмә, һәр төнне күз йоммый чыгасың, миңа болай да бик читен бит.

Миңсылу елмаеп куйды. Аның кызын эшкә киткәндә борчыйсы килмәде, бер теләге калмагандай, чәй эчәргә кереште.

– Карчык кешегә ни кирәк инде ул, кызым? Биргәненә шөкер. Бу сиңа авылның мичле өе түгел. Нишләмәк кирәк. Ни язса, шуңа риза булырбыз. Җәйләрен авылга кайтаргаларсың әле.

Казаннан ерак район үзәгенә, аның да юлсыз бер авылына кайчан да булса бер кайтырмын дигән уй Кәүсәриянең башына да кереп чыкмый иде. Нәрсә нәрсә, монысын ук әнисеннән көтмәде дә. Инде үзе дә олаеп килә, юлда йөрүне яшь чактан ук өнәп тә бетерми. Шәһәрский яши башладым дигәч кенә...

Кәүсәрия берни җавап бирмичә укытырга чыгып китсә дә, әнисе сүзләре хакында көн буе уйланды. Мәктәп ишек төбен саклап утыручы авылдан килгән бер агай бар иде. Гомере буе кешеләргә мич чыгарып яшәгән. Хәзер кулына эш таба алмый интегә. Киткәндә, шуның янына тукталды да болай дип әйтә куйды:

– Фатих абзый, авылдан әнине китергән идем, мичен бик юксына. Соңгы катта яшибез без. Шуның бер почмагына мич ясап бирмәссең микән? Морҗасына рөхсәтне ничек тә алырмын, ЖЭК начальнигының баласы минем класста укый.

Кәүсәрия каравылчы карт сәерсенер, көләр дип уйлаган иде, һич тә алай булып чыкмады. Карт, директордан сорап, ияреп үк кайтып китте. Ике-өч көн дигәндә, җыйнак кына мич Кәүсәриянең фатир түрендә кукраеп утыра иде инде.

Кәүсәрия аны әйбәтләп сылады, агартты. Акшарлары кипкәч, әнисенә ияреп килгән киезләрне өстенә җәйде. Бер уентыгына йоннарын салды, плитәсенә суы белән комганын утыртты. Ахырдан әнисенең киленлек чаршавы белән «мич арты» кебек бер нәрсә бүлеп аласы итте. Инде утырып еласаң да була иде...

Әнисе ул арада чәй әзерләп өлгерткән икән, сөйләшми генә, һәрберсе үз уена батып чәйләделәр. Аннан Миңсылу карчык мытыр-мытыр гына мич өстенә үрмәләде:

– Шәһәрский фатирны күрше Зөлхәбирә иллә дә хурлап калган иде. Нәрсә белә соң ул? Синеке менә дигән: бер дә авылныкыннан ким түгел!

*2006*

## ӨЗЕЛГӘН СӘДӘФ

Ашыга-ашыга атлады ул. Өзелеп күрәсе килү аякларын шулай камчылагандыр инде.

– Таныш өянке астында... – дип өзелгән тавышны, кабат күпме генә шылтыратса да, телефон чыбыкларында тергезә алмады.

Казанда икәнлеген кайдан, кемнән белгән дә тукталган урынын ничек эзләп тапкан?

Көндез Черек күлнең бу почмагында кешеләр булмас әле дигән иде. Ялгышкан икән. Шәһәргә килеп, мыек үстерергә дә өлгермәгән беренче курс студентларының, дәрестән качып, кызлар сайратып утыруына көлемсерәп куйды, күзләренә чалынмаска тырышты, кеше теленә керүдән бик курка, araларында авылдашлары да булмагае дип шикләнә иде. Йөзен алардан читкә борды – студентның күзе, кыек карый торган булса да, туры китерә ул.

Ярый әле аларның утыргычына кеше утырырга өлгермәгән. Төнлә яуган кар тапталмаган килеш, күпереп, ап-ак булып тора.

Соңгы тапкыр бу утыргычта нәрсә сөйләштеләр соң? Җитмеш тугызның язы иде ул. Университет бетергәннән бирле монда килеп чыккан юк, дигәненә Асия: «Шул гомердәнме?» – дип, бик сәерсенде.

Инде аннан соң бу утыргычны ничәмә-ничә тапкыр яшел төскә буяганнардыр. Телевизордан ясаган чыгышлары буенча хөкем йөртсәң, ул Асиясез өченче костюмын туздыра... Соңгысының заказга тегелгәне, гәүдәсенең калынайганлыгы күренеп тора...

Юньләп Казанны да белмәгән чагы иде. Шулай бервакыт Куйбышев мәйданыннан Матбугат йортына үзе килергә булды. Адашмас өчен, адым саен телефон-автоматтан шылтыратып, биш минутлык юлны бер сәгать менгән. Әлеге йортның ишегеннән чыгып кул гына изәсә дә, Асия күрерлек югыйсә! Ә ул аның туп-туры, кып-кыска урам икәнлеген барып җиткәч кенә аңлады. Троллейбуслар йөреп торганда, нигә җәяү килергә кушты соң, дип аптыраган да иде әле.

Гомер узгач, электә озын булып тоелган вакыт та, зур булып күренгән әйберләр дә кечерәеп кала.

Менә Черек күл. Кайчандыр киңлегенә, кешесезлегенә хозурланып йөрделәр... Ул киң дә, төпсез дә түгел икән...

Җәй иде. Өстәге урам агачлар белән капланган. Ят, шомлы иде Казан. Урамнарында да кеше аз. Бакчада үзләреннән башка берәүнең булганын да хәтерләми.

«Мин сине шәһәрдән аралап алдым», – дидеме Радик? Ник, «син мине аралап алдың», дип әйтмәде икән? Асияне күргәнче ничә еллар Черек күлгә юл да таба алмаган югыйсә.

Инде менә тагын... Нәрсә сөйләшергә? Нәрсә сөйләшерләр... «Онытмадыңмы» дип сорамаса гына ярар иде.

Ах, бу телефоны да. «Килә алмыйм» дип әйтергә дә ирек бирмәде. Чыбыклар башындагы кешенең колагына да ул теләгән сүзләрне җиткермәде...

Кырык сылтау табып, чакырылган кунактан да калган иде ләбаса. «Онытмадыңмы» дип сорамаса гына ярар иде!

Күрәсең киләме, имеш... Күрәсе килмәсә, бу кадәр ашыгыр идеме соң... Телефонны алуга кырт кисеп куярга да була иде бит. Ә үзе? Баштарак күрергә бер-бер сәбәп беткәнме?

Шулай да бу күрешү кирәк булдымы икән? Элек тә айлар, еллар күрешми яшәгән шикелле, «онытмадыңмы» дип сорый торган иде ул. Шуның белән онытмаска тиешлекне искәртә идеме әллә?

Тагын шулай дип сорамаса гына ярар иде... Җавабын әйттермәсә бигрәк тә!

Салкын булып китте. Куллары белән капшап, өске төймәсенең өзелгәнлеген белде. Күрде, иелеп аласы итмәде. Карлы утыргыч өстендә икесенә дә таныш сәдәф кояш нурларында ялтырап ята бирде. Ул бу сәдәфне аның кочагында кичләр чыккан пәлтәсеннән күчереп теккән иде...

Ах, бу сәдәфләрең, мине бер дә яратмыйлар, синнән ерагайталар, ди торган иде ул чагында Радик, өзәрдәй булып тарткалап.

Аерылышканнан бирле үзенә инә кертмәгән сәдәф иде ул. Авыл кешесенең яхшыга дигән киеме тузамы соң?! Ул әнә инде өч костюм алмаштырды...

Бу очрашу булмаса, яңа алган пәлтәсен кияргәме, юкмы дип тора иде әле... Ни дип өзелгән аның яңа таккан төймәсе? Нәрсә аңлатырга теләгән ул?

Нәрсә сөйләшерләр? Ни дияр? «Онытмадыңмы» дип сорамаса гына ярар иде!

Асия сәгатенә карап алды. Әле килеп җитәренә тагын биш минут бар. Язмышларны үзгәртергә бирелгән биш минут. Өзелгән төймәләрне ялгый алырмы ул шул вакытта?

Карлы утыргыч өстендә вакыттан бик аз гына кыршылган сәдәф. Кояш нурларында ялтырап ятуында ул. Асия аңа текәлеп, уйланыбрак, икеләнебрәк торган шикелле булды. Аннан сәдәфне дә алмыйча, ял бакчасының чыгу юлыннан атлады. Адымнары кызуланганнан-кызулана барды. Артына борылып карамады.

«Онытмадыңмы» дип сораганчы, өзелгән сәдәфтән китеп өлгерергә кирәк.

*1992*

## САРЫ ТАВЫК ДӘВАСЫ

Гөлниса, башы әйләнгәнгә түзә алмыйча, койма буена килеп чүмәште. Тәне таба мае кебек кыза,хәлсезләнгән йөрәге Гыймазетдин абзыйларның көн дә киртә ватып кача торган тае лапылдап йөгергәндәй тибә иде. Сеңлесе Миңнисаның:

– Апа, төсең качкан, әллә чирләп киттеңме? – дигәненә дә, авызына килгән әче су, буа ергандай, тышка атылыр санап, баш кагып кына җавап бирде, әмма иптәшләренә шунысы да җитә калды. Элекке уеннарын онытып, «брачлы»га күчтеләр.

– Син берүк кузгала күрмә, дөнья хәлен белеп булмый, җан да тәслим кылырсың, – дип, күрше малае Нәсим носилка әмәлләргә кереште.

Якында гына алмаштырырга алып ташланган җилкапка аунап ята иде. Такта-киртәләрне аркылы-торкылы бәйләрлек бау һәм әмәл тапмагач, шуңа килеп ябыштылар. Гөлнисаны, җилтерәтеп, капка өстенә китереп тә салдылар. Ай-ваена да карамыйча, иңнәренә күтәреп, дәррәү Кадыйр абзыйларга юнәлделәр. Кыз тәмам җебегән, бу исәрлекләргә каршы торыр хәле калмаган иде.

Әле генә мәктәптә дә сугыш уеннары уйнап кайтканга, балаларга монысы да бик кызык һәм шуның дәвамы кебек тоелып китте. Имеш, яраланган сугышчыны медчастька илтәләр. Ата коммунист Нәсим тиз арада барысын да үз кулына алды.

– Дошман территориясен узабыз, – диде ул, сугыштан контужен кайтып, халыкта «дизәртир» буларак даны таралган Хәйбүшләр турысына җитәрәк. – Иелергә! Юк, авыруны җиргә куярга һәм үзебезнекеләргә кадәр шуышып кына барырга!

Гөлниса шалтыр-шолтыр, дөбер-шатыр өстерәлгән капка өстендә актык тамчы хәлен дә югалтты, тәне кабат җыелмаслык таралды.

Аларга таба нәрсәдер күтәреп килгән балаларны күргән Зөлхиҗәттинең йөрәге жу итеп китте. Аумас өчен, тәрәз яңагына сөялде:

– Ләхәүлә вәлә куәти!

Сишәмбедә кояш батканчы өер булып урамда баруны юньле эшкә санамаганга, бар белгән догаларын укырга керешкән иде, өзде, үзе дә белештермәстән, ишегалдына атылды. Балаларның нәкъ менә алар капкасыннан килеп керүләрен күргәч, лапылдап, баскыч төбенә утырды.

– Ләхәүлә вәлә куәтел галиел газим, Раббем...

– Брачка, ашыгыч ярдәм! – дип кычкырган Нәсимнең сүзе һавада эленеп калды. Усаллыгы белән даны чыккан Зөлхиҗәттигә якын килергә һәм аны да, гадәттәгечә, уенга кертергә беркем базмый иде.

Карчыкның кыяфәтен күргән Нәсим дә югалып калды. Зөлхиҗәтти, кармалана-кармалана, үзе торды, кыштыр-кыштыр гына, носилкадан күтәрелеп килгән Гөлнисага таба атлады:

– Нишләп ятасың анда, акылың табаныңа төшкере!

Әбекәйнең каршысына Миңниса чыгып өлгермәсә, аның эше харап иде:

– Ни, Зөлхиҗәтти, ул чирләп киткән, менә күтәреп алып кайттык... Әле исән...

Карчык телсез калды, әмма тагын үзен кулга алды. Уенмы бу, чынмы дип карап торгандай итте дә:

– И-и-и, балакаем, сары булган бит сиңа, ничек моңарчы күрмәгәнбез? – дип бот чапты.

Гөлнисаның үзенә дә авызын тутырып килгән сары суларның сәбәбе аңлашылды.

– Иртәгә чәршәмбе. Алла боерса, терелерсең, иптәшләрең барысы да урлап булса да чәршәмбе йомыркасы китерерләр. Аның файдасы бик зур бит.

Дус-иш, кеше капкасын икенче ишегалдында калдырганын да онытып, өйләренә таралышты. Үз иркенә калдырылган Гөлниса көч-хәл белән генә сәкегә кереп ятты да тавыкларның йомырка салганын көтә башлады.

Йокысы туеп уянса, сәке янындагы урындыкта коштабак тулы «чәршәмбе йомыркасы»! Сугыш вакытында авызларыннан өзеп, тирә-як күршеләр керткән аларны. Бәлеш тә ашый алмаслык Гөлниса әнә шул утыз-кырык йомырканы берьюлы сыпыртса, һичшиксез, тереләчәк иде. Тик йомырканың көч-хәл белән чәйнәп йотылган өч-дүрте дә берничә минуттан, өелеп, бугазына килде, һәм ул аларны косып ташламыйча булдыра алмады.

– Син нәрсә, кызны үтерергә җыендың мәллә? – диде әле Гражданнар сугышыннан ук буш җиңнәр җилфердәтеп кайткан Кадыйр абзый. Шул мизгелдә кулларының юклыгын онытып, кызның аркасыннан кагам дигән иде, тик шәлберәйгән күлмәк җиңнәре аңа буйсынмады. – Түз, кызым, йомырка ашау – авырмаганда да авыр ул. Бавыр беткәндә – бигрәк тә. Без үскәндә, сары йокса, сары әйбергә карап утырырга кушалар ие... минем прәшкә әбизәтелни терелтәчәк сине!

Ул, билендәге солдат каешын салып, Гөлниса яткан сәке башындагы кадакка элде. Шул ара ишектән атылып чыгып киткән Зөлхиҗәтти бераздан әллә никадәр әйбер: жиз табак, комган, сыер муенына эленә торган шөлдер ише кебек нәрсәләр күтәреп кайтып та керде.

Әбисе Гөлнисаның, сәгатьләр буена урамга карап, әти-әнисен уйлап, моңаеп утыру гадәтен белә иде. Берьюлы файдасы да тисен, янәсе! Аларны тәрәзә төбенә дә, өстәл өстенә дә тезде.

Көн карады Гөлниса, төн карады, күзләре чепиләнеп бетте, йөзе тәмам саргайды, тик бу юл белән дә терелмәде.

Инде өстендәге җете яшел күлмәге, искергәч, кечерәйгәч, сандыкка салынган сарысына алмашынды, чәйне дә чынаякның лимон төсендәгесенә ясадылар. Әллә каян табып, сары кашык та алып кайттылар. Алардан эчелгән сары гөлҗимеш суы да, кунакка сакланган тары ярмасыннан пешерелгән ботка да кызны терелтергә ашыкмады. Нишләргә белми торганда, күршеләре Нәгыймә килеп керде.

– Илдарханым исән-сау кайтса, сыйларга дип саклаган сары тавыгым барые, инде Гөлнисага язган икән, – дип кычкырып елап җибәрде, – гүспитәлгә эләккән...Ул да кеше күзләренә карап ятадыр, мескенем. Шушы сары тавык итеннән терелсәгез, догагыз барып, менә ул да исән-сау кайтмасмы...

Тавыкны җиренә җиткереп, бисмилла әйтеп суйдылар, сарыга каршы ымлап пешерделәр. Корсагында ярыланып килгән һәм әллә никадәр чирлене кеше итәчәк «чәршәмбе йомыркалары»н да кызганып тормадылар.

Урталай ярганнан соң, шулпа эчендә тагын бер кат өшкереп, Гөлниса алдына куйдылар, шуннан күтәрелгән парны суларга иелгән башына юрган капладылар. Аның бер почмагын күтәреп, әледән-әле балыктай һавага чыккан кыз түздe, сары тавык шулпасы тәмам суынганчы парында утырды.

– Инде теләгәнеңчә итен дә аша, – диде Зөлхиҗәтти, Гөлнисаны шаккатырып. Аның үз гомерендә, бер тавыкны берүзе ашау түгел, ботын да кабып караганы юк! Әле сугышка кадәр кимергән тавык башы белән «очарга» дип бирелгән канатының тәме дә бүгенгедәй телендә тора иде.

Инде менә тавык бөтене белән аныкы! Кыз, ит бүләргә остарып беткән каенанадай, аның бер ботын каерып алды һәм, бер кабуда йотам дигәндәй, авызына китерде. Китерде дә шунда ук читкә ыргытасы килгән кыяфәттә туктап калды. Тавыкны ашарга теләү дә, ашый алмау да шулкадәр көчле иде, ни эшләргә дә белмәде. Аннан ак итеннән бер өлешен өзеп алып чәйнәп караган итенде һәм, зур авырлык белән генә, күзләрен – атылырдай, тамагын ярылырдай киереп, шул килеш кенә йотып җибәрде.

Шушы сары тавыкның симез ботын гына булса да әкренләп, чәйнәп ашый алмаудан керфек төпләренә җыелган яшь бите буйлап тәгәри башлады. Кайчан да булса тагын бирәләрме әле аңа ул ботны, юкмы?! Кыз үзен авыруы аркасында гына эләккәненнән дә нәүмиз калуына гарьлек хисенә буылганнан буыла баргандай тойды. Караватның ялтыраган тимеренә тотынды. Авыздан сары суларны һаман да ныграк китергән сары тавыкка инде ничек тә карамаска. Күзләрен чытырдатып йомды. Ябык күз кабагы артындагы караңгылыкка карап тора башлады. Анда ниндидер кара ноктала р пәйда булдылар да, зурая-зурая алга таба килгәч, бихисап күп тәлинкәләргә салып куелган тавыкларга әйләнделәр. Гөлниса үзенең шулар арасында бөтерелеп диңгез төбенә төшеп киткәндәй юкка чыкканын күрде һәм инде башка берни дә аңламас, тоймас хәлгә килде.

Аның елавына иткә кызыгып карап торган, әмма боты түгел, башы да тәтемәгән өч яшьлек Миңниса тавышы да кушылган иде. Ул, алдында шундый тәмле ит була торып ашамаган апасына, аның, шуны күрергә теләмәгәндәй, күзләрен йомып утыруына бик гаҗәпләнде, иллә мәгәр киселгән үлән кебек мендәренә егылуына исе китмәде. Эчтән генә апасы урынына үзе авырмаганга язмышка үпкәләгән кызның үз хәле хәл иде.

– Апа, башыңны гына тотып карыйм әле, эссеме, юкмы? – диде ул авыруы йокса гына ярар иде дигән татлы хыяллар белән, аңсыз яткан Гөлниса янына килеп.

*1998*

## АКБҮРЕК

– Әй, Акбүрек, Акбүрек, дим!

Бакча киртәсенә тотынган куллар ягына карамаска тырышып, инде мәлҗерәп беткән туфракка капланам. Рифат капланып елап ятканны кайдан белсен, кычкырып-дәшеп арыгач, чыбык кисәге ыргытамы – шап итеп, әмма авырттырмыйча гына, калын мамыктан эшләнгән сырмага килеп төшә.

– Акбүрек, дим, әйдә булышам.

Рифат инде койма аша бакчага узган, яныма килеп, юеш туфракка утырган. Белсәм дә, һаман да күтәрелеп карамыйм. Үртәлеп, гарьләнеп елыйм да елыйм.

Яңгырдан шәлберәйгән бүрек йоннары классташ малайның уч төпләренә салкынлык бирәме, ул һаман шуларны сыпыра... Бармаклары искереп тә төсен җуймаган бүрек тутларын бөтергәлиләр шикелле... Инде алар җирдә яткан юеш чәчләремне җыялар, яка астына тыгарга маташалар... Рифат, булдыра алмагач, сибелгән учмаларны сак кына җилкәләремә салып куя...

* * *

Кайчандыр әти-әнигә әйтми торган бер үпкәм бар иде. Койма аша күрше бабайның уттай кызыл алмаларын сыпыртканда, үзләре дә кычыткан кебек сыгылмалы сыйракларымны өтәгәч дисезме? Һич юк. Классташ малайның борынын канаткач алган кыендыр дип уйлыйсызмы? Алай да түгел. Шаярып, укытучым сурәтен зурайтып, клуб диварына элгәнгә эләккәнне беләсездер әле. Ул да түгел!

Көз көне туганмын мин! Бот чабып, булса соң, бер син генәме диярсез. Көзен туганнар күбен күптер дә бит, анысы белән бәхәсләшмим. Ә менә бәрәңге казыганда туганы, билләһи, башка юк!

Әти әйтмешли, эш беткәнне дә көтеп тормаганмын, бәхетем эштән булганга, көз кайтканмын да инде мин. Әни исә әле дә, минем белән бәрәңге казый-казый үзең дә бәрәңге кадәр генә үскәнсең, дип шакката.

...Мине көз көне эш эшләшер дип алып кайткан әти белән әни, укулар башланып, атна-ун көн үткәнне көтеп торалар да, үзләре белән ияртеп, лапас аша арт бакчага чыгалар. Әтинең кулында ялтырап торган урак. Тешләре аныкыдай эре булмаса да, икенче ялтыраганы минем кулда.

Чыгабыз да иң башта алмасыз калган агачларга, кибеп-корып утырган бәрәңге сабакларына карап, моңаешып торабыз.

Күрше апаның тау астындагы эре тупыллары өстендә каргалар төркеме бөтерелә. Каршыда, тау кочагында үскәнгә киңәйгән, биеккә үрләгән тирәктә төннәрен безнең каралтыга очып килә торган ябалак утырадыр. Торналы инеш коесының колгаларында чәүкә балалары ял итә торгандыр. Инде үскәннәрдер, матурайганнардыр. Укулар башлангач, мине югалтканнардыр. Кое сукмагына килгән эзләр арасыннан минем туфлиләрнең сырларын күзлиләрдер.

– Син туган елны әлеге коеның колгасы ап-ак булып ялтырап күренә иде, аны мин син туган сөенечтән яңарттым, – ди әтием.

Алманың тәмлесен ашатыйм дип, аларны да алмаштырып бетергән ул!

Әтием аз сөйли, күп эшли. Үзенә каршы төшмәгәнне, гел аныңча булганны ярата. Менә ул карашы белән тагын бер кат бәрәңге сабаклары корыган бакчабызны әйләнеп чыга. Аннан аның атсыз бармагы әкрен генә күтәрелә башлый да күзләребезне буразналарның нәкъ урта бер җиренә беркетеп куя:

– Синең туган көнеңне, бәрәңгене тырышып казысак, әнә шунда үткәрербез.

Ничек кенә эшләсәк тә, без бит аны барыбер шунда үткәрәчәкбез. Әти ничек теләсә, шулай бара безнең эш. Сырхаулап, бакчага чыкмый калсаң да, кичләрен соңрак керсәң дә, атсыз бармак төрткән җирне тиз генә уза да, аңа иртәрәк җитә дә алмыйсың.

Хикмәт тәгаен әнә шул бармакта. Әтиемнең нәрсәгә дә булса күрсәтеп, ни дә булса эшләп торучы бармагы нindидер сихри көчкә ияде кебек.

– Әти, – дибез без, кайчак аны сынап, – менә бу чиләктә ничә бәрәңге бар?

– Мондамы, – дип төртә ул әлеге дә баягы бармагы белән, – төп-төгәл егерме тугыз!
Кайдан белә аны әти?
– Әти, безнең ак кәҗәбез нинди бәтиләр алып кайтыр микән?
– Өчне! Саулык! – ди ул шунда ук, ялгышырмын дип уйламыйча да.
Ә бит ялгышмый да!
Әтине һәркем сыный. Мал аласы булса да базарга әти белән баралар. Бәрәңге тапшырасы булса да! Алдап кара син аны! Сатарга китерелгән атның ничә кило сөяге, ничә кило эчәгесе, ничә кило ите барлыгын, тизәккә күпме калганын да шунда ук әйтә ул. Ышанмыйлар. Үлчәүгә дә алып барып карыйлар. Әти хет ярты килога ялгышсын!
– Эш белән яшәгәч, тәҗрибәсе зур! – ди аның турында әни.
Менә мин көн-төн эшләп торам, үзем чүпләгән чиләкләрдә ничә бәрәңге барлыгын әйтә алмыйм бит. Хикмәт әнә шул атсыз бармакта да инде. Әни үзенчә ризалашкан да сыман:
– Иң тырыш бармагы бит ул аның, кызым!
Әтием генә бармакның сихри көченә ышанмый. Бер елны авыл клубына Светлана Ким дигән ниндидер гипнотизер килде. Ялтыраган бер пыяла күрсәтүе дә булды, ярты авыл гырлап йокыга да китте. Минем әти, кырдан арып кайтмаган шәһәр кешеләрен йоклатып карасын ул, ди. Йоклатуын йоклатты, тик кайберләрен бик авырлык белән уятты. Хәсән абыйны мең алдына, мең артына төшеп тә айныта алмагач:
– Хасан, проснись, чайку попьешь, на работу опаздываешь, – дигән иде, тегесе сәхнә идәнендә уң ягына гына әйләнеп ятты да:
– Матри, хатын, тагын бер сәгатьсез дә уятып ачуымны чыгарасы булма! – дигәннән соң, кабат гырлый да башлады.
Халык көлә. Концерт бетәр чак җиткән. Хәсәннең кайтырга уйлаганы да юк. Тиз генә хатынына кеше йөгерттеләр. Бала-чагасын ияртеп, күз яшенә буялып, анысы атылып керде. Алай дип карады, болай, Хәсән генә йоклый бирә.
Менә шулчак әтием сәхнәгә сикереп менде дә, татарчалатып, колагына ук:
– Торасыңмы син, юкмы? «Чулпан»ныкылар сукада алга киткәннәр, персидәтел «флагны кире бирсен, аңа чыпта күтәртәбез» дип әйткән, – дигән иде, торды Хәсән.
Тормый нишләсен, беренчелекне чит колхозга бирсенмени?! Ә сернең аны төртеп уяткан әти бармагында икәнлекне ул да белмәгәндер дип уйлыйм.
Борынга төртсә төртә, әмма колакны бормый гына тыңлата торган бармак ул!
– Зөһрәнең туган көнен, бик тырышсак, калкулыкта каршыларбыз, – дип, мине үрти торган бармак.
Туган көнемдә гәрәбә кебек сап-сары кабак бәлеше пешерәселәрен дә, әтиемнең җилкәсендә корыган сабак чүмәләсе тирәли әйләнгәннән соң, шул чүмәләдә кып-кызыл карбыз белән сыйланасымны да беләм.
Әтиемнең:
– Зөһрә кыз ай ашый, орлыгын җиргә ташлый, – дип шаяртасы да аермачык.
Ул көнне ел саен кабатланган әллә нәрсәләрне алдан ук көтеп алсам да, исем китмәгән бер кыяфәттә чүмәлә өстендә утыра бирәм.
Әкияттәге Зөһрә кыз да айдан аякларын салындырып, моңаеп утыра, имеш... Әтием минем моңсу чакларымны бер дә яратмый.
Зөһрә кызның туган көне кайчан икән? Аңа бүләк алып бирүче дә булмагандыр. Минеке кебек әйбәт әтисе булса, сорарга куркыр идемени! Үги әнисе турында гына язганнар шул әкияттә.
Әтиемнең уттай кызу эш өстендә кая да булса барып йөрергә һич кенә дә вакыты юк. Алдан алып куйса да, көнгә йөз күлмәк алмаштыручы кызының сандыктан табасын көт тә тор! Әнә шуңа ул көнне әти мине кабак, карбыз белән сыйлый. Мин чүпләгән бәрәңгеләрне саткач, Казаннан иң матур күлмәкне апкайта ул!
...Чүмәлә өстендәге туган көн тәмамлана. Кызыл карбызымнан да яшел кабык белән минем теш эзләрем генә утырып кала. Зөһрә кыз да онытыла. Әни дә кузгала, чиләкләргә таба китә.
Җиргә төшәргә дип, әтиемә үрелмәкче булам, кулыма коңгырт күзле куян малае сузылып ята. Күрше кызы Сәлимәгә алып бирерләр дигән шик төшергән, почта аша гына килгән, кибет киштәсендәге бүрек ул! Эләктереп алам да урамга атылам.
Туган көнемдә бу эшем өчен орышмасыларын белгәнгә, кешесез урамда, тирләп-пешеп, бүрек күрсәтеп йөрим.
Бу тәрәзәләрдә, мең булмаса, йөз күз бар, ди әтием. Кичке ашка бакчадан керүчеләргә симез тавык шулпасы пешерүче әбиләр күзе ул!

* * *

Инде мин җиденчегә җиттем. Кечкенә кулларымнан да көн күрмәгән, әмма үзем кебек үк усал күрше малайлары да тынычланып калды. Капка төпләренә ял итәргә чыккан апалар күзеннән дә соклану түгел, моңа кадәр әле бер тапкыр да очратмаган төс булып узам. Күңелемә аваздашланып калган тирә-ягым йөрәккә утырган ташны тагын да авырайта.

Урамда, кырларда, бакчада, җанда сары төсләр артканнан-арта бара. Бакчадагы эшләр дә бу елда үземә генә булыр, ахрысы. Таңнар атканда кош сайравына уянган таллар арасында әтиемнең үле гәүдәсенә тап булганнан бирле, әнинең аякка баса алганы юк.

Күрше апаның бакча башында үскән тупылларның очлары җил кискән кебек корыган. Торналы коеның зәңгәр чиләге, күкләрдән яңгыр эчәрдәй булып, болытларга үрелеп утырмый. Мин карап үстергән чәүкәләр инешнең башка почмакларына күченгәнгә охшый. Төннәрен каралтыга килгән мәче башлы ябалак та күренми. Әллә картайды, әллә уңышы кимегән бакчаларда тычкан азайды.

Аларны, әтиемне сагынып, туган көн дә үтеп китте. Бәлеш тә пешмәде, карбызлар да ашалмады. Төш турында, чәй эчәргә керәсе урынга, чүмәлә өстендә, ялгызым гына сагышка батып, бакча башына карап утырдым.

Яңгырлы ел. Туфрак авыр кәс булып, көрәкләргә ябыша, туфракны авырайтып тубыктан баткан аяклар калкулыкка тартмый. Эш бармый да бармый. Әтинең уңган кулларын, җитез атлап узган аякларын көтә бу бакча.

*** * ***

– Әй, Акбүрек, Акбүрек, дим! Акбүрек, дим, әйдә булышам.

Мин һаман да күтәрелеп карамыйм. Үртәлеп, гарьләнеп елыйм да елыйм. Сак кына җилкәләргә сибелгән салкын учмалардан аккан су, кием аша узып, тәнемә чирканчык бирә. Авыр истәлекләрдән арынасы килгән шикелле, иягемне яныма чүгәләгән Рифатның җилкәсенә куеп торам. Ниндидер җиңеллек сизәм. Аннан икебез дә һаман якынаймаган бакча уртасына карыйбыз. Калкуланып алга сузылган буразналарның теге башыннан, арыма, тукталма, бирешмә, дигәндәй бармак янап, әтием басып торгандай...

*1985*

## СӨТ ӨСТЕ

Нәҗибә сыерсыз өйдә үсте. Тормышлары да бөтен, житеш, башкаларныкыннан яхшырак та иде югыйсә, тик менә сыер асрауны кирәк санамадылар. Тиен генә торган сөт аркасында тирестә казынуга караганда башкача көн күрүне дөресрәк тапты аның әтисе. Абзар тулы ат булганда да, аяк арасында җәйләрен йөзләгән тавык-чебеш кайнашканда да көтүдән алар ихатасына сыер кайтмады. Нәҗибә кичләрен сыер каравылына башкаларга ияреп йөрде, төннәрен колхоз басуыннан башкалар өчен салам урлады.

Һәр эшнең үз рәхәте, үз михнәте була дигәндәй, сыер асрау да шулай иде. Кичке җәйләүдә әллә нинди кызыклы уеннар уйнала, әллә никадәр авыл гайбәте сөйләнә, әллә кемнәрнең моңа кадәр әллә кем генә булганнарга күзе төшә. Җилемле мал асрамасалар да, Нәҗибә боларның берсеннән дә калмый, чөнки ул күңел салып йөргән егетнең кызгылт билле ак сыерларына кадәр ярата иде шул...

Сыер асраучыларның михнәте, диденме, шул мүкләкләрнең көтүдән кайтканда өйгә керми йөдәтүе, ачуы килгәндә, чиләкләргә әле генә мөлдерәп тулып килгән сөтне санлашырга теләмәгән яшь таналарның бер тибеп алуда юкка чыгаруы; таң тишегеннән торып, «сипарат аерту» да, анысы үзеңдә булмаса, чиләк-көянтә асып, авылның икенче башында торган туган-тумачаларга сөт илтү күз алдына килә.

Ныграк уйласаң, рәхәтсезлеге җитәрлек инде аның! Аның каравы, әнә шул кире хәерсезне капкадан кертә алсаң, эти-әниеңнең мактаулары, кич белән тәлинкәдәге ашыңа тавык канаты урынына симез ботның яртысын ук китереп салулары, әниеңнең чиләген авам дигәндә генә тотып калуларың өчен ишеткән рәхмәт сүзләре, инде... инде сөт өсте ябышкан сипарат каймакларын авыз-борыныңны майлый-майлый ялаулары гына да ни тора!

Әнә шул сөт аерткан вакытларына туры килсәң, җиңгәңнәр сипаратындагы унике калайның өчесе булмаса да, икесе, һичшиксез, синеке инде!

Шул тимер тәмнәре килеп торган каймак тәме Нәҗибә теленнән авылдан шәһәргә укырга киткәч тә, сыерлы егеткә кияүгә чыккач та китмәде, чөнки, бер кире килгәнгә гел килә дигәндәй, ул килен булып төшкәч кенә, шәһәр килененә булганда һичбер ризыкны кызганмаган, күчтәнәчне мулдан җибәргән каенаталарының да йортларында янгын чыгып, сыерлары үлгән һәм Нәҗибәләргә сөт өсте дигәннәре авылдан бөтенләй килми башлаган иде. Алай да кайчандыр үзе эшләгән факультетта укып чыккан кызлар, телефоннан шылтыратып, хәлегезне белергә килмәкче идек, күчтәнәчкә ни эләктерик дигәндә,

оят тоелса да, акчага булса да ярты литр каймак инде, дип ярым шаярып, ярым чыннан әйтә торганга әйләнде. Үч иткән кебек алары да олыгайды, шәһәргә юлны сирәкләттеләр...

Сөт өсте күренгән көннәр кими барган саен, аны ашау теләге дә көчәйде генә. Югыйсә колхоз базарыннан да ерак тормыйлар инде үзләре. Нәҗибәнең белмәгән кеше кулыннан сөт ризыгы ашау гадәте бөтенләй юк иде шул. Әлеге дә баягы базар әйберләренә җирәнү тойгысы аркасында, авыл каймагы, авыл корты, казылык ише затлылар, татлылар белән ул дус-ишләренә кунакка барганда гына сыйлана, шуңа күрә булдыра алганча урып калырга тырыша иде. Әмма бервакытта да туйганчы сөт өсте ашаган кебек булмыйча, картаеп пенсиягә чыккач, авылда яшәргә, хәленнән килгән көнгәчә сыер асрарга, кунакка килгән һичкемнән шуның өлешен кызганмаска, күчтәнәчкә каерып тутырган каймак җибәрергә хыялланды. Ул хыял кайвакытта шундый зурая, аңа ераклык, аның татлылыгы күз төпләренә яшь булып бәрә. Кайвакыт түзми, төннәрен торып утыра да сыерсыз яшьлеге, авылдан еракта яшәлгән гомере турында такмаклар чыгарып тынычлана, сөтле чәй, мәтрүшкәле чәй турында җырлар җырлап, йөрәгенә дәва табарга тырыша.

Авылда төпләнгән иптәш кызы Фәйрүзәнең туган көненә кайткач та, бөтен кешене аптыратып, сыгылып торган табынга майлы корт китертте ул. Китертте дә берүзе генә ашап та бетерде. Әлеге дә баягы сөт өсте эретеп ясалган корттан тамчылап-тамчылап сары майлар тамып торганга, шикәре авызда эреп киткәнгә аеруча яратты булса кирәк. Ратуын яратты, тик шул көнне үк хастаханәгә дә килеп эләкте.

– Артык майлы ашыйсыз, ахры, – диде аңа зур борыны өстендә калын пластмасса кысаларга кидерелгән лупа күзлекләре аша калынаеп килүе өчен Нәҗибәне оялтырга теләгәндәй караган карт профессор, – җитмәсә, үт куыгыгыз да юк икән... Һичшиксез шифаханәгә салачакбыз. Атна-ун көн сезгә сөт өстен күрү түгел, корыга пешкән ботка да ашыйсы түгел!

Табиб Нәҗибәнең нәрсә аркасында үләрдәй авыртыр хәлгә килүеннән хәбәрсез кебек иде дә... Өстенә сыер баскан кебек булды. Аның белер-белмәстән сөт өстенә төрттерүеннән Нәҗибә елап ук җибәрде.

– Ни... аннан соң нәрсә дә булса ашарга ярар бит?.. Менә... мае алынган сөт... корт... авыл сыры...

– Суда пешкән ботка көтә инде сезне, кадерлем. Бәйрәм көннәрендә дә сөт өсте дигәнне онытырга туры килмәгәе. Ботканы сезгә әле монда да туйганчы ашатырлар, – диде профессор, хәйләкәр көлемсерәп. – Ияләнгәч, аннан тәмле нәрсә булмый ул.

Нәҗибәнең хәле, чыннан да, хәл иде. Табибка ахмаграк сорау бирсә дә, шушы минутта, авыртуы тукталасы булса, иписез торырга да риза кана! Сөт, корт, сыр дип маташкан була. Чүттән, сөт өсте, дими калды...

Хатын, күкрәк турысыннан ашказанының талаулаган өлешен тотып, үзе ятачак бүлмәгә юнәлде. Керде. Утырды. Тирә-ягына күз ташлап алды. Авыруларның чәйләгән вакыты икән. Өстәлгә кыстый башладылар.

Нәҗибә сиртмәле караватыннан кузгалмады. Ияләнсен дипме, «ризыгыбыз бергә булсын» кебек сүзләр әйтә-әйтә, берәүләр аның тумбочкасына – чәй, икенчеләр кәлҗемә-мәлҗемәләр, кәнфиттер-чурттыр китереп куйды. Ул аларга рәхмәт әйтеп баш селеккәндәй итте дә, берсенә дә кагылмыйча, карчыклар кебек бөкресе чыккан караватына сузылып ятты. Бу төнне ничек тә авыртуга түзеп чыгарга иде... Иртәгә күз күрер...

Бүлмәдәш хатыннарның һәммәсе, Нәҗибә кебек, атна-ун көн элек монда килеп эләккәннәр, берничә көн ашамыйча дәваланганнар, инде шәфкать туташларыннан качырып кына колбасасын да, каклаган казын да капкалый башлаганнар, чөнки авыртуларына түзәрлек хәлгә килгәннәр, эчләреннән биргән антларын да, үлемнән чак кына калганнарын да оныта башлаганнар иде. Аларның туктаусыз, үткәндә аша, дип кыстауларына карамыйча, Нәҗибә түзде, тәки рәтләнүгә таба бара башлады, әмма ләкин башкалар кебек ярамас ризыкны түгел, биргәнен, тиешлесен дә бик сак кына ашауны карады. Әллә аның авыртуы көчлерәк, әллә яшәү теләге зуррак идеме – ул хакта да уйламады, иллә мәгәр биргән даруларын, берәүләр кебек, тумбочка ящикларына да яшермәде, икенчеләре кебек, им-томчылардан соратып алдырган үлән төнәтмәләре белән дә мавыкмады – табиблар ни кушса, бары тик шуны гына эшләде.

Инде ашарга рөхсәт иткәннәрен ишеткән кебек, көннәрнең береннән аның хасталыгын ишеткән дуслары хәл белергә йөри башладылар. Иң элек бүлмәсенә качып-посып вахтер янында узган Фәйрүзә килеп керде. Килеп тә керде – өстәлгә яңа чыгарган ярты литрлы каймагын китереп тә утыртты:

– Син яратасың дип, кызыл сыерныкыннан гына аерттым, малай, рәхәтләнеп аша!

Фәйрүзә белән күрше яшәгән Хашимнар да районга килү уңаеннан хәл белеп чыгарга уйлаганнар. Хатыны Ләмига ярты литрлы банкага каймакның тагын да куерагын, кашык утырып торырдаен тутырган. Бар икән яхшы кешеләр: килгән беренең сумкасыннан сөт өсте чыга торгач, бүлмәдә тыркылдап утырган кечкенә суыткыч киштәләрендә урын ук бетте.

Таныш-белешләр килә торды, китә торды: Нәҗибәгә ашның төшкесе дә, кичкесе дә эләкмәде. Сүз арты сүз ялганып, ашауны да оныттылар. Хәл белүчеләрнең һәрберсе тамак ялгаган булып чыкты.

Инде хастаханә ишекләре дә йозакка ябылып, чәйләп алырга җай чыккач, электр стаканына салынган сулар да кайнагач, тәм-том алыйм дип суыткыч ишеген ачкан Нәҗибә моңарчы башына да кереп чыкмаган уйдан өнсез калды.

Гомере буе туйганчы бер ашарга хыялланган авыл каймагы атна буе түгел, ай дәвамында өстәлдә утырырлык җыелган, тик хәзер, теләсә дә, калак тутырып бер тапкыр гына да каба алмый икән ул аны. Алай да, суыткычта кырыйга сыенып кына кереп утырган бер банканы чыгарып, караваты янындагы урындыкка китереп куйды. Капкачын ачты. Алюмин калагын алды. Банканы авыштырып үзенә каратты. Каратты да калагын ырмавына китергән хәлдә туктап калды. Исән калсам, сөт өсте дип тә әйтмәс идем дигән сүзләрен исенә төшерде. Ничә ел кунакка кайткан ахириеннән моңарчы бер савыт каймакны кызганган Фәйрүзәне эт итеп сүгәргә җыенган иде, дәшмәде, сыерларыгызның башы исән булсын, хәердән китсен дип, теленә килгән иң яхшы теләкләрне теләп, банканы алды да ялгыз карчык яткан бүлмәгә юнәлде.

– Мә, аша, әбкәй, кадерле кешеләремнең күчтәнәче.

Кырык ел гомере кәҗә асрап, сыерлы яшәтергә өлгермичә сугышта үлеп калган ирен сагынып яшәгән Нурҗиһан карчыкның, калак очларында каерылып утырган каймакка карагач, мондый бәхеткә инде өметен җуйган бармаклары дерелдәп киттеләр, көтелмәгән хәлне күтәрә алмыйча калтырарга тотынып, калакны идәнгә үк төшереп җибәрделәр. Ап-ак сөт өсте, идән шакшысында чалкан ятачак калакта калырга теләмәгәндәй, төшкән вакытта ук аерылды да лачкылдап карчыкның иске, сидрәләнгән уң башмак очына сыланды.

Нәҗибә сөртергә дип күрше ханымның тумбочкасыннан кәгазь салфеткалар алып килгәндә, Нурҗиһан карчык башмакларын салып алдына куйган, аннан сыпырып алган майны итсез, сөякчел бармакларыннан иреннәрен чупылдата-чупылдата ялый иде.

*2006*

## СӘЛАМСЕЗ КҮПЕРЛӘР

Хәмәт белән Касыйм тормышның ачысын-төчесен бергә татыган, бер үк көнне сугышка киткән, бергә кайтып кергән, бергә гомер дә иткән, утка-суга да кергән иделәр. Әнә шуңа күңелләрендә бу якты дөньядан да бер үк сәгатьтә, бер үк көнне кичәрләр кебек уртак тойгы яшәде. Бәйрәм вакытларында табын артларында теләкләр теләшкәндә дә, гомерлек ярларга теләгән кебек, бер-берсенә тигез дуслык, мәңгелек әшнәлек сорадылар, авырлыкка тарысалар, ярдәмнән калдырмаска вәгъдәләр бирештеләр.

Башларына икенче төрле булыр кебек уй да кертмәгән заманда Касыймнар капкасын җиде төн уртасында Хәмәтнең зимагурлыкта йөреп кайткан, инде авылда төпләнергә уйлаган олы малае Назыйм какты. Бер какты, ике, өченче кагуга, хуҗа кеше торып, кем икәнлеген карарга, шәйләсә, капка ачарга булды. Каршы яктагы баганадан төшкән ут яктысында тәмәке кабызып маташкан шәүләнең Назыймныкы икәнлеген шунда ук чамалады Касыйм. Кием-мазар да эзләп тормады, хатыны Һаҗәрне уятмаслык кына сак атлап, болдыр ишеген ачты, капкага таба китте.

Күлмәк-ыштаннан гына урам якка ук чыккан Касыймга:

– Әти, тиз килсен «дип» сиңа йөгертте, әйтәсе сүзе бар бугай, – диде Назыйм.

Төн катында кеше очрамасына шик юк иде. Галушын да яланаякка гына кигән булса да, Касыйм аңсыз бер халәттә Назыйм артыннан иярде.

Бер-бер хәл булмаса, пәри-шайтаннан башка урамда җан иясе йөрми торган вакытта Хәмәт авылның икенче башына чакыртмас дип уйлады ул, бара-бара айнып киткәндәй булгач. Нәрсәгә чакырта да, башына ут капкан кебек чаптырырлык нинди уй төшкән?

Касыйм килеп кергәндә, берни булмаган кебек, Хәмәт аш бүлмәсендә чәй хәзерләп йөри иде. Ул, ияк кагып кына, ахириен өстәл артына дәште, Назыймга да рәхмәт белдергән күзләре белән карап, бар, инде кереп кит дигәндәй, ябып куелган түр ишеккә таба ымлады.

Олы малай дәшеп-нитеп тормады, үзе дә йокы калдырып йөрүдән ризасызрак иде булса кирәк, калган бар халык йокы бүскән якка кереп китте.

– Менә шулай, – диде Хәмәт. – Без дә картаябыз. Болай чәй ясап йөргәнемә карама, соңгы көннәрдә хәл китебрәк тора бит әле, яшьти, хәл китебрәк тора... Сине дә күптәннән күргән, сөйләшеп утырган юк. Бүген сөйләшмәсәң... иртәгә көн өчен җавап биреп булмый. Иртәгесен Алла гына белә...

Моңа кадәр пыр туздырып дөнья көткән Хәмәттән мондый сүзләрне ишетү бераз сәеррәк иде сәерен... Юк, нәкъ менә шул сәерлеге белән һәр әйткәне Касыймны уйга калдырды һәм ышандырды да!

– Менә шулай, – дип дәвам итте сүзен Хәмәт, чәйне икенче рәткә ясаганда. – Яшисең-яшисең дә, берни кирәкмәгән кебек, бу якты дөнья белән саубуллашырга хәзерләнә дә башлыйсың...

– Туктале, печәннәр җыелгач, бер яр буена төшеп, балык каптырып утырырбыз дигән идек, син алай ук ашыкма, – дигән булды Касыйм, сүзне уенга борырга тырышып. – Быел балан шәп бит. Минем карчыкның балан бәлешеннән телеңне йотасың. Бергәләп урманда да йөреп кайтырбыз...

Хәмәт, куй әле дигәндәй, кул гына селтәде:

– Мин аның белән чын-чынлап сөйләшәм, ул һаман уенга борырга тора. Кыскасы, әйтәсе килгән сүзем шул: мин үлгәч, җеназаны син генә укырсың!

Касыйм телсез калды. Өстәл артына басып, күкрәгенә терәгән түгәрәк йорт ипиен каерып кискән Хәмәтнең үләсенә ышану бер кыен булса, аның шул сүзләрен аек акыл белән тыңлап утыру башка сыярлык эш түгел иде. Ризалыкны бирсә дә алды Хәмәт, бирмәсә дә алды дигәндәй. Тегесен-монысын сөйләшеп чоланга чыкканда, җилкәсенә кулын салып:

– Мин сиңа тапшырдым инде, – дип, әманәтен тагын бер кат ныгытып куйды. – Дөньялыкта үпкәләшкән булмады, инде ахирәткә дә шул көенчә күчик. Мин сиңа мәңге риза-бәхил.

Баштарак бу сүзләр онытылыр, шаяру кебек калыр сыман иде. Дустының сөйләгәне юкка булмаган икән: атна-ун көн дигәндә, башына кан савып егылган Хәмәтнең инде васыять әйтерлеге юк, күз кыйшатып кына аңлаша, кул-аягы бөтенләй үк хәрәкәтсез калган иде.

Касыйм аның үлем чире белән түшәккә егылуын бик авыр кичерде. Дусты сулышының шундый авыр бер вакытта, җәйге матурлыклар юкка чыгып, яңгырлы, сагышлы көннәрдә өзелү алдында калуы аның күңелендә теге көннән бирле тупланган кичерешләрне тагын да авырайта, телсез, тилмереп карап ятуы үзен дә чарасыз итә иде.

Хәмәт урын өстендә озак ятмады. Касыйм янында утырып, төн кунарга кайтып киткән бер кичтә гүр иясе булды да куйды. Төн катында тагын олы улы Назыйм Касыймнар капкасын какты:

– Торыгыз әле, Касыйм абзый, эти үлде бит! Эти үлде!!!

Хәмәтнең җеназа укуны Касыймга кушып калдырганын инде ярты авыл белә иде. Башта көлке итеп сөйләсәләр, Хәмәт аяксыз-кулсыз калгач, ике дус арасында булган хәлләр халыкны тәмам пошаманга төшереп, тәкъдир дигәнгә моңа кадәр тамчы да ышанмаганнарны да уйга салды. Назыйм Касыймны төн чыгарга чакыра килгән һәм исәбе берочтан әманәтен дә исенә төшерү иде, әмма кеше йортында бу хакта сүз башлап тормады.

Өйдәгеләр бераз тынычланыбрак калгач, теләген әнкәсе Гайнелҗамалдан гына әйттерде Назыйм. Күршеләрендә генә яшь мулла яшәгәнгә, ул исә төшемле җирне бик кулдан ычкындырырга яратмаганга, этисенең сүзеннән чыгарга батырчылык итмәсә дә, егетнең уенда җеназа укуны башка кешегә тапшыру да юк түгел иде түгелен.

Башта Касыймның тел очын тартып карарга, аннан алга таба ни эшләсен хәл итәргә план корса да, әнисенең:

– Касыймҗан, Хәмәтнең дә теләге шундыйрак иде, беләсең, инде җеназаны үзең генә укырсың, – дигәнен башкалар да хуплап каршы алгач, үзе дә Касыймны кыстаган булып маташты.

Күршегә ярыйм дип, ата сүзен хакламауның начар икәнлеген Назыйм бик яхшы аңлый иде. «Җеназа – теге дөньяга күпер», – ди иде этисе. «Үзе теләгән күпердән генә чыксын инде», – дигән булды ул, иртән ике нигез арасына корылган койма башына ябышып, күмү-нитү хәлләрен сорашып торган хәзрәткә. Хәзрәт тә ризалашкан сымаграк баш кагып куйгач, Назыйм тынычланды, кирәк-ярakларны хәстәрләү эшенә кереште.

Минем бер дә җеназа укыган юк бит, дип караса да, Касыймны җеназага җыелганнар арасында тыңлап торучы табылмады, шулай тиеш кебек, бертавыштан бу эшне аңа йөкләделәр. Иренең якын кешесе янында йөргәч, Хәмәтнең тол калган хатыны Гайнелҗамалга да, берәзгәрәк холыклы, комсызрак күзле күршесен бик өнәп бетермәгән төпчек кызы Миләүшәгә дә җиңелрәк, тынычрак булып тоелды.

Җеназа укылды, мәетне кабергә иңдерделәр, садакалар тапшырылды. Ир-атлар инде бездән эш тормый дигән кебек карашып тордылар да, янәшә каберләр кырына ясалган агач утыргычларда бераз тын алгач, зират капкасына юнәлделәр.

Иң арттан бик авырдан гына Назыйм белән Касыйм да кузгалдылар. Икесенең дә эчендә бушлык, яшьсез калдыра, күңелне катырып җибәрә торган, зур югалтулардан соң пәйда була торган бушлык иде. Боларның барысын да бер читтә күзәтеп торган яшь мулла зират капкасы янында аларны көтеп алды да Касыйм абзасының колагына, әмма Назыйм да ишетерлек итеп мыскыллы тавыш беләнрәк:

– Җилкә аша сәлам бирергә оныттың бит, хәзрәт, – дип ысылдады.

Бер тын белән әйтеп ташланган бу дәһшәтле сүзләр әҗәлнең салкын сулыш өрүе белән бер иде. Әллә кайда тирәндә, Касыймның күкрәк эчендә, ниндидер тамырлар өзелгәндәй булды. Кинәт тыны кысылды, күз аллары караңгыланып китте. Тыштан берни сиздермәскә тырышып, Ходай кичерсен, дөресләп кабул итсен инде, дисә дә, әлеге хатадан курку хисе аны бугазыннан ук умырып тоткан иде.

Алга таба Касыйм сөйләшми генә, үз уенда атлады. Аның зираттан агарып кайтып килүен күргән кешеләр моны дустын югалтуга сылтады. Хатыны Һаҗәр бу хәлләргә болай да ризасызрак булып калган, шик белдергән иде, эшнең нәрсәдә икәнлеген шунда ук аңлады. Бернәрсә булмагандыр кебек

кыяфәт чыгарып каршы алса да, иренең башы гына сау булсын инде, дип кайгырды, тәмам пошаманга төште.

Касыйм бу көнне ашамады, чәйләмәде. Алдына бүлеп куелган, булары чыгып утырган бәрәңге шулпасына карап-карап торды да, исе үк күңеленә тигән төс ясап, тәлинкәсен читкәрәк этте. Аның кәефсезлеге йөзенә чыккан, хәлен сорап борчырга да куркырлык иде. Җитмәсә, салкын су сорап алып эчкәндә, чыдарлык хәле калмаган бер кыяфәт белән, кат-кат:

– Йөрәк яна, карчык, йөрәк яна, и-и, яна шул, – дип сыкранды.

Иртән тавыкларны чирәмлеккә җибәреп, Касыймны, чәйләр кайнаткач уятырмын әле, дип, абзарга чыгып барган җиреннән Һаҗәр нәрсәдер итәгеннән тарткан кебек тукталды да сәке-караватта йоклап калган, карчыгыннан, ни өчендер гадәтен бозып, соңгарак кузгалырга уйлаган картына борылып карады. Ул чалкан яткан да йөзен җилкә аша артка ташлаган, күзләре күренми, тәнен сырлап икенче якка сузылган муены әллә нинди ят бер төс... Өстенә әле яңарак кына ябып куйган юрганы аяк очына төшкән, учын өскә каратып ястыкка, колак турысына ук салып куйган.

Касыймның төшендә мәет дәфенләп йөреп бик арыганлыгын, дусты җеназасында бу юлы изге доганы инде дөреслэп укуыннан тынычланганлыгын, әмма шул сөенечне йөрәге күтәрә алмаганлыгын Һаҗәр инде белмәячәк иде... Ул, түр бүлмәдә йоклап ятканнарның барысы уяныр лык итеп, үзәк өзгеч тавыш белән:

– Касыйм! – дип кычкырып җибәрде. – Хушлашмадык тамыни?!

*2006*

## КЕШЕНЕКЕ – КЕШТӘКТӘ

Тәслимә, кияүгә чыкканда, кайчан да булса аерылышырбыз дип башына да китерми иде, чөнки ире Вазыйхны үзен бик тә ярата дип саный, һәм моны аның ягымлы караш ташлаучан күзләреннән, елмаеп кайтып керүеннән, әйткән татлы сүзләреннән үк күрә. Бөтен нәрсә син теләгәнчә генә булып чыкмый икән ул. Тормыш дигәнең бигрәк тә...

Туй мәҗлесләре узып, атна-ун көн дигәндә, Вазыйх йорт салу хәстәрен күреп йөри башлады. Гаилә ишле, аягына басып, энекәшләре үсеп килә, үз нигезеңне корырга кирәклеге бик ачык иде. Вазыйхның теләгенә ата-анасы да каршы төшмәде. Әнә буш торган лапас, гараж бар, иң элек шунда материал җыя тор, диделәр алар, көчебездә чагында үзебез дә булышырбыз.

Башка чыгу уе белән яшәргә керешкәч, Вазыйх бигрәк тә дәртләнеп йөри башлады. Кичләр буе хатыны белән булачак өйнең планын сыздылар, төннәр буе анда ничек яшәячәкләре турында хыялландылар. Бер корган планнар йөз булмаса ун тапкыр үзгәртелде, энекәш-сеңелкәш, эти-әни тарафыннан да аларга төзәтмәләр кертелде. Анысы ошаса, бу төрлесе күңелгә ята, өченчесе инде тагын да заманчарак, дүртенчесе... анысын әйтеп тә торасы юк! Кыскасы, ни уйласалар, шул күңелгә май булып ята торды.

Вазыйх белән Тәслимә бик бәхетле, күзгә күренерлек бәхетле иделәр. Хикмәт өйнең нинди булуында да түгелдер, уртак эшләр аларны тагын да якынайткандыр, яшь пардан чын гаилә ясагандыр инде.

Туйга шактый гына акча җыелып, аны каядыр куярга, урнаштырырга кирәк булгач, барысы да бертавыштан яңа өйгә тотуны хуплады. Авылда тормышны ерак сәяхәтләрдән башлау бөтенләй юк иде. Атна-ун туган-тумача арасында кияү-киленләп йөрделәр дә көндәлек эшләргә тәмам батып ук киттеләр.

Йортның ныклысын, кирпеч стеналысын өяргә уйлаганнар иде, бик тиз җае да чыгып куйды. Колхоз председателе яңа абзарлар төзетүдән калган кирпечләрне хезмәт хакы хисабына Вазыйхларга китертергә булды. Машинаң үз кулыңда, әйдә төя дә алып кайтып кит, диде ул. Эшнең болай уңай башлануы Вазыйхны тагын да канатландырып җибәрде. Таштан салынган өй балаларыңның балаларына да кала әле ул, ди торган иде Вазыйх, Алла шундыен насыйп иткән икән дип, бик тә сөенештеләр. Ә без соң кем өчен яшибез, ди иде Тәслимә дә. Балалар өчен, билгеле, балалар өчен. Әти-әниләр безне кеше иткән, безгә дә шул гамәлләр бурыч булып калган. Бу сүзләр кычкырып әйтелгәндә, яшь килен күкрәге астында туачак нарасыйның беренче күзәнәкләре яралган иде инде.

Вазыйх – колхозның алдынгы механизаторы да, ташчысы да, балта остасы да, әмма соңгы вакытларда күбрәк машина белән булаша. Өй салганда транспорттан да кирәгрәк нәрсә бармыни?!

Председательнең, белмәссең, кире уйлавы да бар. Кирпечне, шул көнне үк алып кайтып, гаражга өяргә булдылар. Аны Тәслимә, малайлар белән бергәләп төяделәр. Төзелеш бригадиры ватылганнарын исәпкә дә алып тормады, бездән яхшылык булсын дип, үзе үк машина арбасына салдыртты, бер-бер яраган җире чыгар, диде.

Вазыйхлар кайтышына гараж капкасы киң итеп ачып куелган, этисе Галимхан утыргычта инде күтеп үк утыра иде. Кирпеч өстендә кайтучы бала-чага арбадан сикереп төште дә әллә кайда югалып та бетте. Тәслимә белән каенатасы анда карадылар, монда, аннан соң, берәмтекләп, тигезләп өярбез әле дип, ишегалдына гына бушатырга уйладылар.

Капкага узган юлга сайгаклар түшәлеп, астан бастырыклар белән шактый шәпләп ныгытылган иде, әмма машинаңны җай кертмәсәң, кырый чокырга төшеп китүең дә бар. Галимхан абый, баганаың түбән оч ягына басып, Вазыйхка юл күрсәтеп тора башлады.

– Мондарак, улым, мондарак.

Машина капка алдына уңайсызрак килгән иде шул. Вазыйх ашыкмый гына артка чигенә башлады. Галимхан абый аңа үзенә таба борылырга кушып кул селтәп маташа. Бераз гына сулгарак алыйм дип, рульне бормакчы гына булган иде, этисенең:

– Туктап тор әле, улым, туктап тор, – дигәне ишетелде.

– Нәрсә булды инде, әткәй?

Кереп китәм дигәндә генә туктарга ишарәләгән этисенә канәгатьсезрәк эндәшсә дә, Вазыйх, ишегеннән сузыла-сузыла гаражга карап, тормозга басты. Әмма... хуҗасын тыңлыйсы килмәгәндәй, машина, күтелмәгәнчә кызуланып китеп, Галимхан абыйны капка белән арба арасына китереп кысты. Тормоз дигәне газ педале булган икән...

Вазыйх агарды-күгәрде, машинасы белән кинәт алга ыргылды. Урамның икенче ягына куеп, капкага атылганда, этисенең җаны чыккан, Тәслимә чәчен йолкып елый иде.

Матур гына башланган хыялларга шул көннән башлап кырау тидемени. Галимхан абыйны җирләгәннән соң,ни яңа нигез, ни өй, ни туачак бала турында бер тапкыр да сөйләшмәделәр. Ул хакта гына сөйләшергә теләп авыз ачсалар да, күңелләренә гел эткәләре килә дә, тешләрен кысып туктап кала иделәр.

Болай яшәү Тәслимәне авырайтты. Җитмәсә, карынындагы баласы да үзен ныклап ук сиздерә башлады, әмма Вазыйхның тормыштан гаме китте, күзенә һичбер шатлык күренмәде. Ул хәзер үлем-җитемнән ваграк хәсрәтне хәсрәткә дә санамый торганга әйләнде.

Әткәсе үлемендә үзен гаепләгән Вазыйх ял көннәрендә басу-кырларга, урман юлларына китеп югала да кичкә кадәр күренми. Бөтен кеше хафага төшкәч, шулай яшәү табигыйдер кебек бер кыяфәттә кайтып керә.

Бала чагында этисе белән инеш буенда сөйләшеп утырган җирләренә бара, аның эзләрен табар кебек миңгерәүләнеп йөри торгач, Вазыйх беркөнне, чыннан да, карт тирәк төбеннән бер тәгәрмәч табып алды. Эзләнә торгач, шул тирәдәге чокырдан икенчесе дә килеп чыкты. Алар аңа Вазыйхның иң беренче сәпиденнән калган тәгәрмәчләр кебек тоелды.

Шул заман инеш буенда ятып та күгәрмәгән, черемәгән тәгәрмәчләрнең этисе алган сәпиднеке түгеллеген өйдәгеләр аңласа да, каршы төшмәделәр, әйбәт булган, диештеләр. Вазыйхның, соңгы көннәрдә тәүге тапкыр сабый бала кебек куанып, «уфалла» арбасы ясарга булса да ярар әле, дип алып кайттым, диюен күрү үзе бер рәхәт, күңелгә тынычлык китерерлек хәл иде.

Тәслимә исә Вазыйхның бу сәер эшләренә тәмам аптырады, үз хәлен кемгә дә сөйли алмый йөдәде. Мотоцикл заманында нинди арба инде дә, аны кем тартып йөрер, дип куйды ул, берсе дә көтмәгәндә, төксерәк кенә сурәттә, гаилә белән өстәл тирәли кичке ашка түгәрәкләнеп утыргач. Мондый сүзнең артыклыгын аңлаган каенана телен тешләгән, аны-моны абайларлык яшьтә булмаган сеңел-энеләрнең күзе, моңарчы ишегалдында кукраеп йөргән әтәчнең тәлинкәдә чалкан яткан сап-сары тиреле түшендә иде.

Вазыйх Тәслимәнең бу сүзенә каршы «ә» димәде, «җә» димәде, ашап бетергәч, дәшми-нитми генә, түр якта чаршау белән әйләндереп алынган караваткa барып ятты. Хатынының эшләре беткәнне дә көтеп тормады, гәҗит-фәлән дә укып утырмады. Төксе генә бер кыяфәттә булса да тыныч йокы да теләмәде.

Вазыйхның үпкәләгәне, ачуы чыкканы һәркемгә тәгаен иде. Тәслимә, ничек тә күңелен табарга тырышып, җылы юрган астына шуып кереп ятуга ук, йомшак кулын иренең күкрәгенә салгач, ягымлы, назлы бер тавыш белән:

– Бәгърем, үлгән артыннан үлеп булмый бит инде, болай ук бәргәләнмә, үзеңне сакла, – дигән булды.

Мондый мәгънәле, хәлгә керүче сүзләрдән башка берәү тынычланып та калыр иде, бәлки, әмма Вазыйх тиз генә үзгәрә алмаучан, бер кызса, озак суынучан холыклы булгангамы, элегрәк әйткән сүзләрнең дә тәэсире астындамы, корт чаккандай сикереп үк торды:

– Үз атаң үлсә, син болай дип әйтмәс идең әле!

Тәслимә бер агарды, бер күгәрде. Каенана йортында һәрдаим күзәтү астында яшәгән, бу өйнең гадәтләрен шактый гына үзләштереп өлгергән яшь килен каршы сүз әйтүнең кирәксезлеген аңлаганга дәшмәде, түзде. Хәер, теләсә дә, сөйләшерлек хәле калмаган да иде.

Икенче көнне таң атар-атмас ук Вазыйх ишегалдына чыгып китте. Тәслимә аның артыннан чыкмакчы булса да, тукталды. Ерак китмәгән, ахры, лапаста шак та шок килеп нәрсәнедер тукылдатуы чоланга ук ишетелеп тора иде. Хатын, эшләр эшләп тынычлансын инде әйдә, дип, үзалдына сөйләнгәли-сөйләнгәли чишенеп, киемнәрен элгечкә элде дә кече якның урамга караган тәрәзәсе янына барып утырды. Нәрсәнедер көткән кебек, хәвеф алдындагы бер халәт иде аның йөрәгендә. Бер-бер эшкә дә тотынасы да килми, җыр җырлап моңаер иде дә... үз өендә түгел шул, болай да хәсрәттә йөргән каенанасы алдында корсак киереп йөрүе дә кыен.

Эшең булмаса, тун итәгеңне булса да уа тор дигәндәй, алъяпкычына бөрелгән балаитәкләрнең әле бер, әле икенче почмагын бөтәрләде дә бөтәрләде Тәслимә. Башкалар рәхәт тормыштан тулыланып киткән дип тапкан гәүдәсенең түгәрәкләнеп килгән корсак өлешен сыпыргалады. Күңеленең болганган, башының чатнап авырткан көннәре иде. Башы әйләнүдәнме, гадәти булмаган яңа халәттәнме, үрдәк кебек чайкала-чайкала гына йөри.

Һәркемгә үз хәсрәте хәсрәт шул, хәлең ничек, килен, дип сораучы да юк үзеннән. Кеше зур кайгыда бөтен вак-төякне оныта, үз борчуын һәрвакыт алгарак куя икән лә... Менә ул да... И-и, инде нигә искә алып торырга... Әйтелгән сүзне кире алып булса икән ул...

Тәслимә, тәрәзә яныннан кузгалып, табын әзерләү хәстәренә керешә, уй уйлаудан гына туктамады. Вазыйх юк та юк, инде шакылдаганы да ишетелми иде. Чәйгә чакырырга җибәргән төпчеге артыннан Хәерниса абыстай:

– Арба ясыйдыр инде ул абыең, – дип әйтеп калган иде, хак булган.

Вазыйх яныннан кергән Хәмит ишектән, бала-чага шикелле юк белән маташа шунда, бу заманда кеше «уфалла»га калганмыни, дип, аның сәер гамәленнән үзенчә көлгәндәй итенде. Мәет чыккан йортта һәр әйтелгән сүз, һәр хәрәкәт җанга кадала, көлү кебек кабул ителә иде микән әллә? Инде бу авырлык чиге юк томан кебек тәнне, акылны изә башладымы?

Тәслимәнең эче бигрәк тә ут иде. Каената үлеме килен кешегә берни түгелдер дип уйлаганга, аның хәленә керүче дә булмады, әмма эш анда түгел. Вазыйхы белән икесе арасындагы салкынлыкның гомерлек икәнлеген төшенә шикелле иде хатын.

Тәслимә ишегалдына караган тәрәзәләргә әйләнде дә килде, әйләнде дә килде. Ире күренсә, чыгып дәшәргә сүзләр эзләде, җайлысын табалмады. Ахырда, ясаган чәен дә эчеп бетермичә, түр якка, чаршау эчендәге үз караватларына кереп ятты. Хәерниса абыстай Хәмитне абыйсын чакырырга икенче мәртәбә җибәртте.

– Җиңгәңнең хәле китеп торганын да әйт, хәсрәт өстенә хәсрәт булмасын тагын... – диде ул, малай ишекне япканда, күңеленә бер-бер уй килгәндәй үзгәреп.

Карчык көтелмәгән авыр кайгыдан соң килен белән рәхәтләнеп сөйләшеп тә утырмавы, аның йөзендәге моңарчы күренмәгән төсләр барлыкны, хәрәкәтләренең салмакланып китүе, күзләренең моңлануы, аякларенең очлануы, гәүдәсенең тулылануы турында уйланды. Кем белә, бәби дигәне борынлап ятмыймы икән карынында?! Аннан әле генә Тәслимә караштыргалап йөргән тәрәзә өлгесен ачып, ныграк тавыш белән:

– Улым, көттермә, буласыңмы син, юкмы? – дип кычкырды.

Вазыйх чәй эчәргә кереп тормады. Әнисен ишетмәгәндерме, ишетеп тә үзсүзләнүе булдымы – Хәерниса абыстай аңламады. Аталары юк, балалар кулдан ычкына, дип уйлады ул, Вазыйхның бу гамәлләрен күңеленә артык якын алып, үпкәләбрәк. Галимханы булсамы, Галимханы булса, йодрыгын гына бер күрсәтерие, мин сезне, диештергәләп... Ормас-сукмас та үзе, әмма ләкин тыңлатыр...

Вазыйх чәй эчәргә кереп тормады шул. Ул бу йорт гамьнәрен бер читкә куйган һәм бары тик үз уйлары белән яши иде. Төш тирәсендә кичәдән суынмаган мунчада ялгызы гына коенып чыкты да, ишек катындагы шкаф башыннан иске чемоданны тартып төшереп, шуңа киемнәрен тутыра башлады. Монысы Хәерниса карчыкны да чыгырдан чыгарды.

– Бәй, улым, нишләвең бу? – диде ул, тавышына кырыслык бирергә тырышып.

Вазыйх дәшмәде. Бернәрсә булмаган кебек кыланып, киемнәре төелеп тутырылган чемоданны, аяк очлары белән генә тибеп, карават астына шудырды. Аннан мич буена куелган шырпы белән тәмәке тартмасын алып ишегалдына чыгып китте.

Ул атна-ун көннәр элек тау як урманнан төшеп килгәндә, тол хатын Наиләнең аркасына бер күтәрәм печән салып көч-хәл белән генә кайтканын күргән иде. Булышырга уйласа да, кыймады, күңеле башкадарак иде шул. Куып җитмәскә тырышып, артыннан төште дә төште... Печәнеңне иңнәреңнән ал да тау итәгенәчә тәгәрәт, дип кенә әйтәсе иде югыйсә...

Наилә авылның бөтенләй башка тарафында – югары очта ялгыз гына көн күрә. Карале, ирләр белән буталган, даны чыккан хатын-мазар түгел, дип уйлады Вазыйх, тормышы да бик үк җимерелеп төшмәгән. Авырлыкта яшәгәч, кеше хәсрәтен дә, ир кирәген дә аңлый торганга охшаган.

Кичке һава керсен дип марля тарттырылган тәрәздән Хәерниса карчыкның инде борчу катыш тавыш белән дәшкәне ишетелде:

– Вазыйх, ни эшләп йөрисең инде син анда? Килennең иртән торасы бар. Ятыйк...

Вазыйх капка төбенә чыгып, тәмәке кабызып бераз уйланып торды да, буш «уфалла» арбасын тартып, авылның Наилә яшәгән очына таба китте. Артыннан энекәше үсеп килә. Чемодандагы киемнәр аңа калыр.

*2006*

## «ЗАДНИЙ ХОД»

Рәйха бишле уенында идәннәреннән тузан күтәрелә башлаган залдан, һава суларга дип, кызыл почмакка чыккан иде, оятыннан ишегалдына атылды. Түгәрәкләнешкән дуслары уртасында Расим ут уйнатып биеп йөри, арты белән баскан килеш, аяк очларында гына кемнең дә булса янына килә дә, җилкә аша карап, уртага чакыра.

– Егетләр, сак булыгыз, мин карчыкка охшаган, «задний ход»ым гына эшли, таптала күрмәгез, – дип, шырык-шырык көлә үзе.

Кыз аның кемне ни өчен мыскыллавын шунда ук белде, әмма шулкадәр көләрлек бер кеше булгач, Расимның үзе артыннан көн-төн чабуының сәбәбен берничек тә аңлый да, аңлата да алмады. Озатып кайтулары да шул мыскыллау гына микән әллә, дип баш ватты ул, утсыз урам буйлап бу юлы ялгызы гына өйләренә атлаганда.

Кичәләрдә уртадан кермәсә дә, кызу сиптергән татарча көйләргә нигәдер алга таба тыпырдый алмыйлар иде аның ыспай, үкчәле туфлиләрдә генә йөргән тәпиләре. Шуңа күрә кара-каршы биючегә таба барасы булса, ул артка барган килеш кенә, кирегә борылмыйча, юлын түгәрәкләтеп, парына ерактан әйләнеп килә. Беркем дә аның «әпипә»гә оста түгеллеген сизмидер, үзенчә бер бию төре генә итеп кабул итәдер дип йөри иде, Расимның күзе үткер икән лә...

Инде яшьләр таралышыр вакыт җитеп килсә дә, Рәйха кайтырга ашыкмады. Алар клубтан шактый ерак, озын урамның икенче башында ук торалар. Кызу атлаганда да, кызның клубта күренмәгәнен сизеп алган Расимның үзен барыбер куып җитәчәген белә. Аны хәзер башка нәрсә – моңарчы пар булырбыз дип йөргән егетенә ничек үтен сытарлык җавап бирү теләге борчый.

Озак та үтмәде, Расимның авыр эш бутыйлары чыгарган су тавышлары Рәйха колагына да ишетелә башлады. Менә алар көчәя, кызулана бардылар да Рәйханың табанына ук басып килгәнне аңлаткан чупылдауга әверелделәр. Расимның кайнар тыны Рәйханың муен чокырларын ук кытыклый кебек иде инде. Кыз артына борылмады. Егетнең шуны көтеп барганын бик яхшы сизә иде югыйсә.

Ахырда Расим түзмәде булса кирәк, иңнәреннән кочаклап алып, Рәйханы туктатты, үзенә таба борды да күзләренә карап тора башлады. Кыз бу эшләргә каршы төшмәде, үзен иректә калдыруларын тыныч кына көтте дә, салмак, үтемле тавыш белән:

– Ә хәзер тизлек рычагыңны арткы йөрешкә күчер, ул сиңа бик килешә икән, – диде.

Әгәр көн яктысы булса, Рәйха Расимның аклы-күкле бер төскә керүен, эшләгән эшләренә үкенүен абайлар иде дә, бәхетенәме, бәхетсезлегенәме, баганалардагы барлык лампочкалар да янып беткәнгә, болай да күзлек киеп йөргән кызга аның бу сүзне ничек кабул иткәнлеге күренмәде.

Рәйха кереп киткән капкасын да ябып тормады, артына да борылмады. Кичерү сораса да, кичермәс кебек бик текә бер кыяфәттә әле кичә генә өзелеп сөям дип уйлаган егетеннән китеп барды. Моны аларның һәр икесе аңлады. «Задний ход» дип әле кайчан гына көлгән егетнең үзенә бигрәк тә артка – үткәнгә юллар шапылдап ябылган иде. Икенче көнне кызы ташлаган икән дигән сүзне күтәрмәс өчен, аның белән үзе йөрмәскә уйлаган кыяфәт ясап авылдан китеп барган Расим, ел үтте дигәндә, татарча бии белмәгән марҗа кызын әләктереп, туган нигезенә кайтып төште.

– Авыл тулы менә дигән мөселман кызлары барда... – дип, әтисенең килен кеше аңламаслык кына игәүләп алырга сүз башлавы булды, ул аны:

– Арткы ходны гына беләләр шул алар, – кебек сәер җөмлә белән бүлде.

Габдрәзак агай, әлеге сүзнең мәгънәсен уйлап, атна-ун көн баш ватты, төбенә төшеп җитә алмады, ахырда, хатыны Бибигөл белән серләшкәч, аның сүзенә колак салып, ата-аналарына китеп-килеп йөргән киленнәргә төрттерде булса кирәк дип тынычланды, инде Расимның әйткәнен күршесе, туган-тумачасы бердәнбер малаеның марҗа кызына өйләнүенә ризасызлык белдерүенә каршы җавап итеп китерә һәм үзеннән:

– Нәчтинкәнең «пиридний худ»ка йөрүе генә түгел, татарчаны аңламавы да бик шәп булып чыкты бит әле, агайне, «җук»ны белмәгәч, «җә» дип баш селкеп кенә тора икән ул, ни гайбәткә катышмый, ни... – дип тә кушарга гадәтләнде.

Авыл халкы алдында мөселман йортына тәреле кызны кертеп оятка калганы да бик җиткәнгә, «ни эшли» дигәнен беркайчан да әйтеп бетерми иде Габдрәзак агай. Соңгы «ни»не кем ничек теләсә, шулай аңлады, әмма ләкин берсе дә начар мәгънәләр салмады.

Пешекчегә укыган Рәйха авылдан китәргә ашыкмады. Аны яңарак кына абыйсы кырчылык бригадасына эшкә урнаштырган иде, шунда үзеннән яшь булса да, эшкә ярыйсы гына уңган Касыйм белән дуслашып өлгерде ул. Иртә уңмаган кич уңмас дигәндәй, озак та үтми, Рәйхага йөрәк яраларлык сүз ишетелде: эшләвен эшләсә дә, юләрлек справкасы бар икән бит Касыймның!

Әйтәм аны «апа да апа» ди, артыннан озатып кайткач та «җаный» диясе урынга, дип өзгәләнде ул эченнән. Сәеррәк сүзләр дә ычкындыргалый... Шул хакта бер төн уйлады кыз, ике төн, өченче төнне уздыргач, түзмәде, абыйсына, документларны алып, хат белән фәлән адреска җибәрерсең, кешегә кайда икәнлегемне әйтмә, диде дә шулай ук авылдан чыгып югалды.

Рәйха Казанда чыбык очы тиешрәк бер туганына тукталган иде, аларның бүген өйләндерерлек буй җиткән егетләре бар икән, шул өйдә төпләнеп, килен булып калды. Йөрми-нитми кавышкан бу пардан да бәхетлерәк ярлар юктыр иде кебек күршеләренә. Гаилә тынлыгы, рәхәтлекләре кеше көнләштергәннәрнең дә һәрвакыт мәңгелек булмый икән. Ыгы-зыгы балалары тугач башланды: әле теге, әле бу төше авырта иде Илнарның. Аннан да, моннан да чир тапкач, каенанасының да сабыр канатлары сынды. Гомер саклаган серен чыгарды да салды:

– Акылга тулы түгелдән тәнгә дә тулы түгелләр генә чыга икән шул... – Аннан, сөйләгәч сөйләргә инде дигәндәй, Илдарның зәгыйфьлек справкасын акча төртеп кире алдыртуын да әйтеп ташлады.

Бәгыренә таш утырды Рәйханың, ник бер бәхетсез урынына өч бәхетсез ясадың, дип, каенанасына бик әйтәсе килсә дә, теш кысып түзде, акылы гына сау булса иде, дип, үз баласына теләк теләүдән узмады. Илдар да каенанасына багалма иде кана! Көтелмәгән хәбәр Рәйха күңелендә бөреләнеп килгән хисләрне дә үтерде. Кемлеген белгәнче, бер дигән ир күренгән Илдарга ни җаны, ни тәне тартмый башлады.

Хатыны белән ике арага мәче йөгергәч, Илдар да суынды, үз эченә бикләнеп калды. Ике арадагы мөнәсәбәтләргә, Илдарга, баласына аек күз белән карарга керешкәч кенә, Рәйха Илдарга сәерлекләр хаслыгын абайлый башлады. Моңа кадәр тапкырлык кебек кабул ителгән килделе-киттеле сүзләре, бервакытта да җиренә җиткереп башкарылмаган эшләре, бер шаярту булып тоелган гадәтләре юләр кешенең холык-гамәлләре булдылар да калдылар. Иялэнгән йортын, каенанасын, баласының атасын мондый чакта ташлап китү бик авыр булганга гына, Рәйха түзде, тешен кысып түзде...

Шифаханәләр буйлап йөргәндә, кабул иткән чираттагы табибы бергә уйнап үскән яшьлек дусты булып чыкты. Больница бүлмәсендә чаршау белән бүлеп алган бер почмакта бергәләп чәй эчкәндә, беркемгә сөйләмәм, дигән вәгъдәләр алып, эч серен шуңа бушатты ул. Зәйнәп тыңлап-тыңлап торды да юатасы, тынычландырасы урынга:

– И, үзең соң! Бу язмышка кемне гаепләр идең?! Шундый егетләрең була торып! Син пешекчелеккә укыганда, Адай малае артыңнан йөргән ие бит әле, сипкеллерәк бер нәрсә, җенем күтәрми иде минем шуны, ә син, акыллы да, матур да дип санап, миңа гел үпкәли торганыең... Шуңа гына чыксаң соң! – дип, җанына тагын да зуррак җәрәхәт ясады.

Монысын ук көтмәгән иде Зәйнәптән Рәйха. Аның сүзләреннән күңеле тагын да ныграк җебеп, буыла-буыла еларга ук тотынды. Сулкылдавыннан туктаган арада, үзе:

– Анысы да юләр иде бит аның, дус-ишләреннән шуны ишеткәч ташладым, ярый әле, вакытында белдерттең, дип, Ходайга мең шөкер кылдым, андыйлар юлыма чәчеп үстергән кебек икән шул... – дип, такмаклый-такмаклый сөйли иде. – Берсеннән качтым, икенчесеннән котылдым, өченчесенә тотылдым...

– Ник, ә Расим, Расим нигә ярамады? – дип сорады бу сүзләргә исе киткән Зәйнәп. – Аның белән дә бер дигән пар идегез ләбаса?!

– Расимга алгы йөрешләр генә кирәк иде, башкасы тормышны артка сөйрәр дип уйлаганмы... Аякларымның, Расим әйтмешли, «задний ход»ы гына эшли иде шул... Шагыйрьләр әйтмешли, бәхет каршы офыкларда була мәллә? Аңа таба йөз белән генә, кочак җәеп кенә барыргамы? Минем кебекләр аңа борылып кына карый ала микәнни?

Дустының бу сүзләре Зәйнәп өчен алдагыларыннан да сәеррәк тоелды. Кирәк булса, аңлатыр әле, дип уйлады ул, хәсрәттән иртә олаеп барган хатынга карап. Рәйха, аның белән хушлашкач, баласын алып, кичке поезд белән яңадан туган ягына кайтып китте. Озата чыккан каенанасына, нәкъ авылдан качкан вакытындагы кебек:

– Документларны, вакыт табып, почта аша җибәрерсез әле, бүген бернигә кул бармый, – диде. – Әнкәй, йә оныгыңның хәлен белергә кайтсаң, үзең белән алырсың. Миңа үпкәләп калма, зинһар, риза-бәхил бул. Тормадым, түзмәдем түгел...

Туган нигезендә, авылында беркем көтмәсә дә, шунда төпләнергә иде нияте. Хуҗалык кенәгәсеннән дә сыздырмаган әле абыйсы, әмма йортта килен булмаса да, аның янында калырга теләмәде Рәйха. Көмәнле чагында кайткач, кайчандыр Расим белән өй салырбыз дип карап йөргән пуҗымда бер дигән йорт кукраеп утырганлыгына игътибар иткән иде. Хуҗалары шәһәргә күчкәннәр икән, акчасы җитсә, шуны алырга, шунда калырга исәпләде. Кичкырын, арт бакчалар аша гына шул өй турысына барып чыкса, киртәсез межасында Расим утыра.

Ни дә булса ишетеп килгәнме? Үтеп барышы гынамы? Ул да шушы нигезне алырга йөрмидер ич инде? Рәйха кайсы фикерен дөрес дип табарга да белмәде. Моңарчы сәламенә җавап кайтарганы булмаса да, ерактан ук үзе башлап исәнләште. Сәлам алышу – изге гамәлдән, ди иде мәрхүм әбисе...

Расим кагына-кагына межа сукмагыннан торды, бәрәңге буразналарын таптап, яшь сабакларны имгәтә-имгәтә, берничә адым атлады. Тукталды. Аның да каршы килгәнен көттеме ул? Рәйха... Ул исә арты белән борылды да, нәкъ бию кичәләрендә турылаганча, җилкә аша карап, аңа таба китте. Биерлек җир булса да, биемәс иде ул биюен. Олыгаеп килә, уен-муеннарга күңеле күптән ятмый.

Рәйханың үзенә килүенә сөенгән Расим тагын атлады, тагын, тагын... Рәйха шулай, арты белән барган килеш кенә, Расимның киң итеп үзенә ачылган кочагына килеп керде. Дөрес эшләдеме, юкмы – берсе дә ул турыда уйламады. Икесе дә утызга җиткәндә кылган бу тилелекләреннән кычкырып көләргә тотындылар. Расим, Рәйха һич көтмәгәндә, аны яшьлектәге кебек уттай кызарырлык итеп:

– Кайчак артка атлаулар да бәхеткә илтә икән бит, – дип куйды. – Ә син теге чакта үпкәләгән булдың тагын...

*2006*

## НИГЕЗ ТУФРАГЫ

Мари якларына, аның чикләвек куаклы тау битләренә, балыклы чиста суларына, нәҗесләндерелмәгән урманнарына иялəнгән иде аның күңеле. Үзләре кебек кыска, нечкә агачлардан салынган тәбәнәк өйләре дә, бәйрәмнәрдә киелә торган ак киндерне сәйләннәр белән чуарлаткан күлмәкләре дә, икегә аерылган, юка чәчле башларының уртасында гына утырган, өчпочмакка охшап торган чүмкәләре дә, инеш буенда гадәти көннәрдә дә гөбердәгән, әчкелтем арыш исе белән күңелне иләсләндергән көмешкә мичкәләре дә якын, бик якын иде аңа.

Ул бигрәк тә кендекче Улинә карчыктан аерылуны авыр кичерде. Киңәш сорап кергәч, китмә, кал, дигәнен көткән, һай, көткән иде бахыр. Ә тегесе үзалдына гына мыгырдана-мыгырдана мичкә ут көйрәтеп утырган җиреннән, барасың килгәч, бар соң алайса, гомер буе безнең арада кимсенеп йөрмәссең, ирле дә, өйле дә булырсың, дип куйды.

Улинә карчыкның мичнең ишек ягы тирәли куелган озын плитәсендә кечкенә чуен савытларда быгыр-быгыр үлән кайный. Берәүләр ышанмаса да, аның турында, сихер белән җенләнә, дип сөйләнгән сүзләр барысы да хаклыгын Гөлсем бик яхшы белә, чөнки дүрт-биш үк булмаса, һич югы, көнгә ике-өч тапкыр аңа керми калмый.

Кызның үзенә дә сихер гамәле ят түгел, тик нәтиҗәсен генә күргәне, файдасын гына сизгәне юк. Улинә карчыкның, минем ярдәм белән кияүле булдың, дип әйтерен көткән иде ул, тик тегесе ул хакта ләм-мим. Пыш-пыш килеп, мич тирәсендә булышкалап йөрде дә ут яктысын саран гына кертккән кече як тәрәзәсе төбенә барып утырды. Оекбаш ямаргамы иде исәбе, башка бер тегү ише нәрсәгә керешмәкчеме – мич аралыгындагы агач тартманы аягы белән генә эләктереп тартып китерде дә гөмбәчеккә кадалган бер булавканы алып, Гөлсемгә күрсәтте.

– Син барасы картның мәрхүм карчыгы менә шуның ише нәмәрсә ырымлатып алган иде, үз башына да җиткән, ахрысы, бәгъремнең. Нигезгә кадарсың дип биргән идем, нишләткәндер...

Улинә түтәйнең татарчасы яхшы, әмма ләкин авазлары бик каты, безнең мишәрләрнекеннән дә катырак килеп чыга иде, шул аның сөйләмен тагын да серлерәк, сихерлерәк итә. Гөлсем, ул сузган булавкага бик озак текәлеп карап торганлыгын абайлап, уңайсызланып китте, шул гына татар хатынының ни өчен андый эшләр белән йөрүен сорарга дигән уен оныттырды. Бераз дәшми торганнан соң, кыңгыр эшләрне башкаларга гына хас санагандай:

– Мөселман карчыгы да сихер белән аңгырайсын инде, – дип әйтеп ташлады.

Улинә түти аның бу сүзләренә игътибар да итмәгән кебек булган иде, тик кыз үзләреннән чыгып барганда:

– Тормыш үзе ышандыра ул, ылан, әле шулай сөйләнеп торган буласың да... Бер сихерләнгән нигезгә яңадан бәрәкәт килми инде ул... – дип куйды. Аннан уйланып торды да: – Туфрагын алмаштырмый торып, – дип өстәде.

Гөлсем бу сүзләрдән соң кияүгә бару түгел, сорап килүчеләрдән үк әллә ничә чакрымнарга качарга тиеш кебек иде, әмма нәкъ әлеге катгый хөкем аның ихтыярын юкка чыгаргандай, аякларын ерак бер татар авылына атлатырга мәҗбүр иткәндәй булды.

Фәхретдин абзыйның яше әле алтмышка җитеп кенә килсә дә, кырыгы да тулмаган Гөлсем өчен шактый карт иде инде, алай да үз өең үз өең инде ул, дип уйлады ул, ят нигезгә аяк басканда. Бу хуҗалык нык. Йортлары юан-юан бүрәнәләрдән, әллә ничә яклы, каралты-кура, авылга хас булганча, биек койма белән уратып алынган, урамга чыгарып, урыс капка ясалган.

Мал өе дә, аш өе дә мариларның кунак өеннән биегрәк, зуррак икән, дип уйлады кыз, хуҗалыкны бер кат күздән кичереп йөргәндә. Гөлсем белән Фәхретдин яшисе йорт, ишегалдының сул як түрендә

булып, җиләк-җимеш агачлары кочагында, җилләрдән, ят күзләрдән ышыкта утыра иде, әмма яшь хатынга иң ошамаган нәрсә шул булды.

– Бер-бер хәл килеп чыкса, кеше дә ишетми, Аллам сакласын! – диде ул, мари бизәкләре төшерелгән төнге күлмәген өстенә кия-кия, ирен аптыраштa калдырып. Гөлсемнең ике якка кош канаты кебек аерылып төшкән толымнарында да мари чулпылары, колакларында да марилар яраткан яфрак алка.

– Мин сиңа ай алка бүләк итәрмен әле, – диде Фәхретдин. – Аннан гел минеке генә булырсың. Мари киемнәреңне дә тотып утка ягарбыз.

Иренең яратыбрак та, якынаерга теләбрәк тә, шаяртыбрак та әйтелгән бу сүзләре Гөлсемнең күңеленә шундук шом йөгертте. Ә нигә мари киемнәрен ташларга? Күбесе Улинә җиңгәсе белән әзерләнгән ич аларның! Сихер-михер дә куркыныч түгел, тәнгә дә рәхәт: үзләре гади, үзләре җылы.

– Безнең өйдәге сандыкларда бирнәләрнең бер дигәне! – дип дәвам итте Фәхретдин. – Патша вакытыннан бирле килгән, әтиләрдән калган мал ул. Сәвит абзаңнан базда гына саклaдым мин аларны. Менә синең бәхеткә икән. Гайниҗамал җиңгән, буйга озын булгач, берсен дә кия алмады. Әле син дә байбичәләр кебек йөрермен дип хыялланмагансыңдыр.

Ул, йокы бүлмәсенең баз авызын ачып, өй астына төшеп китте дә, көмеш йөгерткән калайлар белән бизәлгән кечерәк кенә бер сандыкны идәнгә этеп тә чыгарды:

– Карый тор, матурым!

Каршы килмәс өчен генә сандык капкачын ачкан иде Гөлсем, патшабикәләр генә кия торган киемнәрне күреп аһ итте. Аһ итте, әмма берсенә дә кагылмады, шалт итеп кире ябып та куйды. Сандыктан үлемтек тукымалар исе килә, тән чиркандыргыч таныш түгел хушбуй исләре аңкый кебек тоелды аңа.

Өй астыннан күтәрелгән Фәхретдиннең ай-ваена түзмичә генә, бер төнге күлмәкне өстенә киеп караган булган иде, бик килешле утырды, дип, тегесе яңадан салуын теләмәде. Гөлсемнең беренче көнне үк ирен үпкәләтәсе килми иде, ризасызлык кыяфәтен чыгарса да, кытай ефәгеннән тегелгән күлмәкне киеп, карты янына менеп ятты.

Бу күлмәкме, киләчәк язмышыннан куркумы, әллә башка бер нәрсәме, аның төн йокыларын качырды. Беренче төнне дә, икенчесен дә керфек какмыйча чыкты. Фәхретдин моны ят тормышка, ир кочагына ияләнүнең авырлыгына сылтады, ә хатын исә әлеге күлмәктән, шул күлмәкләрне саклаган нигездән күрде. Шулай дип уйлавы булды, кылт итеп хәтеренә Улинә түтие әйткән башка сүзләр дә килде. Инде аны үзе дә раслагандай, ире ишетерлек итеп:

– Туфрагын алмаштырмыйча, бәхет килми инде бу нигезгә, – дип әйтеп куйды.

Фәхретдингә хатын булып төшәр алдыннан булган хәлләрне сөйләсә дә, тегесе көлде генә, чирле карчыгының ерак бер мари авылына аңа сиздермичә генә барып йөрүенә ышана идеме соң ул?!

Гөлсемнең җәй айлары боеклыкта, күңелсезлектә узды. Җырсыз-биюсез бу татар авылын берничек тә якын итә алмады ул. Иртә эш, кич эш, ярый әле төне бар, дип көрсенә иде, каралты-кура тирәсендә вак-төяк эшләр майтарып йөргәндә дә, нишләргә белмичә тәрәзә төбенә утырып моңсуланганда да. Колхоз эшенә чакыручы булмагач, үзе сорап чыгасы итмәде, карты белән ялгызрак гомер уздыруны, күршеләр белән артык аралашмауны хуп күрде.

Чит бер күзгә сизелерлек булмаса да, Гөлсемдәге боеклыкны Фәхретдин сизә, эчтән генә борчылып йөри иде. Җитмәсә, көзгә кергәч, бәрәңгеләрне алып бетергәч, ни сәбәптәндер аяксыз калып, урынга егылды.

Үлән кайнатмалары белән дәвалаган Гөлсем:

– Синең авыртуың да шул туфрактан булмагае, – дип әйтеп куйгач, үзенең дә күңеленә шик төште. Ышанырга-ышанмаска белмәсә дә, башына, язга чыгу белән, туфракны алмаштыру уен беркетте. Кышын ару гына йөреп торган Фәхретдин, нигез туфрагын алмаштырып, җиргә салынганын ерак басуга илтеп, аның урынына шул ук басудан икенчесен ташый торгач, тәмам аяктан калды да көннәрнең берендә үлеп тә китте.

– Ревматизм чиреннән йөрәгенә бәргән, – диде районнан чакыртылган, аны дәвалый торган врач. – Күпме әйттек үзенә, язын саклан, аягыңны туңдырма, артык авыр күтәрмә, дип. Авыл кешесе тыңлыймыни, мондый чирле йөрәк белән нинди эшләр эшләп яшәгән бит! Атна эчендә нигез туфрагын алмаштыр инде! Ут капкан шикелле. Анысы нигә кирәк булган диген? Бер көйгә яшәргә дә яшәргә генә ләбаса... Үз хәлеңә карап кыймылдап.

– Юк ла, шул туфрак башына җитте аның! – дип төзәтмә кертте күзләре елаудан шешенеп беткән Гөлсем. – Вакытында алмаштырырга өлгерә алмый калды!

Картын җирләгән көнне үк Гөлсем, чын күңелдән чакырсалар да, күршеләргә кереп йоклап тормады, элегрәк тә көн иткән өеннән ызбаның икенче яктагысына күченергә ниятләгән иде, затлы сандыклар саклaнган нигезне ташлап, тәки шунда тора башлады. Монысы кечерәк, җылытырга да азрак кирәк, нигезе турында сүз куертып та торасы юк!

Тормышның бер җөе китсә, яңадан тоташтыруы җиңел эш түгел. Шулчак аның күңеленә тагын шик төште: туфрак алмаштырган Фәхретдин булавка турында берни әйтмәде ләбаса, әгәр ул нәкъ менә монысына кадалган булса? Алай түгел икән, ник бу йортта гына яшәмәгәннәр алар карчыгы белән? Ничә еллар буена бер кереп җыештырмаганнар да...

Күчеп кергән йортны рәткә китерүне ул нигезне тырмалап, ырымланган булавканы эзләүдән башлады. Хәерсез нәмәрсә икән, табылмады. Инде монысының туфрагын алмаштырудан бер-бер мәгънә тапмыйча, сихер кайтару ырымын укып, су бөркергә дә өстеннән ныклап күмәргә, төрле әйберләр белән бастырырга, урын-турын пычак-чәнечкеише нәрсәләр ырымлап ташларга, бер дә ачык җирен калдырмаска, һич югы, янәшәдәге автопарктан трактор кабинасының ишеге кебек авыррак, саллырак нәрсәләр белән булса да капларга ниятләде.

Хәзер Гөлсемнең төп эше, кешеләр йокларга яткач, ачык калдырылган гаражлардан тимер-томыр юнәтү иде. Ниһаять, нигез дә эчтән-тыштан күзгә күренеп биегәйде – аның ике кулына бер эш калмады.

Ялгыз гына көн уздырган хатынның күңелен эч пошу хисе биләде. Урыс капка артына утырып, ишегалдында мари җырларын җырлау да, үзе өчен үзе оештырган тамашалар да әлеге тойгыны баса алмады. Кайвакыт төннәрен, күңеленә тынгы тапмаганда, баскыч төбенә чыгып уларга ук ябышкан иде – авылның җыен ташландык эте аның ихатасына кереп тулды. Капка астыннан кергән берсе, хуҗабикәгә ияреп, йортка узды да, китмәскә килгән килен шикелле, мичле бүлмәләрнең бер почмагын үзенә алды.

Гөлсемнең бу хәлләргә куанычына чик-чама күренмәде. Бернигә кирәге калмаган абзарларны болай да сүтеп яга башлаган иде, ныграк такталарыннан этләргә оя ясарга кереште. Әлеге шөгыль аның вакытын да алды, күңелендәге эчпошыргыч уйларны да бер читкә куйдырды.

Ел дигәндә, өйдә эт оясы куярлык урын калмады, Гөлсем көн иткән бүлмәләр зур бер эт хуҗалыгына әйләнде. Яшь кызлар аның каралтысы яныннан узып, клубтан кайтырга курыкса, вакыты белән купкан эт өрүеннән күрше-күләннең төн йокысы кача иде. Гөлсемгә шул гына кирәк тә. Инде аннан кешеләр үзләре кача! Инде аңа ырымланган нигез туфрагы да куркыныч түгел! Эттән ничек курыкмыйсың, дигән булалар тагын, кеше, кеше куркыныч ул! Һәр саныңны сөяккә калдырырга торалар бу заманда!

Гөлсем этләр белән яши, эт телендә сөйләшә торгач, үзе дә тәмам эткә әйләнде: җиргә иелеп бетеп бөкрәйде, чәчләре тузгыды, күзләреннән нур качты. Картының кешедән яшереп җыйган акчасы бетте дигәндә, яше җитеп, игелекле бәндәләр үзенә пенсия юллап бирделәр. Почтальонка тиешлесен айның бер үк көннәрендә койма ярыгыннан гына сузып, кәгазенә дә шул ярык аша гына кул куйдырып китәргә күнекте.

Матур язларның берсендә Гөлсем карчык яшәгән йорт турысына шәп бер кошевка килеп туктады. Аннан, үз телләрендә сөйләшә-сөйләшә, милли киемнәр киенгән мари хатыннары төште. Арадан берсе, батыррагы булгандырмы, бу нуры киткән нигез капкасын ачаргамы-ачмаскамы дип уйлап торгандай итте дә, бавыннан тартып, капка келәсен күтәрде. Аннан, ишегалдына үткәч, күрер күзләренә ышанмады: яшел чирәмлеккә куелган зур коштабакларның берсеннән кайчандыр аңа кереп йөргән, күршедә бала караган ятимә кыз этләр белән аш чөмерә иде. Кыз дию бала тапмаган хатыннарга эндәшә торган бер гадәт буенча гына инде. Чәчләре пыркыган, күзләре аларган бу җан иясенең кемлеген бары тик сизгер күңеле белән ул гына аңлады. Улинә карчык, әле һаман да төз калган гәүдәсен тагын да турырак тотарга тырышып, Гөлсемгә таба атлады. Этләр дәррәү ырылдап куйдылар.

– Ни хәлең бар, кызым? – дип сорады карчык, үзеннән дә олырак күренгән бу татар хатынына, таушалып беткән киемнәр эченнән елтырап карап торган күзләргә текәлеп.

– Ярый әле. Яшим шунда. Сез сихерләгән булавкидан инде тамчы да курыкмыйм. Чыкмаслык итеп нигезгә яшердем мин аны!

Улинә кайчандыр булган хәлләрне оныткан да иде инде. Сискәнеп китте:

– Кызым, ул булавкины Фәхретдин абзыйның мәрхүм карчыгы башка нигезгә имләтеп алган иде бит! Әле аңа чыкканчы, ерак басу түрендәге йортта ялгызы гына яшәгәндә. Күчереп утыртылганмы, үзе таралып беткәнме бер авылда. Ирсез булгач, каралты-кура күчерешерлек кешесе табылмагандыр инде. Каргалы кыры дип йөртелгән җир шул авылның исеменнән ул. Этләр ияләште, тәмам аздылар, куркыта, качып, таралып бетмәсләрме, дигәч кенә, ырымларга булган идем мин аны. Кат-кат әйттем үзенә анда да, кияүгә китәсең булмаса, ырымлатма, барсаң, кире кайтма, дидем. Сихерләнгән туфракта беркемгә дә бәхет килми бит ул. Тыңлады, чыккан җиренә таш булып ятты. Алай дисәң, барыбер бәхетле булмады. Үлемне сихер белән җен дә җиңәме соң?! Әллә ырымының зыяны үзенә дә төште микән?

*2006*

## АЯК КИЕМЕҢ ТАР БУЛСА...

Аяк киемең тар булгач, дөнья киңлегеннән ни мәгънә, дип әйткән ди берәү. Әнисенең гел, тәне буылганның җаны да буыла аның, дигәне белән бик килешкәнгәме, Нәкыйп гомергә кысан ботинка кимәде, билен каеш белән бумады, күлмәкнең иркенен, баш киеменең чалшаеп маңгайга төшеп торырлыгын сайлады. Бу сүзләрнең башка мәгънәгә ия икәнлеген ул бары тик кызлар артыннан чаба башлагач, бигрәк тә сыйныфташ кызы Кәртинкә Галиясенә күзе төшкәч аңлады.

Кәртинкә дисәң дә кәртинкә иде кыз. Килмәгән бер җире юк: кашы-күзе дисеңме, колагы-борынымы – барысы үз урынында, барысы Нәкыйп теләгәнчә. Елмаеп карап торса, иреннәреннән суырып үбәсең килә, керфек очларын түбән төшерсә, кочагыңа алырга тартыласың, дәшми узып китсә, бөтен тәнеңне дәрт дулкыннары били.

Дәшми дигәннән, Галия сөйләшә торганнардан түгел иде. Менә шунысы гына баштан ук ошап бетмәде Нәкыйпкә. «Кич чыгасыңмы», «озата барыйммы» кебегрәк вак-төяк сорауларга да җилкә сикертеп кенә куя йә бөтенләй үк игътибарсыз калдыра. Шул гадәтен белгәнгә, ул үзе дә аның тирәсендә артык сүз куертуны кирәк дип тапмады. Озата барган саен, бер генә сорау бирә дә китә.

«Яратасыңмы?» – дигәнне һәр кич ишетеп, Галия туяр, йә куып җибәрер, йә уңай җавап бирер дип көткән иде, ул уйлаганча барып чыкмады. Кыз, әлеге серле сорауны һаман-һаман әйтсен әле дигәндәй, күзләре белән томырылып карап тик тора. Ахырда Нәкыйп түзмәде, сорауны башкачага үзгәртте:

– Минем хатын булырга ризамы син, кызый?

Вәт кәртинкә дисәң дә кәртинкә иде шул Галия. Оста рәссам иң чибәр мизгелен тотып алган кыз сурәте кебек сәгатьләр буе бер рәвештә катып калу да, игътибарлы кыяфәт чыгарган булып, Нәкыйп сөйләгәнне тыңлау да – аның өчен чүп кенә! Иң кызыгы шунда: иреннәре һәрвакытта әйтелмәгән сүзе тел очындадыр кебек серле генә елмаялар.

Әнә шул серне беләсе килү, авызыннан бер татлы сүз тартып алу теләге Нәкыйпнең бөтен дөньясын тарайтты. Ул, кызны озатып куйган җиреннән кайтканда, бугазыннан буылган сыер шикелле, муенын боргалый-боргалый кәчтүм сәдәфләрен чишеп, пирчәткә-мазар кигән чагы булса, салып, кесәсенә тыгып кайта торганга әйләнде. Ачуы килсә, башына кашын каплап диярлек киелгән бүреген үз турларына җитәрәк бар көченә биек койманың эчке ягына ук ташлый башлады.

Кыз яшәгән капка төпләренә җитәрәк, тирләп чыккан аякларына яңа гына алган затлы ботинкасы да, аның эченнән киелгән киҗе-мамык носкилары да тар, аяк размерында түгелдер кебек тоела иде аңа. Теге берәү хак әйтсә дә әйтер икән, ботинкаң тәпиең сыймагач, тәнең киемдә буылгач, дөнья киңлегеннән ни мәгънә?!

Нәкыйп тора-бара Галиянең күңеленә якын кушаматын да, азсүзлелеген дә сөйми башлады, әмма ләкин үзен яратудан бизмәде. Ярату тойгысы, торган саен ныграк көчәеп, тәмам үзәгенә үтте, йөрәк бәгырьләренә төште.

Кичке уеннан кайткан бер көнне Нәкыйп түзмәде, кызны кофтасыннан йолкып кискен туктатты да:

– Яратсаң, яратмасаң да, Чәүкә кушаматлы итәм мин сине, кызый! – диде.

Чәүкә – Нәкыйпнең нәсел ләкабе булып, буыннан буынга күчкән һәм ата-бабасыннан килгән кирелекне дә, кешене телсез калдырырлык туры сүзлелекне дә, усаллыкны да, кыюлыкны да аңлата иде. Галия егетнең шулай дорфа итеп үзен кияүгә соравын ошатып бетермәде, шул көнне үк, төнлә, егетнең кыланышлары турында, үзеннән куша-куша, апаларына сөйләде. Әллә башка бер нәрсәгә күңеле тулып, әллә сабыйлык акылы белән елап та җибәргәч, тегеләренә җитә калды, бу елауны зуррак та хәлләргә фаразлап, егеткә шәпләп сабак укытырга булдылар.

Кәртинкәләр болай карап торганда азсүзле күренсәләр дә, үзләренә кирәктә чәүкәнекеләрдән бер дә кимен куймыйлар икән, икенче кичне үк, сеңелләрен өйдә калдырып, Нәкыйпне тукмарга дип, клубка чыгып киттеләр.

Егет клубта күренмәде. Әнисе Мәгыйшә Кәртинкә нәселен болай да өнәп бетерми иде, клуб эчендә колактан колакка сөйләнгән гайбәтләрдән үзенә тиң күргән төлкенекеләргә димче җибәрткәнлеге аңлашылды.

Ахырдан сүзне чын дип тапкач, кызлар туп-туры Нәкыйпләргә төшеп киттеләр. Зәһәрләре тагын да арткан, каннарында үч котырган кызларны күргәч, башка берәү шым гына таю ягын карар иде, капка төбендә тәмәке пыскытып басып торган егетнең керфеге дә селкенмәде.

– Сугышабыз мәллә, түтинкәләр? – дип, үзе үк мыскыллы каршы алды ул.

Кызларның олысы, Зөлхәбирә атлысы, бөерләренә таянып, алгарак чыгып басты:

– Син нәрсә, безнең Галияне һәр чыккан саен елатып кайтарасың? Кулың, телең озыная башладымы?

– Сүз ошамаган мәллә? – диде Нәкыйп. – Әнә сез бик телле күренәсез, аңа биргән соравыма җавап бирә алсагыз, рәнҗеткәнлегемне танырмын. Яратамы ул мине, юкмы?

Чыннан да, ярата идеме соң сеңелләре аны, дип уйлап куйдылар кызлар, тик бу сорауның җавабы үзләренә дә аңлаешсыз иде. Кәртинкәләрнең иң аз сүзлесе булган Галиядән кайтып сорасаң да, апаларына да әйтер идеме икән – шикле. Бер тешләсә, телен шәп тешли иде сеңелләре.

Карап-карап тордылар да кызлар кайтыр якка борылдылар. Икенче көнне Нәкыйп аларның өенә үзе китте. Галияне кеше аша гына чакыртып чыгарды да тагын әлеге дә баягы сорауны кабатлады.

– Кызый, синең белән минем язмыш хәл ителә бүген, ачуымны чыгарма, – диде ул, сабыр булырга тырышса да, дуамаллыгын тыя алмыйчарак.

Кыз юлның каршы ягында үскән тупыл агачына терәлгән дә каткан иде. Нәкыйп дәшми генә көтәргә булды. Аннан күзең чыксын дигән кыяфәт белән кул селтәп китте дә барды.

Әнисе яраткан кызга да өйләнмәде ул, Кәртинкә артыннан чабуыннан да туктады. Ай чамасы бер кызга сүз каткалап йөрде дә ахырдан, яучы төшертеп, шуның белән Донбасс якларына китеп югалды.

Еллар узгач, дөньялар үзгәреп, гаиләсе белән Казанга кайтып төпләнгәч, көтмәгәндә, Ирек мәйданындагы тукталышта Нәкыйп Галияне очратты. Кәртинкә дисәң дә кәртинкә иде шул ул! Бик аз гына калынайган, бераз олы чырай кергән, әмма һаман да кайбер яшь кызларга да алыштыргысыз. Күзләрендә генә боеклык. Эчке сагыш та баса алмый иде Галиянең матурлыгын!

Нәкыйп аны күргәч өнсез калгандай булды. Аягындагы кыскан ботинкасыннан буыннарының хәле китә, күлмәкләренең тарлыгыннан, яка тирәли әйләнгән галстукның бууыннан күз аллары караңгылана төсле тоелды. Ботинкаң кыскач, дөнья киңлегеннән ни мәгънә?! Ә бит ярата, һаман да ярата икән ул Галияне! Менә аның, аның онытканмы, юкмы икәнлеген ничек белергә?

– Яратасыңмы, юкмы, син мине, кызый? – дип сорады ул, аерым сүзләренә басым ясый-ясый. – Һич югы, теге чакта ярата идеңме, юкмы?!

Ярата да, онытмаган да иде Галия. Кайчан да бер очратса, әйтермен дә үзәген өзәрмен әле дип яшәде ул. Ялгыз кичергән гомеренең, бәхетсезлегенең үчен әнә шул сүз белән алыр шикелле иде. Нәкыйпнең дә үзен онытмыйча яшәгәнлеген аңлагач, яратканыңны әйтеп кенә үч алып булмыйдыр шикелле тоелды аңа. Бер бәхетсезне тагын да бәхетсезрәк итү кирәк тә түгел иде шикелле.

Борылырга да китәргә иде кана! Шулай эшлисе урынга, Галия, кызлык горурлыгы терелепме, нәсел гадәтен һаман да ташлый алмый идеме, Нәкыйпнең ни әйтер дип кысылып көткән күзләренә терәлде дә катты. Ни «әйе», ни «юк» димәде.

Көтмәде түгел, көтте Нәкыйп үзе ишетәсе килгән җавапны. Тешләрен кысып, йөрәген учына алырдай булып көтте. Бу матур сурәттән, бу затлы киемнәргә төренгән тәннән бер-бер өн чыгар, түзмәс, Галия гомер эченә бер тапкыр ярату сүзен әйтер шикелле иде аңа.

Хатынның яратканлыгы аңлашылу нәрсәне булса да үзгәртер, язмышын икенче якка борыр идеме – ир ул турыда да уйламады. Нәкыйпкә кайчандыр булган хисләрнең сафлыгына, чынлыгына гына ышанырга, Галияне йөрәгендә, җанлы бер матур сурәт итеп, үлгәнче сакларга кирәк иде. Ә ул әнә аның күзләренә текәлгән дә тик тора. Табан асларыннан өерелеп өскә күтәрелгән хисләр күкрәк эчендәгеләр белән кушылдылар да тамакка төер булып тыгылдылар.

Гомерендә хатын-кызга түгел, балаларына, ир-атларга да кул күтәрмәгән, тупас сүз әйтмәгән Нәкыйп, инде үз җанын, теләкләрен аңлатуның башка чарасы калмаган, гаҗизләнгән бер кыяфәттә, йодрыкларын әле ачып, әле йомарлап торды да, трамвай көткән бар кешене таңга калдырып, хатынның яңагына чәлтерәтте.

Аннан инде эш бетте дигәндәй, кызу-кызу адымнар белән Федосеевская урамындагы өенә, Нәкыйпнең җаена гына торган, үзенең бәхете санаган хатыны янына кайтып китте.

*2006*

## ЯЗЫК – КАЗЫК БАШЫНДА...

Фазылҗан картны үзен белә белгәннән бирле Әүлия дип йөрттеләр. Бала чагында ук бу кушаматның тагылуы бераз сәеррәк тә иде. Аның тарихын авылдашлары түгел, ул үзе дә инде хәтерләми, әмма ләкин, гомер бакый җисеме исеменә туры килеп, изге бер зат сыйфатында яшәде. Әле егет чагында, иптәшләре авылны ду китереп йөргәндә дә, алар белән эчеп алып, авыл буйлап авыз күтәреп җырлап йөрмәде, кызлар өчен борын канатканчы сугышмады, авызына тәмәке кабып хәрәм әйберне алмады, кешегә каршы килү түгел, кайвакыт туры күтәрелеп карарга да җөрьәт итмәде сыман.

Инде өйләнеп алып, олыгая төшкәч тә, һаман шул яшьлегендәге кебек тыйнак холыклы, күркәм гадәтле, ачык чырайлы булып калды. Күршеләрен ярдәменнән ташламады, әти-әнисен ризыктан аермады, хатынына кырын күз белән карамады, балаларына-оныкларына тырнак белән дә чиртмичә, сүз белән игә китереп үстерде. Әүлия дисәң дә әүлия иде.

Мондый холыклы кешенең намазлык өстендә, догада, зур авырулар кичермичә үләсенә һичкемнең күңеленә шик килми иде, алай булып чыкмады. Фазылҗан карт инде ничә ай буена сызланып, ухылдап

урын өстендә ята, нәсел-нәсәп белән хушлашкан, балаларына фатихасын биргән, оныкларына әйтәсе сүзләрен әйтеп бетергән, үлемне көтеп-көтеп тә көтеп ала алмаган иде.

Әүлия карт карап торышка әллә ни каты авырган да кебек түгел, районнан олы улы чакыртып кайтарган докторлар да тыңлап-тикшереп, нинди диагноз куярга белмәделәр, картлык чиредер, яше бар бит инде, йөрәге бик таза, бераз торыр әле, дип киттеләр.

Яшәвенә өмет калдырмаганга гомерен янәшәсендә кичкән карчыгы Гайнибикә табибларга үпкәләмәде, ул моны үзе дә белә, тик беркемгә начарлыгы тимәгән, үсмер чагыннан намазда булган, мәетләрне юган, күмешкән, ата-бабаларының рухына догасын туктатмаган иренең бу кадәр газапланып, сыкранып ятуына аптыраган, инде үз гөнаһлары, үз үлеме турында уйлап, тәмам хафага төшкән иде.

Гайнибикә абыстай җылы суын тутырган комганнан ирен тәһарәтләндерсә дә, аның өчен намазлыгын, таза киемен хәстәрләп торса да, дога-фәләнне бар дип тә белмәде. Баштарак законнан курыкты, аннан, гадәтенә кермәгәч, эш күплеккә сылтады, хезмәтем догадан китсен, дип, үзен оҗмахка өметләндерерлек сәбәпләр, шартлар тапты. Әүлиядай картының үлә алмый ятуы бу көннәрдә аның да тынычлыгын алды, йә терелсен, йә башка бер якны алсын инде, бик азаплана бит, дип өтәләнде, аның артыннан ук, инде безнең ни күрәселәребез бардыр, дип уфтанды.

Фазылҗан абзыйның хасталыгы бөтен тирә-якны тагын бер кат ахирәт гамәлләре турында уйлатты, әле аягында йөргән яшьтәшләренең кулыннан эшен төшерде, иртә-кич алар йортыннан кеше өзелмәде. Күршесе Сәйфетдин дә җомга намазыннан соң авыру янына сугылып чыгарга карар итте. Дөрес, моңа кадәр әллә ничә мәртәбә Әүлия дустының ул инде хәлен белгән, сөйләшәсен сөйләшеп бетергән кебек иде, алай да нинди дер бер могҗиза, аякларыннан ук тартып, алар йортына китергәндәй булды. Килененең намаздан соң кайнар коймак пешереп көтеп торганын белгән килеш тә, туры үзләренә кермичә, Фазылҗаннарга таба атлады.

Күршесе, ул кергәндә, текә куелган ястыгына терәлеп, болдыр яны тәрәзәсеннән карап утыра иде. Баскыч төбендә кәлүш салып азапланган Сәйфетдингә ачык чырай чыгарырга тырышып, шулай да хәлсез генә елмайды, моңсурак карашы белән йортка чакырды. Җомга көнгә каршы Фазылҗанны бик чисталап юындырганнар, урын-җирен, киемнәрен алмаштырганнар, чәчен-сакалын караганнар, караватны кырындагы урындыкка кергән кешегә дә җитәрлек итеп ризыгын куйганнар. Сәйфетдин карават янына ук килеп утырды. Болай өйдәгеләргә ишеттерми, аларны эштән бүлми серләшергә бик кулай иде.

Матураеп, тагын да яктырып киткән, йөзенә нинди дер нур иңгән Фазылҗанны күргәч, Сәйфетдин аның үлем көтүе хакында онытты, янына утыруга ук, дөнья хәлләре турында сөйли башлаган иде, күршесе кулына орынып кына туктатты, тынып тор, әле мин сөйлим дигәндәй, үзенекен тезеп китте. Инде йөзенә төс кунгандай тоелган Фазылҗанның ахирәт эшләре турында тагын сүз катуы Сәйфетдингә бик үк ошамады ошавын, әмма, ни хәл итсен, тыңлады, тора-бара бирелеп үк китте.

Әүлия сүзне ерактан – бала чагыннан башлады, әти-әнисенең үзләрен ничек үстергәнен, мулла бабасының якты гамәлләрен искә алды. Бервакыт йокысыннан тора алмыйча сабагына бармавы, хәлфәсе алдында оятлы булуы да, мунчаны иртәрәк томалап, әнисенә ис тидерүе дә, бәбкә саклаганда, берсен тилгәннән алдыруы да калмады. Аннан көтмәгәндә яшьлегендә күзе төшеп йөргән кунак кызы Сания турында сөйләп китте. Кыюсызлыгы аркасында сүз катмаганлыгына әллә үкенә иде инде?.. Сәйфетдин бу хатирәләрнең болай гына искә төшерелмәгәнлеген күңеле белән тоя һәм нинди дер яшерен сернең картның тел очыннан менә-менә ычкынасын инде көтеп үк утыра башлаган иде.

Ниһаять, ул сүзгә дә чират җитте бугай. Фазылҗан күршесенә ястыгын кабартыбрак куярга, бераз җайлабрак утыртырга кушты. Аннан тагын үзенекен дәвам итте:

– Сания соңгы тапкыр кунакка килгән елны хәтерлисеңме? – дип сорады ул. – Алмагачлар бик мул чәчәк атты, бөтен бакчалар шау шомыртта утыра иде ул язда. Кызый гел безнең тыкрыктан чишмәгә суга йөри. Мин абзар артында эш белән булышкан булып маташам. Эштәмени кайгы?! Ничек тә күрәсе, сүз катасы килә.

Сәйфетдин Сания кунакка килгән елны түгел, үзе өйләнгәннекен дә сораган вакытта төгәл генә әйтә алмый. Хәер, мәрхүм карчыгы турында бик үк уйламаска тырыша, салмыш бер көнендә уеннан ябышып кайткан Гыйззенурга эченнән генә үпкә саклый, әмма кеше сизүеннән бик курка иде.

Һәркемнең, һич югы, бер яшерен сере булгандай, Сәйфетдиндә дә кешегә сөйләү түгел, уйларга да куркырлык нәрсәләр җитәрлек. Яманның да яманы була дигәндәй, шуның иң күңелне ашаганы – оныкларына, килене Марзияга бәйлесе.

Улы да, карчыгы да үлеп, алар кулында гомер кичерә иде Сәйфетдин. Аның да ашаган ризыгы тәмле, кигән киеме чиста, тик рәхәтләнеп, кинәнеп сөйләшеп утырырлык кешесе генә юк. Оныгы Камил район үзәгендә эштә, ялга гына кайта, килен – яшь чагыннан бик тешләк бер нәрсә. Ни уйлаганын бер Ходай гына белә...

Марзияны улы Корбангалигә Сәйфетдин үзе димләде. Улына сүз эндәшмәскә, кыз йортында кыбырсымый гына утырырга бик нык әйтеп барганнар иде, егет башта түзде, аннан ахыры бетмәс кебек тоелган сүзгә чыдамады, әти, тизрәк кайтыйк инде, Акбайны сагындым, дип ычкындырды.

Марзия моны ишетте, әмма ишетмәгәнгә салынды, заманы шуны кушкандыр инде, ирләрнең кадерле чагы, акылга ярты таман ни килде Корбангалинең дә бәһасе чибәр, уңган хатын-кызныкыннан югары иде. Әле генә унсигезе тулган Марзия ачлы-туклы атасы йортыннан икмәкле, өрлектәй ир балалар белән тулы Сәйфетдиннәрнекенә күченде.

Корбангали, өйләнгәч, сабыйлык гадәтләрен бер читкә куйды, су буенда бака тотып та уйнамады, күрше малайлары белән алма бурлыгына йөрүен дә ташлады, йорт эшләренә ныграк булышты, күңеллеләнеп киткәндәй булды, әмма акылга сайлыгы һәр әйткәненнән, һәр гамәленнән күренми калмый иде.

Төп йортка хуҗа булачак Корбангалинең акылы тулмаганлыгы Сәйфетдинне дә, карчыгы Гыйззенурны да һаман саен борчып торды. Инде энеләре дә үсеп, кайсы кайда таралгач, Сәйфетдин тәмам пошаманга төште. Акылга таман улының балалары да шундый ук булса дип кайгырды ул һәм көннәрнең берендә, карчыгының ерак туганнарына киткән чагын туры китереп, җанын ашаган уйларны килене Марзияга да тиште. Ахырдан, ичмасам, картлыгыңда караучың булыр, әллә бер-бер малайны сиңа үзем ясап биримме, дип, туп-турыдан ярды да салды. Эш Сәйфетдин һич өметләнмәгәнчә тәмамланды: килен шул көннән авырга узды...

Узуын узды, әмма дә Сәйфетдин күңеле моның белән һич кенә дә тынычланмады. Инде Корбангали, Гыйззенур каршында кылган гамәленә оят хисе бөтен тамырын кимерә башлады. Үтә дә хурлыкта тотылганнан туган кебек хис йортка бала шатлыгы иңгәч тә кимемәде. Ике арада сер булып калган көннән бирле ул киленне кочу түгел, эштә арыган кулларына да кагылмады, кирәкмәгән чагында күзенә чалынмаскарак тырышты, шулай да оныгы Камилне үз баласы кебек яратты! Хәер, үзенеке булгач, үзеңнеке итеп яратасыңдыр да инде!

Улым дип әйткәндә, чигә тамырлары сулык-сулык килгән чакларында да, Сәйфетдин теш кысып түзде, беркемгә бу хакта сүз катмады: киленгә биргән вәгъдәсе бик нык, хәлне чишә-нитә калса, җәзасының каты буласы аермачык иде.

– Сания ул елны бабаларына озаккарак килде, яз да үтте, җәй дә башланды... Көннәр озын. Төннәр кыска. «Ә» дигәнче таң ата. Мин ишеге бакча артына ачыла торган печәнлектә генә йоклыйм. Сания иртән суга төшеп киткәндә карап калып ләззәтләнәм. Ул тум-тулук чиләкләре белән әйләнеп килгәнче, айлар-еллар үткән кебек тоела.

Шулай бервакыт Сания суга нигәдер кичкырынлатып, моңланып җырлый-җырлый гына төште. Минем ат арбасыннан печән бушатырга әзерләнгән чак. Тыкрыкта үтеп йөрерлек юл калмаган дисәң дә була. Җитмәсә, Сания узган юлда бастырык бауларын чишеп торам. Үтә алмаслыгының көн кебеклеген белгәч, ничек тә эшне озаккарак сузасым килеп, бауларны әле аннан, әле моннан тарткалаган булам. Көтеп-көтеп тә юл бирмәгәч, Сания түзмәде:

– Фазылҗан абый, уздырасызмы мине? – дип сорады.

Ул тавышларының матурлыгы! Ул карашларының тирәнлеге, мәгънәлелеге! Югалдым, беттем. Эшемнән туктап, туп-туры аның күзләренә карадым. Сания, шаяртырга булдымы, тагын да кызартырга теләдеме, көянтәсе-ние белән янлатып борылып, миңа терәлеп үк арба яныннан узып китте. Тәнемә кагылган һәр күзәнәгеннән ут кабарлык иде! Тынсыз, телсез калдырды ул мине!

Кунак кызы су буеннан бик озак кайтмады. Әллә минем печән бушатып бетергәнне көтте, әллә мине артыннан төшәр дип уйлады микән?.. Аның үзенә битараф түгеллегемне белгәнемә шигем юк иде югыйсә... Ә минем менә чишмә буена төшәргә, башкалар кебек тал-тирәкләр төбендә кыз кочарга батырлыгым җитмәде. Мулла оныгыннан тагын ни көтәсең?!

Инде Сания дә, җырлый-көйли генә, сулы чиләкләрен күтәреп өенә кайтып киткәч, печәнлектән төштем дә, атны туармыйча гына, арбасына басып, чишмә тыкрыгыннан инеш буена төшеп киттем.

Фазылҗан абыйның шушы урында сүзе өзелсә дә, бетмәгән булып чыкты. Бер тирән итеп сулады да гомер буе үзен басып торган йөктән котылган шикелле тиз-тиз генә әйтеп ташлады:

– Хикмәт монда Санияне үпмәү-кочмауда түгел, шул чакта, арба өстеннән генә басып торып, тыкрыкка печ иткән идем, кызыкайны көтеп бик тә кысталган идем шул. Әлеге гөнаһым тотып, менә ничәнче көн үлә алмый ятам. Бүтән бервакыт аннан да зуррак яманлык кылмаган идем шикелле. Хәер, анысын бер Алла белә... Әле ярый, күрше, син кердең. Сөйләдем – җиңел булып китте. Инде җиңеләйгән күңел белән үлсәм дә була торгандыр.

Сәйфетдин Әүлия картны тынычландырып матур сүзләр әйтергә теләгән иде, булдыра алмады. Ухылдап, йөрәгенә тотынды. Бу карт гөнаһлары янында аныкы инде тау кебек булып калган иде. Сөйләсә, килене кеше күзенә ничек күренер? Болай да юләрдән акыллы туган, дип шикләнеп караучылар булмады түгел, булды. Сөйләмәсә, Фазылҗан карт кебек, айлар буе караватта бөгәрләнеп, үлә алмый ятмасмы? Артык гади кеше акылы белән, көндәлек тормыш белән яшәгән икән. Аңа Әүлия булырга язмаган шул...

Күршесенә күтәрелеп карарга да оят иде аңа. Фазылҗан үзе сөйләгән хикәяттән Сәйфетдиннең болай авыраеп китүенә аптырады. Якын иткәнлеген, рәхмәтен аңлатырга тырышып, иңенә кагылды, кулларында әллә нинди бер җиңеллек сизде. Ахирие генә бер сүз дә әйтмәде. Әллә Фазылҗанның

яшьлек гамәлләрен бик зур гаепкә алдымы соң?! Бераздан үзе үк сиздерер әле дип, Фазылҗан чаршау артында кыштырдап йөргән карчыгын дәште:

– Әнисе, дим, әнисе! Сәйфетдиннең чәен яңартып җибәрче.

Гайнибикә ишегалдына чыгып киткән икән. Үзе дә белештерми, Фазылҗан урыннан күтәрелде, аны көткән кебек, караватянында торган башмакларын аякларына киде дә аралыкка, суынмаска дип плитә өстенә куелган чәйнекне алырга чыгып китте. Чыжлап утырган чәйнекне тотып әйләнеп килгәндә, терелеп аякка басканлыгын, Сәйфетдингә инде чәйнең нинди дә кирәк булмаганны аңламыйча, һаман үзалдына сөйләнде:

– Инде күпме гомер калгандыр, алга таба үкенмәслек итеп, гөнаһсызрак яшәргә кирәк, әле үләсе дә бар бит...

*2008*

## СОРАП АЛГАН КАРТАМ

Рәсимәнең бик боек көннәре иде. Тышта җәй булса да, күңелендә соры караңгы көзләрдә генә туа торган бер халәт. Кулына китап тотса, бер битенә текәлеп сәгатьләр буе утыра, аны читкә куеп телевизор кабызса, экрандагы хәлләргә исе китмичә, үз уена бата. Күз алдыннан балачагы, мәктәп дуслары, соңгы кыңгырау, саубуллашу кичәләре, аннан соң техникумда укып йөргәннәре, клубтан озата кайткан авылдаш егетләре уза, җаны сыкрый башлый, тәнен сәер бер авырлык изә.

Якшәмбе көннәрен ничек үткәрергә белмәгәнгә, тизрәк таңны аттырасы, эшкә барасы, өстәл артында, кәгазьдәге исәп-хисапларның саннарына батып, инде кайчаннан бирле чолгап алган хисләрдән арынасы килә аның. Таң атса, әле яңа гына йокыга киткәнлектән, ял итәргә өлгермәгән гәүдәсен карават өстеннән чак күтәреп торгыза, вакыты белән елап шешенеп беткән күзләрен чак ачып, юыну бүлмәсенә таба атлый. Инде эшенә дә теләр-теләмәс кенә, һәркемгә мәҗбүри бер нәрсә санап бара.

Күршеләренә кереп утырса да эче поша, бу карт-коры арасында гайбәттән башка ни ишетәм инде мин, дип, үз-үзен битәрли башлый, тизрәк чыгу юлын карый. Сөйләшкәннәренә кысылмый, ишеткәннәренең мәгънәсен тапмый.

Элегрәк рәсем төшереп, чигү чигеп тә күңелен күтәргән кыз кул эшләрен тәмам бер кырыйга куйды. Аяк арасында мыраулап йөргән мәчесенә дә ризыкны аннан котылып, тынычлабрак торыйм дигән бер кыяфәттәрәк сала, юеш почык борынын битләренә куеп иркәләми, колак артын кашып, рәхәтен китереп тә утырмый, артык кәефсез вакытында юлына туры килсә, аяк очы белән генә читкә тибәрә, ачулы сүз белән куып җибәрергә дә күп сорамый.

Рәсимә уйлавынча, боларның барысына да Фәнзиләнең туган көне генә гаепле. Дусты мәҗлескә чакырган кызларның һәммәсе егетләре белән киләсен белсә, барып та тормаган булыр иде. Ахирие Рәсимәгә дә пар тапкан: ул эшләгән бүлеккә яңа гына башлык итеп билгеләнгән Фәндүсне чакырган. Башта ул моңа бик тә сөенде. Кешегә сиздермәсә дә, егетне беренче күргәндә үк ошаткан, үзенеке итәргә максат та куйган иде. Эшләр болай булгач пешә икән, дип уйлады кыз, туган көн ике арага күперләр салырга бик кулай ич.

Фәнзиләнең дә исәп шундыйрак иде булса кирәк. Әле юньләп дуслашып та өлгермәгән ир-атны, җитмәсә, үзләренә баш кешене юкка гына табынга дәшми бит инде ул. Фәндүс... Фәнзилә... Исемнәре дә бик ятыша! Дөрес, Рәсимә бу уйларны үзеннән куып җибәрергә ашыкты. Урыны да Фәндүс янәшәсенә туры килгәч, күңеленә җылы ук йөгерде. Алла боерса, һәрнәрсә башыннан ук уңай килеп тора, белмәссең... Егет кочагына кергәнеңне сизми дә калырсың!

Син алай-болай итәм дип яшисең, язмыш үзенекен эшли. Егерме икедә генә булса да, Фәндүс инде өйләнгән, моңарчы үзе яшәгән район үзәгендә баласы, хатыны калган икән. Фатир алу белән, алар да монда күченәселәр, имеш. Уң колагына шуларны сөйләп утырган Фәндүсне әле генә бу төнне егет кочагында кунам дип хыялланган кыз бәреп үтерер хәлгә килсә дә, тешен кысып түзде. Нигә, нигә аңа гына һаман да бәхет елмаймый, дип үрсәләнде ул. Иптәшләренең күбесе гаилә корып өлгерде ләбаса! Чыкмаганнарының да очрашкан егетләре бар. Фәнзилә белән икесе генә ялгыз казлар кебек үзалларына каңгылдашалар.

Рәсимәнең килмәгән җире дә юк югыйсә. Әбисеннән калган бер бүлмәле фатиры бар. Кызны эләктереп аласы да үз бәхетләре өчен яшисе дә яшисе! Туган көн кичәсеннән чак өстерәлеп кайтып караватына егылган Рәсимә кат-кат шулай дип уйлады. Баш астындагы мендәре чыланып беткәнче яшь түкте, тормышының китек якларын барлап, язмышка рәнҗеп ятты. Аннан, башына кискен бер уй килгәндәй, торып ут яндырды, китап киштәсенең алдында бергәләп төшкән рәсем бар иде, урталарында Фәндүс булган өчен генә, аны ертып атты. Моның белән генә тынычланмады,

фотоаппаратындагы әле ясалырга өлгермәгән, бәйрәм табынында төшерелгән бөтен-бөтен кадрларны бетерде.

Фәндүскә үчләшеп, рәсемнәрен юкка чыгару кызны тынычландырыр кебек иде, бөтен нәрсә син теләгәнчә генә буламыни! Егет торган саен кызга ныграк ошый барды, ахырда Рәсимә, башына аны мәңгегә сөячәкмен икән дигән бер уй беркетте дә каһәрле бәйрәм кичәсеннән соң үзе уйлап чыгарган әлеге уенның колына әверелде.

Фәндүс турында хыялланып, Фәндүс авызыннан бер җылы сүз өмет итеп яшәү авыр иде. Бизәнеп-ясанып та, күз атып та, эштә алдырып та гаиләле ирне карата алмагач, кыз үз хыялларын башкачага үзгәртергә ниятләде, инде Ходайдан, Фәндүснең, һич югы, энесе булсын иде дә, мин аңа кияүгә чыксам иде, дип ялвара башлады.

Ай үтте, ел үтте, Фәндүс янына килгән-киткән кеше күренмәде, ул да үз кул астында эшләгән хезмәттәшләренә ата-анасы, туганнары турында җәелеп китеп сөйләргә ашыкмады. Ахыр чиктә кыз түзмәде, Фәндүсне күрмәс, тавышын ишетмәс өчен, икенче җиргә күченде; бер-беребезгә ияләшеп беткәч кенә китәсеңмени, дип гаҗәпләнгән иптәшләренә, өемә дә якын, хезмәт хакы да мулрак, дигән булды.

Рәсимә эшкә урнашкан тире-яры җыю комбинатында да коллектив начар булып чыкмады, бухгалтердан башкалары – ирләр, араларында өйләнмәгән бер егет тә бар. Рушан исемле. Рәсимә зәвыгына туры килми килүен, батканда агач тапмасаң, саламга булса да тотынасың... Егетнең өстендәге киемнәре ятышлы гына булса да, үзе күрер күзгә шактый сөйкемсез, сөйләшә башласалар, сакаулыгы белән эчен пошыра, нәрсә әйткәнен көтеп ярты гомереӊ үтә. Фәндүс түгел шул инде, дип уйлады Рәсимә. Үзе чибәр, үзе акыллы, яшь булса да, кечкенә генә «ничәлдерик» тә бит әле... И-и, Рәсимәгә язган бер энесе дә булса! Фәндүс дип башын катырып утырыр идеме соң хәзер?!

Башыңа чүп тутырсаң, эш алыштырып кына, аннан котылып булмый икән. Инде башка кирәкмәгән хәлләр алдагыларын түргәрәк төртеп җибәрсәләр җибәрәләр, әмма һичкем узганын тәмам себереп атарга, күңелен буш калдырырга әзер булмый. Рәсимә дә баш миенең бер яртысы белән – янында таңнан кичкә кадәр чүмәләдәй өелгән тире-ярыны, икенче яртысы белән һаман да шул Фәндүсне уйлады. Вакыты белән аның бу эчпошыргыч уйларына, их, энесе генә булсачы да, аңа кияүгә чыксам икән, дигән көлке бер хыял нокта куя, һәм ул тынычланыбрак киткәндәй дә булгалый.

Халыктан җыелган тире-ярыны эшкәртү цехына шуның хисабын алып барган кыз бүлмәсе аша узасы. Туктаусыз үтеп йөрүчеләргә дә эче пошмады Рәсимәнең, биек калай түбәне тотып утырган балкалардагы чыпчыкларның чыркылдашуына да. Аларны ничек тә бер куып чыгарырлар иде әле, ә менә башын чукыган чыпчыклардан агулап та, куып чыгарып та котылып буласы түгел. Ярый әле баш бухгалтер бик үткен күзле, югыйсә, гел бер нәрсәне уйлый торгач, хисабыңда да ялгышып куюың бар. Исәп-хисапны ул, Рушан икегә Рушан тугызны кушасы, берне язабыз, Фәндүсе хәтердә кала кебегрәк, алып бара иде шул.

Башкалар үтеп-китеп кенә йөрсә, Рәсимә янына Рушан көненә әллә ничә тапкыр керә. Комбинатның инженер-технологы булгач, килгән тирене бәяләү буенча киңәшләрен бирә, җыелганының сыйфатын тагын бер кат күздән кичерә, махсус капчыкларга аерып сала, болай гына, чәйләп алырга да җай, вакыт таба. Кесәсендә һәрвакыт кыз яраткан чикләвекле шоколад, юл өстендә очрады да алдым әле, дигән булып, өстәленә чәчәкләр дә кертеп куйгалый.

Тора-бара Рушанның хисап бүлмәсенә элеккедән күбрәк йөрүенә цехтагылар да игътибар итә башлады, җае килгәндә, кызга да төрттергәлиләр, кияү-килен дип шаяртучылар да юк түгел. Рәсимә бу сүзләргә ачуланмый, Рушанның үзенә гашыйклыгын сизә сизүен, тик гади бер дуслык итеп күрергә, күрсәтергә тырыша, һаман да Фәндүс энесен, кара-чутыр күзле, озын буйлы егетне хыялында яшәтә.

Рушан кыздан ошау-ошамавы турында сораштырырга тырышмады, мөнәсәбәтләрнең үз агымында үсешеннән ул канәгать иде, һәм шулай тыныч кына көннәр үтә торгач, Рәсимәнең бервакыт үзенеке булачагына бик нык ышанды. Инде ул, вакыт тәмам җитте, дигән нәтиҗәгә килгәч, кызны үзе торган фатирга – абыйсы белән җиңгәсе йортына чакырды. Әтием урынына калган абый, һәрнәрсәдә киңәшчем, бер күреп кайтыйк әле, дигән булды.

Алар килүенә абыйлары эштән кайтып өлгермәгәннәр иде әле. Залда иртәдән үк ярым әзерләнгән өстәл балкып утыра, яңа йортларда гына була торган буяу исе, яктылык, иркенлек...

Киемнәрен чишенеп алгач, Рәсимә кунак бүлмәсенә узды. Ул арада кухняда аш-чәйләрне ут өстенә куйган Рушан да аның янына чыкты, кыз моңсуланып утырмасын диптерме, телевизор тумбочкасыннан алып, бәрхет тышлыгына яшь солдат рәсеме ясалган калын гына альбом сузды:

– Мә, абыйлар кайтканчы, минем белән ныклап таныша тор.

Рәсимәнең кешедә фотолар карап утырырга җене сөйми иде, шулай да каршы төшмәде. Ул үзенә бөтенләй чит кешеләрнең фотолары хакында, егетнең күңелен күрү өчен генә, монысы кемнеке, тегесе... дип сораштыргандай итенде. Бу рәсемнәр егетнең мәктәп дуслары, армия хезмәте, уку еллары турында сөйли иде. Әкренләп кызда ниндидер кызыксыну да уянды. Рушан зурайтып эшләткәне күренеп торган әти-әнисенең сурәтләренә озак текәлеп утырды, алардан Рушанныкына охшаган

чалымнарны эзләде – тапмады. Инде соңгы битне ачтык, бу теләмәгән эштән котылам дигәндә, Рәсимәне яшен суккандай булды.

– Бу рәс-с-сем ничек с-сиңа килеп кергән? – диде кыз, Рушан кебек тотлыга-тотлыга – анда әлеге дә баягы кызның җанын талаулаган туган көн күренеше иде.

– Ә-ә, үзе җитәкләгән бүлектә эшләүче бер кыз узган ел бәйрәмгә дәшкән иде абыйны. Фәнзилә исемлеме шунда. Минем белән киңәшеп, Чаллыда белгән кешем дә юк, бер кеше арасында ял итим дип кенә барган иде. Бик күңелле утырганнар, рәсемнәргә дә төшкәннәр, монда күченеп килгәч, иренең ялгызы кунаклап йөрүе, чибәр кызлар янәшәсендә рәсемнәргә төшүе җиңгәйнең күңеленә тиде. Абый гаиләдә тавыш чыкканны бер дә яратмый, әллә ни уйлап тормады, барысын ертып атты, ә бер рәсемне миңа бирергә өлгергән иде, шулай очраклы гына исән калган бәхетле фото ул.

Шулай диде дә Рушан фотоны тагын бер кат кулына алды.

– Бәй, монда син дә бар түгелме соң?

– ...

– Әйтәм аны, сине моңарчы кайдадыр күргән кебек идем, – диде егет, Рәсимәне тәмам телсез калдырып. – Абый, бүлегебездә бик акыллы кыз эшли иде, көтмәгәндә нигәдер китеп барды, сәбәбен аңламадым, дигән иде шул чакта. Мактаганы син булгансың икән алайса!

*** * ***

Рәсимә, тузан кунган киштәләрне сөртим дип үрелгәч ялгыш төшереп җибәргән альбомның соңгы битләреннән идәнгә коелган рәсемнәрне кулына алганда, бөтен яшьлеген тагын бер кат күз алдыннан кичергәндәй булды. Тотлыга торган, күзләре соргылт, чәчләре җитендәй сары Рушанга бер дә кияүгә чыгар кебек түгел иде ул. Инде менә үзләре буенда өч кызлары үсеп килә. Барысы да кара-чутырлар, Фәндүс абыйлары кебек чибәрләр. Хәер, әни кеше чегәндәй чибәр әбиләре ягына тартмыйча, бабалары төсен саклаган Рушанга охшасалар да, шулай ук яратыр иде аларны.

Әле гашыйклык утында гына янганда, күңелендәге теле телгә йокмаган чибәр Фәндүс урынын сакау, тышкы кыяфәтендә күңелең төшәрлек җире дә юк сыман Рушан алыр, дисәләр, яшь аралаш кычкырып көләр иде Рәсимә, хәзер менә күңелсезлектә узган әлеге җәйне исенә төшерергә дә ояла, иреннән башка яшәүне күз алдына да китерми. Ә бит, сораганым кабул булды, инде буйсынмый нишлим, дип кенә чыккан иде ул аңа.

Сорап алган картам, тешли-тешли тартам, дигән ди берәү, карта кисәген өзә алмый аптырагач. Ә бу тора-бара сорап алган сөю кебегрәк булды шай...

*2009*

## БӘХЕТ ШАРТЫ

Сәрбиназ әтисен гомер буе тегү машинасы сорап тинтерәтте. Калага китсә, бәрәңге саткан акчасына иске булса да тегә торган кап-кара «Зингер» машинасы тотып кайтып керер кебек иде аңа. Кибеткә товар кайтканын ишетсә, һич югы, «Подольск» атлысы булмасмы дип, шунда йөгерде. Районга үзе барса, «Йорт кирәк-яраклары»на керми уза алмады. Сельпо башлыгыннан алып авыл кибетендә җыештыручы Сәбиханың колагына кадәр шул хакта киртләп куелган иде.

Тегүче булу теләге кызда шулкадәр көчле иде, сигезне тәмамлагач, аттестатта бишле генә дип тормады, профтехучилищега укырга китеп барды. Ата-ана моны баланың сансызлыгына санадылар, йөзгә кызыллык китереп, кара эшчегә укырга китте, дип, көненә ун булмаса биш тапкыр бергәләп уфтандылар. Өстәл янына утырсалар да, йокларга ятсалар да, сүз Сәрбиназның авылда хөрмәт ителгән укытучы, фельдшер булмыйча, тегүчелекне сайлавы турында иде.

Ата кеше баштарак эченнән кызының бу гамәлләренең сәбәбен дә аңлый, бераз гына аклый да сыман иде, әмма хатыны сүзләрендә дә дөреслек табып, соңыннан тәмам аның ягына авышты. Вакытлар үткәч, бу хәсрәт басылды, ата-ана, акылы булмаса, бәхетне кулы белән эшләп табар, бар күрәсебез шул гына булсын, дип, үзләрен тынычландырдылар, инде кирәксә-кирәкмәсә ул турыда сүз куертмаска тырыштылар.

Ай саен уч тутырып акча алган укытучы хезмәте яхшы иде яхшысын, әмма кыз тегеп кидергән киемнәр дә бераздан күңелләрендәге ташны эретте, бу һөнәрдән дә керем барлыгын аңлатты; тегүче таныклыгын алып кайткан көнне үк әти кеше кызга үзе теләгән «Зингер»ны бүләк итте. Машинаның ныклыгын белә, гомер бакый кызына хезмәт итәчәгенә ышана иде ул, шуңа күрә сүзне:

– Менә, кызым, игелеген күр, тамагыңны үзең туйдырырлык булсын, ач-ялангач йөртмәсен, ашаганыңны хәләлдән кылсын, – дип башлады. – Инде бездән сиңа фатиха, үз юлыңны үзең сайлагансың икән, үзеңчә дәвам да ит.

Сәрбиназ уенда болай да эшкә Казанда, һич югы, районда калу иде. Атасының хәер-фатихасы йөрәгенә май булып ятты. Атна-ун көн йорт эшләрендә булышкалап йөргәннән соң, тегү машинасын, көндәлеккә кием-салым, бераз ризыгын да алып, Казанга китеп барды.

Поездда Сәрбиназның урыны авылларына кунакка кайткан бер хатын белән туры килде. Үзен Нурдидә дип таныштырган юлдашының әйтүенә караганда, әнисе, ачлык елларында Ташкент тирәсендәге бер авылга киткән җиреннән кияүгә чыгып, шунда калган икән. Инде менә гомер ахырында кызы белән киявен, мин үлгәнче, туганнарымны күреп, сәламемне җиткереп кайтыгыз, дип, Өскеюлга җибәргән. Татарча авырдан аңлаган ир, алар сүзенә кысылмыйча, тәрәзәдән юл буйларын күзәтеп бара иде. Нурдидә белән Сәрбиназның серләре килеште, юл буе теләсә ни сөйләшеп бардылар: авыл хәлләре дә калмады, әйбер бәяләре дә... Инде электричка Казанга килеп җитте дигәндә, адреслар алыштылар да, Алла боерса, очрашырбыз әле, дип аерылыштылар.

Юлда да кулыннан эш төшмәгән – бәйләү бәйләп барган, ак йөзле, ут күзле Сәрбиназны җылы як җилләреннән яргаланган, үзе дә үзбәк бикәченә әйләнеп беткән Нурдидә апасы бик яратты булса кирәк, җитез кулларына сокланганы күзләреннән күренеп тора иде, алай да кызның тырышлыгын мактап бер генә сүз дә катмады. Инде сөйләр нәрсәләр дә калмаган кебек булгач, әллә кайдан гына бер мәзәкне хәтеренә китерде.

– Сәрбиназ, бәхетең эштә булыр төсле тоела, – диебрәк башлаган иде ул сүзен. – Киңәш бирер идем дә, син инде үзгәрмәссең. Тырышлык бит ул нәселдән килә.

– Нигә алай дисез? Эш эшләп яшәү шулай ук начармыни? Үзегез дә ял гына итеп яшәгән кешегә охшамаган.

– Эшли дә, ял итә дә белергә кирәк, сеңлем. Үлгәннән соң да өч көнлек эшең кала, дигән борынгылар. Хәзерге әйберле заманда ул эшләр бетмәслек кала торгандыр.

– Иркәләнеп өйдә яткан хатын-кыз тормышына үзем дә кызыкмыйм мин! Әти менә бик тә фельдшер итмәкче, әни укытучы ясамакчы иде, ә мин тегүче булуны хуп күрдем, чыннан да, эшне бик яратам шул, – диде аңа каршы инәләренә күз дә төшерми шәл бәйләп барган Сәрбиназ.

– Бер мәзәкне ишеткәнең бардыр. Урам буйлап Бәхет бара икән. Каршысына бик тә уңган бер кыз очраган моның, әмма тегенең сәлам дә бирми үтеп китеше, имеш. «Бәхет, кая барасың? – дип сораган кыз. – Әйдә, минем яныма кил, мине бәхетле ит, һич югы, утырып, янымда хәл ал!» «Юк инде, – дигән Бәхет, – туктап тормыйм. Тизрәк Ялкауны эзләп табарга кирәк. Син менә бәхетеңне эшләп тә табарсың. Ул миннән башка үзе генә нишләр?» Һәркемнең бәхете үзе белән, акыллым, кемгәдер ул болай да килә, кемдер аны тир агызып эзли.

Икесе дә көлешеп алдылар. Нурдидә мәзәкнең эчке мәгънәсеннән көлсә, сүзнең үзе хакында барганлыгын аңламаган кыз күккә төкереп ятып та бәхетле яшәгән Ялкауны уйлап көлде. Ярый әле үзе андый түгел дип куанды. Менә бит, яңа танышкан апасы да уңганлыгы өчен мактап утыра.

Икенче елны Сәрбиназ Нурдидә апасын тагын очратты. Ул бу юлы кунакка олы улы белән кайткан, һәм исәбе – бер уңган татар кызын үзләре белән алып китү икән. Каратут йөзле Әснафны Сәрбиназ тәүге күрүдә үк яратты. Елмаеп кына тора, тотышлары килешле, киеме чиста-пөхтә, кызга артык якынаюны да әдәпсезлек саный. Авыл егетләреннән мондый тыйнаклыкны күрмәгән Сәрбиназ, кияүгә чыгу турында үзенә сүз катылганчы ук, Нурдидә апасына теләге юк түгеллеген әйтте дә ташлады. Шулай итеп, алар өчәүләп Ташкент якларына китеп бардылар.

Еллар узды. Өскеюл авылы кешеләренең Сәрбиназ теккән киемнәре дә тузды, инде кибетләргә әзер киемнәр дә күбрәк кайта башлады. Әкренләп тегүче кыз үзе дә онытылган кебек булды. Сәрбиназдан ни көтеп хат ала алмаган әти-әни аннан хәбәрсезлекләре хакында кешегә тишәргә курыктылар. Елын елына авылга кайтып ял иткән Нурдидә дә башка кайтып күренмәде, Сәрбиназның үзен дә авылга җибәрмәде. Ата кеше әнкәне, бала авырлыкта хәбәр салмый калмый, тормышы җайдыр, дип тынычландырды.

Алай да сер бер ачылмаса бер ачыла икән. Инде биш ел узды дигәндә, Сәрбиназ үзбәкләргә мамык шәл сатып йөрүче күрше хатыны белән авылга кайтып төште. Кулында нибары – инде агач тартмасы искереп, кырылып беткән «Зингер». Йөзләре сулыккан, күзләре утырып кына калган. Бусагадан узып, машинасын идәнгә куйгач, ишек яңагыннан шуып кына төште дә идәнне кочаклап еларга ук кереште. Көтелмәгән хәбәрдән телсез калган ата белән ана ни кылырга да белми, чәйләргә утырган өстәл артларыннан да кузгала алмадылар. Кайсыныңдыр кулыннан чынаягының лыпылдап өстәлгә төшкәне генә ишетелде.

...Сәрбиназ турындагы хәбәр көне-сәгате белән бөтен авылга таралды. Ерак юлдан кайтуына карамастан, чәй дә эчеп тормыйча, урам буенча күрше арты күршегә кереп, әле бер нәрсәне тәфсилләп, әле икенчесен кызны җитәкләп туган йортына алып кайткан Миңзифа апасы үзе үк сөйләде аны.

Сәрбиназның үзбәк тормышы бик үк татлыдан булмаган икән. Кияүгә килүенә озак та үтми, каенанасы вафат булып куйган. Авыру хатыны өстенә хатынлыкка алган Әснафның берсеннән-берсе кечкенә, ачлы-туклы, каралмаган өч баласы алты күз белән көтеп торган аны.

Нурдидә әнкәсе булмагач, авылына да юлы ябылган. Күңеленә бер күрүдә якынайган каенанасының үзенә мондый язмыш әзерләвенә баштарак үзе дә ышанмаган ул, аннан аңлаган: бу авырлыкка хәзерге заманда аннан башка кем түзсен?! Бәхет шарты гына түгел, бәхетсезлекнеке дә тырышлык икән шул. Ул әнә якты дөнья белән улының тормышын көйләп хушлашкан...

Кире юлга акчасыз Сәрбиназ, никахына, кара язмышына буйсынып, телсез-тешсез, хезмәтле көндәш, үги әнкә булып яшәп киткән. Кирәге бер чыкмаса бер чыгар дип, үзе белән алып киткән тегү машинасыннан да рәхәт күрмәгән: төн йокысын йокламый бөтен авылга кием теккән, гаилә ашаткан. Өскеюлда ягымлы, итагатьле күренгән Әснаф үз йортында бөтенләй үзгәргән, сүз әйттерми торган, каты куллы, усал телле бер иргә әверелгән. Үз канаты астынарак алган каенанасыз да калгач, Сәрбиназның яшәве бөтенләй авырлашкан, көндәшен җирләгәч тә, җиңеләймәгән.

Язмыш дигәнең, чыннан да, бардыр, ахры. Миңзифа апасын алып килгән машина Әснафлар турысына килеп туктамаса, юлчы хатын олы себерке белән капка төбендәге тирәк арасын себереп йөргән күрше кызын күреп алмаса, Сәрбиназ гомеренең алга таба ничек языласын кем фаразлый алыр иде икән?..

Хатыннар, карт агач төбендә генә кочышканнар-елашканнар, хәл-әхвәл белешкәннәр дә, әлеге дә баягы «Зингер»ны алып, кышлактан чыгып та качканнар. Тагы да шул бәхеткә дигәндәй, Миңзифаның сатарга алып килгән соңгы шәле генә калган булган, ул аны, ерак юлда туңар дип, Сәрбиназ иңнәренә салган.

Ата йортына кайтып егылуына ышана алмаган кыз, елавыннан туктап, инде тынычлангандай булгач, әкрен генә тупсага утырды да үзе белән ерак юл узган, аның күз яше аша сөйләнгән серләрен сеңдергән «Зингер»га карап тора башлады. Җан ачу түгел, капкачын гына да ачарга теләми икән инде ул аның! Һаман алга таба әйләнгән ак сөяк сапларын куралмас хәлгә килгән ләбаса! Машина өстен ачса, куллары шуңа үрелер дә мәңге эштән туктамас кебек. «Зингер» кебек келтер-келтер типкән үз йөрәк тавышы да җанына тия түгелме?!

Күргән бөтен михнәтләренең сәбәпчесе ул гына төсле дер тоелды Сәрбиназга. Аннан, ата-ана белән исәнләшәсе, тагын бер кат елашасы урынга, хәлсез иреннәре белән ярым пышылдады:

– Әткәй, сат, ват машинаны, кешегә бир, гомеремдә башка тегү тегәсем юк...

«Зингер»ны чыгарып ук атмадылар атуын, әмма ләкин кызны тоткынлыктан коткарган Миңзифа апасына бүләк иттеләр. Аның да кул эшләренә маһирлыгы билгеле, йорты ишле, ирсез иде.

Шул елны, язда, Сәрбиназ яңа документлар ясатты да фельдшерлыкка имтихан тотарга китеп барды. Ул әле Әснафның, өч баласын ияртеп, үзен ризыклы яшәткән яшь хатыны артыннан Өскеюлга килергә чыгуын уена да китермәде. Хәер, китерде ни дә, китермәде ни: бәхетне ул башкача эзләп табарга уйлады. Электричка вагонында барганда, гомерендә тәүге тапкыр кулына бәйләү алмады.

*2008*

## БАСУ ЯКТАН ҖИЛ БӘРӘ

Зөфәрә, чикләвекләрен сатып бетереп, суынмасын өчен куенына тыккан бәрәңгесен алып ашыйм гына дигәндә, баядан бирле бер читтә басып торган чем-кара чәчле хатын кулына килеп асылынды:

– Өстемдәге күлмәгемне салып бирәм, теләсәң, менә бу өр-яңа кофтамны да кушып ал, балаларымны ачтан үтермә, авылда син ничек тә ризык табарсың.

Кызның корыга гына иписез ашаган бәрәңгесе бугазына килеп тыгылды. Зөфәрә чынлап торып тончыкты, йөзе кызарганчы бүселә-бүселә йөткерде. Шуны гына көткән кебек, әнисе итәгенә тагылган сабые бәрәңгенең кулында калган яртысын эләктереп алды да күз ачып йомганчы чәйнәми-нитми йотып та җибәрде.

Эш болайга китсә, ашъяулыкка салынган бәрәңгеләрнең эзе дә каласы түгел иде, тик таныш булмаган хатын, баланы күлмәгеннән йолкый-йолкый, үз телендә әрләргә тотынды. Сабый курыкты: әнисенең бөреп ясалган киң итәге астына кереп үк китте.

– Кызым, мин – мөселманмын, дога кылырмын, балаларымны ач итмәсәң, сиңа бәхет юрармын...

Зөфәрә хәерчеләрнең сүзеннән түгел, күз карашыннан ук курка иде. Бирмәсәң, каргый да ала бит ул! Бирсә, үзе дә бүген авызына ризык капмаган килеш йокларга ятачак. Дөрес, өсте ачылмаган ярты баз бәрәңгеләре бар әле барын, тик язга да бик ерак шул. Бирсәң, үз әнисе нәрсә дип әйтер?!

Соранучы хатыннан болай гына котылып булырга бер дә охшамаган. Аның каршында ашамыйм ичмасам дип, калган бәрәңгеләрне ашъяулыкка төреп, чанасын кайтыр юлга хәстәрли башлаган иде, теге сабый белән анасы кулына икәүләп ябышмасыннармы: бир дә бир, теләсә нәрсә сора, йорт тулы кием-салым, тик аларны гына ачтан үтермә, имеш.

Хәерче диде дә диюен, хатынның элекке тормышы начардан булганга охшамаган. Өстендәге кара панбархат күлмәге киелсә ике-өч киелгәндер, юылмаган-үтүкләнмәгәнлеге әллә кайдан күренеп тора. Карага кызыл килешә бит ул. Көн буе торып та сатылмый калган һинд кофтасы, сугыш заманы

булмаса, ничә капчык бәрәңгегә торырлык. Буй җиткән кызга бер дигән бирнә. Бүген кич вечерга нәрсә киим дип торганда, әнисе рөхсәт итеп әлеге дә баягы кофта-күлмәктә барса, һич начар түгел.

Уйлады-уйлады да Зөфәрә ерак иллардән килгәнгә охшаган бу чибәр хатынның затлы өс-башын бәрәңгедән артыграк күрде. Кибеткә кызыл мал кайтмый, пайга кайтканын да алар алырлыкмыни?! Тире-ярычы да һәрнәрсәне алмаштырып кына җыйган чак.

Зөфәрә чана бауларын чиште дә бәрәңгене ашъяулыгы-ние белән сабый кулына тоттырды. Куллары исән-сау булса, анысын гына ул үзе дә тукыр! Хатын иң башта кофтаны бирде, аннан күлмәк сәдәфләрен ычкындырырга кереште. Бу киемнәрнең үзенә дә кадерле икәнлеге бик ачык аңлашылса да, ул кыйгач кашлары астыннан рәхмәтле күзләрен тутырып Зөфәрәгә карады.

Чибәр дә иде үзе! Моңарчы башына урап бәйләгән яулыгы астыннан гына күренеп торган чәчләре, таралып, бөтен гәүдәсен каплаган. Текә күкрәкле сылу гәүдәсен төп-төз итеп тотса да тотар икән! Хатында хәерчеләргә хас әрсезлекнең, мескенлекнең, аламалыкның заты да юк! Хәер, ул болай гына ризык сорамый. Алмаштыра алырлык әйберләре барга сөенгәндәй, кыз кулындагы затлы киемнәренә әле ничә мәртәбә күз атты да:

– Сиңа бер дигән булачаклар! Мин киемне бер дә затсызлап кимим, хәер, кофтасы әле бөтенләй өр-яңа, – дип куйды.

Затлы күлмәк астында эре кызыл чәчәкле эчке күлмәк тә булган икән. Болай да чибәрнең чибәре күренгән хатын ул күлмәктә тагын да юкарыбрак, тагын да сылуланыбрак калды. Ул бик үк ачык яңгырамаган авазлар белән:

– Рәббана тәкаббәл миннә иннәкә әнтәс сәмигуль галим, – диде дә, бу як мөселманнарына бик үк хас булмаганча, сыңар кулы белән генә ияк очларыннан сыпырып, доганың тәмамланганын аңлатты. – Ходай әҗерен кайтарсын.

Аннан сабыен җитәкләп, базар кырыйлатып кына китеп барды:

– Әйдә, Надиршаһ, агаларың көтеп арыгандыр, кызулый төш.

Зөфәрәнең иптәш кызлары бу базарга килмәгән иде. Ул да авырсынып кына кайтыр юлга атлады. Эченнән әле көлгәндәй дә итенде: бәрәңге, чыннан да, алып бара, алып кайтмый икән шул. Эңгер-меңгер төшкәндә, кыз көч-хәл белән өйләренә кайтып егылды.

Зөфәрә әнкәсе ачуланыр дип көткән иде, алай булып чыкмады. Үзе дә алга таба кайдан, ничек өс-баш юнәтергә дип аптыраган булган икән, җае чыккан, дип сөенде.

Чикләвек уңды бу ел. Чистартып, киптереп куелган эресе генә өч капчык. Җиңел кулдан китеп, Зөфәрәнең башына да алсалар, кыш кияүгә бирсәң дә буласы. Егете азып-тузып йөрми, сугышка да алынасы түгел, хәрби заводта, кем әйтмешли, «кечкенә генә нәчәлник». Сирәк булса да авылга кайтып анасына булышып китә, ризыктан өзми, авыр эш эшләтми, каралты-курасын бик төзек тота. Андый егеткә кызның да затлысы кирәк. Панбархат күлмәктә, кызыл кофтада Зөфәрә дә төшеп калганнардан күренмәс!

Әнкә кеше шулай уйлый-уйлый савыт-саба җыештырганчы, кыз киенеп-ясану белән мавыкты, уч төбе кадәрле көзгедән күлмәгенең әле бер, әле икенче җирен карады. Клубка чыккач, кызыл почмакка кереп, үзенә туйганчы бер карар әле!

Ул да булмады, өй артында кар шыгырдаганы ишетелде. Яңа күн итек чыгарган авазлар иде бу. Сәетнең Зөфәрәне клубка алырга килгәнлегеннән хәбәр. Кыз табан салынган киез итекләрен аягына җиңел генә киде дә, өстенә терсәк турылары кыршыла башлаган плүш пәлтәсен элеп, урамга йөгерде. Клуб дигәне урам аркылы гына – киенеп тормаска, күлмәк-кофтадан гына керергә дә була иде югыйсә, кызның башкаларны нәкъ менә бию бүлмәсенең уртасында таң калдырасы килде.

Шулай булып чыкты да. Баштарак салкынчарак клуб, уен кызгач, шактый эсселәнде, Сәет каршысына үкчә тибә-тибә, сәдәп чишә-чишә килгән кыз, борылып, инде үзең артымнан бар дигән хәрәкәтләр ясаганда гына, киемнәрен ул биергә чыккач бушап калган ян эскәмия өстенә кош кебек кенә ыргытты.

Әле Сәет белән бер-берсенә янәдән каршы киләсе, култыклашып әйләнәсе калган иде, моңарчы чәчәкле ситсы күлмәктән йөргән кызның шәһәр бикәченә әйләнеп клубка чыгуына таң калган гармунчы уеннан туктады. Кием кешене бизәсә бизи икән: чибәрнең дә чибәре иде Зөфәрә!

Кызның тиз генә уртадан керәсе килми иде, аңламаганга салышып, гармунчы каршына килде:

– Яным, тагын уйна инде, арыганчы биерлек булсын! – диде ул, үзен олысыманлап.

Гармунчы уйнаса уйнады, уйнамаса юк дигәндәй. Кырык тапкыр ялгышты, үзе дә сизмәстән, әле чирмеш, әле ар көйләренә күчте, әмма Зөфәрәне тыңлады, хәлдән таеп биеткәнче уйнады.

Үзен затлы күлмәкләрдә күрсәткән көзгене кыз мең кат кочаклап үбәргә әзер иде – болай эшләргә һич тә ярамаганлыгын белгәнгә, Сәетне култыклап алды да, әлеге матурлыкны, әлеге затлылыкны үзенең табигый бер өлеше кебек күрсәтеп, вак-вак кына атлап, кемнедер көнләштереп, кемнедер кызыктырып, клуб ишегеннән салкынча һавасы белән айнытыбрак җибәрәчәк урамга таба атлады.

Матур гына башланган кичнең ахыры бер дә алай тәмамланмады. Сәет белән хушлашып кергән кызның кулларын кычыну алды, ул әле бер, әле икенче уч төбен, бармак араларын угаларга, кашырга тотынды, тик моның сәбәбен генә белә алмады.

Әтисе Кадыйргали кайткач кына тынычлангандай булды. Ул карап-карап торды да:

– Кызым, бер-ике көн түз әле, аннан ачыкланыр, ветстанциядә мал авырса-нитсә дип саклап тоткан дегетем бар, корчаңгы-мазар булса, шуның файдасы тимәсме.

Кыз авырыйм дип тормады, Сәет кайткан көннәр булгач, клубка икенче көнне дә чыкты, өченче көнне дә. Соңгы чыгуында сабырлыгы җитмәгән, үзе дә сизмәстән, әле теге, әле бу төшен кашыштыргалаган, күрәсең. Вечер бетә, таралышабыз дигәндә генә, «назалы» уенын башладылар. Кит-те үртәшү-төрттерешүләр... Үзенең Сәетсез каласын, алга чыгасын Зөфәрә баштан ук сизенә иде (егетләргә кытлык бер заманда парга аны сайламаслар лабаса!), әмма дә ләкин җырның ниндиен ишетәсен башына да китермәде.

Ул назадагыларга йөз белән борылып басуга, әче телле күрше кызы Галимә черелдәвек тавышы белән:

Иртән торып тышка чыксам,
Басу яктан җил бәрә.
Корчаңгыны Тәкәнештән
Алып кайткан Зөфәрә, –

дип үтерде дә салды.
Җавапсыз калдырса була иде кана, тик Зөфәрә аңа күнеккәнмени:

Галимәнең пары булып,
Артка китәрбез әле,
Тәкәнешнең корчаңгысын
Бүләк итәрбез әле.

Кыз шулай дип җырлап бетерүгә үк, Галимә кулын чытырдатып тотты да капка ясап күтәрелгән куллар астыннан Сәет барып баскан якка таба атлады, әмма егеткә күз дә төшермәде. Аннан, Галимәне уенда ялгызын калдырып, өйләренә йөгерде.

Ә бит Сәет корчаңгы хәлләрен белү генә түгел, үз башында кичерә иде. Зөфәрәсе, башкалар күрмәгәндә генә уынгалагач, ул, корчаңгы тарихы кеше күзеннән читтә үтәр әле, дип өметләнде. Әлбәттә, ярты клубның Тәкәнеш корчаңгысында йөрүен белсә, Зөфәрә дә бу хәлләргә тынычрак караган, сәбәпченең үзе икәнлеген сиздермәгән булыр иде. Каның кызганда, башың томалана, ди иде әтисе, шулай икән, җырның хаклыгын раслап, өйләренә качты шул.

Әтисе чиләге белән дегет күтәреп кайтканчы, корчаңгы шактый азып өлгерде, әмма даруның файдасы тиде, чирнең заты да калмады. Теге җанга үткән вечердан соң Сәет бик озак вакытлар авылда күренмәде: үзе эшләгән җирдә дәваланып йөрде булса кирәк. Тора-бара егет белән кыз, мең эшне сәбәп итеп, язга кадәр дип сүзләр куешып, хат алышуга күчте.

Зөфәрә матур күлмәк белән корчаңгы бүләк иткән чибәр хатынга баштарак үпкәләгән кебек булса да, тора-бара үпкәсе онытылды. Хәер, ул ханым үзе корчаңгы турында кайдан белсен: затлы кофтага корчаңгыны көн буе кием киеп карауяыларданберсе йоктырган иде.

Кичке уеннар ешайган язгы көннәрнең берендә тагын Сәет кайтып төште, тагын Зөфәрә белән парлашып клубка киттеләр. Инде корчаңгы хәсрәте күңелдән киткән кебегрәк иде. Тәмам онытырлык булмаган икән: аларны ярым тулы бию бүлмәсе каршы алды.

Әлеге дә баягы төзәтенә-ясана торган көзгеле кызыл почмакка кергәч, завклуб серне чиште: корчаңгы ярты авылга йоккан, һичкем ничек котылырга белми, фельдшерда да дәвасы юк, имеш, кеше янына чыгарга оялып, күпләр өйдә генә утыра. Авыл гайбәтләрен бик үк тыңларга яратмаган, соңгы вакытта кеше күзеннән качыбрак йөргән кызның бу хакта белмәве, әлбәттә, табигый.

Сөйгәне янындагы мыскыл аның үзәгенә үткәнгә, йөрәк тамырларын кискәнгә, Зөфәрә бу хәлләрне көткән, кайчандыр хәтта бик теләгән иде. Дөрес, инде үч тойгысы басылган, әмма чикләвек сатканның соңгы акчасына алынган тагын да матуррак бостон тышлыклы бишмәтендә Сәет кайтканны көтеп түр тәрәзә янында утырганда, ул хакта барыбер уйлаган иде әле. Шулчак күңелендә бүген кич түгәрәк уртасында җырлаячак яңа җыр туган, һәм кыз клубка вечер нәкъ менә урталы уеныннан башлансачы дип кергән иде. Алай булып чыкмаса да, Зөфәрә җаен тапты. Гармунчы егет йөгерек төймәләрдә җитез көйләр эзли башлауга, уртага сикереп чыкты да, тузан чыгарырлык тыпырдап, чебиле кулларын угалап утырган, кайчандыр йөрәгенә тоз салган Галимә каршына килеп басты һәм җыр белән генә биергә чакырды:

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Сәеттер.
Үзеңдә бар корчаңгыны
Читтән эзләү гаептер.

Бездән дә китәр хәсрәт,
Сездән дә китәр кайгы.
Клубларда кулдан телгә
Йога икән корчаңгы.
*2008*

## ТАНЫК ӨЧЕН ХОДАЙ БАР

Гафур Алзәйнәпне ябештереп кенә алып кайтырга уйлады. Туйга тотыласы һәм болай да юк акчага атасының йортына кечерәк кенә бер почмак төрттерсә йә матай-мазар алса яхшырак кебек тоелды, сөйгәненең ризалык бирәсенә ул аз гына да шикләнмәде. Каләмгөл абыстай белән Сабирхуҗа абзасының үзен яратканын белми түгел, беләдер, яше институт-фәлән тәмамламаган авыл кызы өчен шактый – егерме икегә җитеп килә, дуслашып йөргәннәренә, Алла боерса, көзгә өч ел. Алзәйнәпнең авылларында Гафурдан да яхшыракны таба алмаслыгы көн кебек ачык, башка яклардан кунакка төшкән яшь-җилкенчәк сирәк, олы юлдан ерак урыс-мари арасындагы, урман эчендәге Мортазада сабантуй кадәр сабантуй мәйданында авылдашлары гына бил алыша. Егет кыз өчен әнә шулай уйлады.

Гафур, чыннан да, ким-хур егет түгел иде. Тартуын тартса да, артыгын эчми, борынына ис кергән үсмер вакытында да клуб тирәсендә кыз-кыркын өчен сугышларда катнашканлыгы да ишетелмәде, хәзер юк та юк инде. Гафурга, әле җәйдә генә армиядән кайтканга, колхозда үзенә беркетерлек эш тапмадылар табуын, алай да кул кушырып яшәмәс. Көзге урып-җыю беткәч, исәбе – итек өязенә чыгып керү, планнарын тормышка ашырырлык акча туплый башлау.

Гафурның Алзәйнәпкә гашыйклыгы инде бала-чагасына да, әби-сәбиенә дә сер түгел. Армиядә чагында башка кызлар белән хат алышса да, болай гына – кеше арасында дәрәҗә тотар өчен генә иде. Машина өстендә хәрби комиссариатка китеп барганда, кульяулык болгап калган кызларга карап, ахириенең:

– Кулыңны бик тырышып болгама, боларның безгә буласы юк, – дигән сүзләрен һич кенә дә исеннән чыгармады. Аеруча үзенә күз атып йөргән Флүрәгә аталган хатларында тормышын җәелеп китеп сөйләмәде, яратам, сагындым, дигән сүзләр ычкындырмады, күбрәк авыл хәлләрен сорашты, дуслары хакында язды.

Флүрә әче теллелек белән яманаты чыккан нәселдән иде. Андыйлардан авыл егетләре ераграк торырга тырышалар, вечерларда биергә алмыйлар, алар урамының башына кайткан дусларына иптәшкә дә озата бармыйлар. Беркатлы Гафур аның белән хат алышып ялгышты. Кызның тәүге хатын ук җавапсыз калдырса була иде. Яхшысынмады. Флүрәдән килгән хатларда төче сүзләр, тирән мәгънә белән язылган җөмләләр арта баргач та, үпкән-кочкан җилгә очкан, диләр, бу бит әле нибарысы хат алышу гына, вәгъдә билгесе түгел, дип, үз-үзен тынычландырды.

Флүрәнең Гафурга хат язганлыгын Алзәйнәп белә, әмма ул үзе дә вәгъдә биреп озатып калган кыз түгел, моның өчен егеткә кинә сакларга кирәк түгел дип саный иде. Мортазадан сүзләр китеп тә Алзәйнәп игътибарга алмагач, Флүрәнең егеткә бәйле хыяллары хәл-әхвәл сорашу белән генә чикләнмәде, ул әледән-әле күңелендәгесен сиздереп куя башлады.

Гафур – сазап барган Флүрә белән бәйләнешкә кергән бердәнбер ир заты, шуңа күрә кызның кияүгә чыгуга бәйле соңгы өмете дә иде. Яшь агызып, кульяулыклар болгап армиягә озатып калган, әмма шунда ук оныткан яшьтәш кызларның күбесе башлы-күзле булган бер вакытта үзеннән күпкә өлкәнрәк Флүрә хатлары, ул авылга кайтып төшкәнче, атна саен булмаса, ай саен килеп торды. Гафур баштарак, әле бер тиенлек маркасыз конвертларда икенче кызлардан да кайнар сәламнәр килгәләгәндә, ара-тирә җавап биргәләсә, тегеме-бумы сәбәп белән башкалар язудан туктагач, Флүрәнең бер генә хатын да җавапсыз калдырмады.

Армиядән килгән хатлар ешая барган саен, Флүрәдә, Гафур, ниһаять, ярата башлаган, бәлки, үземнеке дә булып куяр, дигән уй ныгыды. Кыз сүзләрнең тагын да матуррагын сайлый башлады, үпкә белдерәсе килеп киткәндә дә, артыгын чәпчемәде, сабырлык күрсәтеп, килер язга кайтуын көтте.

Гафур туган йортына армиядән бик соңлап, иптәшләренең гимнастеркалары җәй кояшында уңып беткәч кенә кайтып төште. Күрше-тирә малайларына – сагызын-фәләнен, карт-корыга чәен-шикәрен күчтәнәчкә өләшкәч, туган-тумача белән бер кат сөйләшеп утыргач, туп-туры Алзәйнәпләр өенә китте. Исәбе, озын-озакка сузмыйча, кыз белән сөйләшеп, шушы җәйдәме, әллә килер көздәме гаилә корып җибәрү иде. Әнкәсе белән әткәсе пенсиядә. Кулларыннан эш төшеп бара. Абыйлары да, хатыннары да олыгаеп киләләр. Әле төпчекләрен хезмәткә озатканда ук, армиядән исән-сау әйләнеп кайткач, озак тормый өйләнүен хуп күрүләрен, яшь барган саен, атна-ун көн саен кайтып, йорт эшләрендә булышып йөрүнең авыраюын турыдан ярып әйттеләр. Бу эшләрне Мортазада төпләнгән Мосаннифка йөкләү дә бик килешеп бетми иде.

Өйләнәм дип әйтүе генә җиңел. Никахын укытасы, туен уздырасы, кеше арасында утырырлык киемен аласы... Яңа армиядән кайткан егеттә боларга җитәрлек акча югын гына ага-җиңгәчәйләренең

башына һич кереп карамады. Алзәйнәп, Гафурны бик сагынып көтеп алса да, ябешеп чыгарга риза булмады. Ул иркен тормышта ялгызы үскән бригадир кызы иде шул. Ак күлмәктә-фатада табын түрләрендә утыруга ни җитә?! Әле бит туйдан соң дөмбергә калуың да ихтимал...

Алзәйнәптән уңай җавап ала алмаса да, Гафур Октябрь бәйрәмендә кызны барыбер ябештереп алып кайтырга карар кылды. Көтүләр кергән, әле генә капка төпләрендә тупырдашып торган казлар суелган вакыт иде. Игеннәр мул, печәннәр күп әзерләнгән елны улларының өйләнүенә Каләмгөл абыстай белән Сабирхуҗа абзый бик шатланыштылар, яшьләрнең клубтан кайтуын өстәл ясап көтеп торырга булдылар, Гафурны аркасыннан догалар укып сыпырып, инде ул да башлы-күзле була бит дип сөенешеп озатып калдылар. Бу кичтә аларда утлар сүндерелмәде, ишек келәләре төшерелмәде, пәрдәләр яхшылап тартылды, башка чакта аяк арасында буталган Акбай, оясына кертелеп, чылбырга утыртылды. Яшь киленне куркыта-нитә күрмәсен, янәсе.

Бәйрәм концертыннан соң кызыл почмакта әзерләнгән табында активисткалардан Алзәйнәп кенә юк иде. Программага кертелеп тә, кызның чыгыш ясарга килмәве клуб мөдирен бик аптырашта калдырды. Гафурның кәефе кырылды. Әгәр сөеклесен, көтмәгәндә күңелләренә шик төшеп, әти-әнисенең клубка җибәрмәвен белсә, хәлдән чыгуның бер-бер уңай юлын тапкан да булыр иде. Әле узган төндә генә иртәгесен дә күрешергә вәгъдәләр бирешеп аерылышканнан соң, Алзәйнәпнең, бернинди хәбәр салмыйча, нәкъ менә иң кирәкле вакытта суга төшкән кебек юкка чыгуы егетнең ачуын китерде.

Әле концерт барганда ук Гафурның сөмсере тәмам коелган иде. Ул, менә-менә күренер дип, әледән-әле ишек якка карады. Алзәйнәп кенә күренмәде. Баштарак егеткә, бер-бер эш чыккандыр да, Алзәйнәп соңлыйдыр, мәҗлескә булса да килер кебек тоелды. Алай уйлаганы да дөрескә чыкмагач, кәефе тәмам төште. Җитмәсә, үч иткән кебек, урыны Флүрәнеке янәшәсенә туры килде. Ул инде Гафурга ничек ярарга белми, алдындагы тәлинкәсенә әле монысын сала, әле тегесен, кыз кеше дип оялып тормый, егет хәмердән бушаткан кырлы стаканны шунда ук тутырып та куя.

Мәҗлес ахырына, халыкны шаккатырып, Гафур тәмам исерде, ялгызы кайтыр хәлдә дә түгел иде. Флүрәгә шул гына кирәк тә. Ул сыер савып көч җыйган куллы, егәрле һәм эре сөякле кыз иде, егетләрне дә шаккатырып, Гафурны җилтерәтеп бер җилкәсенә салды да клуб артындагы бакча сукмагы аша гына кыска юлдан өйләренә озата китте.

Каләмгөл абыстай белән Сабирхуҗа абзый, берни аңламаслык хәлдәге улларын, аның янәшәсендә бүген ияреп кайтыр дип һич көтмәгән Флүрәне күргәч, ни әйтергә белмичә тып-тын калдылар. Хуҗабикәнең күрешергә дип сузылган ике кулы һаман да күтәрелгән килеш тора бирде. Сабирхуҗа абзый, беравыктан соң, ашъяулыклары алынып куелган табын артына – бу хәлләргә башкалардан битәр аптыраган Мосанниф янына барып утырды.

Кыз исә югалып кала торганнардан түгел иде, Гафурны түргә әзерләгән урынга илтеп яткырды да, аяк киемнәрен салдырып, өстенә ябып, өстәл әзерләнгән ишек катына чыккач, без менә шулай итеп өйләнештек, дип белдерде.

Карчыгының Флүрәгә караңгы чырай белән торганлыгын, нидер әйтергә маташканын күргән Сабирхуҗа абзый кешегә сиздерми генә алъяпкыч почмагыннан тартты. Аннан эш тапкан булып чоланга чакырды да, малай хәл иткән икән, килешми чарабыз юк, агасын күрше авыл мулласы Мифтахетдинга йөгерт, вакытында никах укытырга кирәк, Флүрә дә кеше баласы, яманатын чыгарырга ярамас, диде.

Хәзрәт озак көттермәде. Колхозның Мосанниф җигеп киткән турайгырында «ә» дигәнче килеп тә җитте. Чит-ятны да, белгән-күргәнне дә чакырып торасы итмәделәр, эчләре тулы ут иде – бу хәсрәткә нигә башкаларны да китереп кыстырасың?

Мифтахетдиннең сорауларына Мосанниф кына таныкнамә бирде дә, Гафур белән Флүрәне өйләнештереп тә куйдылар. Чәйләп алгач, мулланы да озаткач, кыз белән егетнең икесен бергә калдырып, әти-әни ихатаның йортка каршы ягындагы ак келәткә чыгып китте, Мосанниф йокларга үзләренә кайтуны хуп күрде.

Эчкән аракысыннан башы авыртуга түзә алмыйча төнлә уянып китсә, Гафур таң калды: янында, ап-ак беләкләре белән муенына сарылып, чәчен-башын тузгытып, эчке күлмәктән генә Флүрә йоклап ята. Кияү егетенең башына китереп суктылармыни, ул бар көченә әлеге ак кулларны үзеннән алып ыргытты да:

– Нишләп ятасың монда? – дип кычкырып та җибәрде.

Флүрә тиз генә бирешә торганнардан түгел иде. Мут елмаеп, тагын егетнең муенына асылынырга, иреннәреннән үбәргә чамалады, аның үзен һаман да читкә этәрүен күргәч кенә түзмәде:

– Без никахлы инде, берни эшли алмыйсың, – дип әйтте дә салды. – Мин – синең закунный хатының.

Гафурны әлеге сүз чыгырыннан чыгарды, сикереп торып Флүрәнең урындык өстендә яткан киемнәрен башына ыргытты, аннан, киенгәнен генә көтте дә, кулыннан җитәкләп, өстерәп диярлек

капканың теге ягына чыгарып ташлады. Үзе исә, кызга карап та тормыйча, тау башына, сөйгәне яшәгән йортка таба йөгерде.

Ярый әле Алзәйнәпкә урынны, көз дип тормый, верандага җәйгәннәр икән. Ул көтмәгәндә ачылган капка тавышына уянган да тәрәзә янына килеп баскан иде. Аталары, кызның беркая китмәсенә ышанып, күптән ятып йоклаганнар булып чыкты. Гафур Алзәйнәпне ишегалдына – болдырга дәште дә, тотлыга-кабалана, бу кичтә үзе белән булган хәлләрне сөйләп бирде.

Флүрәнең иллә дә оста борынына чиртә язуы сөйгәненең кытыгына тиде. Ул озак уйлап тормады, верандадагы киемнәрен култык астына кыстырып, өстенә калын шәл ябынып, Гафурларга төшеп тә китте. Аларның беренче төне бу хәлләрне тагын бер кат искә алып, әле елап, әле көлеп дигәндәй үтте.

Ул арада таң атты. Каләмгөл абыстай, ишегалды уртасындагы комганнан гына тәһарәтләнеп, соңга калган намазын укыды, мунчасын ягып җибәрде, Сабирхуҗа абзый мал-туар карады, олы мичкә ут төртергә дип, чырасын-тузын хәстәрләде. Нәкъ вакытын белеп, хатынын җитәкләп, Мосанниф та килеп җитте. Инде киленнең ата-анасына хәбәр салыйк дип, җыйнаулап өйгә керсәләр, күзләре маңгайларына менде. Алзәйнәп белән Гафур кичтән җыелмыйча калган табын артында чөкердәшеп чәй эчеп утыралар.

Аптырасалар аптырадылар, аптырамасалар юк дигәндәй, берсе дә әле төн аша гына булган хәлләрне искә алырга теләмәде, әйтерсең, берни дә булмаган, никах та нәкъ менә улларының яраткан кызы белән икесенә укылган... Мосанниф кына, уңай килсә, сораштырырмын дип, мунчадан соң ук ишегалды тирәсендә балта-чүкеч тотып йөргән энекәше янында булышып маташты да, җае чыкмагач, үзләренә китеп барды. Алзәйнәпнең әти-әнисе әйткәнне көтеп тормаганнар, үзләре үк килеп җиткәннәр, кыяфәт саклап кына, кызны кире кайтырга үгетләп маташсалар да, эчләреннән моны һич тә теләмиләр иде.

Каләмгөл абыстай белән Сабирхуҗа абзый бу көнне дә, әле аннан соң да Гафур белән Алзәйнәпнең теле бер ачылмаса бер ачылыр дип юкка көтте. Ул көнне дә, аннан соң да яшьләр бу мәсьәләдә бик тешләк булып чыкты. Нәфесе аркасында мәсхәрәгә калган, инде үзеннән башкаларның да көлүен теләмәгән Флүрә серле никах төне хакында сөйләми дә сөйләми иде инде. Ахырда карт белән карчык, шайтан коткысы белән үзебез генә саташканбыз, ахрысы, дигән уйга ук төштеләр. Танык өчен Ходай бар, сылтау өчен шайтан бар, диләрме әле?!

* * *

Сулар акты, җилләр исте, гомерләр үтә торды. Алзәйнәп белән Гафур яраткан кияү белән игелекле килен, уллы-кызлы әти-әни булдылар. Пенсия арттыруны юллап йөргән Мифтахетдин мулла бервакыт Мортаза авыл советына кирәкле язуларга пичәт суктырырга килгән иде. Кәнсәләр төшкә ябылган булып чыкты да, тукта, хәлләрен белеп чыгыйм, дип, Сабирхуҗаларга керергә ният итте.

– Әссәламегаләйкүм! – дип ишектән узуга ук, әлеге дә баягы зур мәҗлесләр өчен ясалган озын, тар өстәл артында кап-кара чәчле хатын, шул хатынга охшаган карачутыр ике бала шапыр-шопыр аш чөмереп утырмасыннармы?!

Туктале, мин никах укыган чәчбиха зәңгәр күзле җирәнкәй иде ләбаса, дип гөманлады ул эченнән. Хәзрәт еракта калган, хәтерендә тоныклана төшкән көннәрне, табынны, табын артындагы четердәвек Флүрәне кабат күңеленнән кичерде. Элек күргән сипкелле, очлы борынлы кыз белән тулы битле, почык борынлы яшь хатын арасында һичбер охшашлык тапмады. Тегесе буйга кечерәк, сөяккә какчарак иде дип әйтимме... Нәкъ шулай! Мифтахетдин мулланың башына, Гафур аерылган, яңа гаилә корган икән, дигән уйның килүе булды, ишектән кояш кебек елмайган Каләмгөл абыстай башы күренде:

– Алзәйнәп килен, мулланы чәйгә дәш, укыганнары бик кабул була икән, – диде, аннан Мифтахетдингә карап: – Аллага шөкер, малай белән килен бер итеп яши, – дип өстәде.

Мифтахетдин мулла, булса да булыр икән шайтан вәсвәсәсе дип, өч тапкыр төкеренгәч, күңелгә шик килгәндә укыла торган дога сүзләрен әйтте, аннан берничә мәртәбә:

– Әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ, – диде дә табынга килеп утырды. – Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

*2009*

## КАРГЫШЛЫ ГӨЛ

Массаж ясаучы ханым, ишектән чыга-чыга:

– Телевизор янындагы затлы гөлегезне йә чыгарып күмегез, йә суга агызыгыз, сафлансын, – дигәч, Раянә телсез калды. – Югыйсә авыруларыгызның узуы шикле. Каргалган.

Шушындый матур, өйне ямьләндереп торган яшел яфракларның җепселләре буйлап зәһәр сулары аксын диме?! Булмаганны! Кибеттән гөл алырга да куркып торырсың болай булгач. Ырым-шырымга

ышанмыйм, дип күпме сөйләнсә дә, төрле шикләр күңеленә һәрвакыт килә иде аның. Ходай кушмаган эшләр турында уйларга да ярамаганлыгын белә, әмма адым саен сихерче-убырлы үрчегән бер заманда кем күңеленә дә вәсвәсә төшәр. Алай да Раянә:

– Һич мөмкин түгел, – диде, массажистканың куркыныч шомлы күзләренә туп-туры карап. – Үз гөлемне үзем каргый алмыйм лабаса!

– Мин үзегез каргагансыз димим лә, ул бит башка бер йортта булып кайткан, бәлкем, каргыш та җыймагандыр, әмма кара эчле ханым кулларыннан көн дә су эчкәнлегенә шигем юк.

Шәфкать туташы киткәндәге сүзләре белән Раянәнең йөрәгенә ут йөгертте. Чыннан да, керамик чүлмәк эчендә балкып, күкрәп үсеп утырган гөл аның кайчандыр остазына рәхмәт йөзеннән биргән бүләге иде.

Раянә озак вакытлар аңа ни сайларга белми аптырады. Кыйммәтле бүләкләр китерсә, кире кагар дип курыкты. Татар тәрбиясе алып үсүенә ишарәләп, оныгына алган саф алтын алкалар янына кушылган, ерактагы эссе илләрдә тамыр җибәрсә дә, ризыгын, сулар һавасын салкын бер якта тапкан гөлдә бик тирән мәгънәләр күрде ул. Ак сырлы каты яфракларын чал чәчле укытучысының ныклы характерына охшатты, туры кәүсәсен аның авырлыклар килгәндә дә сыгылмавына тиң күрде. Алай да кибеттә әле сайланып торган бер вакытта кафедра лаборантының: «Гөл бирсәң дә, өйдә эш эшләү гадәте юк, су сипмәс инде ул, шиңеп кенә бетәр... Аңа ничек тә ярап булмас... Яхшылыклары да тиде тиюен, үземне бурычлы күк тоям, бәйрәмгә ни бирим икән?» – дип өзгәләнгәне исенә төште. Ул булмаса, башка сибүче табылыр, гөл – гомерлек һәдия, дип, күңеленнән каршы төште аңа Раянә һәм кибеттәге иң бәһале, иң затлы гөлне күтәреп кайтып та китте.

Ул гөл сайлап ялгышкан булып чыкты. Эш өстәленең түренә китереп утырткач ук, остазның йөзе сытылды:

– Мин гөл карый да белмим, яратмыйм да, җитмәсә, чүлмәге дә пластмасса гына.

Раянә ике дә уйлап тормады, якындагы кибеттән өйне ямьләндерәчәк затлы чүлмәкне күтәреп тә керде. Монысы инде үзбәк осталары эшләгән бик матур савыт иде.

– Ярар, бер кырыйга куеп тор, инде аны кем күчерсен, – дип борынын җыерды остаз. Алтын алкаларны теләбрәк алса да: – Колагым тишелмәгәнгә биргәнсеңдер инде, – дип куйды. – Бер аспирантым, юынып йөрмисең дип төрттергән шикелле, диссертация яклагач, мунча сумкасы китергән, икенчесе, тәһарәт алмыйсыз дигән кебек, комган бүләк итте. Тора шунда, туалет почмагында.

Мондый сүзләрне тыңлап тору кыен булса да, Раянә түзде, алкаларның оныкка икәнлеген тыныч кына аңлатты. Ярар алайса дигәндәй, остаз да алар салынган тартмачыкны өстәлнең бер кырына эшерде. Үпкә сүзе әйтелгәннәр белән генә бетмәгән булып чыкты:

– Гыйззәт букча да китерсен инде, ярар. Акылы да шундый гына, җитәкчебезгә бик ярар анысы, фәне аныкыннан ерак китмәс, классик мәктәп булыр, эчтәлек сөйләп яшәр. Әле кафедрада мактагач, күңеле булып, хушланып утыра, ни әйткәнемне дә аңламый.

Гыйззәтне эшкә калдырыгыз, дип үзем сорадым. Уртакул кеше белән эшләргә җайлы ул. Мин язганны сөйләп чыгар шунда. Герман Петрович, Чаллыга барып, әзер лекцияләремне генә әйтеп яздырып кайткан бит. Әле шуны да аңламый икән. Көчкә укый, ди. Пока синең дустың булганга гына түзәм. Утырыш саен әйтәчәкмен түлке.

Ул ике малай синең өчен генә кеше бит. Йөрсеннәр шунда. Менә Арзуга бик нык ачу килде. Эшен язып бирә торып, комган тоттырып китте. Тәһарәт алырга вакыт сиңа, диде микән ул? Әллә, гарәпкә чыгып кайткач, мин инде тәһарәтле, дип әйтүе микән? Килеп гафу үтенмәсә, өшкерәм әле мин аны, бөтен язганы – минеке. Мөдиргә бүләк биреп дуслаштым дигәч тә.

Раянә эшләгән алман әдәбияты кафедрасында бүләк алышу-бирешү гадәте электән булмагач, гомер буе хөрмәт иткән остазның шундый сүзләр сөйләвенә Раянә ни дияргә дә белмәде, алай да каршы төшмичә, баш селкеп кенә тыңлап торды.

– Бу ел, үзең беләсең, бик авыр елым булды минем, һәр көнем синең өчен көрәшеп, сине саклап узды. Үзеңә этлек эшләгән кешеләрне онытсаң, мәңге ризалыгым юк.

Раянә, бу сүзләрне инде мең мәртәбә ишетсә дә, һич кенә дә кабул итми. Җитмәсә, үзенә килгән авырлыкларның башта оештырган, киеренке хәл тугач, үзе үк тартып алган мөгаллиманең гаепне башкаларга аударуыннан булган эшләргә карата фикере үзгәрерлек түгел иде. Ул остазына да үпкә сакламый, яше барын, картлар холкының ничек икәнлеген белә, адәм хатадан хали түгел, дип, тыныч кына яши бирә.

– Мин сиңа васыятемне әйттем, ә үземә салынган зыянны мин һәрвакыт үзем кайтарып барам. Бармак юанлыгы алтын муенса аскан егетебезне беләсең. Иван Сергеевичны әйтәм. Кеше хакы бер тишеп чыга ул. Хәер, шул алтыннары белән ирлеген бетерде инде ул. Ир кешегә көмеш кияргә генә ярый бит... Бер генә каргадым, шунда ук нәселе кырыла башлады. Иң якын кешеләрен үк югалткач, әйттем, болай ук кирәк түгел иде, артыграк та сораганмын икән, дидем. Әгәренки миңа зыян сала икән, алга таба да үләчәкләр түлке.

Деканны кара. Николай Петровичны. Кичә коридор буйлап бара. Аягын көчкә өстерәгән. Шул минем каргыш төште инде аңа. Төшемә бер ягы кап-кара килеп кергән иде. Рас чыкты. Хәлен белеп тордым әле, тизрәк сәламәтләнегез инде, дигән булдым. Эче тулы этлек, миңа сер бирми. Ректорга барып, тиштереп чыгам мин аны. Озак декан булып тормас. Инде каргышым барып ирешкәндер.

Кафедрадан әле тагын берничә кешегә зур хәсрәт киләсе бар. Күреп торырсың, мин әйткән иде диярсең. Инглиз кафедрасының мут күзле профессоры да минем каргыш белән үлем хастасына иреште. Төшемә керде. Елап тора. Бар әле аның күрәселәре, бар... Кызлар артыннан күп чабалмас. Менә хәзер хатыны да чирләгән. Аерылып, Себергә кызлары янына киткән диме шунда? Әйбәт булган. Бераз ялгыз яшәп карасын. Миңа әшәкелек эшләүнең ни икәнен белер.

Раянәнең тәннәре чымырдап китте. Бу сүзләрнең шомландыру, үзен әллә нәрсәләргә сәләтле итеп күрсәтү икәнлеге өчен әйтелгәнлеген белсә дә, курыкты. Әтисе вафатыннан соң ул хәтта дошманнарына да озын гомер, сәламәтлек теләп яши иде. Укытучысына да:

– Каргарга кирәк түгел, Ходай үзе тигезли аны, – дип кенә әйтеп куйды.

Күрешкән саен ишетелгән, башкаларга таратылып, алардан да килеп ирешкән гайбәтләр онытылмаса да, Раянәне бервакытта да иң якын саналган кешесе үзен дә каргар дип шик алмады. Эчтә яшәгән шайтан барыбер үзенекен итә икән, менә хәзер, массажистка ханым да коткы салгач, йөрәге жу итеп китте, вәсвәсәгә бирелде, каргышка ышанды. Ә бит нәкъ менә остазы гөлен дә, алтын алкаларын да кире кайтарган вакыттан соң ныграк чирләвен уйлап куйды. Чыннан да, аяклары артроздан тилмерә, билен тота алмый, кан басымы ныграк уйный... Бүләкләрне кире кайтарганнан бирле остазның мөнәсәбәте дә тәмам тискәре якка үзгәрде... Нәрсә генә сәбәп булды соң моңа, нәрсә? Кеше каргарлык нәрсә кылдым?

Тфү, тфү! Уйладым исә кайттым, диде шуның артыннан ук Раянә – инде намаз карчыгы булып яшәрлек кешенең ул эшләргә – кулы, каргышка теле бармас. Каргыш таягы ике башлы, ди иде мәрхүм әбисе, үзенә әйләнеп кайтмас дип кем әйтер?!

*2009*

## МӘХӘББӘТ – МӘҢГЕЛЕК!

Җиһангир Мулдашев Алтай экспедициясенә бу юлы студентлар белән генә чыкты. Һаваны аларча сулыйсы, көннәрне аларча кичерәсе килде аның. Язгы ялгыз көннәрдә яшьлек хисләренең дә терелеп күңелен мөлдерәткән чагы иде. Тәүге тапкыр ерак илләргә сәяхәт итә башлавына егерме ел гомер узган да киткән икән! Ул заман гашыйк булган Тибет чибәркәе инде тирмә тулы бала үстерә торгандыр, әллә шау-шулы шәһәргә китеп зур кеше булды микән?

Яшьләр яңа ачылган курганнан бер тау балчык чыгарып өйгәннәр. Көн буе шуны иләде ул. Зур байлык табылмады. Нибары имгәнеп беткән ике колакса. Моңа кадәр бу тирәдә кемнәрдер казынган идеме... Урынлы-урынсыз таралып яткан сөякләр шул хакта сөйли кебек. Егетләр инде аларны да җыйганнар, агач тартмаларга тутырып маташалар.

– Каберлектә өч кеше җәсәде булганга охшаган, әйе бит, Җиһангир Чыңгызович? Бер гаилә түгел микән?

Кечкенә йөк машинасының арбасы янына килеп, тартмаларга карап торган Марина тавышы иде бу. Остаз борылды, елмаебрак:

– Менә сез әлеге сөякләрдән «кешеләр җыярга», кемлекләрен ачыкларга дип килдегез дә инде. Бәлки, бу каберлектән фән өчен зур яңалык та ачмассыз, үзегезгә файдасы тими калмас.

– Скелетларга карап, яшь ханымның портретын ясарбыз да, синеке янәшәсенә куеп, үз «әбисеннән» Марина күпмегә чибәррәк икән, дигән сорауга җавап эзләрбез, курс, диплом эшләре язарбыз, – дип, мөгаллим сүзен куәтләгән булды Марат.

– Әйтсәгез әйтәсез инде, минем йөзем, буй-сыным археологның өйрәнү объекты була ала диярсең!

– Ә бит кайчандыр бу кешеләр дә баш сөяге, умыртка сөяге хәлендә яшәмәгәннәр. Менә нәкъ синең кебек йөргәннәр, ашаганнар... Киенгәннәр, стразлы купальникларда су коенганнар дип әйтмим әйтүен.

– Әллә ничә гасыр элек минем кебек уйлаганнарын да, компьютерда уйнаганнарын да, фән белән шөгыльләнгәннәрен дә өстә, – диде кыз.

Марат, Маринаны җитәкләп, каберлек янына килеп басты:

– Без бит аерма эзләмибез, охшаш якларны тикшерәбез. Беләсең килсә, без җир өстендә генә – кешеләр. Аннан соң барыбыз да казылма байлыкка әйләнәбез. Әнә теге каберлек почмагына кысылып, безнең үткер күздән дә качып калган чүлмәк ватыгы кебек. Кемгәдер өскә чыгу бәхете тия, ә кемгәдер юк. Без казып чыгарган адәмнәр менә тагын якты көнне күрделәр.

– Сиңа мине сөю бәхете тимәгән шикелледер инде, – дип чытлыкланды Марина. – Мин сөймәгәч, без аерым-аерым яткан казылмаларга әйләнәчәкбезме?

Маратка сүз көрәштерү ошап китте. Уенның тәмен тәмам татыган иде. Маринаны биленнән кочып тотты да салкынлык бәреп торган кабер эченә сикерде:

– Егетлә-ә-р, туфрак белән күмеге-е-ез! Тагын бер гасырга хушлашабыз!

Студент халкы шаярырга ярата инде. Шуны гына көткән кебек, барысы да, эшләрен ташлап, ачылган курган янына йөгерделәр.

– Туфрак ыргытыйкмы, ташмы? – диде Зиннур. – Таш яхшырак булыр, элек никахсыз кочаклашканнарны таш белән бәреп үтерү гадәте булган. Алай дисәң, сезнең кебек гөнаһта тотылганнар үзләре теләп үлемгә барганнар. Мәхәббәтнең мәңгелеген расламакчы булганнар.

– Алай гына расларсың! Бергә үлмәсәләр, безнең кебек тарткалаша торгач, йөз аерылышкан булырлар иде инде, – дип көлде Марат. – Әмма ләкин мин шулай расларга риза!

– Талашмый ни! Бөтенесен үзең хәл иткәнгә ул. Минем менә сөяк хәлендә кояшка чыгасым килми. Болай да үлгәнче яшәячәкмен!

Кыз «мәңге» дип әйтергә теләгән иде, ялгышты, шул сүзе аркасында көлкегә калды. Инде иреннәрен тагын да ныграк бүлтәйтте:

– Минем сезнең берегезгә дә исем китми. Маратка бигрәк тә.

– Алай булгач, сине үземнән җибәрмим дә җибәрмим инде, – диде егет, күзе төшкән кызны тагын да ныграк кочаклап.

Марина:

– Җиһангир Чыңгызович! – дип чәриләргә тотынмасынмы.

Мөгаллим бу хәлләрне читтәнрәк күзәтеп тора һәм һәр әйткән сүзне аермачык ишетә иде. Ул, сүзгә катышмый гына, хәрәкәт кай якка чишелеш табар дип көтте. Инде Маринаның чәриләгәнен ишеткәч, каберлек янына килде.

Укытучы да монда торадыр дип уйламаган егет куллары белән кызның башын эләктергән дә көчләп үбәргә маташа.

– Мәхәббәтне мәңгеләштерергә ашыкмагыз, мин сезгә иң башта бер истәлек сөйлим, – диде укытучы, яшьләрне кисәктән өркетеп.

Аның килүен күргәч, Марина белән Марат шаярышудан туктады. Кызарышып торып бастылар да, кагынгалагач, агач ботакларыннан әвәләгән баскыч буенча өскә үрмәләделәр.

– Моннан нәкъ егерме ел элек без чит ил галимнәре белән Тибетка археологик экспедициягә барган идек. Минем әле аспирант чак кына, өйрәнә торсын дип, үзләре белән алганнардыр инде. Ул вакытта бер дәрәҗәле затның курганына юлыктык без. Ат дирбияләре дисеңме, савыт-сабамы – барысы да мулдан, барысы да яхшы сакланган. Хуҗаныкыннан тыш аерым бер уентыкта тагы ике кеше ята. Сөякләреннән ачык күренеп тора: уңдагысы – ирнеке, сулдагысы – хатын-кызныкы. Иң гаҗәпләндергәне шул: алар, әйтерсең, кочакланышканнар, кул сөякләре бер-берсенең башына үрелгәнгә охшаган.

Экспедициягә кытайлы яшьләрне дә алган идек. Шуның берсе тибет кызы булып чыкты. Русча аңламый аңлавын, минем телне су кебек эчә. Гөлҗә татарлары арасында үскән. Аның белән инглизчә сөйләшеп тә тормыйбыз, безнеңчә сиптерәбез генә. Мин дә мәскәүле бит – туган тел сагындырган.

Кыз бик чибәр булгандыр инде, кан да тарткандыр, үлеп гашыйк булдым мин аңа. Генетиклар, һәр дүрт европалының берсе Чыңгыздан килә, диләр бит. Безнең инде аның җиргә таралган орлыкларыннан икәненә һич шик булырлык түгел.

Көнен-төнен Луның койрыгы кебек йөрим, аңа ни кушсалар, мин дә шуңа алынырга тырышам. Ничек тә үземә каратасы килә. Карамый гына бит! Ә читтән күзәткәнгә Фәрхад белән Ширин кебектер инде без.

Каберлек миңа сүземне сүз итәргә мөмкинлек ачты. Теге уентык турысын өстән күзәтеп торган бер вакытында Луны кочагыма алдым да:

– Син миннән баш тартырга ашыкма, минем мәхәббәтем аларныкы кебек мәңгелек булачак! Без теге дөньяда да гел үбешеп кенә яшәрбез, – дидем.

Кыз нишләптер моңсуланды. Кочаклаган кулларымны сак кына сыпырып төшерде дә ераккарак, тау читенәрәк китеп утырды. Мин дә аның янына килеп чүмәштем.

– Син башта бу дөньяңны сөешерлек итеп кор, – диде кызый. – Мәхәббәтне үлем аша раслауның нигә кирәге бар?! Хәер, сөю-сөешүнең мәңгелегенә ышанам мин. Ул бер үк вакыйга-күренешләрнең, бәхет китерәме-китермиме, гасырлар дәвамында кабатлануында күренә. Без синең белән кайдадыр, кайчандыр шушы ук шартларда очрашырбыз кебек миңа. Бәлки, мине оныттым дигән көннәреңдә нинди дә булса хәбәр аша исеңә төшәрмен. Син бит бергә булмаячагыбызны үзең дә беләсең. Җиңел дип уйласаң, сакла мәхәббәтеңне! Әгәр ялгызлыкны – онытудан җиңелрәк санасаң...

Луны тыңлау авыр, рухымны баса иде. Көчкә түздем! Башыма бу илдән кайтмый калырга микән әллә дигән ахмак уйлар килгән чаклар да булды бит минем. Китсәм дә, калсам да ялгыз булачакмын лабаса!

Лу сөйләгәндә башымда мең төрле уй үзара бәргәләште. Аның сүзе бетмәгән икән әле:

– Бу кабер миңа әбием сөйләгән бер тарихны искә төшерде. Нәкъ шушы курган турында кебек тоелды ул.

Даны еракларга таралган бер хан булган, имеш. Кыйтганың җиде кыйсменә баш булып торган. Моның берсеннән-берсе акыллы җиде хатыны, берсеннән-берсе чибәр җиде җариясе булган, әмма кая гына барса да, аларны үзе белән ияртмичә, җырчы егет белән биюче кызны алган.

Әлеге кыз белән егеткә, бер йортта яшәсәләр дә, хан тарафыннан үзара якынаймаска шартлар куелган, бу хакта бер-берсенә әйтмәскә дә кушылган. Бер бүлмәдә йоклаганнар, бер табактан ашаганнар, хәтта бер хәммамда юынганнар. Әлбәттә, кыз һәрвакыт гаурәтен егет күзеннән каплый торган булган.

Ханның җырчысы биючесенә шулай да үлеп гашыйк, имеш. Аның бөтен җырларында кызның матур сурәте чагылган, көенә аңа карата хисләре салынган. Кыз исә егетнең шул дәрәҗәдә моңлылыгын, телгә осталыгын хуҗасына табынганлыктан күргән.

Кыз да егеткә охшар өчен биегән, үзен егетне сөюче итеп күзаллатырга, бию теле аша хисләрен аңлатырга тырышкан. Җырчы моны кызның ханга гашыйклыгыннан дип тапкан. Әгәр шулкадәр сөйсә, ничек бер кәлимә сүз белән кызга аңлатмас иде икән, их, миңа рөхсәт булсамы, ниләр әйтәсен белер идем, дип уйлый, имеш.

Хан боларның күңелләрендәген аңлап торган, әмма тыныч кына күзәтүен дәвам иткән. Инде, авырып, үлем түшәгенә егылгач та, бу хакта исеннән чыгармаган, үз каберендә уртак уентык ясап, егет белән кызны тереләй җирләргә боерган. Теге дөньяда да аларның ихтыяр көчен сынарга уйлаган ул.

Көннәрдән бер көнне малик үлгән. Баш вәзир, аһ-зарларына карамыйча, егет белән кызны кабер кырына китерткән. Болар нишләсен, ачы язмышларына риза булып, кабергә төшеп ятканнар. Башка уентыкларны каплаганнан соң, аларныкын да туфрак ишелмәслек итеп күмгәннәр.

– Мин куркам, – ди икән кыз. – Тычканнар, күселәр кимерә башлар кебек.

– Аңарчы һава бетәчәк әле, – ди егет. – Без инде аңыбызда булмабыз.

– Мин ничек тә куркам, – ди кыз. – Караңгыдан да, озак көткән үлемнән дә. Салкын сөякләремә тәмам үтте.

– Мин яныңда ич, кайгырма, – дип тынычландыра сөеклесе. – Сиңа өзелеп яратуым көч бирер, кочагымның җылысы кабер салкыныннан саклар.

– Алайса, яратуыңны исбатла, озаклап үлү авырлыгыннан коткара күр, – аның саен ялвара икән кыз.

Егет бик озак ризалашмаган, барыбер тиздән үләбез бит, дигән. Аның үзенең дә кыздан ярату сүзләрен ишетеп каласы килә икән. Ул исә курыкканнан-курка барган һәм ахырдан түзмәгән, егетне кочаклап ук алган. Хан җырчысы киеменә яшереп агу алып кергән икән. Кызга бирсә, үзе исән калачак. Бирмәсә, яшь сылу бигрәкләр дә кызганыч. Нишләргә белми генә бит. Ахырдан сөеклесенең ялваруына түзмәгән, мышьякны капкан да кызны үбәргә тотынган һәм муенындагы йокы тамырыннан буа барган. Үбешкән килеш кенә үлгәннәр...

Минем каләм дә тибрәтеп йөргән чак.

– Әдәби әсәр өчен бер дигән риваять бит бу, – дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.

– Сиңа – риваять кенә, ә миңа – чын тарих, – диде Лу. – Теге егет ерак бабабыз булган бит. Гасырдан гасырга күчеп килгән гыйбрәтле гаилә вакыйгасын тыңладың.

Әлеге хәлләрне биюче егетнең кабердән чыгып сөйли алмасын белсәм дә, Луга каршы төшмәдем. Әйдә соң, ышансын, шулай булган икән дип уйласын.

Ә ул һаман да моңсурак була бара.

– Ышанмыйсың инде син минем бер сүземә дә. Ул биюче турында миңа моннан ерак түгел көтүлектә яшәгән шаман да әйтте. Бабамның җаны аның тәнендә яңадан арабызда, имеш. Ә бу хикәят беркемгә сөйләнмәгән риваять иде. Мин нәсел серен чиштем. Ялгышмадым микән?

Әкияткә охшаган хәлләр, шуның аркасында кыз кичергән хисләр минем аңлавымнан ерак иде. Бу якның тарихы, каны белән кушылган кыз миңа бик якын утырса да, миннән кош биеклегендә өстәрәк булгандыр, ахрысы. Аны кабат җир өстенә төшерәсем килмәде, кайтмый качып калу уеннан да суындым. Киткәндә коры гына хушлаштык.

Хикәятнең дәвамын ишетергә теләгәндәй, Марина:

– Аннан кемгә өйләндегез соң? – дип сорап куйды.

– Ничек «кемгә»? Ялгызым яшим. Икенче тапкыр чын күңелдән яратып буламыни?

– Үзегез, суындым, дигән булдыгыз тагын, – дип шик белдерде Марат.

– Суынган кебек кенә тоелган. Теге хикәят һаман төш булып керә. Бүген тагын яшьлекне күреп уяндым... Яңа ачылган курган аша тагын бар нәрсә кабатланды... Нәкъ Лу әйткәнчә. Баш очыбызда әйләнгән тау бөркетендә әлеге карт шаман җанының безне күзәтүе дә бик мөмкин.

Галим җыен шырды-бырдыны сөйләп утыруыннан укучылары көләр, дип уйлаган иде, алай булып чыкмады, барысы да хикәяттән исәрләнделәр. Марат, кызга карап:

– Марина, әйттем ич, – дигәннән соң, югарыда бөтерелгән бөркетне, гасырлык курганнардагы мәетләрнең рухларын сискәндерерлек итеп, кулларын күккә күтәреп кычкырды: – Мәхәббәт – мәңгелек!

– Элек-элек... – дип җавап кайтарды таулар итәгеннән искән язгы җилләр.

*2008*

## СИРЕНЬНӘР КУЛЪЯУЛЫК БОЛГЫЙЛАР

Төнге юлчы шикелле, көзнекенә охшаган җил тәрәзәгә яңгыр бәрә.

– Кайттыңмы, җил? – дим мин аңа, ишеткәнемне белдереп.

Җил кайткан. Караңгы болытлар, усал яңгыр алып кайткан ул, мин үпкәләмим. Һәрбер язгы, җәйге иртә җиле истәлекләремне яңартканга, тәрәзәне ачып, башымны аның кочагына куям. Күңел күзләләр генә күрерлек куллар ачык муеныма үрелә, тыпыр-тыпыр тәрәз төбендә биергә ымсынган тамчылар авырайган керфекләремә тамалар да йокысын үзләренә алып качалар.

Безгә көнләшеп карап торган канәфер куаклары, башка чарасы булмаганга, шәмәхә кулъяулык болгый.

– Кайттыңмы, җил?– дим мин йомшак кына, инде күптән йокыга киткән күршеләремне уятасы килмичә. Бәрхет ашъяулыгыма терсәкләремне терәп, кул аркасына иягемне куям да тып-тын калып утырам. Өйгә узган җил тәрәз пәрдәләре белән уйный, минем вазамда да күперенеп утырган канәферләрнең хуш исен тугай-урман исләре белән бутап, бүлмәмә тарата.

Җил кайткан. Яшьлегем кайтавазы булып, күңел тәрәзәмә дә истәлек тамчылары сибә ул. Йорт каршында үскән сиреньне ап-ак тәлгәшләрен өстәл өстенә салып куярлык итеп бөгә.

...Кызык бит әй. Күпчелеге журналистлардан, егетләрдән торган гарәп төркеме китеп, армиягә алынып сирәгәя торгач, парта артында өч ахири утырдык та калдык. Алтын кысалы күзлеген борыны белән маңгае арасында уйнаткалап тора да Лена Кәлимулловна дәресен кырыс тавыш белән башлап та җибәрә.

– Күрәм, дәрескә йөреш тагын 70 процентка гына якын.

Без дәшмибез.

– Бу хәлне деканат беләме? – дип сорый ул бераздан, тавышындагы ныклыкны киметеп. – Инде икенче мәртәбә дәрескә йөреш 70 процент та булмасын әле!

Илмира баш селки. И-и, яраталар да инде шуның баш селкүен мөгаллимнәр. Яңа темага кергәндә селкесә – аңлаган, орышканда – килешә, мактаганда – ул электән шундый булдыклы икән дип кабул итәләр. Бу селкүнең мең төрле рәвешләрен мин инде күптән ятлап бетердем. Башы селкенгәннән мәгънәсезлек күрү куркынычы янамаган галим-голәмә алдында бераз иреннәрен җәебрәк куеп, як-якларыннан икешәр теш күрсәтеп селкенә ул.

Илмираның күзләренә тоныклык йөгереп, башы кагылып куелганнан соң, Лена апабызның болай да йомшаклыгын яшереп бетерә үк алмаган йөзенә кайгырганлык галәмәте чыга.

– Нураниягә бер-бер нәрсә булмагандыр бит? – ди ул, инде аңа гына карап.

– Урындыкка утыра алмый. Һәр ягына өчәр сызлавык чыккан, шу-у-ндый зурлар! – ди Илмира, авызларын очлайтып, үзе үк санаган шикелле.

Алтын кыса, борын очына төшеп торып, Лена апаның кара уйчан күзләренә сөзеп карарга мөмкинлек бирә.

– Ой-йой-йой!

Мин астан гына Илмирага төртеп алам: баш, баш! Инде аның Нурания өйрәткән сүзләрне әйтү оятыннан тел астына юешлек җыелган. Шул чайпалып китәр дип уйлыймы, баш кабат селкенми, яңа туган сарык бәрәне шикелле мәэлдәп кенә куя.

– Ә Нураниягә... «Әнһәду фис сәгатит тасагати сабахан» шул аңа һәр көнне!

Киләсе дәреснең 70 проценты эчендә – Нурания белән мин. Лена апа күзлеген салып өстәл кырыена куя.

– Нурания, Илмира башка дәресләрдә булдымы? – дип сорый ул тавышын күтәрмичә генә.

– Жук, Лена апа, жу-у-к!

Методика кабинетында чебен очканы ишетелерлек тынлык. Лена Кәлимулловна чып-чынлап хәсрәттә, уйда икәнлекне кырыенда җыерчыклары артып киткән күзләре үк күрсәтеп тора. Ул әле кирәкле сүз эзли. Әдәпле итеп сорау сүзе.

– Илмира... авырыйдыр инде...

– Жу-у-ук... Егетләр янына кайтып китте. Алсуларга. Аның әтисе бригадир бит. Трактор белән каршы ала инде аны. Тиз генә барып җитә алмаслар...

– Үзгәргән Илмира, үзгәргән...

– Ие, Лена апа, ие. Трактор арбасында, салам арасында бит әле ул... Оялмыйча...

Нурания, миһербансыз! Сиңа кызык! Ә бит Лена апа, гадәттәгечә, үз баласы кебек, аның өчен ут яна. Нураниянең уены-чыны бергә сүзенә катнашмыйча, икебез өчен дә укыйсы текстны караштыра башлыйм. Сәбәпсез гарәп теле дәресен калдырмый торган Илмира да кызганыч, телгә осталыгы хәттин ашкан, башкалар батасы судан да коры чыгарга өйрәнгән Нуранияне карап тору да кызык... Әмма шулай икәнлеген укытучыга да сиздерәсе килми.

Өченче дәрескә аска карап кына керәбез без. Утырабыз. Нурания юклыкның сәбәбен аңлатмаска, ялганламаска сүз бирәбез, үзенә калдырабыз.

– Кан алмаштырырга авылына китте, дип әйтергә кушкан иде дә инде... – ди миңа Илмира.

Әле без аның икенче атнага сызлавыкларын кистерергә, өченчесендә имеш, әлегә Мөслимдә генә булган УВЧга кайтачагын белмибез. Аннан... аннан уку елы бетәргә күп калмас, Нурания хәйләләренә генә чик юк...

Лена Кәлимулловна, узган атнада «салам җәйгән чаналы тракторда кайткан» Илмираны күреп өнсез тора. Озак вакыттан соң гына сайлап кына сүз башлый:

– Илмира, син акылсыз кыз түгел, егетләр янына кайту өчен дәрес калдыру килешми. Укуың да шуңа начарланып киткәндер дип уйлыйм.

Кызыйның башы җөпләп селкенә дә селкенә.

– Менә күрәсең, үзең дә килешеп утырасың. Синең белән бергә тора башлагач, Нурания дә үзгәребрәк китте.

Эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап алган Илмира аңсыз: селкенгән башын минем якка бора, Нуранияга дигән йодрыкны өстәл астыннан миңа күрсәтә.

Ә Нурания... гадәттәгечә, «фил яумир рәхәти»дә. Федосеевская урамының алма бакчасы эчендә утырган кызыл такталы өйдә йокы бүсә.

Хәер, гарәп теле дәресендә нибарысы өч кенә кеше булганга, үзебезне без дә рәхәт, иркен хис итәбез. Укытучы сораганны да көтмәстән, рәттән укыйбыз да укыйбыз. Аның әниләрчә йомшак күңеллелегенә, балаларча беркатлылыгына, ихласлыгына мөкиббән китеп, тәрбия сүзләрен тыңларга да өлгерәбез.

Менә ул сап-сары трикотаж костюмнан, җил-җил атлап, аудиториягә килеп керә. Дәфтәрләрен чыгара-чыгара, борчулары белән уртаклашып та ала:

– Ата-аналар комитетыннан килеш, өлгермәм дип, такси гына ялладым. Кайберәүләр өйдәгеләргә бик күп хәсрәт китерә. Инде сез андый булмасагыз гына ярар иде!

Алтын кысалы күзлеген ап-ак кульяулыгы белән бик яхшылап сөрткәннән соң, пыяла аша томанлымы-юкмы дип караганда, башларыбызны бераз түбәнрәк иябез. Әйтерсең, начарлыкта тотылганбыз да шуңа кыенсынабыз. Шул үткен караш бигрәк тә үзенә юнәлтелгән дип уйлаган Илмираның башы да, селкенүен әкренәйтә барып, яшел шакмаклы ситсы күлмәгенең беренче төймәсенә кадәр иелә.

– Лена апа, Сез бигрәк әйбәт инде! – ди Нурания, сүз саен өзеп-өзеп, хисләнеп, дәрес өчен махсус буялган бармакларын уйнаткалап.

Дәрес бетә. Без коридорга чыгабыз. Каршыма ук атылган Рафис сискәнеп китә:

– Ой, куркыттың, сине Лена апа дип торам. Охшасаң да охшарсың икән! Үзең күренмичә, тавышыңны ишетсәм дә, ул дип уйлап куям мин.

Сәерсенеп аңа карыйм. Сары төстәге кием, кыска чәчтән башка бернинди охшашлык та тапмыйм.

– Безгә гел тәрбия сүзе сөйлисең бит, аның кебек, – дип өсти дустым.

Ә бәлки, ул охшашлык бардыр да... Күңел юкка сары яктылык булып утырган мөгаллимәгә тартылмас.

– Икъра! – ди ул кайвакыт, бугаздан чыккан тавыш белән мине сискәндереп. – Укы!

Шушы кечкенә гәүдәгә чәчәкләр чыңлавын, җилләр пышылдавын, кояш җырын сыйдыра алам, гарәпнең ата казлардан гына ишетелә торган авазлары анда барлыкка ышанасы килми. Ишеткәндә дә кабул итә алмыйм. Кошлар белән ярышып җырлый алырлык апабыз образы белән күңелдә безгә һәр көн «Икъра!» дип әйтүче ханым кушылмый.

Мине ул еллар узган саен үзгәрмәгән тавышы белән сокландыруын дәвам итә. «Җидегән чишмә», «Әллүки», «Туган тел» – милли моңнарыбызның кайсын гына җырласа да, үзәктән күтәрелгән моң тышка – ирекккә омтылган кош шикелле, тәрәз пыялаларына кадәр зеңләтеп, үз җырына куша.

Лена апаның мең төсмерле тавышында укучыларына юлланган ярату да, үз балаларына дигән наз да, тормышка мәхәббәт тә, яшьлеген сагыну да, киләчәккә өмет тә бардыр шикелле. Ул тавышта шушы яңгыр сафлыгы да, канәферләрнең серле пышылдаулары да, синең еракта калган яшьлегебезгә чакырган тавышың да бар, җил!

– Кайттыңмы, җил?! Син остазымның хәлләрен белеп тә кайттыңмы? Китә калсаң, шушы төндә туган якты хисләрем турында җиткер аңа. Тәрәзеннән үтә алсаң, йокыдагы чәчләрен минем кулларым булып сыйпа. Йорт каршысында чәчәкләр үссә, аларны аның өстәленә сал.

Төнге юлчы шикелле, көзнекенә охшаган җил тәрәзәгә яңгыр бәрә... Яңгыр астындагы сиреньнәр, бәхеттән исергән шикелле, ап-ак кулъяулыклар болгый.

*1999*

## ЗӘҢГӘР АЛМА ДИМӘСКӘ

Аны, якасыннан өстерәп, безнең класска завуч Мәхмүт абый китереп ташлады. Кара кысалар эчендә кырысланып күренгән күзләрендә ачу иде. Әллә юри генә ачулы булырга тырышты микән? Әлбәттә, шулай. Шулай инде!!!

Өстәл каршындагы партага төртеп күрсәтте дә, башын иеп, күзлек өстеннән генә Раифка карап:

– Моннан соң урының шушында, башны катырма! – диде.

Хөкемен чыгарып ишеккә атлаганда, сары чәчле малай артыннан өер булып килгән алтынчылар куркып чигенгәндәй итсәләр дә, какча гәүдәле укытучы «Учительская»га кереп югалгач, тамаша карарга җыелган авыл хатыннарыдай, тагын алга таба ыргылдылар, әмма, чит сыйныф бусагасыннан узарга батырчылык итмичә, ишекнең тышкы ягында туктап калдылар.

Гәүдәгә шактый эре Расим, үзеннән алга җибәрмичә, өерне аркалары белән этеп тора иде. Ваграклар – аның култык астыннан, буйлыраклар җилкәсе өстеннән әле узган ел гына үзләре белән укып йөргән Раифка текәлгәннәр. Йөзләрендә ни кызгану, ни сөенү галәмәте юк. Барысының да эшнең нәрсә белән тәмамланасын көткәнлеген ялтыраган күзләре генә аңлата.

Ә Раифныкылар... зәп-зәңгәр икән ләбаса! Безнең авылда мондый күзләрне эзләп йөреп тапсаң гына... Елап шешенеп бетсәләр дә, аяз күк кебек зәп-зәңгәр алар! Зәңгәр алма дисәң, әллә ничегрәк шул... Ә нигә димәскә!

Раиф беркем утырмый торган партаның сул ягында «эленеп калган» һәм башын, бөгеп, сумкалар торучы шүрлек капкачының астына ук тыккан. Сыйныф бүлмәсенең иң кырый партасыннан миңа аның бөтен йөзе ап-ачык күренә. Ул сулык-сулык елый. Яшен дә сөртми, авызын да җыймый.

Мәхмүт абый парта өстенә ыргытып калдырган кыр сумкасының почмагыннан Раифның тышлары ашалып беткән китап-дәфтәрләре «борынлаган». Сәлимә апабыз, сумканы ача-ача, аннан:

– Ник бу сыйныфка кереп утырмадың? – дип сораша.

– Мин күчми калганымны белмәдем, ы-ы-ы...

Раиф инде бераз тынычланган, тик әле зәңгәр күзләрен генә күтәрергә базмый. Аңа бездән оят, кыендыр шикелле. Әле ул нинди яхшы сыйныфка эләккәнлеген белми.

Берәм-берәм кара букчадагы китапларны өстәл өстенә куйганда, Сәлимә апа, әллә китапларга, әллә Раифның сүзләренә гаҗәпләнеп:

– Барысы да бишләр өчен бит болар! – ди. – Күчтем дип уйлагач, нигә алтынчыга барырга әзерләнмәдең соң?

– Белми-и-им... – Ул ныграк та сулкылдарга керешә.

Коридордагыларның аның саен кычкырышырга, инде үзләренеке саналмаган Раифны һаман да үртәргә маташканнарын күреп, Сәлимә апа:

– Җитте сезгә кызык карау, барыгыз, дәресегезгә керегез! – дип, балаларның борыннарын кыстыра язып, ишекне ябып куюы була, кыңгырау да шылтырый.

Ни генә язсак та, ни генә укысак та, барыбызның уенда – Раиф. Кылт итеп, әле иртән генә әтиемнең, борчылып:

– Өстәмә дәресләр вакытында өйрәтеп төзәтәм дип кенә чыгарган икеле иде лә. Нигә кайтмады инде, нигә укырга теләмәде... –дип өзгәләнгәне искә төшә.

* * *

Җәен без әдәбият, татар теле укытучы әтием белән аларның өйләренә барган идек. Раиф авылда булып чыкмады. Казахстандагымы Фастин абыйларына киткән дә, җибәрмиләр, ишәк җиктерәләр, печән чаптыралар, имеш...

Аның кайтуы турында хәбәр минуты-сәгате белән бөтен авылга таралды. Берәүләр, Раиф кайтып килгәндә, күршесе Габи Фәрите капка төбендә утырган икән дә, аңа «Здравствуй, Фаритка, я – Ромка, татарский забыл», – дип әйткәнлеген сөйләсә, икенчеләр моны кире какты, «булмас, онытып ук бетермәгәндер», – дип баш чайкадылар, өченчеләр, «оныткандыр, казахлар татарча белми бит», дип килешкәндәй итте.

Шунысы хак: бөтен бала-чага хәзер Раифлардан ерак түгел генә, кибет турысында кайнаша. Кайчан урамга чыгар да ничегрәк сүз башлар дип көтәләр. Мин дә икенче көн Габи Фәридәсе белән генә уйныйм. Үзебез уйныйбыз, үзебезнең күз гел Раифлар капкасында.

Менә, ниһаять, төш турысына җитәрәк, аннан авызы колагына кадәр ерык Раиф күренде һәм туп-туры безгә таба юнәлде.

– Здравствуй! – диде бу иң башлап миңа, бик дөрес әйтергә тырышып, егетләрчә нык итеп уң кулын сузып. – Я – Ромка.

Әле яз көне генә Раиф иде бит. Нәрсә әйтәсең инде бу мактанчыкка? Әллә соң чынында да безнеңчәне оныткнмы? Татарча җавап бирсәң, аңламас йә үземне үк наданга санар. Татар авылында авыз күтәреп русча сөйләшү дә килешеп бетми. Хәзер әләктереп алырлар...

Менә чит җир нишләтә! Җәйгә генә югалып алды, тәмам урыс булып кайткан. Минем күрше урыс авылыннан кайтып кергән юк, ник бер татарча сүзне онытыйм?!

Алай да Раиф белән ничек сөйләшергә? Тегене сорыйбыз моннан, монысын – татарча аңламый гына бит. Юләр кеше кебек баш селкеп торуыннан тәмам туйгач, түзмәдем:

– Че ты там делал то? – дип русча гына эндәштем.

– Ни, ыс Шаштыйн (монысы инде Фастин абыйсының халыктагы исеме) печән таскал на ишак, – ди бу, башын кашыгандай итенеп һәм безне бөтенләй аптыраштта калдырып.

Юри генә кылануымы... урыс арасында яшәп, телләренә шактый күнеккән кебек тә күренә... Беркемнекенә охшамаган русчасын аңлау алай да җиңел түгел. Шулай ярым-йорты телдә аралаша торгач, татарчасы тәки исенә төште бит тегенең. Шартлатып сөйләшә үк башлады.

– Һи, Шаххый! – диде Фәридә, зәһәр хатыннар кебек кенә бөеренә таянып һәм тупаслыгы, зәп-зәңгәр күзле Раифны кушаматын ук бозып мыскыллавы аркасында минем дә ачуымны чыгарып. – Кыланып кына маташкансың икән лә!

* * *

Инде менә шул Раиф безнең классыбызда укый. Сөенергәме, көенергәме моңа? Уку турында онытып, үткән- нәремдә казынырга тотындым. Узган ел Яңа ел бәйрәменнән кайтканда, өрлек кадәрле ике әзмәвернең типкесеннән аралап алган идем мин аны. Шундый яхшы малайны югалтканнарына үкенсеннәр менә хәзер! Ә бездә йомшак күңеллеләр укый, аңа һич тә читен булмас.

Көне дә көн бит аның! Нәкъ бәйрәм өчен генә! Көз кояшы малайларның беренче сентябрьгә ялтыратылган такыр башларында бии. Раифның казах ташлыкларында саргайган керфекләре, көз кояшының нурларын күтәрә алмыйча, аска иелгәннәрдер шикелле. Ә зәңгәр күзләрен, алмаларын дип атарга сөйләштек ич, җылы як кояшы да саргайтмаган!

Раиф ел эчендә иң якын дустыбызга, ихлас бер иптәшкә әйләнде. Мин аның шулай булачагына шикләнмәгән идем дә. Раифның мәңге җыелмас авызы:

– Ярый күчмичә калганмын әле, ы-ы-ы... – ди еш кына, кырыйдагы тырпаеп үскән тешләрен күрсәтеп.

Алтынчы класска без тагын да олаеп, матурланып килдек. Инде кайберәүләр егетле исемен күтәрә. Малайлар гына... Аларга торган саен өстәнрәк карыйбыз. Ни буй, ни акыл үзләрендә. Күзләре генә безнең тарафка бик тә өметсез елтырый.

Раифныкылар турында гына ямьсез сүз әйтеп булмый. Аның зәңгәр алмалары элек тә кыл уртада тик кенә тора алмый иде, хәзер бигрәк тә арлы-бирле йөренәләр. Аңа килешә ул. Раифның күзләре нәп-нәкъ үзенә охшаган! Төнге дулкыннарда тирбәлгән зәп-зәңгәр ай да кебек. Юк, юк. Суга ыргытылган алмаларга!

Эреле-ваклы малайларның башкаларында да кешедә булмаган гадәтләр бар. Янымда утырган Мәгъфүр идәнгә басмый гына сыйныф буйлап йөрергә ярата. Ничек итеп як-ягындагы парталарга таянган учларында гәүдәсен алга таба чөя-чөя рәт арасыннан китеп барса, шулай ук кирегә дә килә. Кайвакыт тәнәфес буе очып йөри ул. Аның инде юантык бармакларында кайчандыр таянган саен яшь китереп авырттырган егерме дүрт сөяле юк, барысы да диярлек, ырымны белмичә санавым аркасында, минекеләргә күчеп беткән.

Әнә арткы партадагы Йосыф. Тап-такыр башы уртасында, үссә, чәчләрен икегә аерып җибәрер кебек ак юл. Фаизнең башында да шул юл бар. Капка түбәсеннән баш белән ташка сикереп ясаган юл ул...

Аларны күзәтүдән туеп, тәрәзә пыяласында сәяхәт иткән чебенгә карап утырам. Арт яклары бик очланган. Пошынмас Рафисның битенә егылып төшмәсме дип, каты гына өргән идем, ул гөл чәчәгенә килеп кунды да, борынын метер-метер китереп, Сәлимә апага текәлде.

...Яратам да инде Сәлимә апабызны! Шуның белән, моның белән утыр дип тинтерәтми. Маңгай чәчләренең санламавын белдереп, колак яфракларына асылындырып керә дә:

– Әйдә, ярар, кайсыгыз кем белән утыра? – дип, кызлар исемнәрен укырга керешә.

Ул арада мин аның үземнеке кебек кыска муенын, узган елдан безнең белән алтынчыга күчкән көрән сарафаны белән ак кофтасын, авазларны тырышып-тырышып чыгарган иреннәр хәрәкәтен тикшерәм. Вакыт-вакыт муен сеңерләре өзелер, «ы» белән «е»ләрнең әйтелешенә түзмәс шикелле.

Апаның текә күкрәкләре әкрен генә дулкынлана. Алар көрән сарафанны ертып чыгарлар да кош кебек алга ыргылырлар... Бу омтылышларның ни өчен икәнлеген беләм мин, беләм!.. Ул Рифә... исемен бик ягымлы атый. Сарафан күкрәкчәләренең текәлеге кими. Унбер малайның һәр кулы аерым-аерым түшәмгә таба сузыла.

Тишек борыннар! Беләләр алар кем белән утырасын! Кемнән күчерәсен!

Унбер баш арасыннан Сәлимә апа миңа идәнгә коелган бетергеч, ручкаларны алып биреп тору өчен Раифны сайлый. Безнең малайларның егетлеге бу гадәтләр дисәгез, хаталанырсыз. Мисал, мәсьәлә чишкәндә борчылуыбызны теләмиләр алар, булышкалап, ярдәмләшкәләп, үзләренекен дә чишеп биргәнне яхшатланып көтәләр.

Минем бу елда үз янына утыртылмасымны белгән Мәгъфүр парта эченә яшерелгән таба ярым көнбагышыннан бер чеметемен авызына ыргыта, икенче чеметемен тәнәфестә Раифка бирергә хәл итәме, башкагамы – кире сала. Ул, җай чыкса, бездән арттагы партага утырырга тырышачак. Кыска буем аша минем алдагы дәфтәрне күрү аңа берни тормый!

Мәгъфүр – юмарт малай. Контроль эшләрне күчертмәсәң дә, эшләп бирмәсәң дә сыйлый ул. Әтисенең чәчү орлыгыннан урлаган капчык ярым нигъмәттән ел дәвамында һәркемгә өлеш чыгарачак, әмма быел шуның күбесе Раифка эләгер шикелле, шулай да, югары оч кызларының усаллагын белгәнгә, аларга – талатып алдырырга, безгә ялындырып, әз-әзләтеп, елмаю кушып бирергә ярата.

Мәгъфүр үзе кебек иренчәк артын боргаландырып кына утырганда, гадәтенчә, «Һей!» дигән аваз чыгарырга да, шул вакыт ирен кырыйларына орлык тәменнән чыккан юешлек, ике яктан агып чыгарга да өлгерми, көнбагыш тутырылган «хезмәт даны», чалбар каешына эләгепме, нигъмәтен тирә-якка сибеп, идәнгә шуып төшә.

Иң алгы партада – Раиф янәшәсендә утырам. Ул, миңа елышыбрак, колагыма:

– Шәп, малай! Мин сине озын тәнәфестә коймак белән сыйлармын, әни абыйларга әйтмичә генә кайтып килергә кушты... – дип пышылдый.

Безнең класста һәр малайның үз сые. Рәшит мине дүртенчедә чакта берничә ай әчтерхан чикләвеге, мармелад белән «кунак итте». Мәгъфүрнең кесәсе бервакытта да көнбагыштан бушамый, дидем инде. Көз көне Мөхлисуллалар Бөртәк алмасын күп урлый. Ә менә Раифтагы ризык башкаларда бөтенләй юк! Ел буе коймак ашатырмын, дип кенә тора бит үзе дә. Ул вәгъдәсендә тора белгәнгә охшаган. Ун балага да җиткереп булмагач, әниләре тәм-томны өстәлгә әбәт вакытында, тегеләр мәктәптә чакта гына куя икән. Кем кайта, шуңа гына эләгә, имеш, коймак та. Раифның аяклары кызу. Минем өчен һич иренмәячәге хәзер үк күренә.

* * *

Быел, көн саен ук булмаса да, атнага бер мәртәбә Миңсылу апа коймаклары белән сыйланырга гадәтләндем. Хәерлегә генә булмаган икән. Малае дәрескә әзерләнмәгән, шаяргалаган өчен, күп тә үтми, аны мәктәпкә чакырдылар. Сыйныф җитәкчебез укыткан урыс теле дәресенә килде ул.

Миңсылу апа, әби чәчле дип аталган көмеш төсендәге затлы шәлен кызыл йон кофтасы өстеннән иңнәренә салып, өченче рәттә буш калган партага барып утырды.

– Менә шундый-шундый хәлләр. Раиф һич кенә дә укып килми, нишләргә дә белгән юк! – диде Сәлимә апа, әни кешегә катырак күренергә тырышып.

– Булма-а-ас, Сәлимә, ышанмы-ы-йм. Минем малайдан да акыллы кеше юк. Урысча чартлата гына бит ул!

Раифның әнисе үзеннән дә көләчрәк. Тут йөзендәге сипкелләре аны гел елмаеп торгандай күрсәтә. Шуның өстенә сөйләве дә җырлау кебек кенә, улын үлеп яратканы әллә каян аңлашыла.

– Әйдәле-е-е, улым, чык әле-е-е... Нәрсә укып килгәнеңне күрсә-әт...

Минем кот ботка төште. Бетте Раиф. Өй түрләрендәге матчага эленгән солдат каешы белән бүген кич шәпләп каезлыйлар моны. Ул гына башын тота алмаган үрдәк бәбкәсемени... Авызы – колагында!

– Нәнәү, хәзер, нәнәү... – диештергәләп такта янына чыгып басуы булды, дөбер-шатыр сөйләргә дә тотынды. Чәт-чәт килгән авыз, болганган куллар дисеңме... һәм үзе уйлап чыгарган өр-яңа повесть. «Дубровскиең» бер якта торсын! Пистолеттан да аталар монда, пулеметтан да, кызлар да сөяләр. Миңсылу апаның йөзендәге горурлыкка чут юк. Сәлимә апаның күзендә – яшь. Без – телсез.

Әни кеше, укытучының югалып калуыннан файдаланып, дәресне үз кулына ала, урыныннан күтәрелеп, рәт араларыннан Раифка таба килә. Инде йомгакны да ул гына ясый:

– Болай урысча яхшы сөйләүче ысысысырда юк әле ул!

Раиф, башын игән килеш кенә, шәп иттемме дигәндәй, безгә каш сикертә, рәтләрнең төрлесенә таба күз елтырата. Әнисе җиңүче кыяфәтендә һәм, малаеның иң яхшы укучы икәнлегенә ышанып, өенә кайтып китә.

Раиф шуннан соң да укыса укый, укымаса юк. Безнең моңа ис китми. Аның белән яшәү кызык. Дәрес вакытындагы эшсезлектән туеп арысам, гел Раиф коткара мине.

– Бармагың белән партаны кырдырт әле, эч поша, бигрәк күңелсез укыталар инде, гел бер сүзне чәйниләр дә чәйниләр... – дим мин аңа кайвакыт, башкаларның җиңел генә теманы да авырлык белән аңлауларыннан туеп.

Раиф, мәсьәлә эшләгән чагы булса, киреләнебрәк тә куя:

– Куып чыгаралар бит аннары...

– Кырсаң да чыгаралар инде сине, кырмасаң да! Син тәртипле булырга яратылмаган! Менә отличникларга шыгырдатырга ярамый. Шыгырдат инде, Раиф, күңелсез бит...

Кемгә-кемгә, ул миңа каршы тора алмый. География дәресләрендә болай шаяру бигрәк тә кызык. Галимулла абый үзе бездән дә шаян ул! Аның Раиф кебекләрне тәртипкә кертә торган, үзе әйтмешли, женьшень таягы бар. Кайда яшерелгәнен, кайдан чыкканын да күрмисең, сине иң кычыткан җиреңнән шунда ук яратып тешләп тә ала. Сыйныфта аның тәмен белмәгән малай юк. Шуңа яратам да мин Галимулла абыйны. Тәртипкә кертсә, аларны ул гына тәртипкә кертә!

Раиф, учларын язып, бармакларын парта буйлап йөгертә – тешкә тия торган тавышлар чыгарып шыгырдата гына башлый, Галимулла абый тактага язган җиреннән ялт кына борыла да, күрсәткеч таягын күреп калмаслык тизлектә җиң эченнән чыгарып, башына эләктереп тә ала.

– Әнә бит янында менә дигән кыз утыра. Ичмасам, шуннан үрнәк алыр идең.

Раиф, әллә миңа ничек ошарга дип, әллә таякның тылсымын тикшереп, башын кашырга тотына. Ул, аны үзен эләктереп алып коридорга ыргыткач та, озак кашыячак...

*** * ***

Мәктәбебез сигезьеллык кына булгач, тормышка иртәрәк тә өлгерәсең икән. Без – сигезенчеләр. Укытучылар фикеребез белән санлашалар, олылар итеп карыйлар.

Чыгарылыш имтиханнары бирәбез. Бүген – алгебра белән геометриядән. Минеке тапшырылган, мәктәпнең Гайфетдин абыйлар ягына корылган койма киртәсе буенда башкаларны көтәм. Минутлар сәгать кебек тоела. Ашханә эшләсә, шунда чәй эчеп юаныр идең, җәй шул, эшләми.

Әнә Раиф та күренде. Әле яхшы укучылар да чыкмаган дип аптырыйм. Кулында – алты-җиде сантиметр озынлыгындагы сынык линейка.

Мәхмүт абый, сорауларга юньләп җавап ала алмагач:

– Ичмасам, билгеңне эшләп ал, – дип, мәктәп яшелчә бакчасының мәйданын үлчәргә чыгарып җибәргән. Хезмәт кадерен белсенгә, юри кечкенә линейка биргән икән. Алар, ахирием Гөлфия белән бергәләп, шунда таба киттеләр. Салган линейка санында гына буталмас та буталуын, шыттыра торган гадәте бар. Бездә малайларга болай да бик ышанмыйлар. Бәдрәфтә озаграк торсалар да, нинди йомыш үтәгәннәрен контрольгә алырга дип, берәрсен артларыннан чыгарып җибәрәләр. Хезмәт дәресләрендә, агачтан әйберләр ясаганда да, бер малай янына, эшләргә өйрәтсен дип, аермачык кулга оста кызны куялар. Алар – «егет», алар – мировой, әллә шуңа күрә безнең авылда кызларга да «малай» дип эндәшәләр микән?!

Көзләрен бәрәңгегә чыгарсалар, без чүплибез, егетләр, чалбар балакларын пычрата-пычрата, маңгай тирләрен агыза-агыза, абына-сөртенә көч-хәл белән чиләкләрне трактор арбасына ташый. Безнең кызларга җитешеп кара! Хи, аларга түгел, безнең авылның теләсә кайсы хатын-кызы белән ярышмакчы булып маташ! Барыбер барып чыкмаячак.

Медпунктка барганда, алдамасыннар дип, өйләрендә калган әйбергә кайтарып җибәрелгәндә, качып китмәсеннәр өчен, малайларны һәрвакыт диярлек кызлар озата бара. Алар болай да яхшы белә, дәресләре калудан куркасы юк. Эксперимент рәвешендә үзләрен дә җибәргәлиләр җибәрүен. Берсенең дә юньле тәмамланганы гына юк. Әле бишенчедә укыганда, аклы-күкле булып, фельдшер яныннан Раифның кайтып кергәне хәтердә. Хәле соңгы чиккәчә беткәндәй, партага авып кына төште дә, кулларыма ябышып, аһылдарга тотынды:

– Рифә, үләрмендер, ахрысы, Валя апа да шаккатты, ничек чыдыйсың моның кадәр температурага, ди. Итек кунычына ышкыган идем, градусник 51не күрсәтә! Үләм, тучны үләм, малай...

Башка тиз барып җитә минем, кычкырып көлдем генә:

– Тор давай, үлмисең! 51 градуслы термометрны кайда күргәнең бар?

– Ник, 42 генә иде микәнни?– дип сорый бу миннән, әле кызгануыма өметләнеп һәм итек кунычына ышкыганын әйтеп ташлаганын онытып. – Анысы тучны үз температурам инде, авыртам бит мин.

...Аннан соң узган егерме ике ел эчендә юлым Раифныкы белән нибарысы бер мәртәбә кисеште. Автобусыбыз ватылып, поездга чапкан чак. Нindидер кызыл машина, Кукмара автозаправкасыннан чыгып, артымнан куып җитте дә, ишеге ачылып китеп, аннан бер адәмнең елтыр башы күренде:

– Утыр, кызый!

Кысылып, тыгызланып, тәмәке исе аңкып торган машина эченә утыргач:

– Без Пүләнкәгә барабыз, әйдә безнең белән, – дип, янымдагылар теленә салына башлады.

Көзгегә карыйм. Шофер йөзендә ниндидер таныш чалымнар. Раиф бит бу!

– Раиф, син мине тимер юл вокзалына гына илт инде, соңга калам, – дип, сүзенә каршы төшкәч, аның көзгедән олыгаеп күренгән елмаюлы йөзе әллә нишләп китте.

– Син икәнне танымадым да, үпкәләмә инде, Рифә, без хәзер, – диде ул кыенсынган, оялган тавыш белән.

Юк, бу мин белгән, Шаһи кушаматы йөрткән малай түгел инде. Хәер, ул кушамат белән бер генә тапкыр да эндәшмәдем ич мин аңа. Үзе кебек, Ромка дияргә дә телем бармады. Керсез карап торган зәңгәр күзле малайга Раиф кына дип эндәшә ала идем. Һәм ул минем күңелемдә әнә шулай яшәде дә. Әнисенең үзе турында каяндыр уйлап тапкан хикәятләре, хыяллары белән үрелеп яшәде. Аның чалымнарын тупаслаткан, үзен олыгайткан елларга үпкәләми кемгә үпкәлисең...

Ә бит көзге аша булса да мин аның зәңгәр күзләренә текәлеп карамаганмын. Гомер кояшы аларның төсен үзгәртмәде микән? Олы юлларның тузаны кунмаганмы? Саф сулар, чиста күзләр тиз генә болганамыни ди... Зәңгәр алмалары... Юк инде, күңелне иләсләндереп, башка алай димәскә...

*2000*

## ӘБИЕГЕЗ

Юлларда йөргәндә, йоклый алмый ятканда, мин мәңге эштән бушамаган әнием турында уйлыйм. Аның кер юган, мал караган, дәфтәр тикшергән, балалар иркәләгән җыерчыклы кулларын кызганып, чал чәчләре өчен хәсрәтләнеп, җылы сүз көтеп яшәгән күңеле хакында уйлыйм. Инде әби булган әни турында уй керсә, әбиләрем дә хәтердә терелә.

Нәни чакта шаулап уеннан кайтып кергәнебездә, баскыч төбендә аяк киемнәрен каккалап утырган бабам:

– Чү, әбиегез ял итә, тавышланасы булмагыз, – дип, хәтта тышта сөйләшүдән тыя торган иде. Ул әнә шулай, йөрәге хәлсезләнеп киткәч, кече өйдә ятып торган әбине урам шау-шуыннан да саклап, сәгатьләр буена ишегалдында йөренә йә, тын гына белгән догаларын укып, үзе дә ишек янында хәл ала.

Беребезгә – өч, икенчебезгә дүрт тулган ике бала, тын алырга да куркып, әкрен генә, аяк очларында яңа өйгә кереп шылабыз. Әле анда да тыныч кына китап караштырып караватта утыру инде. Ә бит ул арадан хет акыр, хет үкер – әби барыбер ишетми! Ә кем белә? Инеш буенда ни кылганнарыбыздан да сәгате-минуты белән хәбәрдар әби бит ул! Һәм шул әби дигәнебезгә нибары илле тирәсе...

Ул – инде намазга утырган, яулыгын өлкәннәр күк бәйләгән, мут көлеп кенә самавыр янында утырган карчык. Утыны-суы кертелгән, малы каралган, идәне юылган. Бабакай, кыз-ул, оныклар эшләгән боларны. Дөрес, әби үзе дә тик тормый. Ашына бара, изге китаплар укый һәм, бушады исә, йорт эшләренә керешә. Хаҗәт түгел, гадәт.

Менә без өстәл янына килеп утырабыз. Иң тәмле, иң эре җиләк – бабай алдында, иң кыйммәтле көмеш калак – аның кулында.

Алдында – ап-ак тастымал, үзе урындыкларга күпертеп салынган мендәрчек өстендә.

Бабай дигәнебез селтәнеп-селтәнеп печән чаба, кычкыра-кычкыра азан әйтә, кич буена дога укуда. Инде ул безгә бик олыдыр кебек, аннан да озаграк яшәү шаккаткыч тоела. Без аны ни дәрәҗәдә яратсак, аннан шулкадәр куркабыз да.

– Әбиегез... – ди бабай, күзе белән генә ымлап.

– Бабагыз... – ди әби, иренен бөрештереп.

Аллага шөкер, әнә шул «әбиегез», «бабагыз»ны без бик озак ишеттек. Кечкенә генә җемелдәвек әбием. Озынның озыны, елтыр күзле, колакка чак кына катырак, шаян сүзле бабам. Әмма ул әби хәл алганда һәрвакыт җитди, аз гына кыштырдауны да ишетеп ала һәм шаярганны һич кенә дә өнәп бетерми.

Ә башка чакта чиктән тыш җитди әби бергәләшеп артык шаяруыбыздан хәлсезләнә торган иде. Кайвакыт, ялынып:

– Кызым, бабаң син кайткач бигрәкләр аза. Артык көлмә инде,чиген белми шаяра. Нәрсәгә инде аңа әллә кайдагы Брежнев, Горбачевлар? Намаз карты бит, оят, дога карты, – ди торган иде.

– И карчы-ык, – ди бабам. – «Бет» урамында үскәч, дәү политикадан ерак шул син, политический неграмотный дип әйтергә кирәк. Мин Кремль марҗалары белән гөрләшеп, алар китергән кәнфитләрне ялап, Брежневка тирләгән аркамны шадра сөлге белән сөртгереп утырганда, син сыер савасың. Сөйлим, син дә ишет, күр, бел картыңның патшалар белән генә аралашып көн иткәнен. Урамың да өч йортлы, бет сыярлык кына, үзең дә бәләкәй...

Менә китә үртәшү! Берзаман бабай туктый, чигенә.

– Үпкәләмә, карчык, шул бәләкәйлегең өчен сөйдем бит инде сине, кулларымда гына күтәреп йөрттем. Башка беркемгә алмаштырмый торганым бит син минем.

Әби яулык очы белән иреннәрен яшерә:

– И-и-и, балалар каршында шул сүзне сөйләмәсәң! Гел бер балык башын чәйнәмиләр инде. Оят бит, картаеп беткәч. Шул шаярганнарың өчен яшь чагында картлар мәчет астына япканнар дигән ие аны...

– Ие, карчык, яптылар, шунда да җырлап яттым бит мин! Тәки чыгардылар аннары.

– Вәт имансыз...

– Менә дөрес әйтәсең! Син бит мине денле, юньле иттең. Ул җырулар онытылган инде. Аның каравы миндә син бар!

Әкрен генә кет-кет көлгән була әби. Без дә, чынаяк тәлинкәсенә иелгән булып, аска карап көлешәбез. Сиздерергә ярамый – бу сүзләр безнең өчен түгел.

– Әбиегезнең сүзен тыңлагыз, – ди бабай, өстәл янынннан кузгалганда. – Карчык, үзең йөрмә, балаларга куш, аякларың бетә ату.

Әбинең эше күрер күзгә күренмәсә дә бик вак: ул гел бакчада җиләк-җимеш, яшелчә тирәсендә маташа. Бу – аның патшалыгы, монда рөхсәтсез керергә, таптарга, өзәргә ярамый. Монда – тәртип. Шуңа күрә уңышы да мулдан. Ул нигъмәт һәр утырганда өстәлдә булачак.

Әбигә түтәл араларында бик рәхәт. Ул бакча башында җилкенә-җилкенә печән чапкан, аннары аны кабарткан бабабызны да күреп тора. Аңа тиз генә, сусынын бассын дип, салкын су да менгереп төшә. Монда киртәләр дә юк: күрше белән гәпләшәсең, иген кырларын күреп хозурланасың. Кай көннәрдә, бабай белән безнең урманнан кайтуыбызны көтеп, абзар ишегенә сөялгән була ул. Бәлки, көтеп, бәлки, эштән арып.

– Әбиегез... – ди бабай. – Сез рәхәтләнеп урманда йөреп кайттыгыз. Инде әбиегез ял итсен. Бар, чәй куеп, өстәл әзерләгез.

«Ял итүчеләр»нең аркасы кинәнеп печән чабудан, «уфалла» тартудан кара тир генә, күз-башлары акайган. Бабайга каршы сүз әйтергә батырчылык итмибез, чалгы-сәнәкләрне абзар артына терибез дә өйгә юнәләбез.

Хәер, ул табын инде күптән әзердер. Самавыр җырлап торадыр. Тышта гына юынабыз. Аяк тирәсендә мәче бутала. Тавыклар кытаклаганы ишетелә. Чыннан да, дөнья бөтенлегеннән күңелдә бер рәхәтлек.

Сәгать уникене сугып яткан чак. Әби бездән алда өйгә кереп өлгергән. Өстәл янында утыра.

– Бабагызны көтик, – ди, елмаеп. – Ул арыгандыр... көне буе урманда, сахрада ял итеп йөргән яшь кешеләргә аннан алда чәй эчү яхшы булмас.

*1999*

## ЯЗГЫ ТАШУ

Дусларым да, көндәшләрем дә гел малайлар минем. Егерме малай арасында берүзем уйнаганда да, берсе дә рәнҗетергә батырчылык итми. Алар белән ярышу түгел, җиңү генә мәртәбә булганга, гел ярышлы уеннар оештырырга тырышам.

«Буй җитмәслек»кә дә үрелә торганнар була икән. Шулай боз аккан бер көн. Язның иң тәүге уены «Бүрек урлашлы»ны уйнап арыгач, без түгәрәккә җыелдык. Чират «Каешлы»га җитте. Туганнарымның туганы, икенчедә укып, «егет» кисәге булып йөргән бер малай (миңа әле алты гына яшь) йөгерергә алынды. Дер калтырап, кайсыбызга суга инде бу дип көткәндә, түгәрәк тулы кызларга иреннәрен чупылдатып әйләнгән булды да, минем турга җиткәч, битемнән суырып үбеп, урам башына йөгерде.

Мин беттем. Бу – укытучы кызын сугышка чакыру белән бер иде. Акырып елап җибәргәндә, башка беренче килгән уй үч алу уе булды. Җыен вак-төякнең, бала-чаганың бертуктаусыз юатуына да карамыйча, үзем елыйм, үзем эчемнән генә план корам.

Мин аңа, әнигә әйтеп, иртәгә үк икеле куйдыртам!

Әйтүен әйттем дә бит, әнидә әле тагын ике елдан гына укыйсы.

Ул да кире борылган, елый да, җиңелә дә белми торган күзләремне кызганган сыман, нәүмизләнеп бер читтә басып тора.

– Әнигә әйтәм мин синең үпкәнеңне!

Эндәшми. Беләм, курка ул. Бу уй миңа тагын да гайрәт өсти. Торган саен ныграк калай әтәчләнәм. Изелгән горурлыкны болай гына җиңеп булмый. Үчнең куркытудан башкасын уйлап табарга кирәк. Әһә!

– Моннан ары син минем сакчым булырга, миңа хезмәт итеп, гаебеңне юарга тиеш! – дим.

Рәфкать этнеке кебек ышанычлы күзләрен миңа төби. Башымны югары күтәрәм дә минем белән горурланган карашлар астында урамга юнәләм.

Икенче көнне мин болынга бик матур башлык киеп төштем. Кызлар, кызыгып, аһ, сәдәфе дә сәдәфе, диләр. Яшьтәшләремнең сәдәфен тотып карарга йөрәге җитмәсә дә, миннән шактый олы күрше

малае башлыгымны җәлт кенә эләктереп ала да уртак «Уен базары»на ыргыта. Мин кымшанырга да уйламыйм:

– Рәфкать!

Бичара мәгъшук гарәп җитезлеге белән килеп тә җитә, зәңгәр сәдәфле башлыгымны кулларыма да тоттыра.

Ә мин, сипкеле дә чыгып өлгермәгән кызый, рәхмәт әйтәсе урынга:

– Әле син мине үпкән иең дә... – дим. Үзем, борынымны чөеп, җиңелгән малай янына барып басам.

Еллар уза. Без дә зураябыз. Уртак вакыйгалар да арта. Әмма мин аны күрергә теләмим, мин аны белергә теләмим.

Шулай да шактый еш очрашкалыйбыз.

Менә мин клубта. Сеңлесе: «Абый, мин чыкканчы конфет суыра торсын, диде», – дип, учымны тутырып, конфетлар сала. Әйтерсең, ул клубта көнне без бергә утырабыз...

Кайчакта батыраеп озатмакчы да була Рәфкать. Мин, күзләремне йон башлыгымның теге зәңгәр төймәсе кадәр ачып:

– Син? Мине? Ничек курыкмыйсың?– дим дә... боегуын күреп, күңелем нечкәрә, йомшаграк кына: – Күрәсеңме, әнием капка төбендә, башка клубка да чыга алмам, – дип өстим. Үзем, ике уйларга да бирмичә, капкага йөгерәм.

...Инде мин дә җиткән кыз. Яраткан егетем дә бар. Мәктәптә балалар укытып йөрим. Тиздән укып бетереп кайтасы. Инде Рәфкать белән сөйләшеп торырга да кыенсынмыйм... Аннан гына берни дә үзгәрмәячәген беләм. Әни белән үзеннән-үзе куркытыла.

Клубта биегәндә, урындыкның кешенеке икәнлеген белдертеп, перчаткаларымны калдырып киткән идем. Рәфкать килеп алган. Шаяртып кына, әнинекеләр ич алар, дигән идем, яшен тизлеге белән кулларыма кире тоттырды.

Ул мине бары тик күршеләр турысына кадәр генә озатып төшә. Тор, кал, дияргә батырчылык итмәгәне аска караган күзләреннән, оешкан карны ваткан булып азапланган аякларыннан күренә.

– Рифә, син болын вакыйгасын хәтерлисеңме? – ди ул. – Ә мин онытткан идем. Сөйләделәр дә, ышанырга да, ышанмаска да белмәдем.

Миңа бик авыр булып китә. Ул онытткан, ул онытткан! Бу авылда, балачакта гына булса да, укытучы кызы булуымнан курыкмый, мине үбәргә җөрьәт иткән бердәнбер егет онытткан!

Рәфкать калтыраган кулларымнан тота: шулай булса, мин бик бәхетле, ди. Кирәкмәгән сүзләр сөйли башлый.

Мин аны вәгъдәләр биреп сөендермим. Арада инде болай да безне ерагайтып торган елларның җиде генә дә булмавын онытткандай, кимендә тагын җиде ел укыйм, дип алдыйм. Фәрештәләр, әйтерсең, «амин» дип тора. Мин менә һаман да укыйм... Язын Бөр ташый да ташый. Аннан, кисеп аккан болыннарына безне алмаштырып туган яшьләрнең төшмәвеннән моңсулапмы, бөрешеп, кибеп кала. Уенлыклы балачакны еракта күкселләнгән урманнарга алып китә Бөр.

Ул урманнарда мине сөйгән, мине хөрмәт иткән, үз гомерендә бер генә тапкыр сузылган кул аралыгыннан якынрак килергә җөрьәт иткән авыл малае юктыр инде. Ул киң Каманың дулкынлы күкрәкләрендә көймә эчләрендә тирбәләдер. Кызганып, балачакта кармактан ычкындырган балык балаларының ерак оныкларын тотадыр. Башлыкларның әллә ниндиләрен күргәндер, ә минем башлыктагы күз кебек төймәлесен генә очратмагандыр.

Дәрестә мәктәп тирәли чаңгыда әйләнгән кызлар арасыннан мине эзләп, йорт түбәсендә дә утырмыйдыр. Кесәсе тулы конфетлар булса да, арасында миңа дигәне – иң-иң тәмлесе юктыр.

...Ә бит без аның белән яшьлектә тагын очрашабыз. Тагын сөйләшәбез. Ул – мине, мин – башканы яратуым хакында. Мин сөйлим. Мин сыныйм. Ул йортыбызга кадәр озатып кайтырга әле дә базмый. Соңгы утлы багана төбендә хушлашабыз. Әллә ут яктысында, әллә хушлашудан аның да иреннәре дерелди. Китәр алдыннан:

– Мин сине егетләр, барыбер сөйләшмәс, дисә дә, озаттым,– ди. – Күрәсеңме, сиңа пардан ак бүрек киеп озаттым.

Мин китәм. Ак бүрегенә борылам да карыйм, борылам да карыйм. Мин Арчага, сүзләремдә тора аласыма ышанмасам да, аны яңадан бер тапкыр да күрмәскә үз-үземә вәгъдә биреп китәм. Икенче бер егет мине кып-кызыл чәчәкләр тотып каршылый.

...Әйтелгән сүз дә нибары сүз шул. Аның күңелдәгесе, тирәндәгесе һәрвакыт төрле мәгънәдәрәк, телдән төшкәндә аңлашылганыннан киңрәк була.

Без аның беренче сөюе белән хушлашу өчен очрашканбыз. Мин шулай дим. Ялгышсам да, кичерәсен, онытмасын белгәнгә, шулай дим. Күземә балачагымның коелып бетмәгән яшьләре тула. Бу яшьләр «укытучы кызы» яшьләре түгел инде... Болар – күңел ярларын мин көтмәгәндә килеп ера торган ташу.

*1988*

## КҮҢЕЛ КҮГЕНДӘ ЙОЛДЫЗЛАР

Кап-кара күк йөзенә, бихисап чәчелгән йолдызларга карап тын калганмын. Серле, шомлы һәм бер үк вакытта үтә тыныч та. Меңләгән хисләрнең кайсына бирелергә белми торган бер мәл. Карашымны, әлеге йолдызлардан сурәтләр ясый-ясый, түбәнрәк төшерәм. Серле очкыннар офык тирәсенә шәфәкъ төсмерләре бирә. Нәрсә бу? Авыл яшьләре учак яккан икән.

Хатыйп абый үтә салкын, хатын-кызларныкыдай нәфис куллары белән сак кына минекенә кагыла:

– Ишетәсеңме? – ди ул.

Ишетмәскә соң. Тук, тук... Тук, тук... Кайдадыр атлар чабыша.

– Атлар чабыша, ахрысы...

Чабышса ни, дип уйлыйм эчемнән кирле-мырлы гына, ә үзем ишетелгән тавышларга тагын да сихерләнеп китәм. Йолдызлы күк. Үрләгән ялкыннар. Тояклар биюе...

Әкрен-әкрен генә әлеге серлелек төн пәрдәсе белән бергә эреп юкка чыга. Без дә киртәләр өстеннән кузгалабыз.

– Соңдыр инде, керергә кирәк...

Соң дип! Иртәдер инде! Таң якынлашадыр. Учак тирәсендәге яшьләрнең тавышы көчәйгәннән-көчәя. Алар, безнең кебек, җылы юрганнар астына чумып тормастыр, кайсының – кырга, кайсының колхоз сыерлары янына барасы бар. Ә без студентларны... тәмле йокы, иртән – татлы ризык, көндезен җыр-моң көтә.

Мин аңа карамый гына хушлашам. Тагын нәзек куллары белән кулларымны тотардыр да сәерсендерер шикелле. Баса башлаган йокы халәтеннән аерыласы килми...

– Мин, сине эзләп, ничә мәртәбә мунчага чыктым, – ди каршыга баскычлардан төшеп килгән Әлфия.

– Менә юләр! Мине нигә мунчадан эзләргә! Капка да юк ләбаса! Без утырган киртә өемен ишегалдыннан күрмәслекмени?! Ай яктысында су юлы кебек сузылып ята!

Тәрәзә аркылы баянчыбызның ярык тузаннарын коярлык итеп гырлаганы ишетелә. Ул тимер раскладушкасында төшләр күреп йоклый булыр. Юк ла, кызлар күреп...

Әллә кермәскә микән? Артыма борылып карыйм. Мөгаллим күренми. Ул басып калган җирдә булачак капканың баганалары ялгызлары гына тырпаешканнар. Алар озын какча гәүдәле мөгаллимне хәтерләтәләр.

Хатыйп абый инде, егетләрчә җил-җил генә атлап, авылның аргы башына бара торгандыр. Костюмнан гына китте. Төшә башлаган томан җилкәләренә таң салкыны кундыргандыр. Күзлек пыялалары парлангандыр. Әле буа аркылы да чыгасы бар. Анда зират... Каберлекләре буага ишелеп төшкәнлектән, мәетләр су буйлап таралган, диләр. Мөгаллим курыкмас микән? Ул мине озатып куйды югыйсә, ә мин аның берүзен генә җибәргәнмен.

Йокы да тәмам качты. Сөйләшеп утырырга иде әле. Мин, кире, тыңламаган булдым.

Ну, Гена! Болай ук гырламасаң! Синең борын көйләрең Хатыйп абзыйга кадәр ишетелә торгандыр. Әле генә бергә ашап кайткан Сания апа бәлеше шулай сикертә сине!

Хатыйп абый гына, мескен, сүзгә бирелеп, юньләп ашый да алмады. Озын бармакларын әйләндерә-болгандыра сөйләде дә сөйләде...

Еллар узгач, карале, Хатыйп абыебыз безнең белән теге чакларда, экспедиция вакытында, концертлардан соң уза торган мәҗлесләрдә генә тамадага әйләнгән бит ул, дип уйлыйм. Хәзер инде нотыклар саллырак. Куллар да бераз гына булса да элеккеге буталышуларын киметкәндер...

И-и-и, бу гомер дигәнең... Себер сулары кебек тын гына аксачы. Ә бит Хатыйп абыебыз, бер карасаң, әллә ни олыгаймады да. Безне, укучыларын, хезмәттәшләрен аптыраштa калдырып, сокландырып, һаман да яшь күңел белән яши бирә. Матур сүзне, җылы сүзне кешеләрдән кызганмый.

Әй лә, аның мине үпкәләткән чаклары да юк түгел. Мәңге эндәшмәслек хәлгә килгәнемдә күзләремне йомам да ул миңа җиләк җыеп ашаткан тау буйларын күз алдына китерәм. Аның, безне үзе кебек озын, арык, тап-тар каекка утыртып, мыш-мыш килеп, каршы аккан тау елгасы буйлап чакрымнар буе каек эткәннәрен күз алдына китерәм. Ә бит без дә аны шаярткан. Мөгаллим булса да, гөнаһсыз шуклыклар икәнлеген аңлагангамы, кичергән, безне шулар аркылы да аңлаган, яраткан димен.

Хәер, ничек кенә шаярткaнбыз әле! Әкиятләр, көйләр язып йөргән Пермь, Свердлау яклары зур әдәби әсәр сорый. Аның өчен вакытлар гына вәгъдә итми. Күңелдә сакланган истәлекләр кәгазьгә, әлбәттә, шаян тел белән генә төшерелә ала. Һәм инде, һич югы, хикәя язган очракта да анда мөгаллимнең үз исеме булмастыр. Кеше шаяруны, әдәби күпертүне һәм, һич югы, чынбарлыкны син теләгәнчә аңласа икән! Ул чагында бу каләм ниләр генә сөйләмәс! Әлегә хәтта ки мөгаллим үзе дә үпкәләмәгәе дип куркыта...

Менә бит... күренекле әдәбият галиме, күпләрнең остазы булган Хатыйп Миңнегуловка да алтмыш яшь тулган. Вакытлы матбугатта аның хакында, ул эшләгән эшләрне санап, теркәп, аны мактап

күләмле мәкаләләр күренер. Мөгаллим боларга лаек, әмма мин аны эшләгән эшләре өчен түгел, укытучы буларак, дус-иптәш буларак, безне җитәкләп йөргән эти буларак күз алдыбызга бастырыр идем. Гомер булса, кеше яза торганнарга охшашларын да язарга өлгерербез.

Хатыйп Йосыфович иң яхшы мөнәсәбәт күрсәткән таифә – әлбәттә, студентлар. Ул алар өчен кайгыра, аларны эчке бер җылылык белән сөя, үз балалары шикелле тоеп, яшьләр белән әңгәмәләр кора. Һәм син аның янында эшли башлыйсың. Һаман да элеккеге «әтине» эзлисең, тик... тапмыйсың. Миңа әнә шул мөгаллим Хатыйп абый җитенкерәми. Әгәр аны сагынсам, күзләремне йомам...

– Рифә... – ди ул йомшак кына тавыш белән. – Ләисләр группасы матур, име.

Карале, матур шул. Егетләре дә, кызлары да озын буйлылар. Араларында әллә ничә шагыйрь, җырчы. Берсеннән-берсе кызыклар, сәерләр, күңеллеләр.

– Шулай булмаска. Аны Мөхәммәт абыең белән без җыйдык бит, – ди ул бераздан. – Аның да, минем дә зәвык яхшы инде!

Мактанчык! Әйем лә, зәвыгы начар түгелдер шул...

– Кешенең тышкы кыяфәтендәге матурлык аның эшләренә бәреп чыга.

– Һе...

– Менә ал син Зөлфияне!

Ал дип... Алам!

– Үзе чибәр, үзе акыллы, бер елмаюы гына да ни тора!

– Инде килеп Асия...

Анысын да алыйм микән?!

– Әйбәт кенә укый. Матур бит? Матур!

– Әйе, матур.

– Мин ялгышканда да, Мөхәммәт абыең ялгышмас иде барыбер. Ул инде хатын-кызны әллә каян күрә!

Хатыйп абый ялт итеп башын минем якка бора. Әнә шулай ялт иттеме, аның күзенә бала-чаганыкына хас бер мутлык чыга да сүнә, әмма башкалар сизмәслек мизгел эчендә елмаеп җибәргән ирененә сирпелә дә аны тагын да киңрәк җәя. Беләм: ул әле беравык авызын җыя алмый торачак. Минем кулларымны тотар микән? Юк, тотмады. Нишләп соң гел салкын аның куллары? Әллә үземнекеләр ут инде...

Мөгаллим миннән сүз көтә. Фикерләренә пичәт куйган сүз. Әйтмичә торыйм әле. Бераз елмайган хәлдә көтсен.

Хатыйп абый, әлеге сүз чыкмагач, башын тагын бер мәртәбә ялт итеп ала. Инде бу юлы көлми. Елмаймый.

– Ие, – дим мин белдекле бер кыяфәттә, сүземнең һәм шуның белән үземнең дә кадерне арттырып.

Мөгаллимнәр янында студент чакта күп сөйләшергә ярамый. Акыллы күренсеннәр, кинәнеп сөйли алсыннар өчен. Вакытны аларга калдырырга кирәк. Хатыйп абый да хәзер үзен зур хис итсен, кирәкле санасын, вәкарь белән генә янымда утырсын.

– Инде килеп...

Монысы ни дигән сүз тагын... кызлар белән утырганда...

– Инде килеп, егетләрне ал.

Алам! Егетләрне бишкуллап алам! Арасында минем ирем дә бар бит.

– Менә Ркаил. Зур кеше чыгачак аннан.

Чыгачак.

– Ал Ләисне.

Алам, алам!

– Ул минем ирем бит, Хатыйп абый.

– Кит аннан, мин бит сезне йөрисез генә дип торам! Кай арада өйләнешеп тә өлгердегез?

– Мин бит Сезгә әйттем, аннан башка барырга кыен, дип...

– Бергә барырга кушкан идем ләбаса.

– Һаман-һаман безгә ияреп йөрмәс инде... Менә мине калдырсагыз соң...

– Аны бит үз телең белән, кияүгә чыктым, дип әйтергә була.

И-и бу Хатыйп абый... Күрешкән саен, кулны тота. Балдакны да сизмәгәч...

– Монда йөргәнеңә үкенмисеңдер ич...

Нинди үкенү! Әгәр Пермь суларында коенмасам, әгәр шушы киртә өсләрендә утырмасам, әгәр иңгә-иң эшләмәсәм, остазымның йөрәген бу кадәр аңлар идемме? Аның ни дәрәҗәдә эшен, кешеләрне яратканлыгын күрер идемме? Һәм үзен яратыр идем микән?

Ярату-яратмау, соклану, нәфрәтләнү, рәхмәт хисе, үпкә кеше күңелендә алар гел янәшәдә. Тышка бәреп чыгарга рөхсәт кенә бир.

– Ну, бу тавышың, – диде ул миңа бервакыт. – Колакларны яра!

Үпкәләтте бит, шуның белән үпкәләтте! Шунда ук:

– Хатыйп абый, экспедициядә йөргәндә, ай-яй нинди матур синең тавыш, чишмә чылтыравы кебек, дип әйтә идегез әле, – дидем дә салдым. – Менә хәзер генә яратмыйсыз, үземне дә, тавышымны да, әйткән сүзләремне дә.

Әйттем дә, өйгә кайткач, уйга калдым. Яратадыр ул мине, яратадыр... Кеше яраткан кешесен генә үпкәләтә бит. Менә мин дә аңа катырак әйттем түгелме соң?! Ә бәлки әле, Хатыйп абыем да, шул сүзләр өчен борчылып, төн йокламый чыгар...

Бу язмам белән мин дә аның нечкә күңел кылларына кагылган булсам, ул миңа үпкәләмәсен. Мин ихластан, яратып һәм хисләргә бирелеп яздым аны.

Укучыларның башкалары да аның турында истәлекләр калдырсын. Минем киләчәк юбилейлар өчен дип күңел сандыгына бикләгәннәрә бихисап. Аларны ул исән чагында, мин исән чагында, башкалар исән-сау чагында бергәләп укырга язсын иде.

Хатыйп абыйның җан аткан гаиләсенә иминлек, мәңге сүнмәс үзара җылылык телим.

*1999*

# Балалар өчен хикәяләр

## КИБӘН БАШЫ

Кече яктагы сәке өстендә әнинең табадан ипи төшергәнен көтәбез. Ул әле мич белән өстәл арасында тыз да быз булышуында. Мин аның җитезлегенә хәйран калып утырам. Камыр әзерләгәндә суына да чыгып керә, чаен дә куеп җибәрә, мал ризыгын да әзерләп өлгертергә тырыша.

– Табаннан утлар чыга, – ди ул кайвакыт, бөтен идәннәрне дер селкетеп баскан аякларына үзе дә шаклар каткандай.

Әни әледән-әле калын бияләйләрен киеп ала да тыннарны куырырлык эссене бабам суккан кирпечләрдә сакларга булышкан калай капкачны ачып карый. Ярты гәүдәсе белән үк куыш эченә кереп китә дә үзе дә күмәч шикелле кызарып килеп тә чыга. Аннан, саплары шомарып беткән иске табагачны алып, йә теге, йә бу табаны куышның түренәрәк этә, әйләндереп-әйләндереп куя.

Мич капкачын япканнан соң да, кайнарлыкның үзәгендә булып чыккан табагач, салкын су салып куелган ләгәндә бик озак чыжылдап, безгә ипи пешергәннәре турында җырлап утыра әле. Аның янында, салкын кое суында күрше Галияттәләрдән өмәдә, казлары мул булсын өчен, мин чәлеп чыккан канат та плитә алдыннан көл сыпырып каралган башын кыңгыр салып ята.

Сәкенең без утырмаган тигез өслегенә әбиемнән калган киндер соргылтым шакмаклы ашъяулык җәелгән. Тузып килсә дә, әни аны ташламый, иплэп-сиплэп, гомерен озынайтырга тырыша. Мин терәлгән ястык өстендә – әни белән ияреп килгән, аның үсмер кыз чагында тукыган ипи япмасы. Миннән дә олырак булса да, җепләре нык, кызыл җирлекне бүлгән куе зәңгәр буяуларына кадәр җете.

Япма матурын матур, тик ашъяулыкны яратарак төшәм. Аннан әллә нинди затлы сабыннар белән юганда да бетми саклана торган ипи исләре килә. Анда кырларда үскән зәңгәр канәфернең минекедәй очлы борын гына тоярлык нечкә хуш исе саклана. Әбиеңнең әбисе дә ипи төргән җәймә ул, ди әнием. Гомеремдә күреп белмәгән әллә кемнәргә, әмма иң якын кешеләргә – әби-бабамнарга, аларның күпсанлы улларына-киленнәренә хезмәт иткән, җәйге челләләрдә басу түренә ризык илткән, кышкы салкыннарда суынып киткән агач өйләрдә ипекәйгә мич биргән җылыны кочагында саклап сәке түрендә ял иткән, кунакка баручының чәкчәкләр, сумсалар өйгән түгәрәк кунасына чүпрәк сап булган ашъяулык бит ул.

Киң сәкенең арт ягыннан абыйны әйләнеп аның янына күчәм. Әле генә безнең ашказаннарына кереп кунаклаган кабартма исе борыныма тагын да ныклабрак килә. Миңа бу гына җитми, сәке буенча сузылып ук ятам. Абыем минем нигә болай эшләгәнне белә. Колагыма, марҗалар кебек ризык иснәмәкче буласың мәллә, дип пышылдый. Гөнаһ бит ул, янәсе.

Гөнаһ диделәрме, кот ботка төшә минем, әмма барыбер татлы күмәчтән күтәрелгән кайнар һаваны суламыйча түзалмыйм. Монда яткан кабартмадан әллә кайчан җилләр искән! Тик аның хуш исе үзе үк борыннарыбызга юл таба, бөтен өйгә тарала.

Куркып кына әнигә карыйм. Ризыкны иснәргә ярамаганлыгын болай да беләм. Кабартмадан калган татлы һава да ризыкка санала микәнни соң?

Әни эшли дә эшли. Беркемдә, бернидә гаме юк. Күмәчләрне әти кайтканчы өстәлгә китереп утыртасы бар аның. Әбиебез, комачауламас өчен, ишегалды тирәсендә кыштырдап йөри торгандыр. Бу – безнең көчтән килми торган бер хәл. Ничек инде, ипи кадәр ипи пешкәндә, авыз күтәреп тышта йөрисең!

Əнинең, үзе аш бүлмәсендә булышканда, аяк астында буталганны яратмаганлыгын беләбез. Тып-тын гына, берни сөйләшмәскә тырышып, аякларны сәке кырыннан салындырып тик кенә утырабыз. Ул безнең янга якынлашканда, сәке астыннан берәр нәрсә алырга килүедер дип куркынып, тәпиләребезне тиз генә астыбызга җыябыз.

– Əни, – дим, – әни!

Нигә дәшми инде? Кара кашлары борын өстендә җыелган. Борчымасаңчы ди микән? Сүзне эчемә йотам. Әниемә абый хезмәт дәресендә тегеп биргән алъяпкычының баулары бушаганлыгын гына әйтмәкче идем югыйсә. Көлле ләгәнгә төшәр дә китәр әле...

Абыйның күңелендә нииндидер хәйлә пешеп киләме: иреннәре бер җыела, бер тарала. Менә ул башын кыңгыр салачак та, сул күзен кысып, бүлмәнең аргы почмагына карап хыялга чумачак. Шул планының ничек тормышка ашачагыннан алдан ук рәхәтлек кичерә.

Бераздан абый уң кулын җилкәм өстенә сала. Бик яратса да, миңа мәкер эшләми түзмәгәнен беләм лә! Ул корган хәйләләрнең ипи кыерчыгына бәйле икәнлеген дә, гадәти бер хәлгә әйләнгәнгә, алдан ук сиземлим.

Әнинең мич каршында торып кабаланудан, өсте килерме дип эче янудан кызарган бит алмаларыдай түгәрәк кабартма белән сыйлану рәхәте дә калган әле абыйның йөзендә. Болай да шук сипкелләре отыры эреләнеп, шаянланып киткәннәр, ирене белән бергә әле тегендә, әле монда сикеренешәләр.

Камырны соңгы тапкыр басар алдыннан кечкенә генә өлешен бүлеп калдыра да әни йә коймак пешерә, йә кабартма ясый. Бу юлы да шулай эшләде. Күңелегезне тыя торыгыз, мине борчымагыз дигәндәй, кабартма белән аягүрә торып кына сыйлады ул барыбызны да. Аннан әти – бакча буена, әби ишегалдына чыгып китте. Тырышып-тырышып та безне үзләренә ияртә алмадылар. Без, бер дә сөйләшмәскә, тыныч кына утырырга сүз биреп, әнидән ялварып сорап, сәке өстендә утырып калдык.

Бу ел җәй эссе килде, ашлык сыйфатлы, дип сөйләнә әнием, келәткә он иләргә чыккан саен. Камырның ниндилеге чүпрәдән генә тормый шул, онның да ап-агы, һава сулаганы, хуш ислесе кирәк.

Һи, ис дисәң, миңа берсе дә җитми. Он лары кырыннан үткәндә дә чыдаша алмый минем борын. Әни сизмәслек итеп, кинәнә-кинәнә сулый. Кисмәк кырына ябышып калган, без абый белән кыра-кыра җыеп утырган йомшак камыр кисәкләреннән дә тоям мин ул быелгы ашлыктан ясалган он исен!

Менә әни соңгы тапкыр мич авызын ача, беренче табаны табагачка җиңел генә эләктереп тартып чыгара да олы учакны каплаган озын плитә өстенә алып куя. Тагын, тагын шул ук эшләрне кабатлый. Көймә астында кызарып пешкән биш икмәкнең икесе мич каршындагы плитә өстендә кала. Әни алар өстендәге он бөртекләрен каз канатының йомшак каурыйлары белән сыпырып-сыпырып ала. Аннан юешләнгән калын сөлгеләр белән табаны ике куллап кына тота да без утырган сәкенең буш башына – ашъяулык өстенә әйләндерә.

Кызарып пешкән, сусыл камырлы, вак күзәнәкле ипи, авыздан әчеләр китереп, кетердәп торган түбе белән безне үртәгәндәй туңкаеп ята бирә. Бераздан әни, чекерәешкән күзләребездән яшерергә теләгәндәй, аны ашъяулыкның кырыйда калдырылган почмагы белән ябып ук куя.

Өй эче кайнарланганнан-кайнарлана, әни бите пешкәннән-пешә, шул ук вакытта инде анда сак кына җәелә башлаган елмаю ирен читләренә кадәр төшә.

Ул ис! Яңа пешкән ипидә такыр басу юлындагы ак тузаннарның да, юл кырында узган-барганга баш селкеп калган күкчәчәкләрнең дә, хәтта басуда сорамый-нитми тишелгән, ач булса да, татлы солычаларның да хуш исе бар кебек! Көз көннәрендә ындыр табагыннан авыл ягына юл алган җылы җилдән тотып алырлык һәр тәм бардыр шикелле. Безнең авыл өстеннән очып узган болытлар да, су өсләреннән күтәрелгән пар да яратып үзенә сеңдергән истер ул.

Кытыклый гына мине әни уңганнардан уңганы дип сайлаган түгәрәк ипинең өзелеп төшкән башыннан таралган бу. Бөтен бер күмәчне зур тәлинкәгә кискәләп куйганнан соң, су буеннан кайткан әтиебез юынып өстәл кырына кереп утыргач, шуның бер почмагына әбием белән мин дә кысылышкач, бер кырыйга алып куйган кибән башын нәкъ урта турысыннан икегә бүлеп, абый белән минем кулыма тоттырачаклар. Без аны эретелгән майда йөздереп кенә ашарбыз. Без аны ашарга да кызганып бик озак күз ялтыратып утырырбыз. Без аны, без аны... күрше малайлары кызыксын өчен, әни күрмәгәндә, уенга да алып чыгарбыз!

Абый миннән бер яшькә олы, шуңа күрә өлешне алдан аңа бирәләр. Бу юлы да шулай булды. Ул аны кабалана-кабалана ашарга ябышмады. Гадәттәгечә, башта кулыма аныкыннан соң сузылган кыерчыкка күз ташлады: өлешнең үзенекеннән зуррагы китмәгәнме диюедер инде.

Абый ике такталы өстәл башыннан – әби белән минем уртадан – әти белән әби арасындагы урындыкка күченгәннән бирле күңеленә тынгы тапмый башлады. Инде минем турыма кадәр буе җитми аның, тырыша-тырмаша үрелергә әтидән шүрли, шуңа күрә кибән башын тигез кистеләрме дип тикшерә – телемнәрне өсле-аслы куеп карый алмый. Авызы икмәк кимергәндә, күзләре белән минем өлешнең ничек кимүен күзәтә.

Ашыкмыйм. Вак-вак тешләп, кетердәтә-кетердәтә чәйнәгәннән соң гына йотам. Майлап, вареньелап та тормыйм.

Абыйның кибән башы күптән бетте инде. Хәзер кыскычтан зур-зур булып ватылып чыккан шикәр кисәкләрен шатырдатып тешли дә чөмереп торып сөтле чәй эчә, шуның белән ипи телемнәрен бик җиңел генә бер-бер артлы ашказанына шудыра бара. Елмайган, бәхетле бер кыяфәттә чәй эчүендә булса да, эченнән сыза ул. Уң күзенең почмагы белән генә барыбер һаман минем кибән башына караган! Менә берчак абый түзмәде, үзе дә сизмәстән:

– Тиз генә ашап бетермәсәң, барыбер тешләп алам мин аны, – дип ычкындырды.

– Тик кенә утырсаңчы, – диде әни, абыйның ул гамәлен өнәмәячәген белдереп.

Абыем мине үртәүнең хэйләкәррәк юлын сайлады. Аның эш эшләп шомарган табагач кебек аягы өстәл астында буталып йөри-йөри дә минем уң аякка шәпләп кенә берне элэктереп ала. Бу – барыбер шулай эшлим дигәнне аңлатуы. Эндәшмим. Шушындый тәмле ипи ашаганда бүленәсем, авызга җыйган хуш исне югалтасым, хәтта киметәсем килми.

Кибән башы белән генә ипи катысына булган теләкне җиңеп булмас. Калган мәмәй өлешен генә ашыйм да кыерчыкны әтигә сузам:

– Үрелеп кенә шкафка алып куй әле. Мин ипи катыларын бик күп итеп җыям да аннан туйганчы бер ашармын, яме.

Әти минем теләсә кайсы сүзне җөпли:

– Үскәч, ипи фабрикасының директоры итеп куям мин сине, тешең коелып беткәнче ипи катысы кимерерсең, кызым.

Аның дуслары күп, белмәссең, куяр да. Кичә хәлвәдән туймыйча һаман сорап-сорап аптыраткач, абыйга, көлдән генә ясап ашатыйкмы, зур үскәч, хәлвә заводының директоры гына буласыңмы, дип сайлау мөмкинлеге биргән иде, абыйның ризыкка ымсынуын тәмам сүндерә язды.

Ишегалдына уйнарга чыккач, ул теш арасыннан гына чертләтеп бер төкерде. Аннан, зур бер нәтиҗә ясагандай, дуракка саныйлар болар безне, матурым, дип куйды, адым саен мыскыл итәргә генә торалар. Кичә әти абыйга пищекомбинат директоры ясарга вәгъдә биргән иде инде: ә анда барысы да бар! Абый, әти үзе директор булса, хәзер үк рәхәтләнеп ашар идек без аны, ди. Дөресе шулай, әти, олы кешегә килешкәнен белгәнгә, һаман сүз белән алдый.

Алдарсың абый кебек тәмлетамакны! Ул шикәр савытын әти ягынарак эткән дә ипине инде карлыган кайнатмасы белән ашарга керешкән. Сыйса сыяр икән бер кешегә!

Үзем дә икенче бер кечерәк ипине алам да кыры кебек үк тәмле тоелмаган эчен тиз-тиз ашарга тотынам. Минемчә, һәр утырганда дүрт телемлек эч белән туклансаң, биш-алты көннән соң ипи катылары тамак туйганчы ашарлык җыела. Аннан инде ял көне дә җитә. Ипинең яңасы пешәчәк.

Калган кыерчыкларны, өйдәгеләр табын артыннан торып киткәч, әти куйган кибән башы янына урнаштырам. Өстәл яныннан китеп барган абый:

– Син күрмәгәндә барыбер берсен булса да ашыйм мин аның, – дип пышылдый.

Күрмәс! Мин бу кыерчыкларны көненә ун булмаса, биш тапкыр саныйм. Абый ашаганмы дип түгел-түгелен, туярлык җыя алырмынмы дип кайгырам. Ипи катысы очсызын очсыз да, кыш уртасында ун бәясенә алынган алма түгел! Әмма анысы да кызганыч. Абыйдан качып иркенләп ашармын дип саклыйсың да, барыбер аңа кала: йә тешләп куйган булыр, йә, син күрмәгәндә яладым инде мин аны, дип котыртыр. Ничек инде кимсенмичә кешедән калганны ашыйсың. Алдан ашауның да начар ягы бар. Абый үзенекен саклап утырып, синеке бетте инде, ә мин хәзер авызыңнан сулар китереп ашячакмын, дип үртәячәк. Алмасы-кәнфите дә әнә шулай итеп гел абыйга эләгә бит аның. Анысына да түзәм, тик менә ипи катысын – кырның үзен ашаган кебек ашау туганнан бирле тормышка ашырылмаган һәм күңелдән мәңге китмәячәк бер хыял булып җанны газаплый.

...Ялда пешерелгән ипиләр саны кими бара, шкаф почмагындагы кибән башлары, эче алынган телемнәрнең кырлары арта гына. Ниһаять, әни ипи калдыклары өеменең зурайганнан-зураюына түзми, ашыйсыңмы, юкмы, әллә тавык ипиенә генә кушыйкмы, ди.

Өлкәннәргә каршы төшәргә яратмыйм. Иртәгә ипинең барыбер яңасы пешәчәк, тагын җыярга булачак, бер пакет чамасы җыелган ипи катылары белән, бәлки, туярга да буладыр. Шулай дип уйлап, аларның барысын да аш өстәленә күчерә башлыйм. Кибеп каткан кыерчыклар шалт-шолт килеп тагын бер турыда ята. Әнием, абыйсы күрмәгәндә, борчымаганда, тынычлап ашасын дип, үземә генә, суынып өлгермәгән чәйнекләрдән агызып, калган чәй ясый.

Ипиләрнең инде хуш исе беткән диярлек, әмма минем борын аны да сизә! Кипкән кыерчыкларның үзгәрәк, әчкелтем-төчкелтем икенче исе бар. Ул минем борынны элеккечә үк котыртмаса да, барыбер кытыклый. Тәмле вакытны ничек тә озынайтырга тырышып, иң кечкенә катыны алам да шартла%тып тешләмәкче булып авызга кабам – алгы рәттәге башкалар өстенә ярган азаулар яртылаш каерылып чыга, әмма кыерчык, тимер шикелле кап-каты булганга, кителми дә.

Казналарым канап бетә, ул теш белән, бу теш белән кимерәм, авызга килгән селәгәй белән җебетәм, өстәл башына алып бәрәм, мәгънәсе юклыгын аңлыйм.

Әле кайчан гына миңа бар нәрсәдән кадерле, бар нәрсәдән хуш исле булып тоелган ак күмәчнең ашалып бетмәгән кибән башы да киеп ташлаган сандал табаны шикелле өстәл өстендә ауный. Аның

хуш исен дә тоймыйм, кулыма да алып торасым килми. Ташаяктагы чәйгә җебетсәм, ул инде каты ипи булудан туктаячак. Нишләргә? Моңсуланып карап утырам да, ризыкның ни гаебе бар дигәндәй, алай да кибән башына үреләм – анысы ташның да ташы! Тешләп азау тешеңне кубарам дисәң генә инде. Үземнән өзеп җыйган ризыкны ашый алмаудан кычкырып елап җибәрәм, әни катыларның барысын бергә җыеп, мал чиләгенә илтеп сала.

...Атна арты атна уза. Һәр якшәмбенең йокы бүлеп туган иртәсендә тагын сәке өстендә әнинең мичтән ипи алганын көтеп утырабыз. Абый күзләрен кыскан да, йолдызлар күзләгәндәй, мич кебек ап-акка буялган түшәмгә текәгән. Беләм: ул ниндидер татлы мәкер кора, ә мин тагын менә-менә табалардан тәгәрәячәк ипиләр, аларның үз авызымнан өзеп җыйган кибән башлары, җыелган катылары турында хыялланам. Их, бер генә тапкыр булса да туйганчы ашарга иде, дим...

Атна арты атна уза. Һәр шимбә әти-әни белән бергәләп хәйләкәр абыемнан саклаган кибән башларын, әни, башын чайкый-чайкый офтанып, юләрлегем, кысмырлыгым өчен мине дә кызганып, маллар чиләгенә илтеп сала.

...Ел арты еллар үтә. Мин, сигезенче сыйныф кызы, өстәл башында чынга ашмаган теләкләремнән арына алмый елап утырам. Әтием, аркамнан кагып:

– Кызым, Арча педучилищесының бөтен каты ипие синеке булыр, – дип юата. – Абыең Әлмәттән язган хатында, ашханәдә кибән башын беркем дә алмый икән, мин дә балачакның көлке гамәлләреннән туктадым, дигән, ә син алай эшләмәссең, яме!

Ашханә ипиенең юка итеп җаны суырылып киселгән кибән башлары әнинең затлы күмәчләре белән ярыша ала димени! Мин дә иң йомшак, иң калын телемнәрне саныйм. Әле аларны да эч ягыннан башлап ашамыйм, балачагымның татлы теләкләре өлешчә генә булса да чынга ашсын, үз өлешем үземә язсын дигәндәй, иң элек каты тышчасын кимереп куям.

*2006*

## КЕСӘЛ

Мәктәптән кайтуыбызга әбием кура җиләге кебек бап-баллы, кояш батканда күккә җәелә торган нурлар сыман кып-кызыл кесәл пешереп тора. Аны ашаган саен ашыйсы килә. Әле генә тум-тулук торган касәләребез бушап калгач та, озак кына өстәл яныннан китми утырабыз. Абыем ипи йомшагына сеңдергән соңгы тамчыларны кат-кат суыра. Мин исә үзе дә касә төбе кадәр генә учларыма савытны куям да, сыгылмалы бармакларым белән кырыйларын сыпырып, ирен очларына китерәм. Менә инде икебезнең савыт та юган кебек ялтырап кала. Тик барыбер китәргә ашыкмыйбыз. Сыпырган саен кесәл чыгар төсле, һаман өстәл тирәсендә маташабыз. Бераздан әбиебезнең коры гына:

– Җиттеме сезгә, юкмы?! Бабагызны кура бакчасы каравылчысы дип беләсез мәллә?! – дигән тавышы ишетелә.

Без үз эшебезне дәвам итәбез. Инде кайчаннан бирле авызларыбызга берни йокмаганлыктан, иякләребезгә селәгәйләребез үк агып төшкән. Күзләр – дымлы.

Моны күргән әбиебез:

– Ашап туймаганны, ялап туймассыз, – ди дә капылт кына касәләребезне алып, табакка салып куя.

Беркөн безгә кесәл тагын да тәмлерәк, кызылрак тоелды. Озаккарак җитсен дип, мин аны курчакларымны ашата торган калаклардан гына суырдым. Алай да кесәл барыбер бетте. Бетте, әмма тамакларыбызны туйдырмады. Шуңамы, табынның ахыры булыр сыман, без китәргә ашыкмадык. Абыем белән икебез дә, сөйләшеп куйган шикелле, әбиебезгә карап утыра бирдек.

...Безнең тып-тын гына утыруыбызны әбием күрми дә, ишетми дә. Өстәл белән мич арасында кайнашып йөри бирә.

– Матурым, бүген бигрәк баллысы булган, рәхмәт инде әбигә,– дигән була абыем.

– Ы-ы-ы...

– Иртәгә тагын пешерер әле ул, иеме?

– Ы-ы-ы...– дим мин тагы.

– Бүген дә пешерер иде дә, кесәл озакка җитми шул,– абыйның тавышы касәгә салынган кесәл төсле дерелдәп китә.

– Безнең әби бигрәк әйбәт шул инде. Айдарларның әбиләре кесәл дә пешерә белми торгандыр әле! – дим мин, тапкырлыгыма сокланып, абыема өстәл астыннан гына баш бармагымны күрсәтәм.

Ул да сүзне дәвам итәргә була:

– Пешерде ди. Алар бәрәңге боламыгыннан башка нәрсә ашыйлармыни!

Үзенең гомеренә бер генә Айдарларга кереп караганы булсачы...

Мич төсле агарынган әбиебез кыштыр-кыштыр йөрүен дәвам итсә дә, авызыннан бер сүз чыгармый. Ул инде, соңгы өметебезне бетереп, әле генә кесәлдән бушаган касәләребезне юып та куя.

Озакламый әти дә эштән кайта. Без һаман өстәл янында утырабыз.

Әтием дәфтәрләр тутырылган капкорсак портфелен урындыкка куя да минем яныма килә. Әтигә, үтсә, минем сүз үтә инде.

Уемны белгән шикелле:

– Нәрсә, кызым, кесәл ашадыгызмы? – дип сорый ул.

Минем кесәл көтеп юешләнгән авызымнан бер тамчы иренемә төртеп чыга:

– Ашадык та, бүген бигрәк тәмле булган, ахры, бер дә туйдырмады шул.

Инде бу юлы абыем:

– Ы-ы-ы...– дип өсти. – Минем кесәл савытның өске сызыгына бераз җитмәгән дә иде әле...

Әтием миннән:

– Кызым, синең кесәлең касә кырыена җиткән идеме соң? – дип сорый.

– Юк шу-у-л...

Әтием, нигәдер көлемсерәп, әбиемә карый да:

– Әбиләре, ясаганда касә кырыена игътибар белән рәк карарга кирәк. Шуның өчен туйганчы кесәл ашат әле үзләренә. Кибеткә бүген генә яңасы кайткан. Портфелемнән алып, килосы белән яса. Теге олы табакка. Туйганчы ашасыннар.

Менә нигә аның портфеле көндәгедән дә калынрак күренгән икән! Әбиебезгә карата кылган кечкенә генә гөнаһыбыз бераз тырнаса да, кесәл тырнавыннан кимрәк булганга һәм дә юылган касәләрдән дөреслекне ачыклап булмаганын белгәнгә, эчебезгә җылы йөгерә.

Әтием, борылып, абый белән икебезгә күз кыса да түр якка чыгып китә. Аның:

– Карагыз аны, туйганчы ашагыз, җитмәсә, кибеткә барып тагын алып кайтырбыз,– дигәне ишетелә. – Әбиегезгә, әти кушты, диярсез.

Әбием һаман да, дәшми-нитми генә, кып-кызыл кесәлне табагы белән алдыбызга китереп утырта. Без өстәлдәге иң олы кашыкларны алабыз да атлыгып ашарга тотынабыз.

Абыем минем турданрак ашарга тырыша. Сизмәмешкә салынып кына, кашыгын күпме этсәм дә, әйләнеп йөри-йөри дә, тагын минем алдымнан ук кесәлне эләктереп, авызына бушата.

Соңрак юкка гына борчылганымны аңлап алдым. Сыек кесәл, озак та үтми, барыбер, шуышып, минем турыма ук төшеп утыра икән. Абый да юләр түгел, тора-бара бу хакта тәмам онытты. Инде аның кашыгы минекеннән тизрәк йөри башлады. Түзмәдем:

– Кабаланып ашама, чәйнәп йот,– дип, аның очлы терсәгенә китереп төрттем.

– Минем теш юк бит, – ди ул, көлеп.

– Төпләре калган ич әле. Әкрен ашасаң, тәмлерәк тә була ул.

Шундый акыллы сүзләремне абыем колагына да элəргә теләми.

– Әнә сиңа тәмлерәк булсын, миңа болай да бик тәмле. Минем авыз кесәл ашау өчен туган да инде ул,– дип кеткелди.

Мин шунда гына кесәлнең кичә пешергән карт тавык ите булмавына төшенәм.

Без инде сөйләшми генә ашыйбыз. Кесәл менә табакның урта тирәсендә. Ул инде хәзер бик акрынлык белән генә төшә. Калакларга да элекке кебек тум-тулы булып керми. Бер алган кесәлне без ирен очларыбыз белән кат-кат кабып утырабыз. Тәме дә алай ук баллы тоелмый. Табак төбенә сылашкан саен, төсе дә тоныклана бара.

...Без әле һаман ашыйбыз. Кесәл бетми дә бетми. Инде ашыйсы да килми. Тулган эчләребез белән өстәл яныннан кузгалып китеп тә булмый. Табак булып киерелгән күзләремне йокы баса, әмма керфекләрем аларны йома алмый газаплана.

Түр ишеге ачыла да, аннан әти килеп чыга.

– Нәрсә, балалар, әбиегез кесәл ашаттымы? – ди ул, табак янында утырганны күрсә дә.

– Әти, җитте бугай инде,– дим мин, куркып кына.

– Ы-ы-ы... – ди абыем да.

– Шту сез, разе мондый кесәлне калдырырга ярый? Сез ашамасагыз, тавык та ашамый бит аны,– ди ул бик житди итеп. – Туйганчы ашагыз, икенче әбиегезне йөдәтерлек булмасын!

– Без туйдык бугай инде, әти...

– Ы-ы-ы...

– Ай-һай, кып-кызыл. Бик тә тәмле булдымы, улым? – ди әтием һәм, яратып, абыемның аркасыннан кага.

– Юк ла, кичәгесе тәмлерәк иде, без мондыен яратмыйбыз.

Мин дә аның хәйләсен сизеп алам.

– Тегесе аның кура җиләгенеке ие бит, монысы кызыл карлыганныкыдыр әле, шуңа әче ул, – дим дә кулымдагы теге олы кашыкны ялт иттереп өстәлгә куям. Абыем да шуны ук эшли.

– Карале, әбисе, иртәгә үк күрше авылдан теге кесәлне алып кайтып куярга кирәк. Балалар монысын бик үк яратып бетермәгәннәр икән. Калганын иске су чиләгенә түк, иртәгә туйганчы ашатырбыз,– дип, өстәл яныннан кузгала башлаган әтигә без икебез ике яктан асылынабыз.

– Әти, лутчы без монысын ашап бетерик. Иртәгә алып кайтып торма инде. Шуның белән туярбыз,– ди абыем.

– Ы-ы-ы...

– Карагыз аны, штубы туярлык булсын.

Эчебезгә курку салып, әтием мал-туар янына чыгып китә.

Без күралмас хәлгә китергән кесәлне газаплана-газаплана ашап бетерәбез дә, әбиебезгә рәхмәт тә әйтә алмаслык хәлгә килеп, өстәл янындагы караватка түнәбез.

Икенче көнне мәктәптән кайтканда, безне тагын ике стакан кып-кызыл, бап-баллы кесәл көтеп тора, әмма без аны күрмибез, аңа кагылмыйбыз. Юк-бар сәбәп табып, урамга чыгып шылабыз.

*1993*

## ТАҢ ЧЫПЧЫГЫ

– Таң чыпчыгы син, – ди миңа әнием, – ни үзең йокламыйсың, ни килгән кунакларга йокларга ирек бирмисең.

Бер сәер гадәтем бар. Аны үзем сәергә дә санамыйм санавын. Шәһәрдән кунаклар кайттымы, әле кояш торганчы ук, караватлары янына килеп, күпме йокларга була инде, дип тинтерәтәм. Әнинең мал-туар карарга чыгып киткәнен генә көтеп торам да, әпчи карчык шикелле, колак төпләрендә авыл борчуларын сөйләргә тотынам:

– Сез кайтканга күрә, әнинең әллә никадәр эше артты, торып, ерак чишмәдән су алып кайтып куйсагыз булмыймы, бакча түтәлләрен чүп баса башлады, чык арасында эшләве үзе бер рәхәт ул, өстәл әзерләгәнче шунда маташсагыз ярамыймы?

Әни минем шундый икәнне сизенә булса кирәк. Кайвакытта, уфтанып:

– Ике генә тулып килә бит әле үзеңә, биргән дә соң Ходай телне, – дип куя.

– Эш эшләргә ярамагач, сөйләшергә генә булса да ярыйдыр ич инде, – дим мин дә.

Эш эшләү дигәннән, анысы бөтенләй үк тырай тибеп йөрүчеләрдән түгел мин. Аның бөтен хикмәте – әнинең үзе карап тормаганда эш эшләгәнне яратмавында. Миннән башка үзе дә берни эшли алмый ул эшләвен. Әле беркөнне икәүләп ипи, бәлеш кебек нәрсәләр пешердек.

– Кызым, су, кызым, канат, кызым, таба, – дип йөгертепме-йөгертә.

Түзмәдем:

– Әни, әтигә ипине Рифә пешерде, дип әйтерсең, яме, – дип ычкындырдым.

Шулай да иң кызыгы түбән оч җиңгәләремдә идән юу минем өчен.

– Язиләгә идән юарга ярый да, нигә миңа гына ярамый, – дип аптыраткач:

– Аңа дүрт яшь инде, – ди әнием.

Менә без аларда, Фаиз палас астына качып яткан идән такталарына, мич кырыйларына ясап бетергән сурәтләрне бәяли-бәяли, идән юабыз. Ул идән тулы бер тиен акча! Аларның, гадәтләнгән булгач, исләре дә китми. Ә мин, әйбернең кадерен белергә бик өйрәнгән кеше сыман, тиеннәрне бер савытка тутыра барам. Мин беләм: икенче атнага ул тагын да күбрәк җыелачак. Моның серен Фаизләр үзләре дә аңламыйлар. Аш уздырганнан калгандыр дип көләләр. Атна саен аш уздырмыйлар лабаса! Әбиләренә тайган кул-аякны утырттыручылар күп килә, әллә алар сибеп калдыра микән?

Әле өченчекөн, кибет янынан бер тиен акча табып кайткач, әнием дә, ай-һай, булдыргансың, дип, башларын чайкый-чайкый көлгән иде, җиңгиләрдәге акчаны күрсәме?.. Юк ла, ул акчаны безнең идәндә күрсәме, ул миннән идәнне иртә дә, кич тә юдырыр иде. Ә болай... Юдырмый шул, юдырмый.

– Идән чүпрәген корытырлык кулың да юк бит синең, – дигән була. Аннан: – Вак тавыктан вак чебеш инде, – дип өсти.

Әле дә әнә шул чебеш вакыйгасын сөйләмәкче идем. Быел Казаннан әтием укыганда фатирда торган йорт хуҗалары кунакка кайтты безгә. Алар кайтканчы ук, таң тишегеннән кеше уятып йөргәнеңне сизсәк, дип кисәтеп куйдылар үземне.

Менә кояш та чыкты. Утырам шулай баскыч төбендә, моңаеп. Күрше кызларының тәрәз төбен саклаган егетләр дә кайтып китте. Мин дә аптырап иягемне тез өстемә терәгән кулларыма куйдым. Эч поша. Өйалды астыннан чебиләрнең черек-черек ашарга сораганнары ишетелә.

Түзмәдем. Бүлмәгә кердем. Шуның идәненә абыем кул яссылыгы ярык ясаган иде. Шуннан гына тары сибәбез без чебиләргә.

Салкын идәнгә ятып, ярыктан да зуррак ачылган күзләрем белән шул бәләкәчләргә карыйм. Алларында ни су юк, ни ашарларына куймаганнар. Кич буе кунак сыйлап, пешереп-төшереп хәлдән тайган әнием, җитмәсә, үзе дә бүген соңрак торырга уйлаган булса кирәк.

Чебиләр мине тиз күреп алдылар. Күрделәр дә тагын да ныграк черкелдәшергә тотындылар. «Чик-чик»ләре «сип-сип» дигән кебек ишетелә башлады. Якындагы савытта тарысы да беткән, җитмәсә!

Җаен таптым, шигырь сөйләп, күңелләрен күрергә тотындым. Тора-бара ятлаган шигырьләр дә бетте. Күңелемә аларны кызгану хисе тулды. Түзмәдем:

И чебиләр, чебиләр,
Өйдә кунаклар бик күп,
Сезнең ашарыгызга
Бирүчеләр генә юк, –

дип елап та җибәрдем.

Үзем елыйм, үзем ярыктан коелган яшьне чебиләр чүпләп барганга сөенәм.

Шулай тын гына елап ятканда, үземнән артта йомшак кына аяк тавышлары ишетелде. Борылып карасам, кунак абый дигәнебез күлмәк-ыштаннан гына өйгә кереп бара. Төнге эч бушатулары да кояш күтәрелгәч кенә бу шәһәр ялкауларының, дип уйладым мин эчемнән.

Менә барысы да торып беттеләр. Әни кунакларга кайнар коймак чыгарды. Кап-кара итеп чәй ясады. Ни Сафа абый, ни Мәгъмүрә апа авыз ачып бер сүз әйтмәде. Бу табын шулай шау-шусыз, тып-тын гына узды. Өстәл янынннан кузгалганда гына, аларның инде бүген үк төш тирәсендә китәселәре билгеле булды.

Инде төш җиткән иде. Әни ашка салырга дип чистарткан симез тавыкны кыздырып аларның юлларына тыгарга уйлады.

– Теләсәгез, шулай итәрмен, юл озын түгел, дисәгез, болай гына алырсыз, – дип, ул кунакчыллыгын күрсәтергә тотынган гына иде, йөзен кинәт кенә күләгә баскан Сафа абый:

– Кирәкми, без шул тавыклар аркасында китәбез дә инде, – дип куйды.

Аларның, белүемчә, Тукай урамындагы алачыкларында урланган йомыркаларын сылтау итәргә токан сыңар тавыклары бар иде, эти моны шуңа дип аңлады булса кирәк. Дәшмәде. Хәтәр эшләрнең сәбәбе миндә генә булганлыгын белгән әнием, минем берни булмаган төсле кукраеп басып торуымны күргәч, кулындагы тавыгын төшереп үк җибәрде.

Менә кунаклар үзләрен озатырга дип юллаган машина арбасына утырыштылар.

Кунак абый да зерәгә генә тавык фабрикасында эшләп йөри, үзе дә шагыйрь икән. Машина кузгалып китәр алдыннан, ул мине, бармак очларын гына кәкрәйтеп, үзе янына чакырды да бер генә шигырь укыды. Минем аны әниләргә әлегә кадәр әйткәнем, ни йөдәтсәләр дә, әйткәнем юк. Ә менә сезгә әйтәм, әнигә әйтмәсегезне белгәнгә әйтәм:

И чебиләр, чебиләр,
Тары сорап йөриләр.
Инде кунакларыгыз юк,
Сезнең тамагыгыз тук.
*1993*

## КЫЗЫЛ БАШМАКЛАР

Минем күз явын алырдай кып-кызыл башмакларым бар. Әнием, район үзәгенә баргач, сабантуйда гына киярсең, дип, әле яңарак кына алып кайтты аларны. Үземнең дә, бәйрәмгә кадәр киеп, буяуларын әз генә дә кырдыртасым килми. Күп вакыт, такыр юлдагы вак ташларны санап, болынга яланаяк кына сыпыртам.

Яланаяк дигәннән, безнең авыл малайлары берсе дә җәй көне аякка нәрсә дә булса киясе дип башына да китерми.

Кай көннәрне мин, түр тәрәзәбез чәчәкләре артына качып, аларның тезелешеп болынга төшкәннәрен карап торам. Кояш урам башындагы тупыл тирәсенә җиткәндә, өй җиләтергә дип ачык калдырган тәрәзәдән шап та шоп аяк тавышлары ишетелә башлый. Болар – беренче булып суга керергә дәгъва кылучы югары оч малайлары. Барысы да балаклары тез башларына кадәр төшкән кара трусиклардан. Шушы юлдан бер төшеп, бер менеп йөри торгач, такыр башлары да аяклары кебек каралып калган.

Иң алдан инде икенче ел киеп ал яклары ук сидри башлаган трусиктан миннән бер яшькә кечерәк Ибраһим атлый. Кичә ләмле ярдан шуып уйнаган, ахры. Бердәнбер өс киеменең агарып беткән урыннарында кызгылт-көрән таплар бар.

Аның артыннан төшүче Рафиска, өйләрендә аннан башкалар гел кызлар булгангамы, ай саен яңа трусик алып кидерәләр. Яңа булса да, гел «каз боты» ясала торгач, балак очлары чачакланып калган.

Бездә кеше күрмәгәндә кием-салымнарны чишә алмаслык итеп чияләндереп китү ир-егетлек санала. Мондый «бәхет» бөтен дөньясын онытып су коенучыларга көн саен диярлек эләгә.

Рафис артыннан баручы Рәкыйп, биш-алты мәртәбә чаптырдатып атлаганнан соң, уң кулындагы тал чыбыгы белән җирне ярыр сыман кизәнеп ала. Кулларына шөгыль тапмаган малайлар трусик бөрмәләрен тотканнар. Бу аларга булганлык, егетлек кыяфәте кертә.

Бала-чага көне бue казлар шикелле төшә дә төшә. Мин менә бүген алар белән коену кызыграк булгангамы, олырак кызлар күренгәнне көтеп торам. Зур булсалар да, минем кадәр дә йөзә белмиләр үзләре. Яр буенда тезелешеп утырган малайлар, булдыксызлыкларын сизмәсен дип, уртасында да батарлык булмаган турыда гына, озын кулларына таянып, чуптырдашып йөриләр.

Тәрәз каршысыннан аларның да аллы-гөлле күлмәкләре узып китте. Инде капканы ачам гына дигәндә, әбиемнең, һай бу кызыйны, аяк киеме була торып, дип сукранганы ишетелде дә, аның күңелен күрү өчен, кире борылып, баскыч төбенә сөяп куйган кара башмакларымны алып кидем.

Бу башмакларым да өр-яңа. Уймак кебек кенә алдына кызыл тасма тагылган. Чит-читләре дә шул кызыл тасма белән каелган. Шулай булса да, яланаяк йөрү ошыйрак төшә миңа.

Урам башына җыелып торган дус-ишләремне күреп кабаланып киттемме, көтмәгәндә, шул каралы-кызыллы башмакларымны тузанлатып, сыдыртып, яңгырдан соң чокырланыбрак калган җиргә барып төштем. Кире кайтасы да, тузанлы башмаклар белән урам буйлый узасы да килми иде, янәшәдәге бер йортның өйалды баскычы астына яшерелгән кремнары белән тиз генә ялтыратып җибәрдем дә кызлар янына элдерттем. Тәрәзләреннән күреп торган Васфибану апаның минем фыртлыгыма елмайганын күрсәм дә, сизмәмешкә салыштым үзем.

Әле моңарчы «чеби чыгарып» йөргән түбән оч кызлары мине көтеп түгел, сандалиларын кисеп ясаган «танкетка»лары белән мактанышып торалар икән. Ялтыр-йолтыр килгән җыйнак, яңа башмакларым әллә бар аларга, әллә юк.

Берсен-берсе узыша-узыша, безнең урамда моңарчы күрелмәгән төр аяк киемен мактыйлар.

Рәисә:

– Комга барып та керәсең, ул синең табан асларыңны кытыклап, үкчә артыңнан килеп тә чыга, – ди.

Язиләсе:

– Сандал чагында Наиләнеке генә иде, хәзер әнә икебезгә дә ярый, – дигән була. Үзләре, борын җыерып, минем яңа гына кап-кара итеп ялтыратылган башмакларыма караганнар. Янәсе, укытучы кызы нәрсә киеп йөри!

Мин борылдым да өйгә кайтып киттем. Беркемне күрү, сөйләшәсе килү, хәтта су коенасы килү теләге калмаган иде. Әти белән әниеңә бер кыз була торып! Шундый танкетка да ясап бирмәсеннәр әле...

Кирәк түгел сабантуйга дигән кызыл туфлиләре дә! Иртәгә үк тирескә күмеп куям мин аларны! Миңа сандалдан тишеп ясаган танкетка кирәк. Танкетка! Башка берни дә!

Үпкәләгән чакта, баш шәбрәк эшли минем. Туктале, мәйтәм, мунча артына кадакка элеп куйган озын кунычлы бутыйлар бар. Шулардан башта галуш, аннан танкеткалар киссәм?

Кычытканнарга чагыла-чагыла, күршеләр белән ике арага чыктым. Малларга турый торган үтмәс пәке белән озак кына газаплана торгач, беренче галош та ясалды. Икенче бутыйга үреләм генә дигәндә, кычытканнар белән бергә муеннарымнан ниндидер көчле куллар эләктереп алды да ишегалды уртасына алып кереп ташлады.

Ташлавы булды, колак төбендә генә әниемнең:

– Өр-яңа бутыйны харап иткән бит, харап иткән, – дигән үзәк өзгеч тавышы ишетелде.

Әллә ишетеп, әллә болай, өйдән әтием килеп чыкты. Мин әле генә үземне «гаепле эштә» тоткан әниемнең итәк астына ук кереп киттем. Беркемнең дә өстәп берни әйтерлек хәле калмаганын аңлагач, шул итәкнең бер почмагын гына күтәрдем дә:

– Әтием, минем бит сандал-танкеткаларым да юк, үзең яратам дигән буласың тагы, – дип елап та җибәрдем.

Менә ул башын чайкап карап-карап торды да, бер-бер уй килгән кеше төсле, өйгә кереп китте. Мин дә, тынычланып, утын өемнәре өстенә барып утырдым. Әтием ничек керсә, бер кулына – елтыр пычак, икенчесенә кып-кызыл башмаклар тотып, шулай ук тиз килеп тә чыкты. Инде бу нишләргә җыена дип, әнием дә аптырап торганда, ишегалдындагы пүләннәр өстенә куеп, шул кызыл башмакларның ал өлешен кисеп тә төшерде.

Мин көенергә дә, сөенергә дә белмәдем. Инде минем кешенеке шикелле танкеткаларым бар, әмма бер кешедә дә булмаган башмакларым юк иде.

*1993*

## ГАЕТ КОЙМАГЫ

Иртәгә гает. Яхшы кабара, гает коймагына калсын дип, келәт уртасында утырып торган ак он тутырылган кисмәкне әнием түргәрәк этеп куйган иде.

Гает коймагы диделәрме, авыздан сулар килә минем. Сер итеп кенә әйтәм: бу көнне авылда коймак белән бездән дә күбрәк сыйланган кеше юк.

Сөннәткә утыртылган абыем өчен райком абзыйлары әтиемнең теңкәсен корыткannan бирле, гает коймагы пешергәнне кешедән яшерәбез без.

Гает бәйрәме дигәннән, и-и, ул көнне урам тулы бала-чага! Барысының да кулында – майлары агып торган гает коймагы. Без, укытучы балалары, читтән генә кызыгып карап торсак та, сер бирмәскә тырышабыз. «Урамда ашап йөрү – әдәпсезлек» дигән булабыз үзләренә.

Кайберәүләр, безнең акыллылыгыбыздан көнләшеп:

– Мәчтүрәйләр бакчасыннан чирткән алма дип белдең мәллә качып ашарга, – дип кенә җиффәрәләр. Сүземнең дөреслеген ныгыту өчен, Фәхриямалттәйнең өй почмагына кадаклаган зу-у-р тактага төртеп күрсәттем:

– Әнә күрәсезме, нәрсә дип язылган? Урамнарда тәмәкене йөреп тарту катгый рәвештә тыела!

Күрше малае Фәндәс, күлмәк җиңнәремнән тартып, кулымны кире төшерә:

– Минем бәләкәй вакытымда авызга салам кабып йөргәнне күреп, эче катып көлә торган булган ул. Билләһи, дип әйтәм, Фәхриямалттәй үзе язып элгән моны, – ди. – Минем «тәмәке тартуымны» ташлату өчен.

– Алайса, башка урамнарда да нигә шундый ук такта бар? – дигән соравыма да бер дә исе китми генә:

– Мин уйнамаган урам бармыни?! Беткән ди анда да тәмәке пыскытучы ыштансыз малайлар, – дип кенә куя. – Әйтәм җирле, әни, аның кулыннан килмәгән бер эше юк, мунчада эчеп яткан ирен айныта алмый тилмергәч, мунчасы-ние белән тарттырып әниләренә алып барып бирде ул, дигән иде.

Сүзнең озынга китүен сизеп торган малайлар Фәндәсне туктаталар:

– Ай-һай, малай, тарттырып алып менде микән? Вертолет була торып, – диләр. – Илтсә дә, шуның белән илткәндер. Әле узган ел да, кызы безнең Бөрне сагынуына түзалмагач, бер сәгатькә генә вертолет белән су керергә кайткан бит!

– Булса булыр да, – дип куәтлим мин дә. Безнең Фәхриямалттәй таныгыңны да, ракетаңны да йөртә ул!

Бәхәс китсә, гел минем сүз җиңеп чыга бездә. Барысы да, үзләрен дөрескә чыгарганым өчен сөенешеп, бер горурлык тоеп, миңа карап торалар.

Йөртә пычагым! Аның өчен чәчең коела башлаганчы укырга кирәк әле, ди әтием. Менә ул йөртсә дә, йөртер. Бөтен урамга пеләш баш бер безнең әтидә генә. Шуңа күрә белмәгән нәрсәсе юк та аның. Гает көнне, өй яңгыратып, «әкбәр» әйткәнен дә ишетсәләр! Ишетсәләрме... Ишетсәләр, үзе әйтмешли, район юлына җәяүләп асфальт сала инде. Шуңа күрә ул абыйны башка малайлар белән гает көнне олылар артыннан урам да әйләндертми.

Без тәкбир әйтүчеләрне кырыйдан гына күзәтәбез. Гомер буе кыш көне дә башына яулык бәйли белмәгән Сәлиматтәй, ирләргә тән күрсәтмим дигән булып, сыңар күзен койма ярыгына сылый. Авыз тирәсен яулык почмагы белән каплаган Галиматтәй, ябылган кое капкачына басып, сузыла-сузыла урам якка карый. Үзе бертуктаусыз:

– И Ходаем, кырыгынчы адымнары безнең турга туры килсә, койрыксыз кызыл тавыгымның кырык йомыркасын кырык күршемә садака итеп бирермен, – дип кабатлый.

Кырыгынчы адымнары әллә нигә ел саен безнең турга туры килә. Урамны яңгыратып, бабайларга безнең өй эчендәгеләр дә кушыла:

– Алла-а-һак-бәр, Ал-ла-а-һак-бәр, лә илаһе ил-лал-ла!

Иртәгә гает. Мин кемдә нинди коймак пешерәселәрен алдан ук белеп торам. Каян дисезме? Ул көнне укытучыларның коймак пешермәсенә ышанган бөтен халык безнең өйгә коймак ташый.

Иң элек Галиматтәй керә. Персидәтелдән качып-посып итек түшәгәнгә, сәгать өчтән торырга күнеккән ул. Кайсы елларда инде таң атканчы ук капканы дөбердәтергә тотына. Торыйк, булмаса, ди эти, барыбер тынгы бирмәс, йә, теге елгы кебек, арт яктан лапас тәрәзәсен алып керер.

Сәгать бишләр тирәсендә Сәлиматтәй керә. Өстәлдәге үзебез пешергән коймакларны күреп, бераз тукталгандай була.

– Күршеләрнеке ул, күршеләрнеке, – ди әни.

Шуннан соң Сәлиматтәй дә бер эрелек белән өстәл өстенә өченче тәлинкәне китереп куя:

– Сабый хакы инде, күршем, гаепләмәссең.

Сорур апаның коймагы үзе кебек вак. Алар быел да шактый гына колхоз ашлыгын чәлдерә алдылар. Коймаклары йорт онынннан булыр микән, әллә төнлә бер шешә аракы өчен урыслар калдырып киткәннәреннәнме?

Кәримә апаң агач сайлый белми, ди әнием. Ул пешергән коймак битендәге сипкелләре шикелле кара төрткеләр белән чуарланган. Белә. Бик белә... Затоннан урланган агачларын урнаштырасылары бар. Мондый сүзне кычкырып сөйләшергә ярамый. Шуңа күрә җавап биреп тормыйм.

Иртәгә гает бәйрәме. Әле узган елгы гаетне әйтәм. Әбием, мәктәпкә киткәндә, кызым, озын тәнәфестә бүген өйгә генә кайтырсың, бер-ике печеньедан башка әйбер тыгып тормадым, дигән иде.

Мин дә хитри. Бер-бер сере бар моның, мәйтәм. Мәктәптә әллә гает көнне чәй эчерү булмый микән? Чәй кайнатучы апай абыстай булып йөри түгелме?

Калырга, тәнәфестә өйгә кайтмаска дип, бик нык беркетеп куйдым үземә.

Менә кыңгырау да, ашау вакыты җиткәнне хәбәр итеп, озын-озак шылтырады. Без әле урыннан кузгалмадык. Апаның кушканын көтеп, эчтә улаган бүреләрне басарга тырышып, тын гына утырабыз.

Апабыз – бик тә тәртип ярата торган кеше. Бер рәт белән генә тезелеп чәй алып керәбез. Боерык белән генә өстәлгә куябыз.

– Бер, ике, өч! – ди ул, хезмәт дәресендә теккән ашъяулыкларны өстәлгә җәеп.

– Бер, ике, өч!

Карыйм: як-ягымда барысы да әле парлары да чыгып бетмәгән коймакларын яхшылап төрелгән капчыклардан ашъяулык өсләренә бушаталар.

Шундый ук коймак апа алдында да. Өстәл өстендә озак торып искергән печенье кисәге тамагыма килеп тыгыла. Күземнән яшь чыга. Укытучы апа моны үзенчә аңлый булса кирәк.

– Бәтәч! Гает коймагыңны оныттыңмыни? – ди ул. Һәм белен кадәр бер коймагын минем кулларыма тоттыра.

Минем мондый тәмле коймакны үз гомеремдә ашаганым юк! Үзе тәмле, үзе зур! Ашап бетергәнемне әле дәрес башлангач та көттеләр. Мин аны беләгемә салып үлчәп тә караган булдым.

Дәресләр бетә. Без өйләргә йөгерәбез. Керә-керешкә:

– Әби, мин беләк буе коймак ашадым!– дип кычкырам.

Майлы җиңнәремне күргән әбием көлми дә, тиргәми дә. Әллә нинди бер сөенеч белән:

– Иманлы укытучы икән, – дип куя.

Укытучы апа өйгә эш итеп биргән «Яз» исемле иншаның беренче юлларын мин «Безне иманлы апа укыта» дип башлыйм. Мин аны әлегә үземчә «коймаклы укытучы» дип аңлыйм.

*1993*

**ЭЧТӘЛЕК**

Күңеле байдан хис йогар. *Илһам Гомәрев* ...............

**Кыйссалар**

Сөннәтче әби ..................................
Исемгә исем киткән ..............................
Әйләнгеч юллар ................................

**Хикәяләр**

Чалбар ......................................
Нәсиб-Нәсибә .................................
Таныш тавыш .................................
Тик сине алып кына .............................
Депутат иптәш .................................
Кәфенлек инәсе ................................
Кыз куенында нәрсә бар? ...........................
Бер төш тарихы ................................
Әтисез алма ...................................
Атның хәлен тай белер ............................
Рәсем ......................................
Таң җиле ....................................
Ямаулык ....................................
Шәһәрский тормыш .............................
Өзелгән сәдәф ..................................
Сары тавык дәвасы ..............................
Акбүрек .....................................
Сөт өсте .....................................
Сәламсез күперләр ..............................
Кешенеке – кештәктә .............................
«Задний ход» ..................................
Нигез туфрагы .................................
Аяк киемең тар булса... ...........................
Язык – казык башында... ..........................
Сорап алган картам ..............................
Бәхет шарты ..................................
Басу яктан җил бәрә .............................
Танык өчен Ходай бар ............................
Каргышлы гөл .................................
Мәхәббәт – мәңгелек! .............................
Сиреньнәр кулъяулык болгыйлар .....................
Зәңгәр алма димәскә .............................
Әбиегез .....................................
Язгы ташу ....................................
Күңел күгендә йолдызлар ..........................

**Балалар өчен хикәяләр**

Кибән башы ..................................
Кесәл ......................................
Таң чыпчыгы ............................... ..
Кызыл башмаклар ..............................
Гает коймагы ..................................

Литературно-художественное издание

**Харрасова** Рифа Фатхрахмановна

**НЕ ДУМАЙ, ЧТО ЗАБУДУ...**

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Харрасова** Рифә Фатхрахман кызы

**ОНЫТЫРМЫН, ДИМӘ...**

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2010.
Форматы 84x108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 12,6.
Тиражы 2000 д. Заказ О-1916.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.